ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

8.2008



# ТАТАРСТАН—РЕСПУБЛИКАМ МИНЕМ













**Казан утлары**
**Qazan utları**

2008

**8**
**(1030)**

*ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:*
***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***Редакциянең хезмәт коллективы***

*НАШИРЕ:*
***«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте***

татмедиа

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

*420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
*Баш мөхәррир—292-38-60.*
*Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—541-38-77.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.*
*Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.*
*Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.*
**Факс**—*(843) 541-38-77.*
**E-mail:** *kazanutlari@telebit.ru.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Роберт МИҢНУЛЛИН. Сандугачлар туа гына... *Шигырьләр*. 5
Айдар ХӘЛИМ. Хунвейбин. *Роман—эпопея*. 10
Илсөяр ИКСАНОВА. Кичер, хәят... *Шигырьләр*. 41
Зәки ЗӘЙНУЛЛИН. Кави Нәҗми дигән язучы... *Роман*. 46
Рөстәм МИНГАЛИМ. Янмый калган шигырь эзләп... *Шигырьләр*. 85
Луиза ЯНСУАР. Җәйрәп ята гомер—алдыбызда... *Шигырьләр*. 108

ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Ләбиб ЛЕРОН. Кичерәлсәң, кичер... *Ике пәрдәле мелодрама*. 88

ПУБЛИЦИСТИКА

Фәүзия БӘЙРӘМОВА. Себер иленә сәяхәт. 114

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Марат КӘБИРОВ. Ул да берәү генә... 132

ФӘН

Марсель БАКИРОВ. "Идегәй» дастанына яңа караш. 138
Фәнис ФӘТХИ. Замана мәгърифәтчесе иде. 154
"Татар энциклопедиясе" битләреннән. 151

СӘНГАТЬ

Габделбәр РИЗВАНОВ. Күңеленә сандугач оялаган. 156

ХӘТЕР

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Хатларда да безнең язмыш. 159
Әхмәт РӘШИТ. Һәркемнең... үз сукмагы. *Хатирәләр*. 177

Бер сорауга—бер җавап. 185
"Казан утлары" архивыннан. 186
Котлыйбыз! 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. 189

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": роман-эпопея А. ХАЛИМА "Хунвейбин" (продолжение); роман З. ЗАЙНУЛЛИНА "Писатель Кави Наджми" (окончание); стихи Р. МИННУЛЛИНА, И. ИКСАНОВОЙ, Р. МИНГАЛИМА, Л. ЯНСУАР.
"Драматургия": мелодрама Л. ЛЕРОНА "Прости, если сможешь".
"Публицистика": Ф. БАЙРАМОВА. "Путешествие в Сибирь".
"К 60-летию Р. Миннуллина": статья М. КАБИРОВА о творчестве поэта.
"Наука": М. БАКИРОВ. "Новый взгляд на поэму "Идегей"; статья Ф. ФАТХИ посвящена 75—летию Р. Утябай-Карими.
Страницы из "Татарской энциклопедии".
"Искусство": статья Г. РИЗВАНОВА о народном артисте Татарстана М. Сунгатуллине.
"Память": Р. ФАЙЗУЛЛИН. "И в письмах—наша жизнь"; воспоминания А. РАШИТА "У каждого своя судьба".
Журнал поздравляет М. ЗАКИЕВА с 80-летием.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: В Казани—День республики; писатель Марат Кабиров.

## IN THIS ISSUE:

"Prose and poetry": novel-epopee A. HALIM "Hunveybin" (continuation); novel by Z. ZAYNULLIN "Writer Kavi Nadjmi" (termination);
verses by R. MINNULLIN, I. IKSANOVA, R. MINGALIM, L. YANSUAR.
"Dramatic art": melodrama by L. LERON "Forgive me, if you can".
"Publicism": F. BAYRAMOVA. "Travel to Siberia ".
"To 60th anniversary of R.Minnullin": article by M. KABIROV about creativity of poet.
"Science": M. BAKIROV. "New sight at poem "Idegey"; article by F. FATHI devoted to 75th anniversary of R.Utyabay-Karimi.
Pages from "Tatar encyclopedia".
"Art": article by G. RIZVANOV about national actor of Tatarstan M. Sungatullin.
"Memory": R. FAYZULLIN. "In letters is our life"; memoirs of A. RASHIT "Everyone has his destiny".
Magazine congratulates M. ZAKIEV with 80th anniversary.
From photoarchive of magazine.
Diary of a social-cultural life.
On our covers: In Kazan- Republic day; writer Marat KABIROV.

*The magazine edits monthly*

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 22.07.2008 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Т-905 Тираж 4732.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2008 ел.



Роберт
Миңнуллин

# САНДУГАЧЛАР ТУА ГЫНА...

## Хөррият

*1996 елның 30 августында*
*Казан өстенә «Хөррият»*
*һәйкәле күтәрелде*

**Без булырга тиеш азат халык,**
**Без булырга тиеш хөр милләт!**
**Тик хөр милләт булып яшәр өчен**
**Кирәк безгә ирек, хөррият!**

**Йөрәкләрдә—дүрт гасырлык максат,**
**Күкрәкләрдә безнең бер ният!**
**Халкым сине гомер буе көтте—**
**Өметләрне акла, хөррият!**

**Без хөрлеккә әле өйрәнмәгән,**
**Хөр яшәргә безне дә өйрәт!**
**Сине безгә бүләк итмәделәр,**
**Яулап алдык сине, хөррият!**

**Тибәме соң безнең күкрәкләрдә**
**Хөрриятккә лаек хөр йөрәк?—**
**Сине әле якларга да кирәк,**
**Сакларга да кирәк, хөррият!**

**Хөрриятне яулап алган икән,**
**Татар җаны әле хөр, димәк!**
**Татарстан, Казан өсләренә**
**Канатларыңны җәй, хөррият!**

**Оч син, талпын, и азатлык кошы,**
**Үз артыңнан безне дә иярт!**
**Тик Ватанның биек күкләреннән**
**Очып китә күрмә, хөррият!**

Роберт МИНҢУЛЛИН (1948) — *Татарстанның халык шагыйре, публицист, җәмәгать эшлеклесе; татар, рус, башкорт телләрендә басылган күпсанлы китаплар (шул исәптән быел дөнья күргән җиде томлык "Әсәрләр") авторы. Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Вакыт

Вакыт төшенчәсе
Хәзер инде бүтән.
Һич өлгереп булмый,
Хәлдән таеп бетәм.

Тыгызлана Вакыт,
Тора-бара нишләр?
Бер елга да җитми
Бер гасырлык эшләр.

Гасыр белән сәгать
Тәңгәлләшер беркөн—
Эшләр шуңа бара,
Туктаталмас беркем.

Кысылмасмы соң ул
Шартлар дәрәҗәгә?!
...Чиртеп узды Вакыт
Минем тәрәзәгә.

## Нигезләр

Газизләрдән газиз туфрак,
Изгеләрдән изге нигез!
Туган җирнең газизләре
Нигезләрдән бизде, дибез.

Кемдер бизгән, кемдер түзгән,
Кемнәрнедер биздергәннәр,
Өметләрен өздергәннәр—
Күпме шундый без белгәннәр.

Бәргәләнә, өзгәләнә
Бәгырьләре киткәннәрнең,—
Күз яшьләрен түккәннәрнең,
Чит җирне үз иткәннәрнең...

Юатырга үзебезне
Тәкрарлыйбыз бер үк тәгъбир:
Кешеләрне йөртә язмыш,
Бәндәләрне йөртә тәкъдир.

Ничек кайтсын чит туфракка
Кендекләрен беркеткәннәр.
Көтмә, нигез! Кайтмый икән,
Кайтмый икән бер киткәннәр.

И илдәшләр, нигездәшләр,
Кайталмыйбыз ни сез, ни без.
Көтә, беләм, туфрак белән
Тигезләнгән азмы нигез?!

И сез!..
И без!..

## Авылым төннәре

Якты иде авылымның төне,
Татлы иде төн мин киткәндә.
Моңлы иде—сөю жилкеткәндә,
Дәртле иде—давыл көткәндә.

Нигә тынган әле авыл төне?
Тынган әле нигә тальяннар?
Тал-тирәкләр нигә тол тирәкләр?
Талгын гына уйга талганнар...

Йолдыз яктысында ярлар кая?
Парлар кая тирәк төбендә?
Иң оялчан, матур сүзләр хәзер
Ник әйтелми авыл төнендә?..

Төн түгел, мин үзгәргәнмендер лә,
Миндә инде бүтән күңелдер.
Минем өчен генә җырсыздыр төн,
Ә яшьләргә җырсыз түгелдер...

Башкаларның яшьлеге шул бу төн,
Яшьлеккә төн әле дә бик тәмле...
Ә тальяннар көтәләрдер, ахры,
Минем тизрәк йоклап киткәнне.

## Халәт

Яна, яна
Җанда яра.
Яра—яна.
Яра—яңа...

Җанда—яра.
Җан да—яра.
Ян ла, җаным!
Ян ла, яра!..

Җанда—яра.
Җан—яңара.
Ул көнгә мең
Яралана!

Яралы җан...
Җанлы яра...
Җаның булса,
Янмый кара!

## Тайлар

Тыпырдаша
Кайнар
Тайлар,
Тик тузан
Тузып кала,
Тик күзләр
Кызып кала...
Тайлар оча!
Булдыралсаң,
Узышып,
Узып кара!

Күккә ыргый берсе әнә—
Кояшны тешләмәкче!
Ялан гына җитми, ахры, –
Биектә кешнәмәкче!
Әллә ничә ат көчледер
Яшь тайлар ярсынганда,
Иге-чиге күренмәгән
Киңлекне тарсынганда...

Тайлар оча!
Алар да бер
Җиз йөгәннәр
Киярләр.
Яшь тайларны
Иң беренче
Яшь егетләр

Иярләр.
Ә аннары
Очар әле
Алар әллә кайларга.

...Карт ат кына
Гаҗәпләнеп
Карап тора тайларга.

## Туган илдә кем пәйгамбәр?..

Туган илдә кем пәйгамбәр,
Туган җирдә кем бөек?..
Көләчәкләр генә синнән,
Йөрсәң: «Мин бөек!»—диеп.

Анда бар да авылдашлар,
Анда бар да бертигез:
Барыбызга бер үк тарих,
Барыбызга бер нигез.

Барыбызга бер үк бишек,
Барыбызга бер зират.
Киләчәктә берәм-берәм
Кичәсе бар бер сират...

Мин дә шул ук авылныкы,
Мин дә шул ук ырудан.
Моңнарым да—әбиләрем
Җырлаган җыр-җырудан.

Иген икмим, мин җыр язам—
Шунда гына аермам...
Хөрмәт юк дип үпкәләмәм,
Көтмиләр дип кайгырмам.

Рәхмәтле мин нигеземә—
Җырларымны мул иткән.
Туган җиремнең бер улы
Булсам, миңа шул җиткән.

## Ырынбур далалары

Ырынбур далалары...
Кайларда сез, татарымның
Таралган балалары?

Ырынбур далалары...
Бу татар балаларының
И ерак аралары.

Ырынбур далалары...
Атлар чапкан... Чыдамаган
Атларның дагалары.

Ырынбур далалары...
Әле һаман әрнеп ята
Тарихның яралары.

Ырынбур далалары...
Өстәлеп тора яңадан
Яраның яңалары.

Ырынбур далалары...
Ул төзәлмәс яраларның
Кайларда дәвалары?

Ырынбур далалары...
Ник дәшми татар даласы,
Кайда ил агалары?!

Ырынбур далалары...
Сабырлыклар бирсен сезгә,
И дала аналары!

Ырынбур далалары...

## Сөн буенда кояш байый

Сөн буенда кояш байый,
Байый күзгә күренеп.
Нурларына рәхәтләнеп
Куеп була кер элеп.

Кызыл шәфәкъ. Кызыл болыт.
Кызылдан кызыл кояш.
Бигрәк ямансу—кояшның
Тиздән батасын тойгач.

Сөн буенда кояш байый...
Сүрәнләнә, сүрелә.
Ничек кенә төшенергә
Бу кояшның серенә?

Төшеп бара кызыл кояш
Нәкъ Актаныш янына.
Анда—якты...
Безнең авыл
Инде төнне ябына.

**Сөн буенда кояш байый**
**Моңсу гына, соң гына.**
**Кояш түгел, гомерләрем**
**Байый сыман тын гына.**

## Кылганнар

**Әй, кылганнар, кылганнар.**
**Әнкәемнең чәчләренә**
**Көмеш булып кунганнар...**

**Тавышсыз-тынсыз гына**
**Җилфер-җилфер җилфердиләр,**
**Җырсыз да моңсыз гына...**

**Дулкынлана кылганнар.**
**Кылганнар ниләр кылганнар,**
**Кылганнар ник тынганнар?..**

**Көйләр көйлидер алар.**
**Без белмәгән, без теләгән**
**Серләр сөйлидер алар...**

**Узып барышларыдыр.**
**Болар—Болгар кылганнары,**
**Болгар сагышларыдыр...**

**Чынлап, алардыр, алар.**
**Болгардан Татар Иленә**
**Ашыгалардыр алар...**

**Җилфердиләр җилсез дә.**
**Кылганнарның җыр-моңнарын**
**Ничек җиткерим сезгә?..**

## Сандугачлар язын туа

**Әллә күңел сандугачлар**
**Сайравыннан тулды микән?**
**Моңландыра. Сандугачлар**
**Әллә бүген туды микән?**

**Сандугачлар туган көнне**
**Мине никтер моңнар баса.**
**Нәрсә булыр иде, әгәр**
**Сандугач та моңланмаса?!**

**Ярый әле сандугач бар!**
**Юк аларның тынганы да.**
**Сандугачлар язын туа,**
**Язын туа моңнары да.**

**Кайчан үлә? Ничек инде?!**
**Колак сал җыр куагына!—**
**Сандугачлар үләмени?!**
**Сандугачлар туа гына!**

**Редакциядән:** ***Бу айда журналыбызның күптәнге авторы, Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллинга 60 яшь тула. Күпсанлы укучыларыбыз исеменнән аны ихлас котлыйбыз, сәламәтлек, яңа иҗат уңышлары телибез.***

Айдар
Хәлим

# ХУНВЕЙБИН

РОМАН-ЭПОПЕЯ

## ИКЕНЧЕ КИСӘК

### Бер кандилдә мең шәмдәл

I

Ишеккә чак сыеп, бүлмәгә алыптай таза гәүдәле, калын кыйгач кашлы, җәенке йөзле, агара башлаган бөдрә чәчләре өстеннән бераз унгарак янтайтып, кара кәләпүшен дә чәпәп алган Лотфрахман килеп керде. Көн җылы булуга карамастан, гадәтенчә, җәйге чилләдә дә өшегән кеше кебек, өстенә һаман да шул кара төстәге калын йон кәчтүнен кигән. Еллар буе иләнеп, майланган-ялтыраган, шуның белән беркайчан да юуу-үтүк күрмәгән кәчтүненнән, җитмәсә, дүрт сәдәфен дә элэктергән. Бавыры начар эшлиме—йөзе көлсу-сары.

—Гафу-мәгъфирәтләре, Иркен ага! Без нарсудта көтәбез, ә сез монда дөньягызны онытып ятасыз түгелме?

—Көтәсез?!—диде аптырап әле һаман да истәлекләреннән айный алмаган Иркен-ага.—Ни-нәрсәнә?

—Бәй, судка! Иҗтимагый үзәк халкы көтте-көтте дә, таралды...

Иркен-аганың зиһеннәре таралып китте. Моннан йөз, иң кимендә егерме алты ел элек булган вакыйгаларга батып, ул үзенең эше каралачак мәхкәмә турында да онытып җибәргән ләбаса!...

—Кичерә күрсәләр иде... Ни үкенеч... Лотфрахман кардәшем, инде нишләргә соң?

—Яңа хөкемне көтәргә кала, Иркен ага. Көне билгеләнгәч, сезгә, шәт, чакыру җибәрерләр. Ә сез безгә хәбәр итәрсез.

Лотфрахман шулай ашыкмыйча, җиренә җиткереп, тәкәллеф белән сөйли. Ул, әйтүенчә, Норлат мишәре икән. Ләкин бу мишәрлек аның телендә бөтенләй дә чагылмый диярлек. Әдәбият мөгаллимнәренә биргесез белемгә ия бу инсан, җөмләсен саф татарча, гел тулы итеп, тәмләп, иясен-хәбәрен, иярченен-теркәгечен урынына куеп, үзе тапкан атамаларын да кушып сөйли. Мәсәлән, Иркен ага аның "гафу-мәгъфирәтләре"нә Казанда танышканда ук игътибар иткән иде. "Мәгъфирәт" гарәпчәдән "ярлыкау, кичерү, гафу итүне сорау" дигән сүз. Лотфрахман кардәш "гафу" дип әйтәсе урында аны бер юлы "гафу-мәгъфирәт" дип сырлый. Аны тыңлап тору үзе бер юаныч. Әйтик, ул синең "Бүген көн нindirәк?" дигән соравыңа гади

---

*Дәвамы. Башы журналыбызның 5 санында.*

генә “Суык”, йә “Жылы” дип кенә түгел, ә артына ут капса да, “Көн бүген өйләгә кадәр сигез градуска кадәр жылы, өйләдән соң ике градуска кадәр салкынча һәм аязлы-болытлы булачак,”—дип ноктаи назарына житкереп жавап бирәчәк.

—Сезгә бер сөенеч хәбәр итәргә тиешмен.

—Нинди?—диде сагаеп Иркен ага.

—Мәдинә ханымнан бүген интернет буенча электрон-почта килде.

—Сөбханалла!..—Ул, яшьләрчә сикереп торып, Лотфрахманны кочаклап алды.—Әйтмәй дә торасыз, кардәш!..—Үзе дә сизмәстән, “син”гә күчте.—Монда бирең!..

Ул, ак кәгазьне Лотфрахман кулыннан тартып диярлек алып, укый башлады. Электрон хатның имлясы латин, теле татарныкы иде.

“Saumı sez minem səyekle xələl cefetem Irken xəzrətlərə!—дип язылган иде анда.—Telefonnan səyləgəndə zihenem tarqalıp kitəder, süzlərem onıtıladır. Seznen өçen qayğıram. Balalar da вik qayğıralar. Qayçan qaytasız? Gəlmərfuğa da, Çıngız da sine bügen barıp alırğa rizalar. Qartayğan kənegezdə də tatar dip, millət dip yabışıp yatarğa kirekməs ide. Sezne minnən başqa kem anlıy?

Bıltır sez qıynalğannan sunra sezne alırğa dip balalar barğaç, sezgə Ştatlarğa qaytası bulğan.

Seznen üzegeznen xəlləregez xəlme? Məxkəmə buldımı? Ni nərsə qabul qıldılar? Yort өçen borçılmağız, barısı da tərtiptə. Xezmətçelərebez Tommi ilə Barbara mallarımıznı yaxşı qarıylar. Umartalar barısı da sawlar. Bal bıyıl mul bulmaq. “Wiskonsinhoney” firması ilə kontrakt təzedek. Aqbaş atlı ber sıyır malıbız gına zıyanlap quydı.

Sez Rəsəydə, Qazanda bulğanda Gəlfanıy qızıbıznı cirləü өçen ziratta urın da xəstərləp qaytırğa tırışığız. Tuqay ziratında. Xoday nasip itsə, Qarlığaç sırtınnan qazıp alıp, bez anı Qazanğa küçerep cirlər idekemez.

Sezne uylap tənnərem yoqısız ütəder. Ni nərsədən beznen yazmış gel genə qıynaludan torğandır inde. Min sonğı waqıtta tormışıbıznın məğnəse turında uylanamdır... Sez də uylanasızmı?

Uyğurstandin qotsız xəbərlər kiləder. Amerika matbuğatı yazuına qarağanda, Qıtay xakimiəte otuz uyğır qaharmanının başın kiskənnər.

Üzemnen saulığım tüzərlekter. Gimalayda eləktergən astmanı sanamağanda.

Sezne bik sağındım. Sağınğanda cırlar cırlıym.

Citte kitər kənnərem,
Kemnər kiər külməgem?
Külməgemne kem də kiər?
Kemnər yarımnı səyər?
Sinen beləzegen ike par,
Berse inle bulsa, berse tar.
Matur yeget bulsan, səy ike yar,
Berse sırxau bulsa, berse bar...”

Бу күптән таныш, иң кадерле кешең авызыннан чыккан иске жырулардан Иркен аганың бугазына төер тыгылды. Хатны янадан, бер ялгызы тынычлап укырмын, дип күкрәк кесәсенә тыкты. Гомер буе яратышып яшәп, алар беркайчан да көнләшү дигән түбәнлеккә төшмәделәр. Бу жырулар аша Мәдинәсенең ана булган мәхәббәтенең мәңгелек икәнлеген халыкның үлемсез ижаты аша исенә төшерәсе, чит-ят илләрдән туган илендәге хәләле белән туган телендә сөйләшәсе генә килгән, әлбәттә...

Аның бу тынчу бүлмәдән чыгасы килде.

—Әгәр каршы булмасагыз, хакимияткә сугылып чыгар идек. Мин бит, Иркен-ага, ни дисәгез дә, хакимияттә милли телләрне үстерү Фондының

башкаручы директоры вазыйфаларын үтим! Сезнең судта катнашам диеп йөреп, төштән соң, хезмәтемдә күренгәнем дә юк. Шунда борынны күрсәтеп алыйк та, теләсәгез, болгарчылар симпозиумына, кичкырын халык җыенына барырбыз...

Иркен агага тәкъдим ошады. Кара син аларны, Чаллы болгарчылары фәнни симпозиумнар үткәрер дәрәҗәдә хәлле болады!..

—Телләрне үстерү Фонды, дисез... Телләрне үстереп буламени?—дип сорап куйды ул үзенә хас шаянлык белән.—Шалкан да үсә, тел дә үсә, әйеме!.. Ничә литр, ничә метр?..

Алар рәхәтләнеп көлделәр.

Һәр нәрсәгә җитди, фәлсәфи мәгънә бирергә яраткан Лотфрахман чыгарга юнәлгән җирдән туктады һәм, форсаттан файдаланып, тулы бер лекцион укып алды:

—Әйе, үсә! Үстерәбез! Татарстанның дәүләт мөстәкыйльлеге декларациясе нигезендә безнең Чаллы, җөмһүриятебездә беренче булып, телләрне үстерү буенча киңәйтелгән программа кабул итте. Бездә бүген егерме алты милли җәмгыятьнең утыз алты милли теле гөрләп чәчәк ата. Башта җәмгыятьләрне аерым-аерым очраштырып, чәй-мәйләр эчертеп, таныштырабыз. Аннан милли киемнәр тектереп биетәбез! Аннан барлык милли җәмгыятьләрне җыеп биетәбез дә, хисап чәе эчертәбез. Иң шәп биегәннәре, чукынган, грузиннар! Анда безнең шундый бер Абрамашвилиебез бар, кызып алса, татарча да бии, Иркен ага, ышанасызмы? Безгә караганда ныграк татар!.. Сталин оныгы татарча бии, халыклар дуслыгы тарихында күрелгән хәлме бу?

—Ә нигә егерме алты җәмгыятькә... утыз тел?—диде аптыраган Иркен ага.—Таулы һәм болын марилары телләре бөтенләй аерыламы?

—Аерыла, гафу-мәгъфирәтләре, ничек кенә аерыла әле! Мордва дигән милләт юк. Мокшень бар, эрьзян бар. Бер-берсеннән аерылагынамы? Бер-берсен аңламыйлар, әфәндем!.. Тау башкорты белән дала башкорты, татар белән болгар аерыламы? Ничек кенә!.. Чеченнәр белән ингушлар? Тыштан гына бер халык. Нигә без аларны кушарга тиеш? Безгә күбрәк аерырга кирәк. Безгә на кой чорт бергә булырга? Бергәлек—демократиянең дошманы, әгәр телисез икән—бергәлеккә чакыру—ул тоталитаризмга чакыру! Без һаман да большевиклар бергәлегеннән котыла алмыйбыз. Шулай бит? Безнең татар да бердәм түгел, төрле булсын. Бергә түгел, күп булсын. Болгарлар, мишәрләр, типтәрләр, керәшеннәр, нугайбәкләр!.. Менә бездә башкортча сөйләшкән этник башкортлар юк. Без аларны татарча сөйләшкән башкортлардан ясарга тиешбез. Булсыннар!.. Балалар бакчасы ачтык, әлегә балалары юк. Булыр. Мәктәп ачтык, укырга балалары гына юк. Булыр. Йөз милләт—йөз илле тел! Никадәр байлык!...

Лотфрахман белән былтыр Бөтендөнья татарларының Икенче Конгрессында, дөресрәге, кунакханәдә танышкан иде. Конгресстан соң, Иркен ага Чаллыга килеп урнашкач, табыштылар да, якынаеп та киттеләр. Ул аңа бик тә рәхмәтле. Көтелмәгән фаҗигагә тарып, хастаханәдә яткан көннәрендә Лотфрахман аны ярдәменнән ташламады.

Капма-каршы сыйфатларга ия булып чыкты Лотфрахман кардәш. Көрәшчеләр нәселеннән микән, эре сөякле яратылса да, гамәлендә исә кәгазь корты, вакчыл педант булып, фикерендә бер караганда—рәсми, академик, икенче караганда—стихияле урам көрәшчесен хәтерләтеп, соңыннан ачыклануынча, кайчакта артык вакланып китеп, кайчакта эчендәген яшермичә әйтеп, үзенә хас булган максимальлеге нәтиҗәсендә авыр хәлләргә дә тарып, кичәге үпкәсенең бүген нәрсә икәнен дә оныта торган бу чуар, әмма яхшы күңелле кешене ул чын-чынлап яратты. Иркен ага аның бер генә сыйфатын кабул итә һәм сәбәбен аңлап җиткерә

алмады: Лотфрахман—төзәлүе мөмкин булмаган дәрәҗәдә “сырсып чыккан” болгарчы икән. Бу әсастан караганда, алар тигез: Иркен ага никадәр татарчы-мөселман булса, Лотфрахман шулкадәр мәҗүси-болгарчы. Лотфрахман-кардәш болгарчылыкның корыч большевигы—Ленины, әгәр, телисез икән—аның Чаллы туфрагындагы кечкәнтәй генә “фюреры” да иде.

Алар урамга чыктылар.

Хакимият каршындагы күпергә житәрәк, Иркен ага туктады һәм күпер чормасына язылган шигарьне ижекләп укыды:

—Ха-лык-лар... дус-лы-гы... төп... бай-лы-гы-быз...

—Әйе, сатылмаган бер генә байлыгыбыз калды. “Халыклар дуслыгы”! Урыска ул дуслык кирәкми, ул аның теленә йокмый. Муенына элмәк салынган вак милләтләр генә “халыклар дуслыгы” дип кычкырган була. Аның белән гомер озайтып булмый... Жырлыйбыз, биибез!.. Биемәгән көнебез калмасын өчен хәтта күрше Калмия, Минзәлә, Сарман, Мөслим авылларының якташлык жәмгыятьләрен оештырдык!.. Америкадагы Чаллы болгарлары жәмгыяте диярсең. Ә менә Чаллыдагы Америка болгарлары оешмасын сезгә оештырырга туры киләчәк, Иркен-ага!..

Хакимиятнең милли бүлеге мөдире Стомат Сибгатуллович үзендә иде. Алар берсен-берсе күреп белә. Шулай ук конгресста танышкан иделәр.

—Һо-о, Иркен ага! Әйдәгез!..—Ул кунакны өстәл артыннан чыгып каршылады.—Моңа кадәр һич кенә дә якыннан танышып, иркенләп сөйләшә алмаган идек... Кереп, бик дөрес эшләгәнсез!.. Менә бирегә утырыгыз!..

Кара костюмлы, ак күлмәгенә шундый ук кап-кара галстук бәйләгән, сул якасына шәһәр парламенты депутаты билгесен беркетеп алган мөдирнең кәефе ихластан да яхшы идеме, әллә күрсәтә генә идеме—моны белү читен иде. Көйдереп караган коңгырт күзле, кыска буйлы, һәр хәрәкәтеннән теләктәшлек һәм дәрт ташып торган бу зат, беренче карашка, Иркен ага эзләгән “матур затлар” рәтенә керә иде.

Әллә гаиләсендәге асыл тәрбиядән, әллә эчендә кайнаган борчуларыннан бит алмасы атланмайда йөзгән коймак булып алсуланган Стомат Сибгатуллович теш казнасындагы эре алтын тешләренә кадәр күрсәтеп елмайды һәм бу елмаю аның кыяфәтендә аерылышканчы үзгәрмәде.

“ Утларны-суларны кичкән түрә бу. Елмаюы кытайча...—дип уйлап алды Иркен ага.—Кешелекнең нәсел-нәсәбе никадәр бердәм. Чулман буенда яшәгән татар Чанчунь кытаенча елмаядыр...”

—Бүгенгә кадәр очраша алмавыбызга үзебез гаепле, Лотфрахман Галимуллович!—диде Стомат Сибгатуллович.—Милләттәшебез Америка кадәр Америкадан килеп житкән... Татарстанны аркылыга-буйга кызырып чыккан. Ә безнең очрашу түгел, салкын чәй дә эчергәнебез юк!.. Әй, онытып торам ләса, сезгә чәйме, кофеме?

—Кәһва, әгәр мөмкин икән,—диде Иркен ага.

Мөдир ишегән ача төшеп, аваз салды:

—Октябрина Искәндәровна, өч кофе!..

—Лотфрахман Галимуллович, әйдәгез, Иркен агага бирәр истә калырлык мәдәни чара күрсәтик? Таптым!..—Мөдир кычкырып жибәрде, аннан йәнә елмайды да, түшәмгә карап, бер секундка уйга калды.—Са-бан-туй!.. Американың үзеннән килеп... күреп китсен. Авыл сабантуе!.. Әйдәгез, минем Жукәтауга! Сез каршы түгелме, Иркен ага?

—Каршы буламы соң?—Иркен ага елмаеп жибәрде.—Каршы имәс!..

—Сезнең авылыгыз юк бит, Стомат Сибгатуллович...—Лотфрахман-кардәш уфырып куйды.—Су астында калган бит...

—Су астында калса да, ыңгыраша, рухы исән! Теркәп куй, Лотфрахман

Галимуллович, бу җаваплы бурыч безнең өскә йөкләнә!..

Текә маңгайлы хатын кәһва кертте. Ияреп, бүлмәләрендә купкан низаг та керде.

—Это что за еще рухият да хиссият? Ничего подобного у нас нет! Это у вас фамилия что ли?[1]

—Нет, из-за незнания татарского языка, вы меня не так поняли,—диде бүлмәдәге икенче бер хатын йомшак кына тавыш белән.—Моя фамилия Хакимуллина. Зовут Сихат. Я сказала вам, что могла бы вести при вашем отделе бесплатные женские курсы под названием “Рухият-Хиссият”[2]...

—Сихәт ханым тагын килгән...—Лотфрахман, күн кумтасыннан кенәгә чыгарып, нәрсәдер теркәп маташты.—Эшсез калган. Файдам тисен дип, хатын-кызлар өчен түгәрәк оештырырга тәкъдим итә...

—Сабантуйга кайтырга кем каршы?—диде Стомат Сибгатуллович Лотфрахманга игътибар итмичә.—Кулларыгызны күтәрегез!

—Туган җирдә сабантуйга кем каршы болады?—Балаларча куанган Иркен ага сүзен шигырьгә китереп ялгады:

Атам кияү болган йир,
Анам килен болган йир,
Кендегемне кискән йир,
Тәмле суын эчкән йир!..

—Сез—яттан шигырь?!—Стомат Сибгатуллович кулларын чәбәкәйләде..—Гениально!.. Ишеткәнем юк иде. Кыскасы, кайтабыз! Әйткәндәй, шәһәр советына карата берәр үтенечегез юкмы? Көнкүреш, ашау-эчү, торак ягыннан?

—Әлхәмдүлиллаһ, барысы да яхшы.

—Гаиләгез белән элемтә тотасызмы? Алар кайдалар?

—Әлхәмдүлиллаһ, барысы да яхшы.

Иркен ага мөдирнең, вазыйфасыннан чыгып, аның тәрҗемәи хәлен энәсеннән җебенә кадәр белгәнлеген белсә дә, итәгатьлелек белән барысын да сөйләп бирде.

—Җәмәгатем Әмрикәнең Висконсин штатындагы Kizlau атлы шәхси утарыбызда яшәп ята. Кызым Гөлмәрфуга Торонто милли паркында кошлар буенча белгеч-орнитолог булып эшләй, улым—Чыңгыз Төркиядә, Таштюпедә мәрмәр илә сату итәде...

—Элемтәгез ышанычлымы? Тартынмыйча әйтегез, ярдәм кирәкмиме?

—Рәхмәт, кирәк имәс. Галәми телефон аша даими элемтәдәмез. Кирәксә, Лотфрахман кардәшнең кәмпүтере аша интернеттан хат та алышабыз...

—Монысы яхшы. Гаиләгезнең кайтканы юкмы?

—Мин хәлгә тарып, хастаханәгә яткач, Чыңгыз улым белән кызым Гөлмәрфуга кайтып киттеләр. Мине алып китәргә иткәннәр иде. Мәхкәмәдә эш бетмәй торып, китәргә ярамай. Миңа каза салган инсан минем якын борәдәремдер, гуй.

—Җинаятьче... наркоман... сезнең туганыгыз?

—Салют Сәлахов—турыдан-туры туганымдыр кү. Туганнан туган туганым.

—Онытып торам, бүген хөкем булдымы? Карары ничегрәк?

Иркен ага Лотфрахманга, Лотфрахман исә аның үзенә укталды.

[1] (Урыс.)—Бу ниткән рухият-хиссият була тагын? Бездә андый нәрсәнең булганы юк. Әллә ул сезнең исем-фамилиягезме?

[2] —Юк, сез татар телен белмәвегез аркасында мине дөрес аңламадыгыз. Минем фамилиям Хәкимуллина, исемем—Сихәт. Сезнең бүлек каршында мин хатын-кызларыбыз өчен түләүсез оештырылган “Рухият-хиссият” дигән курсларын алып бара алыр идем, дидем мин сезгә...

—Мәхкәмә минем аркада өзелде, Стомат кардәшем...—Үзен бик унайсыз тойган Иркен ага карашын идәнгә төшерде.—Сәгатен онытып җибәргәнмен. Картлык галәмәте...

—Нинди картлык ди әле сезгә!.. Онычу яшьләргә дә хас нәрсә. Ә сез шундый яшь күренәсез! Бернинди тетрәнү, авыру, җәфа кичермәгәнсездер кебек. Йөзегездә бер җыерчык та юк!—диде ул аны канатландырырга тырышып.

Иркен ага бүлмәгә, бүлмәдәге җиһазларга күз йөгертеп алды. Шәһәрнең зурайтылган харитәсе, милли җәмгыятьләрнең түгәрәкләр эченә алынган исемлеге, алар белән идарә итүнең кемнән кемгә төшүен уклар белән күрсәткән схемалар, үсеш яки чигенеш чагыштырмалары белән тулган дивар, гүя, фронт шартларындагы армия диспозициясен, эре икътисади офисларда була торган планшетларны хәтерләтә иде. Почмакнын тыныч, бернинди дулкынсыз һавасында, канаты сынган кош кебек, сапларыннан ләшперәп төшкән бернечә Татарстан әләме серәеп тора. Иркен ага моны күреп читенсенде. Аның ошбу әләмнәргә әверелесе, аларны канатландырасы һәм җилкендерәсе килде.

—Сезгә бәлки шәһәребез турында кыскача күзәтү ясарга кирәктер?

—Бәракалла!—Иркен ага, көтелмәгән тәкъдимнән куанып.

Мөдир, урыныннан торып, шәһәр картасы каршына килеп басты. Ул лекция укырга әзер иде.

—Урыслар Татарстандагы борынгы татар шәһәрләрнең нигезләнү сәгатен, гадәтенчә, бары тик үзләренең басып алу чорлары белән генә, ягъни XYI-XYII гасырлар белән генә бәйлиләр. Алар уйлавынча, кыргый татарлар, шәһәрләр төзи белмәгән, алар бары тик җимерә генә белгән. Алай караганда...—Кулына сыек таякчык та эләктереп алган Стомат Сибгатуллович үзенә биргән мөмкинлеккә куанып, тагын да кытайча елмайды.—Алай караганда, урыслар үзләре ике йөз меңлек гаскәрләре белән ике ай буе камап торып та алалмаган, Германиядән егерме мичкә дары һәм Бутлер кебек махсус шартлатучы мастер китертеп, диварларны, астан чокып, ике урыннан шартлатканнан соң гына ала алган Казан каләр Казан каласын шул татарлар төземи, марсианнар төзеде микәнни? Безнең галимнәрнең фикеренчә, Кама кебек зур елга буенда форпост булган Чаллы, шул исәптән, Алабуга, Мамадыш, Арча, Бөгелмә калалары XI-XII гасырларда нигезләнгән булырга тиешләр. Кем белә, бәлки иртәрәктер дә? Яңа татар тарихы шәһәрләребезнең чын тарихын аякка бастырудан башланырга тиеш! Президентыбыз шундый бурыч куйды һәм шул күрсәтмә нигезендә Казан Керәмәлендә киң масштабларда казыну эшләре башланды. Гениально!.. Безнең Казаныбызга ким дигәндә мең ел!—Стоматның миенә илһами шаукым сукты бугай, ул урыныннан кузгалып йөренә башлады.—Арчага—мең ике йөз ел! Буага—мең бер йөз ел! Норлатка—тугыз йөз ел! Мамадышка күпме? Алабугага, Бөгелмәгә, Бәләбәй, Чаллыга күпме? Аларга кимендә мең ел, ә менә урыслар шәһәр тарихын 1650-57 еллардан гына башлыйлар. Гүя, аңарчы татар халкы булмаган!.. Нигә без боларны ачыклаудан куркабыз?—Ул аның алдына килде һәм коңгырт күзләре белән өттереп туктап калды.—Әйтегез әле, Иркен ага, әгәр бу калаларны урыслар салган булса, алар, татар исен йөз чакрымнан да кичермәгән баскынчылар, бу шәһәрләргә... ул заманнарда... Бөгелмә, Алабуга кебек татар исемен биргән булырлар идеме?—Ул бераз гына тынып торды да, үзенә-үзе җавап бирде.—Бирә ди!..Тоттырды ди...

"Тарихны яхшы белә бу,—дигән фикер килде Иркен агага.—Мантыйгы да чын тарихи. Кызык, белеме белән кем икән? Тарихчы, телче, әдәбиятчы? Теле дә саф татарча."

—Чаллы 1939 елда шәһәр статусы ала...—Ул, шикләнгәндәй итеп,

Лотфрахманга карап алды.—1969 елда Яңа Чаллы төзелә башлаганда анда нибары утыз мең кеше яши...

—Кырык мең!—диде Лотфрахман кардәш.

—Ярый, кырык мең булсын. Күз алдыгызга китерә алсагыз, китерегез: 1970-1980нче еллар арасында—нибары ун ел эчендә аңа СССРның төрле почмакларыннан ике миллионга якын кеше килде. Барысына да күз-колак кирәк булды!.. Килде—калды. Килде—китте. Гениально!..

—Бер миллион сигез йөз илле мең...—дип төзәтте Лотфрахман-кардәш.

—Ярый, бер миллион сигез йөз илле мең булсын,—диде тыныч кына Стомат Сибгатуллович.—Алар барысы да кеше бит...

—Барысы да кеше түгел шул...—диде аңа каршы шундый ук тынычлык белән Лотфрахман.—Андагы төрмәдән чыккан комсомолецлар, наркоманнар, физиклар-шизиклар, кеше үтерүчеләр, ата караклар, рецидивистлар...

Мөдир аңа кискен караш ташлады.

—Татар халкы җир шарының бөек санитары ул! Барысын да йотты... Әмма күз-колак кирәк...—диде Стомат Сибгатуллович.—Килгән һәр биш килмешәкнең берсе генә бездә ныгынып калалды бит...—Бүлмәдә тынлык урнашты.—Еш кына татарның кем икәнен белмәгән һәм белергә дә теләмәгән, зур акча, фатыйр, яңа хатын, яңа ир артыннан, имеш, иркен Кама, Идел буйларында ауный-ауный эчәргә, гөмбә җыярга, балык тотарга, куян, төлке ауларга, шешенгәнче йокларга... да-да!.. килгән бу кадәр массаны... җиребезгә беректерү, аларны бераз булса да, татарны ихтирам иттерү юлына бастыру өчен безнең халык никадәр түземгә ия булырга тиеш иде? Гениально!.. Мондый шартларда сүз татарлаштыру, аны абсорбцияләү турында сүз бара алмый иде, әлбәттә, анлыйсыздыр... Татарга урамнарда, хезмәт урынында, транспортта туган телдә сөйләшергә ярамады, татар белән татар арасындагы никах хурланды, урыс белән татар катнаш никахы күккә чөеп макталды... Да-да!.. Әйе, хәтта шушы бөекурыс диктатурасы шартларында да урыс туганнарыбызны бераз булса да үзебезгә якынайту, татар милләтен бар итеп күрсәтү өчен чагыштырмача аз санлы татар халкына никадәр авырга төшкәнен сиземлисез микән?.. Мин үзем дә Норильскийдан кайткан һәм КамАЗ капкынына капкан кеше!..

"Нинди капкын?" Иркен ага сорарга уңайсызланды.—Иске Чаллыдагы утыз мең утрак инсанның канчасы татар, канчасы урыс иде кү? Алар үзара кандай мөнәсәбәттә көн итәде? Килгән урыслар алар илә ничек итеп интеграциягә индерелде?

—Кызык сорау бу. КамАЗ төзелә башлаганчы халыкның алтмыш проценты татар, утыз биш проценты урыс, калганнары башка җирле кавемнәрдән торган. Татарлар үз телендә иркен сөйләшеп, җырлашып, урыслар белән бертугандай аңлашып яшәгән, диләр. Җирле урысларның күбесе татарча белгән. Татар арасында яшәп, алар эчкечелектән әле болай ук азынмаган булганнар... Эчкечелек һәм бар яман гадәт КамАЗ белән килде. Комсомолец-урысларның җирле халыкка карашы явыз иде. Беренче көннәрдә җирле халык—татарлар һәм урыслар—бергә булсалар да, тора-бара җирле урыслар килмешәкләр ягына чыгып, славянлык идеологиясендә берләштеләр. Ләкин татар түземе, татар сабырлыгы милләтара дошманлыкның бер генә чагылышына да юл куймады...

—Бәрәкалла!..

—Бигрәк тә татар авылына төшкән сынауларны алыйк! ...Беренче айларда бу килмешәкләр массасы булачак шәһәрдән йөз чакрымлык радиуста урнашкан авылларда яши. Моңа кадәр эчкечелек һәм йозак дигән нәрсәләрне күрмәгән татар авылында бурлык, алкоголизм, җинаятьчелек, зиначылык көчәя. Урманнарда шифалы үлән, гөмбә, җиләк-җимеш

тамырыннан корый, күлләрдә балык, авылларда халык бетә!.. Читтән килгән интернационалны бераз булса да сыегайту өчен, Татарстанның ул чактагы житәкчелеге татарларны, Үзәк Комитетка әйтмичә генә, авыллардан күчерә башлый... Нәтижәдә татар авылы кешесез, малсыз кала. Татарның бөек байлыгы булган татар хатыны шәхес буларак жимерелә, рухы белән маржалаша... Күз-колак кирәк!..

Стомат әфәнде, күрәсең, "күз-колак" дигән сүзләргә аерым мәгънә салып, авыр итеп уфырды. Гүя бу кайгы милләт кайгысыннан хәтәррәк дәүмәлдә аның шәхси кайгысы да иде...

—Ничек кенә булмасын, без мондый халыкка, мондый авылга дан жырларга тиешбез! Кайсы милләттә, кемдә бар безнекедәй үлемсез авыл?! Татарда гына калган иде ул, Иркен ага!..

—Дан белән тамак туйдырып булмый, Стомат Сибгатуллович,—диде кискен итеп Лотфрахман.—Болгар авылына ярдәм итәргә, иserek татарны шәһәрдән кире авылга кайтарып, болгар ясарга кирәк!..

Стомат Сибгатуллович тешләрен шыгырдатты.

Лотфрахман астында урындык шыгырдады. Ул кара кенәгәсенә нәрсәдер теркәп куйды.

Бу сөйләшү Иркен аганың иртән жир асты юлында күргән-кичергән манзараларын, затсызлык турында иртән ачкан ачышын хәтеренә төшерде. Бу таң калырлык кызык иде. Стомат Сибгатуллович Иркен аганың затсызлык теориясенә килеп үк туктады түгелме?

—Бүген шәһәребездә биш йөз дә утыз өч мең кеше яши. Алар—йөз дә ун милләт балалары. Шуларның кырык сигез проценты—татарлар, кырык биш проценты—өлкән туганнар, калганнары—башка милләт вәкилләре,—Мөдир йөз мәртәбә сөйләп өйрәнгән сүзләрен телендә өерелдерде.—Бу тарихи күрәштә татар милләте үзенең нәсел чыдамлылыгын, генофондының үлемсез булуын раслады. Мондый татарга һәйкәл куярга кирәк! Да-да!.. Мондый милләт үлемсез!..

Ул яңадан бүлмә буйлап йөренә башлады.

Бу сүзләрдән Иркен ага алдында офыклар яктырып китте. Бу яктылык Иркен аганы гомер буе озатып йөргән уй, бу яктылык татар милләте язмышында Аллаһы Тәгалә, аның рәсүле Мөхәммәт пәйгамбәребезнең тоткан урыны иде. Әгәр ата-бабаларыбыз моннан нәкъ 1076 ел элек ислам динен кабул итмәгән булсалар, жир йөзендә саклана алган булырлар һәм ничек сакланган булырлар иде икән?

—Бер мәктәпсез үлеп барган татарның проблемаларын, Татарстан күләмендә беренчеләрдән булып, без күтәреп чыктык. Бездә, татар милли азатлык хәрәкәте беренче булып оешты һәм, бу ижтимагый-сәяси көч барлык Татарстандагы этнологик процессларны гадел хәл итүгә этәргеч бирде. Шәһәребезнең үзәк мәйданына, беренче булып, без "Азатлык мәйданы" дигән исем куштык. Милли лидерыбыз Жиһаннур Хәлиуллин шул мәйданда милләтне яклап ун көн ачлык тотып яткан көннәрдә Минтимер Шәймиев Чаллыга Борис Ельцинның үзен алып килде. Монда без, депутатлар белән очрашкан чагында да әйтте бит ул теге бар дөньяга таралган "Мөстәкыйльлекне күпме телисез, шул кадәре алыгыз!"—дигән тарихи сүзләрен! Анда, Лотфрахман, син дә бар идең бит? Ырасмы?

—Ырас!—диде Лотфрахман танау астыннан гына мырлап.—Борис Николаевич палаткада яткан Жиһаннурны үзенә чакыртты. Әмма Жиһаннур Ельциннан килгән чапкынга "Мин урыс патшасы янына бармыйм, ул үзе минем янга килсен!"—дип кенә жавап бирде...

—Кара син аны!—диде Иркен ага.—Шундый лидерлар да бармы?

—Булмыймы соң!.. Шәһәрнең комплекслары буенча йөреп чыгып, ата-аналардан имзалар жыеп, Татарстандагы беренче унлаган милли мәктәпне,

балалар бакчаларын кемнәр беренче булып ачты? Без ачтык!

—Комплекс түгел, мәхәлләләр!—дип төзәтте житәкчесен Лотфрахман кардәш.

—Кама аръягындагы беренче татар курчак театрын, беренче татар яшьләр театрын, беренче татар гәзитләре "Нур", "Шәһри Чаллы"ны, беренче татар әдәби журналы "Аргамак"ны кем ачты? Без ачтык!..

Коридордан, күрше бүлмәдән хатын-кызның безле үкчәләре шыкылдады. Гүя, ханымнар урыннарында утырып эшләми, алар очлы үкчәләре белән паркет кына чүки иде.

—Кем урамнарына Сөембикә, Хәсән Туфан исемнәрен бирде? Без!... Авылның гади бер гидае Салаватны, тынкыш малайны, җырчы итеп кем үстерде? Хәния Фәрхи, Гөлдания Хәйруллиналардан кем йолдыз ясады? Без!..—Стомат Сибгатуллович хәле бетеп, беразга тынып торды да, кулындагы таягының очын харитә буйлап йөртә-йөртә аңлатырга керешге. Бу мизгелдә ул армияләр белән җитәкчелек иткән маршалларны хәтерләтә иде.—Шәһәребез алтмышлап комплекска бүленгән. Озынлыгы бер башыннан икенче башына егерме чакрымга якын. Бүген ул Татарстанның гына түгел, барлык Рәсәй Федерациясенең иң матур, иң төзек шәһәрләреннән санала. Соңгы елларда бездә халыкара чаралар да үткәрелә башлады. 1994 елның җәендә, мәсәлән, бездә ЮНЕСКОның вак шәһәрләргә багышланган халыкара симпозиумы үтте... Шәһәребез турында кыскача белешмә менә шул, Иркен ага!..

—Чаллы турында олуг тарихи хезмәт укыгандай булдым!

Бу сүзләр Стомат әфәндене йөрәгенә сары май булып ятты. Бу аның елмаюында чагылды.

—Рөхсәт итсәңез, сезләргә сөалем дә бардыр... Шәһәрдә мәдәният-мәгърифәт учаклары сирәк күренәде...

—Монысы дөрес!... Менә монысы хак!.. Безнең кунакларыбыз нәкъ менә шушы сорау белән безне төп башына утырта. Генпланда алар бар!... Сез ничек уйлыйсыз, Иркен ага: сез, әгәр төзүче булган булсагыз, читтән, шул исәптән Татарстан районнарыннан килгән биш йөз мең халыкка башта торак төзер идегезме, әллә цирк бинасымы?

—Мин барысын берьюлы төзегән булыр идем...

—Юк. Сез шулай уйлыйсыз гына. Бездә, СССРда алай була алмый иде.

—Ул чакта... цирк бинасы көтеп торады!..

—Менә шул шул! Дүрт-биш йөз мең халыкны урнаштырырга ашыгып, партиянең шәһәр комитеты барлык көчне торак төзелешенә салды. Нәтиҗәдә...—Стомат Сибгатуллович генплан харитәсе янына очып килгәндәй килде һәм күрсәтә башлады. Шәһәр комитеты партиянең, СССРның таркалачагын күз алдына китерә ала идеме? Алмый иде. Рәсәйдә Ельцин демократиясе, кыргый капитализм урнашып, илне талау башлангач... шәһәрдә төзелергә тиешле биш кинотеатр, драма театры, цирк, филармония, үзәк китапханә, мәхәлләләрдәге дистәләгән китапханәләр, мәктәпләр, яшьләр үзәкләре, никах йортлары—берсе дә төзелмичә, без йокы шәһәре, сукбайлар шәһәре булып калдык... Бүген шуның касафатын кичерәбез. Чаллыда җинаятьчелекнең, мафиозлыкның Татарстан белән чагыштырганда югарырак булуы менә шул ике фактор—халыкның төрле яктан җыелган милләтсез, имансыз, чуар масса булуы, аларны бердәм Чаллы халкы, "Чаллы милләте" итеп тәрбияләү мөмкинлекләренең накыс булуына барып төртелә... Бүгенгә Чаллының милләте юк. Анда бары тик "гавам"—население генә бар...

—Мин сезнең белән килешмәем...—дип кыстырып куя алды Иркен ага.—Минем һәм башка бик күпләрнең фикеренчә, Татарстанда иң югары

милли үзаң Чаллыда саклаңган. Сәбәбе ни-нәрсәдер?

—Сез монда да хаклы. Монда берничә фактор. Беренчесе, табигый фактор. Милләтнең характеры ул эчкән судагы сирәк металлар составы белән билгеләнә, диләр.

Бу Иркен ага өчен яңалык иде.

—Без ярлары милләтебезнең каны белән сугарылган Агыйдел, Кама, Ык, Сөн суларын эчәбез. Бу суларда миллилек витаминнары бик югары...—Стомат әфәнде үзенә урын таба алмагандай, йөренә башлады.—Икенче фактор—КамАЗ төзелеше башланыр алдыннан Тәбиев һәм Беляевлар җитәкләгән партиянең өлкә комитеты махсус пленум үткәреп, барлык Союздагы татарларга Чаллыга кайтырга чакырып мөрәҗәгать иттеләр... Безгә татарлар агылды!.. Һи-и, бездә татарның ниндие генә юк! Алар безнең алтын фонд!.. Сез алар белән танышырсыз әле, шәт...

—Сез Чаллы эчкән сулардагы сирәк металларны атый алмыйсызмы?

—Анысын Аллаһы Тәгалә генә белә, Иркен ага. Ул аны үзгәртеп тора. Әгәр теләсәк, санэпидстанция аша без аны белә алабыз, әлбәттә... Ләкин аларда...—Мөдир авыз чите белән елмаеп, күз кысты.—Мәгълүматлар ике төрле—берсе хөкүмәт, икенчесе халык өчен... Кайсы кирәк?

Киңәшеп алу өчен түшәмгә карап та өлгермәде—киндер тарткан тегермән кебек дырылдап, өстәлдәге телефон шылтырады.

—Исәнмесез, Графит Мәгъдәнурович!—Мөдир трубкасын учы белән каплап, кунакка асфальт заводы директоры шалтыратканын җиткерде.—Казанда идем... Казан-Чаллы юлы төзелешендә "Камдорстрой" белән сезнең хезмәттәшлек шактый күзгә чалына хәзер. Евростандарт булачак! Рәхмәт, рәхмәт... Яхшы. Сөйләшкәнчә, иртәгә көтәм!..

Ул трубканы куйды.

Иркен аганың Стомат кардәшенә сүзе дә калмаган иде кебек. Күңелендә нидер теркелдәп куйгандай булды. Аның үзенә ошап җитмәгән бер сыйфаты бар: күңеленә килгәнне сорамаса, соңыннан үкенә, чирли.

—Зинһар гафу итә күрегез, сезнең исемегез бик сирәк, оригиналь.Әле генә сезгә шалтыраткан кардәшнең исеме дә Графит...

—Әйе, сирәк...—Стомат Сибгатуллович көлемсерәгәндәй итте.—Минем исем... "Стоматолог"тан алынган ул. Әти, фронттан салкын тидереп кайтып, зәңгелә авыруы белән бик тә җәфаланган. Минем теш табибы—дантист булуымны теләгән. Дантист кушарга иткән, аңа бу исем Пушкинны үтерүче Дантес белән бутарлар, дигәч, баш тарткан. Флюс кушарга теләгән, анысының теш казнасындагы шеш икәнлеген төшендергәч, тоткан да "стоматолог"ның беренче ике иҗеген алып, Стомат кушкан...Укымышлы кеше булсаң да кыен, да-да!..

—Үзегез...стоматолог?

—Әйе. Мин медицина институтын стоматология буенча тәмамладым. Әле дә сирәкләп шәхси практика алып барам. Ә менә сез әйткән Графит кардәшебез—авылдашым. Аның әтисе дә, Мәгъдәнур абзый, графит кебек кара улының... э-э... нык ... э-э... уалмаучан булуын теләгән.—Ул бер мизгелгә түшәмгә карап уйланды.—Графит... Графит.... Нигә аптырарга, минем хатынымның исеме Элексир, балдызныкы—Партия!.. Кайнешләрем—Маркс һәм Энгельс Зәйнулловичлар!.. Без бу мәсьәләне ул кадәр игътибарга лаек нәрсә дип уйламыйбыз. Баласына исем бирүдә кеше иректә. Нәкъ мәхәббәт кебек...—Стомат әфәнде беразга уйланып торды.—Кешегә син марҗаны яратма, аңа өйләнмә, дип әйтеп булмый, шулай бит? Проблема бар!.. Татарда Экзема, Маузер, Мортираларның килеп чыгышы егерменче-утызынчы елларда Совет Россиясендә котырган культура революциясе касафаты ул. Безнең рухи мирасыбызны җимергән пролеткульт турында ишеткәнегез булгандыр? Мәчетләрне шул ук ата дәһрилек, шул ук пролеткульт җимерде

бит инде...

—Ишеткәнмен. Ул Кытайдагы шул ук хунвейбинчылык болады.

—Хунвейбинчылык? Һм. Кызык чагыштыру бу. Пролеткульт безгә иске исемнәр бирүне тыйды. Мөхәммәт, Аллаһ, пәйгамбәрләр, дини төшенчәләр кергән исемнәргә табу салынды. Балаларына яңа совет исемнәре кушу буенча сельсовет белән сельсовет, колхоз белән колхоз, район белән район социалистик ярышка чыкты. Әгәр балаңа Галиәхмәтләр, Мөхәммәт Әмин исемнәре күтәреп килсәң, ЗАГС балаңа туу турында таныклык бирми. И все тут!.. Галактикада казынырга, яңа Марслар эзләп табарга кушып кайтарып җибәрә. Әгәр тагын да кәҗәләнәсең икән, труттиненне сызып ыргыталар, җигәргә ат, печәнлек, утынлыктан мәхрүмсең... Яна исемнәр кушу буенча ярышта җиңүчеләрне кер сабыны, чәчүргеч, крәчингә, эрзин калушага талон белән бүләкләгәннәр... Ләкин яшибез, исемнәр зыян итми. Җисемең булсын! Татар булып калырга иң тәүдә җисем кирәк, шулай бит Лотфрахман Галимуллович?

—Татар болгар исеме белән генә җисемле була ала, Стомат Сибгатуллович,—диде җавабында Лотфрахман.—Ләкин татар болгарга кайтырга теләми. Менә Иркен ага, ичмасам: чын болгар! Менә кем ул чын мәҗүси!..Исеме генә ни тора—Ир-ке-е-е-н... Әйтү белән иркен булып китә. Чын болгарларча, чын мәҗүсиләрчә!.. Бернинди гарәп мөселманлыгы да, Минзәлә мөхәммәтҗанлыгы да юк!

—Мин хак мөселман. Мин мәҗүси имәс...—диде Иркен ага уңайсызланып.

—Сез шулай уйлыйсыз гына. Көн килер, "мәҗүси"леккә кайтачаксыз!.. Әнә, Чаллының беренче милли лидеры Җиһаннур Хәлиуллинны алыйк. Бөтентатар иҗтимагый үзәген оештыручы мөселман-галим Марат Мөлековның антиподына әйләнде. Татар-мөселманлыктан ваз кичеп, төрки-мәҗүсиләрнең бил буган атаманына әверелде... Биләсәпидтә йөреп, мәҗүси гәзитләр, университетлар ача!... Молдавиядә гагаузларга, Литвада Торакай караимнарына Чаллы мәҗүсилеге турында лекцияләр укый!.. Караим яһүдиләрен мәҗүсилеккә өнди...

—Әйе, бәла!.. Мөлеков канаты астыннан татарның интеллигентзыялылары, Хәлиуллиннар канаты астыннан мәҗүсиләр, Шиһаповлар канаты астыннан анархо-синдикалистлар агымы аерылып чыгып, үзара сугыша башлады...—дип өстәде Стомат Сибгатуллович моңсу гына.—Болар әле безнең башка тукмак булып төшәчәк...

Алар кабинеттан чыктылар.

## II

Иртәгәсен ишек аша башын ия биреп, секундка кадәр аныклык белән—нәкъ сәгать тугызда—Лотфрахман килеп керде. Шул ук калын йон кәчтүнен, аның эченнән фланель күлмәк кигән, аны, гадәтенчә, өске төймәсенә кадәр каптырган. Өшиме? Килеп тә керде, кочаклап алды, кочаклап та алды һәм иңенә асылган күн кумтасыннан перфокартасын чыгарып, шунда язылганны укый да башлады:

—Гафу-мәгъфирәтләре!.. Сез тыңлый гына күрегез! Без, болгарлар, нинди бөек халык булганбыз!.. Һәм булачакбыз! Без үз кадеребезне үзебез генә белмибез, шулай бит?... Профессор Западов—ул "О"-га басым ясады.—үзенең "Державин" дигән китабында менә нәрсә яза: "Державиннар нәселе кенәз Василий Темныйга хезмәткә күчкән һәм чукындырылганнан соң Илья исем алган болгар-татар морзасы Баһрамнан башланган...Бу XV гасырда була..."

Лотфрахман кардәш, төннәрен йокламыйча, акыллы сүз эзләп, иртән

торгач, күзләрен тырнап ача да, андагы гакыл белән үзе надан санаган дөньяны гакылга утыртырга тотына бугай, дигән фикергә килде Иркен ага.

—"...Урыска күчкән Баһрамнан урысларнын Нарбеков, Акинфов, Кеглев дигән дворян фамилияләре тарала... Дмитрий Ильич Нарбековның Державa исемле бер улы Казанда колониаль армиядә хезмәт иткән була. Безнең бөек шагыйребез үзенең нәсел башын шуннан ала..."—укуыннан туктап, кәгазен кумтасына салып куйды.—Әйтерлегегез бармы, болгардашым, урыснын беренче бөек шагыйре Державин безнең Баһрам дигән болгар-бабадан, икенче бөек шагыйрьләре Пушкин Ганнибал дигән е-эф-фи-оптан бит! Аларның Мәскәүләре дә борынгы варягларнын "моск"—болгарча "мүк" дигәннән, "Волга"лары без болгарларның "Болгар"ыннан алынган бит!.. Беләмсез, аларның Мәскәвендә сазлыктан, мүктән башка бернәрсә дә юк бит! Шул сазлыкларында ничәмә-ничә исерек кенәзләре батып үлде!...

Алар урамга чыктылар һәм Ямашев бульварына таба юнәлделәр. Күк йөзенә тулып бетмәгән өлешләренә кадәр сызылган Айның лимондай элпәсе эленгән иде.

"Ай күрдем аман белән..." Иркен ага эченнән генә укынды. Көпә-көндез, тарихи ватаны күгендә күргән тере Айдан мөһаҗирнең болай да зәңгәр күзләре тәмам зәңгәрләнеп калды. Бик тә яшел, бик тә чиста шәһәр икән бу Чаллы. Баш очындагы агач ябалдашлары куера, кояш нурларын үткәрмәс дәрәҗәдә калыная барды. Урамнарның киңлеге, йортларның артык биектән алдырмыйча, өскә ишелеп бармаулары, ишек алларында, мәйдан-скверларда чәчкә түтәлләренең ифрат та күп булуы Иркен агада җылы тәэсирләр уятты. Шәһәрнең бу өлеше "Гидротөзүчеләр бистәсе" дип атала икән. Яңа Чаллы төзелеше нәкъ менә шул, әле алар барган урыннан башланган, ди. Студентлар урамына чыгып, унга борылдылар. "Ак Барс" банкының курорт сөяркәсе кебек актан киенгән купшы офисы каршында урам аша чыкканнан соң, Лотфрахман аны тагын да уң тарафка тартты.

Сентябрь башлары булуга карамастан, көн шактый җылы, һава тымызык, хәтта бераз гына бөркү иде. Күк гөмбәзе исә яварга чамалагандай сәленеп төшкән. Иркен ага, кәчтүнен салып, иненә элде. Лотфрахман кардәш бу бөркүлеккә түзепме түзә һәм изүенең бер генә сәдәфен дә ычкындырырга уйлап та карамый. Кинәт кенә һава томалангандай булып, вак күзле яңгыр тамчылый башлады. Аннан явыштыра ук башлады. Бераздан яварга ук тотынды. Лотфрахман кардәш кунакны агач астына ышыкка тартты, әмма Иркен ага юлын дәвам итте.

—Яусын. Бу ягмур озак яумастыр.

—Чыланасыз бит.

—Чыланса. Мин бит тарихи Ватанымда беренче тапкыр чыланам...—Яңгыр явуыннан, Иркен ага баруыннан туктамады. Шифалы дым астында күзгә күренеп чылана, яңгыр сулары чәчләреннән саркый башлаган мөһаҗир кеткелдәп көлде.—Минем белән син дә чылан!..

Һәм шигырь укый башлады:

Кояш көлә, диләр. Көлә микән?
Нигә көләр икән ул, көлсә?
Көлү түгел, җылар битен каплап,
Җир өстендә хәлне ул белсә.
Болытласа, кайбер кеше әйтә:
Бозылып тора бүген һава, дип.
Битен каплап, күктә кояш җылый—
Без әйтәбез ягмур җава дип...

—Сез... яттан шигырьләр беләсез?!—Лотфрахман каушап калды.—Кем шигыре? Тукай? Такташ? Туфан?

—Юк,—диде көлемсерәп Иркен ага.—Хәлимхан Хабаров. Металлург шагыйрь. Сбердлау өлкәсенең Ревда дигән каласында яши, ди. Казанда Конгресс вакытында китабын бүләк итте...

Шулчак көтелмәгән могҗиза булды. Күк йөзен кояш яктырты, ә янгыр, туган илнең шифалы яңгыры, һаман сибәлгәли иде.

—Мондый ягмурны бездә, Уйгырстанда, "сукур тавук ягмуры", диләр...

—Сукыр тавык, димәк. Бездә "күзгә ләйсән" диләр...—Ул, күккә күрсәтеп, кычкырып җибәрде.—Карагыз, бу могҗиза сезнең хөрмәткә!..

Ни күзләре белән күрсеннәр, бүген, 1997 елның 5 сентябрендә, күк йөзенә жиде төсе белән чагу яктырып, салават күпере калыккан иде!

—Бәрәкалла! Машалла!.. Бу ни-нәрсә?

Салават күперенең хәйран төсләр белән уйнаклап торган мәһабәт дугасы астында, монда, жирдә, икенче бер мәһабәт корылма булып ниндидер бер һәйкәл күтәрелде. Бу мөкяфәт—бүләк әллә күзләремә күренәме, дип, Иркен ага күзләрен угалаштырды. Юк ла, чын бугай...

—Бу ни-нәрсә, кардәшем?—Ул каршында дию кебек күтәрелгән корылмага күрсәтте.

—"Ил-Ана" һәйкәле. 1975 елда, мин Чаллыга килеп, болгарчыларнын идән асты түгәрәген оештыра башлаган чорда ук куелган иде...

Иркен ага, әсәрләнеп һәм илһамланып, бу мәһабәт сынны тулаем күздән кичерү максатында бердәнбер ноктаны эзләде. Жаны-тәне белән мөселман булып, сурәткә, ташка-сынга табынуны зур гөнаһ санаса да, ул сәнгать рухы алдында мөкиббән иде. Чын матур, чын гүзәлгә тутырып карарга базмаган егет кебек, һәйкәлне сирпеп кенә күздән кичерде. Әле шәһәр белән бөтенләй диярлек таныш булмаса да, үзен уратып алган йортларнын, урамнарнын архитектур халәтенән чыгып, ниндидер сирәк сиземләү белән бу сынның каяндыр ерак Атлантидадан китертеп, бөтенләй ят, чит мохитка көчләп утыртылган бер экстравагант сыннар эрмитажы булуын чамалады; әйе, атлантларга хас көч, илһам, киеренке ихтыяр белән тудырылган бу тимер-бетон эрмитажда борынгы Мисыр пирамидаларында яткан фиргавеннәрнең көленнән очып чыккан Һөдһөд кошы—Феникс талпынуыннан, инсанга мең ел гомер эзләгән һиндусларның серле чакра[3]ларыннан алып, борыны белән жир жимереп, күкрәкләрен ниндидер корыч казаннар белән каплап, бер кулы белән балаларын ышыклап, икенче кулы белән Өч Кылычы тоткан, карынына янартаулар, шартлар динамит бәйләп, бармаклары белән хәрби кораллар—кыскасы, кара кургашны кан косканчы кысып тотып, күзләреннән нәфрәт лазеры яудырган ир-егетләр камалышында киләчәккә очып барган Ил-Анага кадәр барысы да бар иде; үзе өчен, көтмәгәндә, Чаллы кебек "гадидән гади", провинциаль шәһәрдә шундый ачыш очраткан Иркен-ага күзләренә типкән яшьне кул сырты белән сыпырып алды—әйе, бу гигант аңа, бер яктан, бик тә ошап, хәйранга салса, икенче яктан, үзенең миллә тсез, монсыз, артык зур, тупас булуы белән вәйранга да салды; берүк вакытта Иркен ага сынчыны да аңлый иде—тоталитар, ирекле фикердән ерак шартларда яшәп, индустриаль шәһәрнең монсыз пространствосын ул лекаль, иркә, милли, сызымнар белән түгел, ә бәлки шушындый гадәти булмаган кискен почмаклар ясап, эчтән шартлатырга иткән... Һәм шартлаткан да. Нечкә хисле булырга ярамаганга тупас хисле, хокукы була алмаганга тупас көч белән сугарылган иде бу сын. Тирә-яктагы Никита Хрущевның үзе кебек тумпак башлы, тумпак күкрәкле, биш катлы төрмә баракларын хәтерләткән йортлар алдына мондый чит-ят "элементны"

[3] Чакра—борынгы һиндиләрнең жан-тәнне мәңге яшәтү тәгълиматы.

тоталитар хакимият ничек куйдырган? Димәк...анламаган? Әллә... анлап шулай эшләгәнме? Ә менә бүген... анламыйлармы?

Сын үзенең күләме, масштабы белән генә түгел, ә бәлки тирә-юньгә булган дәгъвасы белән дә мөһабәт иде. Миллилектән качкан скульптор, оста, гүя, планетар милләтсезлек дингезендә йөзеп, бар тирә-яктан көлә, күрә торып, жирлексез жирдә бөек итальян Микеланджело Буанороттиⁱ[4], мексикан скульпторы Давид Альфаро Сикейрос[5]ның гигант масштабларын кабатларга омтыла иде. Бу грандиоз композиция ни-нәрсәсе беләндер аңа ят күренде, үзе кебек шыксыз һәм шакмак кебек жансыз йортлар арасында ул чамасыз зур күләме белән шаклар катыргыч иде. Бу куна тактасы сыман яссы маңгайлы, агач йөзле йортлар, урамнарның архитекторлары, проектлаучылары, төзүчеләре кемнәр икән?

—Атсыз-нисез...кая оча болар?

—Үзләре дә белми,—диде Лотфрахман ачу белән.—Мин беләм. Мәләкәс сазлыгына...

Казанда һәм Чаллыда атка бер генә дә һәйкәл булмавы аны чын-чыннан сәерсендерә. Нәрсә өстендә оча бу Ил-Ана? Хәрби кораллар өстендә генәме? Атта яратылган, Алтын Айдан чыгып, Адриатикада ат эчергән, атларының тоягын юган татар беренче һәйкәлен атка куярга тиеш иде, әлбәттә. Аның бу урында карын астына шартлаткыч динамит бәйләгән гыйфритне түгел, Пар Акбүз Атка менгән Татар Егетен һәм Татар Кызын күрәсе килеп китте. (Зиһенендә бу мәйданны ат пошкырулары, тозлы тир, пешенгән әче кымыз исе басты...)

Студентлар урамы аша чыгып, алар салават күперенен дугасы астында яткан сынның янына ук килделәр. Яңгыр сибәләүдән туктады. Иркен ага киндер кебек агарып калган күккә карады. Салават күпере юкка чыккан иде.

Корылманың нигезендә бернинди дә белешмә-язу кебек нәрсә күзгә чалынмады. Алар кинәт кенә ап-ак туй күлмәге кигән килен-кызлар, кара смокинг кигән кияү-егетләр, кулларына чәчәк гөләндәмнәре тоткан килеш чыр-чу килеп буталган, черт-черт фотога төшкән яшьләр арасында торып калдылар.

—Гаилә корган яшьләребез шушында тарихка керә. Аларга шушы бетон Ил-Ана никах укый. Элек никахны Лениннан укыталар иде...

—Хәзрәт... укымыймени?

—Хет хәзрәттән, хет Карл Либкнехттан укыт. Барыбер аерылыша хәзер халык. Чаллыда ике мең никахка мең ярым аерылышу...

—Авторларын... белмисездер?—дип сынга ымлады, күңелсез темадан китәргә теләгән Иркен ага.

—Беләм. Күреп беләм. Үзебезнекеләр. Скульпторы—Вилдан Хаков. Архитекторы—Зиннәт Гасыров[6]. Хаков—әкәмәт кеше, мин сезгә әйтим.

—Ничек... әкәмәт?

—Оригиналь, диюем. Чыгышы белән Мамадыш. Комазан авылыннан.

Бабасы ягыннан үзе дә Мамадыш тупрагыннан чыккан һәм шул тарафларга бүген-иртәгә юлга чыгарга жыенган Иркен ага моңа бик тә куанды.

—Ифрат талантлы кеше. Мәскәү сынлы сәнгать институтын тәмамлаганнан соң, башта коммунизм темасы белән котырды...—дип өстәде Лотфрахман анын кызыксынуын тагын да көчәйтеп.—Аннан фонтаннар төзергә тотынды. Сезнен кунакханә, базар каршындагы сусыз калган

[4] Буанороттн Микельанджело (1475-1564) – бөек итальян сынчысы.

[5] Давид Сикейрос (1898-1974) – Мексиканың атаклы сынчысы. Коммунист. Халыкара коммунистик монументаль сәнгатькә нигез салучыларның берсе.

[6] Исемнәре үзгәртеп бирелә.

фонтаннар да анықы. Заманында Мәскәүдә Джавахарлал Неру, Индира Ганди, Святослав Рерих, скульптор Давид Сикейрослар белән таныш булган, дип сөйлиләр. Теге гырылдык тавышы белән СССРны җимергән җырчы бар иде бит әле? Наркоман...—Кардәш җырчының исемен хәтеренә төшерә алмый торды.—Ә-ә-ә, Владимир Высоцкий! Алар Мәскәүдә икесе бер караватта йоклап яшәгәннәр, имеш!..

Иркен ага бу легендаларга ышанып бетмәде.

—Сикейросның шәкерте, дисез?!—Үз фикереннең чит кеше авызыннан расланууын ишеткән Иркен ага, куанып, елмайды.—Охшашлар!.. Икесендә дә инсаният табигатен таптап барган гигантизм!.. Хәтта ки, Хаков—татар коммунистик таш сәнгатенең Сикейросы түгел микән?..

—Биек кенә дисезме, чамасыз биек!—дип кычкырып җибәрде Лотфрахман.—Үлчәп караганым юк, гәзиттән беләм: буйга утыз, аркылыга тугыз, биеклеккә унбиш метр ул, гафу-мәгъфирәтләре! Бирегә салынган тимерле-бетонның авырлыгы гына да 360 мең тонна. Бер яна гидростанция төзергә җитә! Бармы җир йөзендә шундый икенче бер һәйкәл? Икенче бер оста? Юк! Ул бездә, болгарда гына бар!.. Сынның макетын корыр өчен гипсны барлык Татарстан буйлап кашыклап җыйдылар. Җитмәгәч, Тау ягына—мариларга да чыгып керделәр. Моның белән партия комитеты секретаре Беляев җитәкчелек итте. Монументны ачканнан соң, җәмәгатьчелектә төрле фикер таралды. Берәүләр хуплады, икенчеләр каһәрләде. Олы туганнарыбыз, болгар егетләренең шундый батырлыгына эчләре көеп, Үзәк Комитетка шикаятьләр яудырды...

Ул, мөселман, бер яктан, сыннарга, аларга табынуга каршы килеп, икенче яктан, татарлык, саф милләтчелек күзлегеннән караганда, өммәтенең сәнгатен дөнья күләмендә тизрәк танытырга теләүдән булса кирәк, татар идеясенә хезмәт иткән, аны данлаган, атаклы татарларның һәйкәлләрен-сыннарын булдыру ягында иде. Гомумән алганда, Иркен ага рух һәм матдә, идеализм-материализм нисбәтләрендә аларның икесен дә килештергән дуализм тәгълиматы тарафдары иде. Ул Казанда, Мулланур Вахитов һәйкәленнән башка, татарның горур исем-җисеменә торырлык башка бер генә дә мәһабәт һәйкәл күрмәде. Чаллыдагы бу монумент мәһабәтлеккә мөһабәт, әмма биредә татарга хас күнел нечкәлеге, моң җитми, ул очраклы бер гыйфрит, бетонга катырылган таш кыя, башка сыя алмас гигант һәм тупас гигант иде. Татар җирендә татар кулыннан бетонга катырылса да, бу гигант сында татар идеясе юк иде, киресенчә, ул татарның урыс коралы астында яшәвенең табигыйлыгын, дөреслеген, гаделлеген данлый торган горур пот-ташбүкән иде...

Иркен аганың башына шул ук вакытта “Бу Хаков дигән сирәк инсан белән очрашканда начар булмас иде”,—дигән фикер килде.

Кардәше, култыклап алып, биек кара гранит диварга таба алып китте. Менләгән сугыш корбаннарының исемнәре белән яктырган кара таштакты күрү белән бәгыре теленде. Ул аны “Сагыш Дивары” дип атады.

—Мәңгелек Ут,—диде Лотфрахман, җилдә өзелеп-өзелеп янган ялкынга ымлап.

—Учак көне-төне... даимән янып торады?

—Яндырсалар, яна. Сүндерсәләр, сүнә. Ул бит мәңгелек.

—Аны теге... без булган зират каршында да кабызсалар иде!..

—Ике Мәңгелек Ут асрарга шәһәр бюджетының хәленнән килми...

—Учакта янган газ Татарстан газы түгелмени?

—Татарстанныкы ла ул. Мәскәүдән рөхсәт кирәк. “Ил-Ана” мәйданында Мәңгелек Учак кабызырга безгә Компартия Үзәк Комитеты үзе рөхсәт иткән иде!..

Салкын жил искәндәй булды. Иркен ага иненә элгән кәчтүнен киде. Гитлеризмга каршы сугыш корбаннарының диварга чокып язылган багана-багана исемнәрен күргәч, башы әйләнеп китте.

—Егерме менле Чаллыдан барлыгы өч меңгә якын ир-егет һәлак...—Лотфрахманның тамагына да нидер тыгылды.—Шуларның алтмыш-житмеш проценты болгарлар...

Иркен ага алдында өч меңгә якын исем чокылып язылган ташкойма аша гына дистәләрчә мең туганнары ятып та, йөз ел кеше аягы басмаган, ташландык, сукмаксыз килеш чүплеккә әйләнгән зиратны, артында фантастик гыйфрит булып күтәрелгән 360 мең тонналы бетон тавын, көн-төн яна торган Мәңгелек Учакны бербөтен кайгы, бербөтен сагыш, бербөтен яшь тамчысы итеп төйнәргә тырышты, тик һич кенә дә төйни алмый газапланды...

—Мәчеткә барыйкчы, кардәш...—диде ул чак кына ишетелерлек итеп.—Жомга намазы житеп килә...

Таяклы кеше адымы белән барган хәлдә, алда ныклы бер сәгатьлек юл ятканга һәм әлегә вакыт булганга күрә, Лотфрахман, Иркен аганы култыклап, “Тәүбә” мәчетенә таба юнәлде.

Алар күз житүгә карамастан яшеллеген югалтмаган Хәтер аллеясы буйлап киттеләр. Матур иде, пөхтә иде, күнел тирәненә төшеп гүзәл иде бу хәтер ызаны!.. Мөһажир тирән уйларга чумды. Ул, гүя, зираттан ерагайган саен, зиратның хәтеренә якыная барды. Иркен ага совет режимының корбаннарын зират кылганда аларны оста итеп сортларга аера белү нечкәлекләренә төшенергә тырышты. Бередә гүя сагыш, гомумсагыш түгел, бары тик патетика гына сагыш була ала иде. Аның өчен тоталитаризм инде үзе дә к о р б а н ч ы л ы к корбаны булып сурәтләнгән төшенчә иде. Корбанчылык хакимиятенең сугыш корбаннары да, “тыныч мәгыйшәт”ендә вафат булганнары да бер үк корбаннар түгел мени?! Ул, гомумән алганда, бер үк зират исәпләнгән, гамәлдә бер үк зират булган, аның алгы, сугыш корбаннарының исемнәре ташка уелып язылган ягының шул кадәр купшы, әгәр шулай әйтергә яраса, гадәттән тыш тантаналы, бәһале, ә менә, күрәсез ки, шул ук зиратның “тыныч мәгыйшәт” корбаннары яткан арткы, ягъни, төп, иң зур ягының ни сәбәпле шул кадәр дә кадерсез чүплек вә бәһасез булуын миенә сыйдыра алмады. Моның өчен беркемне дә түгел, ә бары тик үзен генә гаепләде, ул моны әле тарихи ватанындагы тормышны, хәятне, мәгыйшәтне аңлап-белеп житкермәве, мондагы чынбарлыкны беркатлы кабул итүе белән аңлатырга тырышты.

Аңа рәнжеш килде. Юк, бу рәнжеш хакимияткә булган гади, беркатлы рәнжеш кенә түгел иде. Бу рәнжеш гүя кырыкмаса кырык, күп очракта гаделсез, басып алу сугышларында башларын салып, кайсы кайда жирләнгән, хәбәрсез югалган, атылган, ачтан туңып үлгән, бирегә, туган туфракларына исемнәре генә ташка уелып кайткан телсез әрвахларның рухлары шушында койма аша гына шул кадәр кадерсез, караусыз яткан ата-аналары, туганнарының жәсадләре өчен рәнжиләрдер кебек тоелды. Кинәт кенә аның мие яктырды, анда бербөтен Сагыш Мәйданы итеп тәртипкә китерелгән Гомумзират калыкты һәм аңа Тантаналы Капка ачылды. Иң алда—Мәңгелек Учак, аннан—кадерле исемнәр язылган гранит дивар, аннан—сагышлы Триумфаль Капка, аннан—гомуммилли зират—татарлар, урыслар, чуашлар, ябрәйләр... Мөселманнар, носарилар, яһүдиләр... Гомуммилли зираттан хәтер сукмагы Тантаналы Капка аша менә шушы Хәтер аллеясына чыга...

Ул, бер сүз эндәшмичә, артына борылып карады. Әбиләр чуагының кояшлы рәшәсендә аның күз алдына—төшендә түгел, гүя өнендә—салават күперенә асылынган яшь тамчысы сыман мәгърур Тантаналы Капка—

Триумф-Тантана Капкасы күтәрелгән иде.

Универсам кырыеннан алар үзәк базар мәйданына үттеләр. Иркен ага базардагы җөмлә инсаннарның кигән кием-салымнарын, килеш-килбәтләрен, үзләрен тотышларын җентекләп күзәтә, алар барлыкка китергән ымлык, ишарә, мәгънәле һәм мәгънәсез авазларны игътибарыннан үткәрә башлады. Иң беренче чиратта ул татар телендә сөйләшүчеләрнең хәтта базарда да аз, бөтенләй диярлек булмавын искәрде. Бу телнең ярлы, артык бертөрле, чуерташ шикелле чарланган, чит-ят төкректән тапланган булуы аптыратты. Әйе, туган тел үтә дә бозылган икән. Тарихи ватанда татарча сөйләшеп азапланганнарның күпчелеген бөтенләй төшенеп булмый.

Ул бер франк фәйләсуфының "Тел чисталыгы—җәмгыять чисталыгы ул", дигән сүзләрен искә төшерде. Аның биредә озаклап ятуы, бүген үз эше буенча мәхкәмәнең инде өченче—әүвәлдә урыс, аннан инглизи, аннан татарча барырга тиешлегенең сәбәбе дә шул телнең тәмам имгәтелеп, җәмгыятьнең телсез калуы касафатыннан килә иде бит инде. Телгә бу яссылыктан карау аның гаделлеген тагын да арттыра төшә иде. Ул татар, инглизи, кытай, уйгыр, үзбәк, кыргыз, казакъ һәм башка барлык төрки телләрне камил белә һәм җиңел аңлаша ала. Урысча белмәсә дә, кирилл имлясында укып, урамнардагы кайбер татарча язуларны аңлаштыра башлады башлавын. Араларында бик тә мәзәк тәрҗемәләр очраштыра. Иркен ага бу мәзәк тәрҗемәләрнең килеп чыгуы тел комиссиясенең "махсус" татарча белмәгән кешеләрдән торуына бәйледер, дип уйлый. Мәсәлән, ярымлатин-инглизидән килгән "универмаг"ны татарча гади генә итеп "Сәүдә йорты" дип булыр иде. Юк, ул мотлак "универмаг" булырга тиеш икән.

—Карагыз әле, кичә үлсәм, бүген күрмәс идем!—дип кычкырып җибәрде Лотфрахман һәм "Универсам" кибете диварыннан белдерүләр укый башлады .—"Ночной отдел"... "Буляк тонге. 24 сикать"... "Ирләр консультациясе". "Хэр тэрлэ ирлэргэ прэблэмысы"...

—"Ир-атларга җенси киңәшләр", йә булмаса, "Гыйшкый киңәшләр" дип әйтәселәре килгәндер, күрәсең,—диде Иркен ага.—Бу язмаларны кемнәр әзерли, укып тикшерә, язарга күрсәтмә бирә, кем буяу, пумала алып, кәгазь-картонын табып, акча, вакыт исраф итеп моны яза, элә, яшь буынны гарипли?

—Без. Безнең эш бу,—диде Лотфрахман кардәш салкын гына.—Мин үзем топонимия комиссиясе әгъзасы буламын. Без үзебездән түбәнгә дөрес язып төшерәбез төшерүен. Үтәлеш менә шундыйрак килеп чыга. Минемчә, Татарстанда вывескаларны ничек кенә булса да бозып яздыру буенча бер гакылга сыймаган антиштаб эшли. Кешеләр мондый гыйлләтне укымыйлар һәм берни эндәшмиләр... Нәрсә, миңа гына кирәкме ул?

Билхаккый, шәһәрдә мондый язмаларга Иркен агадан башка игътибар итүче дә юк кебек. Югыйсә, әйтүләренчә, татар телен гамәлгә кую буенча һәр оешмада да махсус комиссионнар эшли. Димәк, алар үзләре дә Лотфрахман әйткән "антиштаб". Ачның күзе икмәктә, тукның күзе хикмәттә, диләр. Иркен аганың, гөнаһлы кеше сыман, тәне тартышып куйды. Тәүбә, тәүбә! Күзе икмәктә булсын өчен, Чаллы ачмы? Ач түгел монда халык, тук, хәтта туклыктан туеп сикерә. Шулай булгач, тукның күзе хикмәттә булырга тиеш тә бит. Әмма нигә ул телсезлек "хикмәтләренә" күз йома? Ә менә урамнарда түтәрәм-түтәрәм икмәк ауный...

Шулай да татар җәмәгатьчелеге, Татарстан мөстәкыйльлек игълан иткәннән соң, урамнарда туган телендә сөйләшә, балаларын туган телдә укыта башлаган. Милли горурлык Татарстанның һәр баганасында үзен сиздерә. Иркен ага, бик ышанып та бетми: имештер ки, совет заманнарында урыслар татарча сөйләшкән һәр кешегә "Шо ты балякаешь!" дип кенә җикергәннәр. Булмас ла! Була диме! Әгәр чынында шулай булган булса,

сан ягыннан урыс белән бермә-бер тигез татар мондый хокуксызлыкка ничек түзә алды икән?! Соң татар да, урыс та бер Аллаһ бәндәсе бит. Татар туганда ук урыска бурычлы булып тумыйдыр бит? Нинди гөнаһлары өчен? Уйгырстанда, гадәттә, Русиягә, урыска ихтирам тәрбияләнә. Иркен ага да шул ихтирамда әвәләнде. Күз алдына да китерә алмый: әйтик, ул, Иркен, татар илбашы, чуашларны аракы эчереп, алдап-йолдап басып алды да, аларны туган телләрендә сөйләшүдән тыйды, ди. Бу бит мөмкин түгел эш. Соң үзенне илләренә керткән, җир-су, аш биргән, синең өчен иген иккән халыкка рәхмәт укырга кирәк!..

Алар "Меха"дип язылган кибет, отыш автоматлары янынннан килеп, сул кулдарак үскән каеннар астында күкрәгенә ниндидер язу аскан картны күреп алдылар. Башында чуар түбәтәй.

—Ни-нәрсә язылган?—Иркен-ага кардәшенең касыгына төртте.—Укып күрче.

—"...Ачлык игълан иттем... Властьләр газ кертмичә, йортыма кайтмыйм!...—дип укып китте Лотфрахман.—Үзем-не кис-тегез... Куштирәгемне дә кис-тер-мәм!.. "

Алар бакырдан йөз көпшәле фонтан ясап, мәйданны бизәп утырырга тиешле сусыз корылманың нигезенә утырган картка якынлаштылар. Өстенә соргылт, чабулары тәмәке утыннан тишкәләнеп беткән пинҗәк, чалбар, юк, тезләре һәм янбашлары кәҗә тиресеннән иләнгән йомшак күн белән көпләнгән галифе, аякларына иске булса да, ялтырап торган матур хром итекләр киеп алган бу карт үзеннән бераз читтәрәк очлары күккә олгашкан, төптән юан, күтәрелә-күтәрелә икегә аерылган куштирәк белән бердәм гармония тәшкил итә иде.

—Исәнмесез, болгар кардәшебез!—диде Лотфрахман киң елмаеп.

Сүзсез генә күрештеләр. Картның кул яссуы кышкы чана табаны кебек салкын иде.

—"Өрә белмәгән эт өенә кунак китерә", дигәндәй... Мен-нә фонтал читенә утырып садись.—Ул үзе утырган җәймәсен рәтли биреп, урын күрсәтте.—Вакыт күп, санап чыктым. Тыштан сиксән, эчтән кырык, уртада тагын алтмыш дүрт сиптергеч!.. Чаллыдагы йөз сиксән дүрт халык санынча. Ләкин аракы эчеп, бугазлары тыгылган көпшәләрнең берсе дә сиптерми... Халыклар дуслыгы, яппуна мать...

—Аллаһы Тәгалә сезгә түзем вә тазалык-саулык бирсен...—Иркен ага, аякларына ял бирергә теләп, сулга янтайды һәм гарип аягын суза төшеп, утырды.

—Чурт с ним, шулай булсын!..—Карт поф-поф китереп тәмәке кабызды.

—Сез... болгарчылар клубына да йөрештерәсез түгелме?—дип сораган булды үз тирәсенә мөритләрне күбрәк тупларга хыялланган Лотфрахман.

—Нинди суп-харча? Нинди хыллуп?—диде карт ишетеп җиткермичә.— Мин бит ашамыйм. Ач ятам.

—Болгарчылар клубыннан түгелме, дип сораган идем.

—Бернинди болгар да, волгарь дә түгел мин. Хәзер Волгасы да, Камасы калмады!.. Суын эчеп, электрын печеп булмый...

Бу кадәр пырдымсыз, кырыс кеше янына тукталганнарына үкенә башлады Иркен ага. Кыска буйлы, йодрык кадәр генә кечкәнтәй башлы, почык борынлы, гомер буе авыр эштә изелеп, беләкләре келәшчә сабы, бармаклары кармак кебек кәкрәйгән, бит-иякләрендәге, кулларындагы сумитләре генә түгел, барлык тән-шәрифләре дә сеңергә әйләнеп, нәселсез халәткә кергән, дөресен генә әйткәндә, бик тә төссез бу адәмзат аларга карата тәмам битараф иде.

Көтелмәгән сөаль биреп, Иркен ага яңа танышын сынап карамакчы

итеп:

—Сез әнә теге һәйкәл хакында ни-нәрсә уйлайсыз?—диде һәм монументка күрсәтте.—Ул безнең татарга кирәкме? Безгә хезмәт итәме?

—Анауы таш Алпамшамы?—диде карт җанлана төшеп.—Итә, ник итмәсен! Каршысындагы Чаллы листаранына юл күрсәтә...—Ул бер ялгызы онытылып көлде.—Халык аны "Толпа татар смотрит на Чаллы-бар" дип йөртә...

—Бу кардәшебез... Америкадан...—диде картны чишәргә теләгән Лотфрахман.—Безләрне күрергә кайткан...

—Америкадан? Безне күрергә?! Булмас!—Күкрәгенә асылган транспарантны кулы белән тотып, яшьләрчә сикереп торды. Яшәреп киткән күзләре очкынланды. Ул кармактай бармаклары белән Иркен аганың уң кулын эләктереп алды.—Татарча да беләсең, диген, ә?! Чынмы?! Исемең дә бармы?!

—Чын,—диде Иркен ага.—Исмем-атым Иркен болады.

—Ирке- е-ен? Һы? Ирке-е-е-ен, диген, ә? Шундый исем дә була диген, ә? Хикмәтле!.. Ә мин Зөфәретдин. Кәҗә Зөфәр... Тимер акчадагы патша башы кебек билгеле кеше мин. Кушаматларым да күп. "Кавалерист Зөфәр", "Ни гурыт—ни сала Зөфәр" дип тә йөртәләр...—Ул үзенең "келәшчәләре "белән Иркен аганың йомшак бармакларын балавыздай изде.—Америкада татарлар күп дип сөйлиләр иде сөйләвен, ә менә аннан кайткан чын татарны беренче тапкыр күрәм!.. Нигә кайтып күренмисез, нигә ябрәй Клинтоннарны төшереп, урынына безнең Шәймиевне Президент итеп куймыйсыз? Америка бәлки мөселманга каршы сугышмас иде?—Ул күзләренә саркып чыккан яшь тамчысын җилләп очырды, йөктән төшкән таш сыман, лып итеп урынына утырды һәм фонтан нигезенең эчке ягында торган капчыктан aклы-кызыллы калай өлгеләр белән бизәлгән саратский гармунын өстерәп чыгарды.—Моны болай гына калдыралар, диме?! Монымы?! Болай гынамы?!—Тынын чыгарган күрек кебек, үзе дә пошкырып куйды.—Сез нәрсә?! Ви ышту?!—Аннан авызындагы тәмәке төпчеген поф итеп төкерде.—Ам-ме-рикадан кайткан бит ул!.. Ыс-луш-шай, нарут!.. Эсписиәльни кәнсирт в супствинном исполненжи Зөфәретдина Жәүһәретдинова!!..

Иркен аганың Шәркый Төркестандагы туган авылы Кизләүдән чыгып киткәннән бирле... ничә ел...исәпләсәң... мең дә тугыз йөз дә алтмыш дүрттән алып... утыз өч ел була икән... күргәне юк иде саратски гармунны.. Авылдашлары күнче Салих абзыйның бар иде нәкъ шундый гармуны. Өздерепләр уйный иде!..

Ул арада булмый, әлегә юньле-рәтле танышып та өлгермәгән Кәҗә Зөфәр абзалары, монда, Татарстанның кап уртасы булган Чаллыда, Чаллының уртасы булган Үзәк Базар мәйданында, киң ябалдашлы, олпат кәүсәле каеннар, куштирәкләр астында, нәкъ Шәркый Төркестанның туган Кизләү авылы татары Салих абзыйлары кебек өздереп уйнап, уйнап кына түгел, "Баламишкин" көйләренә үзе үк җырлап та җибәрде...

Казан урамнары ташлык,  
Анда чәчмиләр ашлык.  
Төрлебез төрле якларга  
Таралдык та, адаштык...  
Их-ма!..

Гармунчы ачулы карашы белән тирә-ягын сөзеп алды. Тирәктәге чәүкә-каргалар Зөфәретдиннең гармуны кузгаткан моңнан кире зират ягына очтылар.

Калхуз кырларына чәчтем
Киндер дигән культура.
Коммунизм төзү—безнен
Төп бурыч булып тора,
Их-ма!....

Ыргыткан сыман итеп, гармунын нигезгә ташлады һәм—ышанасызмы, шушы яшендә—малайларча әче итеп сызгырып җибәрде дә, күн янбашларын кояшта ялтырата-ялтырата урынында тыпырдап та алды. Анын гармун күрегедәй сырланып яктырган хром итекләре үзенә бик тә килешә иде. Сталин заманыннан калган хром итекләр чынлап та матур—аларда Сталиннын җаннары гына юк иде.

—Күрдегезме? Шушы җырны ишетеп, яныбызга берәрсе килдеме? Килмәде. Килмәячәк тә. Монда... кеше хәлен белерлек кеше калмады, яппуна мать...—Карт базарны колачлагандай итеп хәрәкәт ясады.—Бездә кешегә төкерсәләр генә түгел, кешене базга түнкәрсәләр дә килмиләр!.. Хокукын өчен көрәшкәч... бездә кешене тиле, диләр. Монда мон да... мән дә... мин дә кирәкмим!.. Чурту-матыр, дөбер-шатыр!.. Монда сатылганнар сата!..—Ул Иркен-аганын күзләренә текәлде.—Сөйләш-шер кеш-ше калмады, быррат!.. Кешесе күп, күбесе—чүп!.. Шуна гол-лодов-кага чыктым.. Яр-рый әле, Куштирәгем исән!.. Ахырзаман микән әллә бу? Сездә бу ахырзаман башланмадымы? Әллә... син алып килденме?.. Ярый әле, Америкадан син килден, син-на сөйлим, ичмасам!... Кайткач, яз-зарсын, муж-жыт!..

Ул очкыннар очыра-очыра тагын да тәмәкесен кабызды.

—Нишләп йөрисез? Эшегез юкмы? Сөйләшергә кеше эзлисезме?—Зөфәретдин абзыйсы мөһаҗиргә яшьле яшкельт күзләре белән карады.—Мәгънәле кеше күренәсен син!.. Әйдәгез, сөйләшик!.. Сөйләшү бездә дифисит, бездә аны үлчәүгә салалар!..

Иркен ага тан калды. Баягы карт, төссез, монсыз, ямьсез, кәкрәеп беткән Кәҗә Зөфәрне танырлык түгел иде. Ул мәнгелек зәм-зәм шифасын эчкән кебек яшәреп һәм, яшьлеккә манчылып, сафлангандай күренде. Ничә көннәр инсан арасында кайнап та, үзе әйтмешли, сөйләшергә инсан тапмаган кардәше, кулы белән кош тоткандай, чиксез шат һәм илһамлы иде...

—Язмасан, Американа кайткач, менә шундый гуардин карт очраттым, дип Президент Клинтонга сөйләрсен, яме. Шулай да, ошый ул мина. Безнен Шәймиев кебек, матур малай ул. Моникаларны ярата, кәнишне. Не дурак. Мина житмеш ике... Фронтта үлгән саналам мин.

—Ничек?—диде Иркен ага аптырап.

Ул түшендәге катыргы язуын кисәк кенә читкә этәрде һәм анын астыннан кояшта бер кочак орден-медаль елкылдады.

Зөфәретдин абзыйнын күкрәге үзеннән күпкә кинрәк иде.

—Минем күкрәктә тыштан гына чурт-чураман язу—оград, астында анын шыр наград!.. Эчендә анын Керимель. Ялкын!.. Әнә тегендәге “Мәнгелек Ут” каршындагы мәрмәр ташта... үз исеме язылган Зөфәр мин! Мәнге тере Зөфәретдин!..

Ул күнеле тулудан тукталып калган кебек булды.

Колакларда базар гаме генә гүли иде.

—Сезнен алдыгызда—Генерал Доваторнын кавалерия корпусы кавалеристы Җәүһәретдинов Зөфәретдин Фәлих угылы булыр!..—Зөфәретдин-кардәш Иркен агалар килгән “Сагыш дивары” ягына ишарәләде.—Их-х, бар иде заманнар...—Ул кулындагы чыбыгы белән ярсып, хром итек кунычларына сугып куйды.—Егерме бишенче елгы чаллылардан сонгы татар мин... Сонгы... Үлемне котеп, сигез ай госпитальдә яттым да...

Шул арада атам-анама улыгыз һәлак булды, дигән хәбәр дә салганнар... Ваянкамат, яппуна-мать, пахарункыны һаман төзәтмәгән булган икән, үлгәннәр исәбенә язганнар да куйганнар... Мин исән бит, төзәтегез, дип барып әйткән идем, ярар инде, гранитның хакы кыйммәт, диләр, синең өчен генә бозмыйбыз, алмашка үзең мәрмәр алып килсән, төзәтербез, анда синең өчен безплатны ут яна, диләр... Ярар тек ярар, үзе белеп янар... Янар, дигәннән. Анда минем исәпкә дә газ яна. Күргәнсездер. Бушка яна!.. Ә менә йортыма һаман газ юк. Кертмиләр!.. Чаллы уртасында!.. Каффалер орден Слабы[7] бит мин!.. Орден Слабы Чаллыда түгел, илдә сирәк кешедә. Нәкъ газ кебек. Газ безнең Дикий пачулкада гына түгел, Орловка, элепатыр, шакал-трис пачулкаларында да газ юк...

Ул авыр итеп тәмәкесен суырды да, авызыннан төтен көлтәсен чыгарды.

"Мәетләренең каберташларына номер куймаган ил...—дип уйлап алды Иркен ага,—тере геройларын да белми булып чыга түгелме?!"

—Көн тудымы, инигрәнәсительләргә хак артты, диләр. Бәй, бездә инигрәнәсительләр үзебезнеке бит? Нифтесе, газы, электры үзебезнеке, яппуна-мать, әмма хаклары күтәрелә, төшми, ә? Нишләп ул нәсительсез Калуга өчен дә, нәсительле Татарстан өчен дә бертигез булырга тиеш? Нишләп инигрәнәситель дигәнен без җитештерәбез, ә аларга хакларны Чубайс күтәрә? Утында көн күрәбез, чурту-матыр, дөбер-шатыр. Аптыраганнан шушында чыгып утырдым. Бәлки влачлар игътибар итәр, дигәнием...

—Иттеләрме соң?—диде Лотфрахман хәйләкәр елмаеп.

—Итте ди сина, бар!.. Сигез көн утырам, ни влачлар, ни ваянкамат килми, ни арестауайт итмиләр, чурту матыр, дөбер-шатыр... Пчамуптамушты мин франтауик, кавалер орден Слабы, туда-сюда... Милитсия килә дә китә, килә дә китә... Саклыйлар, малай!..

—Сезнең нәсел шәҗәрәгез сакланмаганмы?—дип сорады Иркен ага сак кына.

—Нинди шәҗәрә? Агачларны әйтәсеңме?—Дымланган күзләрен сөртеп, агачларга ымлады.—Чынлап нәселле алар. Ерак бабам Җәүһәретдин утырткан. Без атаклы сәүдәгәр Хәлфиннарның корытып бетелмәгән тамыры, сезгә әйтим... Хәлфә ул хәлифә дигән сүздән икән. Баш булу, димәк. Безнең нәсел гарәпчә укып, мең ел хәлфә булып харап булды. Ә мин менә нибары биш класс латин белән Европаны аша кичтем!..—Ул буылып калгандай тынып торды.—Юк, без элек кенә—Җәүһәретдиновлар идек, хәзер—Чүбетдиновлар!.. Миңа житмеш ике, бу агачлар миннән йөз яшькә өлкән... Сугыштан исән-сау кайткач, атам өйләндерде һәм васыяте буенча мине, төпчек улын, туган нигездә калдырды. Мин сугышта... күп тапкырлар дошман камалышында булып, туган нигеземә хыянәт итмәдем... Мине менә шушы Тирәгем-Йөрәгем саклады!... Үтермәде, дүрт ярама дүрт ярангөл булып сеңеште... Әмма мин, генерал Доваторның дошманнан җиңелмәгән кавалеристы Зөфәретдин, илгә кайткач, үзебезнең янаралллардан җиңелдем, яппуна мать!.. Дошманны җиңеп, илгә кайткач, их!.. үзебезнекеләр җиңде, малайгынам!.. Үзебезнеке дигәннәр дошман булган икән. Алар камап алгач, атам-анам гомер биргән нигеземә хыянәт иттем...—Ул авыр итеп тын алды һәм өнсез генә елаган кебек тоелды.—Әнә, тегендәрәк, урам аша, утрамбай рильселәре янында, җир асты юлының авызын күрәсезме? Ул Җәүһәретдиновларның туган нигезләренең урыны... Хәзер ул урын юк! Хәзер Иске Чаллы да юк... Их, белсәгез иде, Иске Чаллының матурлыгын!.. Яңа Чаллы төзибез дип, Иске Чаллыны җимерергә, су астына җибәрергә кирәк

[7] СССРның "Дан" ордены. (Орден "Славы") – I,II,III дәрәҗәле. Солдат һәм сержантлар составы өчен 1943 елның 8 ноябрендә булдырыла.

идеме?!—Анын конгырт күзләре хәтәр ут булып кабынды.—Әнә, зур сәякне йота алмыйча, тамаклары тыгылдымы, тыгылды!... Яна Чаллыларында кая карама, башланган да ташланган буш төзелеш мәйданнары сыкрап ятамы—ята! Андагы тиле кычыткан һәм сары әремдә Иске Чаллынын җәүһәр жаны сыкрап елый... Иске Чаллының мең еллык жаны су астында!.. Мең еллык кадимге зираты, Аттила-бабаларнын курганнары белән бергә су астында калды!..—"Кадимге зират", "Аттила-баба" кебек гыйбарәләр белән генә чирттерә башлаган Зөфәретдин кардәш тыштан гына белемсез, болай бетерешкән күренә бугай. Иркен ага дулкынланды. Менә сина Чүбетдинов!..—Нәрсә, жимереп, су астына жибәрмәсәләр, жир житми идеме?! Ата-бабаларнын сөякләре, кабер ташлары... Кызылэрмисләр, Кызылгвардисләр урамнары... Синтрәльни, Прафсаюзы, Фыррунзе, Карлы Маркыс, Фырридрих Ингелес, Виттериннар, Пуләвәй урамнары барысы да су астында калды. Сүтелеп бетәр-бетмәс килеш ике мәктәп, кечкенә чиркәү, туку фабрикасы, дум пианир биналары... Лилин паркы һәйкәлене белән бергә су астында калды. Күз алдыгызга китерәсезме: су астында, бүген булса, бәпкәләре-ниләре белән тырпаеп, йортлар, урамнар утыра? Менә бу яна электростанция буасы кипсен-корысын гына, аннан, әйтте диярсез, пеләш башын калкытып, кояш кебек Лилин бабай янадан калкып чыгачак!.. 1972 елнын үктәбер бәйрәме алдыннан ниндидер килмешәкләр безнең урамны йорттан йортка язып йөределәр. Фәрман шундый димәк: моннан утрамбай-терәлепуз юллары үтәчәк, йортларыгызны теләсә кайда алып китегез. Телисез икән, яна күпкатлы йорттан фатыйр, телисез икән, жир Дикий пачулкада жир бирәбез—янадан төзегез, имеш... Күпләр тавышсыз гына шулай иттеләр һәм киттеләр дә.

Кеше арасында зарын сөйләргә кешесен тапмаган Зөфәретдин абзый бар зарын түкте. Алар аны туктатмадылар.

—Авылчадан шәһәрчә яшәүгә күчәбез дип, кәжәләренә кадәр суеп ашап, биек йортларга күчтеләр дә, аракыдан сукбайга калып, буш шешә кебек, теге дөньяга тәгәрәделәр... Сыеры—пычак астына, үзе пычрак астына!.. Төннәрен исәпләп ятам: безнең урамнан бер мин, райпо тимерчесе генә исән, малайлар!.. Үз йортыбызны төзеп, үз йортыбызда яшәп кенә исән калдык без! Әби дә, мин дә!.. Песи Әкрәм—эчеп, Үтүк Салихжан—эчеп, Пишке Хәбир—эчеп, Песнәк Гыйльмияр—асылынып, Итек Гомәр машинага тапталып, Кумерче Галим—акылдан язып, илле-алтмышларына да житми китеп бардылар. Безнең урамнан гына кырык жиде ир-егетне эзли минем шушы Тирәгем-Йөрәгем... Типсә тимер өзәрлекләр иде... Урамнан без икәү йорт-жирләребезне ташламадык, димәк. Пима басучы Балавыз Хәбиржан абзый һәм мин, тимерче Кәжә Зөфәр! Күз алдыгызга китерегез: Беляев жибәргән бульдозерлары белән гүләп, утрамбай-терәлепуз юллары сала-сала, солдатлар безнең ихаталарга ук килеп туктаган. Мангайга мангай. Бер кисәтәләр, пырырып ясап, икенче тапкыр кисәтәләр. Өченчегә пырырып ясап, ниһаять, бульдозерлар безнең өйләр өстенә дип кузгала... Безнең урамнан бульдозерга каршы беренче күтәрелгән Садретдин абзый йөрәге ярылып үлде, мәрхүмкәй... Икенче бульдозерлары минем өскә килә бит, яппуна-мать... Кулымда гранат кына юк, булсамы? Булса, селәгәенә сылый идем!.. Мин, Смәлински яланнарында танкыларны спичке урынына вжик кына яндырган солдат, монда, туган нигеземдә, бер йолкынып бетмәгән әтәч шикелле бульдозерга каршы тора алмадым, чөнки ул... үзебезнең йолкыш иде, яппуна мать!... Калганын хәтерләмим. Бульнискә алып киткәннәр... Өч айдан чыксам, утрамбайлар тыррым-тыррым йөреп ята, минем өемне сүтеп, Дикий Пачулкага китереп аударганнар!...Шундагы биш сутый жирдә... мал асрап кына исән калдым мин... Шулай итеп, "ни гурыт-ни сала Зөфәр" гә әйләндем. Ну и ышту? Песи Әкрәм—эчеп, Үтүк Сәлихжан—эчеп, Пишке

Хәбир—эчеп, Песнәк Гыйльмияр—асылынып... Хатыннары—эчкече, балалары—наркоманнар!.. Ә без—исән!.. Их-ма!..

Ул яшьләрчә дәрт белән урыныннан сикереп торды, йөгереп барып, тирәкләрен кочаклады, кәүсәләрнең үзе кебек кытыршы кайрысын капшап, иркәләде дә, йөзе белән Иркен агаларга таба борылып басты.

—Хәзер миннән шушы яңа татар дигәннәре... шушы Тирәгем-Йөрәгемне дә тартып алмакчы итәләр... Ерак бабам Җәүһәретдин утырткан, ике йөз ел буе бакчабыз башында шаулап утырган Йөрәгем-Тирәгемне төбе-тамыры белән төпләп ташлап, аның урынында фәхишәләр притоны... казино салдырмакчы итәләр! Не быв-вать этому!.. Монда, шушы тирәкләр астында, без әнисе белән түмәр-түмәр алты кыз үстердек... Шушы бәдбәхет КамАЗ вакытыннан алда йотты аларның барысын да!.. Икесе генә исән—берсе кияве белән Сбердлауга, икенчесе, күзем күрмәсен дип, Новосибирскига чыгып ычкынды... Тугызынчы көн утырам инде мин монда!... Кирәк икән, ун ел утырачакмын, чурту матыр!... Кирәк икән шушында үләчәкмен. Әбиегез газ күрмичә китеп барды. Мине башта йортсыз-җирсез, аннан әбисез иттеләр дә, хәзер инде Тирәксез-Йөрәксез дә итмәкче булалар!..

Иркен аганың бу инсанга ничек кенә булса да ярдәм итәсе килде. Тик чараларын таба алмыйча газапланды. Зөфәретдин кардәше белән әңгәмәне сузасы килде.

—Атилла баба, диденез... Чаллыда һунн-бабаларымызның эзләре бар мени?

—Менә, сөйләшә торгач, эшлиябез майланды—эшләребез җайланды!.. Бар иде, нишләп булмасын! Сез мине надан дип уйламагыз... Мин бу хакта күп укыдым. Атилла—Чаллыдан киткән Кытай татары икән бит ул. Исеме дә “Ат иле”ннән алынган. Кая безнең галимнәрнең шул хакта бер хезмәте?! Иске Чаллының милитсия бинасыннан ерак түгел биек тау-корган бар иде... Аны Атилла баба корганы, дип сөйлиләр иде. Барысы да су астында калды... Без Рим, Византи патшалыкларын тез чүктергән төркиләр!..

Шушы фантазиясе өчен генә дә Зөфәретдин якын иде аңа. Кинәт кенә башына, уйлавынча, дөрес фикер килде.

—Сез барасыздыр бит?—диде ул, сәгатенә карап.

—Кая?

—Җомга намазына.

—Намазга?—дип көлде ул, тешләрен ыржайтып.—Мин Аллага ышанмыйм бит... Мин афтаматически... Лилин-Ысталин партиясына гына ышанам.

—Сез...?!—Кардәшенең дингә тел тидергәне өчен унайсыз булып китте.—Тәүбә, диегез!..

—Мин—динсез. Әмма дә имансыз түгел. Халыкта “Дингә ышанган—малсыз калган”, дигән мәкаль бар. Аны мин чыгармаган. Мәчеткә ике аягымның берсен атламыйм! Сабый чактан намазга басмагач, кеше алдар хәлем юк. Дүртенче сыйныфта укыганда булса кирәк, бездән бер шигырь ятлаткан иделәр. Шуны мәңге онытасым юк:

Башларын ваткан татарларның
Тик шул бер Алла!
Бетәрләр микән татарлар, Алла, ди-ди?
Әллә белерләр микән хаталарын бер алда?

Бу Сәгыйть Рәми—татарның олуг шагыйре иде.

Картның җан заты белән тән заты аерым яши икән.

—Кызганыч... Кызганыч...—диде нәрсә әйтергә дә белмәгән Иркен ага.—Сез ялгышасыздыр... Сезнең тәнегез җаныгызны эзлидер, гуй. Болай... яшьләрне ничек тәрбияләрбез?

—Нигә тәрбияләргә?—диде Зөфәретдин тагын тәмәке кабызып.—Аларны ике көч тәрбияли: берсе—физиклар, икенчесе—шизиклар...

Иркен ага ни әйтергә дә белмәде.

—Чаллыда Ленинга һәйкәл бармы?—диде ул аптырап.

—Булмыймы! Элек Лилиннарыбыз өчәү иде... Бу кадәр Лилин Ысысысырның бер шәһәрендә булмагандыр. Ничек дисәң дә, татарга афтаномия биргән якташ бит...—Нәрсәдер эзләгәндәй, Зөфәретдин очлы күзләре белән тирә-ягын сөзеп чыкты.—Берсе анауы Синтрәльни урамындагы иске райком бинасы, икенчесе—ваянкамат каршындае. Эльсин-тиле элеп атты... Өченчесе, Элепатыр тавындагысы гына калды... Кәҗә бәрәне хәтле генә булса да, барыбер Лилин!.. Басып тора, малай, коммунистлар аны күрү белән—по швам!.. Райком каршындагы Лилинны үзебез ашап бетердек...—Ул ыржаеп көлде.

—Ничек... ашап бетердегез?

—Сугыштан соңгы елларда бездә үләт чире булды. Ачлыкның да ачлыгы. Ашамаган нәрсә калмады...

—Атсыз калганга инде ул...—диде чак ишетелерлек итеп Иркен-ага.

—Кара әле, минем кебек хикмәтле син, ә? Әнә шул атсыз калган шантрапа митингыга чыккан саен ашап бетте Лилиныбызны, чурту матыр-дөбер шатыр.. ...Саруы кайнаган һәр кеше райком каршына килеп, Лилинны кимереп, саруын басар иде... Андагы Лилин чиста акбур... чиста кәльсикстән ясалганые... Көлмә, энем!—диде ул Лотфрахманга.—Башыңа төшсә, көлмисең—елыйсың!.. Безнең кебек хокуксыз Чаллыга... бер Лилин кирәк инде, югыйсә... Үзебезнең Казан малае, афтаномия бирде... Саклар-яклар кешебез калмады хәзер!..

—Шул Ленин һәйкәле урынына, атка атландырып, татарны милләт иткән, аңа ерак Гарәбстаннан дин алып килгән Ибне Фадлан сәхибкә һәйкәл куйсаңызчы!

—Фадлан. Фадланга атлан. Ә менә Лилин бабайга атлы һәйкәл... һм... кирәк булыр иде. Лилин брнавикка менде, атка менмәде. Бу аның стратически хатасы. Хикмәтле бу!.. Шунда ук Чыңгыз хан, Атилла бабайларга атлы һәйкәл куябыз, әйеме? Юк, туктале, син бик җинел генә!..—Зөфәретдин абзый уйланып калды.—Солтангалиев кебек атлы татарлар бит Лилиннарга влачны алганчы гына кирәк булды... Влачны алгач, алар, Солтангалиевләрдән атларын тартып алып, суеп ашадылар да... үзләрен сөргенгә сөреп, атып бетереп, балаларын трахтырга утырттылар...—Карт бераз гына тын алгандай итте.—КамАЗ килгәнче атлар күп иде бездә. Атларның соңгысын суеп ашап, авылны дивьятиятажкага куып менгезделәр. Атсыз калдык калуын, ә менә машиналы булып булмады... Хәзер минем үземнең дә ат күрмәгәнемә егерме ел буладыр...

—Шәһәргә ат нәрсәгә ул?—дип, күзләрен әйләндерде Лотфрахман.—Яңа Чаллы—Татарстанда Ленинга һәйкәл куелмаган бердәнбер яшь шәһәр. Беляев шуны куйдыртмавы белән дә тарихи шәхес. Чөнки партиянең бетәчәген алдан күрде...

—Пр-ричум Бел-ляев?! Лилин янында Беляев кем ул?!—диде карашы белән җир җимереп Зөфәр-кардәш.—Партия үзе җимерелеп төште!.. Җимерелмәсә, Беляев һәйкәлне әбәзәтелне куя иде... Куйдырта идек!.. Ул менә Җәлилгә куйды, тик кисек башлысын. Үлгәч, үзенә дә кисек баш элделәр. Кешедән көлсәң, шулай була ул. Тәк ышту,бездә, Чаллыда, кисек башлы ике һәйкәл—берсе Җәлил, икенчесе Беляев үзе...

Алар хушлаштылар. Зөфәретдин-кардәш исә кискен хәрәкәт ясап, сусыз фонтан нигезендә уйнаклап яткан елтыр гармунын келәшчә куллары белән эләктереп алды һәм утырган җиреннән җырлап җибәрде:

Кызыл фыллак күрсәтәбез
Чит ил калаларына.
Чит ил калаларындагы
Эшче балаларына...
Башларымны игән чакта
Белмәден кадеремне.
Килерсегез шул көннәргә—
Кочарсыз каберемне,
Их-ма!..

Юк, ул исерек тә, тиле такмакчы да түгел иде. Иркен ага уйлавынча, үзенә бернинди теләктәшлек тапмаган Зөфәретдин абзый тирә-як дөньяга мөнәсәбәтен бары тик т а к м а к аша гына белгертү халәтенә күчкән бер нечкә һәм фаҗигале шәхес иде...

Иркен ага артына борылды. Зөфәретдин, уйнавыннан туктап, гармуны өстенә гүя киселгән баш сыман сыгылып төшкән. Баядан бирле сүзсез барган Лотфрахман аны сулга тартты. Алар сары яфраклар түшәлгән сукмак буйлап бакча эченә керделәр. Карр-карр килеп, иске ояларыннан каргалар күтәрелде. Иркен ага игътибар итте: агачлар артык биек, нәзек кәүсәле, дөрес каралмау аркасында булса кирәк, иртә картайганнар иде.

III

Иртә белән ул Сент-Льюиска, Мәдинә-иркәгенә мобиль телефоннан шылтыратырга уйлаган иде, тегесенең корылмасы беткән булып чыкты. Көтәсе килмәде.

Нумерындагы телефоннан Сент-Льюиска, дөресрәге, Сент-Льюис янындагы утары—Kizlaurә шылтыратып азапланды. Конгресс тәмамланган көннән алып сөйләшкәне юк. Форсаты чыкмады. Юк, мондагы телефон рәтсез икән. Аптырагач, Торонтога Гөлмәрфуга кызына чыгып карады. Сигнал бармый иде. Төркиягә, Чыңгыз улын чакырып карады. Монысы да булмады. Кунакханә вәкиләсе телефонны төзек, халык-ара бәйләнешкә яраклы дип расласа да, аның яраксыз булуы көн кебек ачык иде.

Кизү аңа халык-ара телефонга барырга киңәш итте. Почтамт якында гына, имеш. Бу киңәш аны канатландырып җибәрде.

Көн кояшсыз, вәләкин кичәгедән дә жылырак икән. Көннәрнең болай жылынып китүен карт кичәге сукыр тавык янгырына һәм салават күперенә китереп ялгады. Иртәнге саф һаваны ул күкрәгеп тутырып сулады. Кунакханә алдындагы агачлардан коелган сары яфраклар өстеннән йомшак кына шуышкандай итеп атлаштырып, сулга борылды да, аска таба төшеп китте.

Чынлап та, бик яшел, чынлап та, бик пөхтә, чынлап та, бик матур шәһәр икән бу яңа Чаллы! Әгәр барлык шәһәр шулай булса, бу бит—гөлбакча! Вакыт-вакыт ана ихластан гөлләр бакчасыннан баргандай тоелды. Газеталар, матбугат чаралары шаулавынча, икътисади авырлыклар кичергән Рәсәй, атап әйткәндә, Татарстан, КамАЗ-ы янган Чаллы, бу кадәр чәчкәләр үстерү өчен, аның фикеренчә, акча таба алмаска тиеш иде. Бу кадәр чәчкә үстерү өчен бу шәһәр ярымач яшәргә, бик ярлы киенергә тиеш иде. Әмма аңа каршы очраган инсаннар һич кенә дә ач күренми, кигән киемнәре дә Европа стандартыннан күпкә фырт һәм фасонлы иде... Дөньяның иң бай иле Әмрикә, мәсәлән, Сент-Льюис, Висконсин штаты мәркәзе Медисон урамнарында да бу кадәр чәчкә күрмәссең. Ул Чаллыда чәчкәләрнең күплеген татар өммәтенең чәчкә-гөлләр үстерүгә мөкиббән китүе белән аңлатырга тырышты. Нигә, оныттыңмыни, тәкъсир, аларның Шәркый

Төркестандагы Кизләүләрендә дә, һәр тәрәзәдән тышка ишелеп, кына гөлләр чәчкә атып утырыр, һәр ихата мосафирны кочак-кочак гөлләр белән каршылар, кызлар шул кына гөлләренең яфраклары белән тырнакларын буяр иде бит...

Егерме-утыз ел эчендә адәмзатның шундый шәһәрләр сала, шундый агачлар, шундый гөлләр үстерә алу могҗизасына таң калды ул. Яшьлеге көрәшләрдә һәм катырларда үтеп, аның үзенә яна, яшь шәһәрләр күтәрергә насыйп итмәде. Бөек тойгыдыр ул яңа шәһәр торгызу!.. Гүяки бу шәһәр монда Борынгы Мисыр, борынгы юнан империяләре белән бергә яралган да, мең еллар буе берни булмагандай яшәп килгән...

Шундый уйлар белән ул урамнар мөешендә утырган почтамтны килеп тапты. Телефон-телеграф бинаның уң канатында икән. Автоматик телефоннарны хезмәтләндерүче, рәхмәт төшкере, татар кызы булып чыкты. Сылуы аны, ышанасызмы, бик тиз генә Әмрикәдәге Kizlaue белән тоташтырды да куйды. Теге очта хезмәтчеләре Барбараның нәзек тавышы яңгырады.

—Hello, who am I speking to?

—Oh, Is that, you, Barbara? It, mr Irken. Could I spek to Mis. Medina, please?

—Yes, of course. Just a minute[8]...

Барбара Мәдиналәрдә менә уникенче ел инде хезмәтче булып эшли. Аның җәмәгате Джакоб исә бик уңган умартачы. Алар—кара тәнлеләр. Джакобны хуҗалар татарча Ягъкуб дип йөртәләр. Иркен-аганың кортлары әүвәлдә, корым кебек кара ниггерны кабул итмәгәндәй, тузындылар, чагып газапладылар. Иркен-ага, аптырагач, “Коръән-Кәрим”нен “Бал кортлары” сурәсеннән берничә аять укыды. Чыгышы белән Сомали христианнарыннан булган Ягъкуб мөселманга да күчкәч, сөбханалла, бал кортлары тәмам тынычланды. Хәзер алар—ак кораб кебек ап-ак Иркен ага һәм антрацит күмере кебек кап-кара Ягъкуб, гүяки җитәкләшкән ак вә кара континент—умарталыкта битлек кимичә дә йөриләр.

Иркен аганың йөрәге дарс-дарс типте. Ул Мәдинәсенең аның өчен дөньяның икенче ярымшары икәнлеген күптән аңлады. Мәдинәсенең күзе җир шарының Иркен ага күрә алмаган икенче ярымшарын күрә, икенче ярымшары аһәңнәрен ишетә, икенче ярмшарындагы гөлләрен үстерә. Алай гынамы? Мәдинәсе, тагын да аныграк итеп әйткәндә, чын ярату белән яраткан һәр хатын-кыз ире өчен ике ярымшарны да берьюлы күрә һәм бербөтен итеп тәрбияли. Нишләп озак? Ятып чирләмидер бит?! Чирләсә, Барбара әйткән булыр иде.

—Әйе, әлбәттә. Бераз гына көтегез...—диде бит ул.

Әнә, килә... Аякларында тапталып беткән чүәкләре паркетта чап-чоп итәде...Элемтәнең теге очында астма—тын кысу хастасыннан җәфаланган Мәдинәсенең сөекле тавышы яңгырады.

—О, бу сезме, Барбара? Бу мин, мистер Иркен. Мин мисс Мәдинә белән сөйләшә аламмы?

—Әйе, була. Бераз көтегез.

—Исән-амандыр кү, картыкаем... Хәлләрең кандай?

—Исән-аман гына...

Иркен ага шатлыгыннан елаганын сиздермәскә тырышып, хатынын тынычландырырга, куандырырга ашыкты...

—Минем биредә барысы да яхшы!.. Корылтай тәмамыннан соңра безләрне Питрәч дигән вилаяткә, аннан Бөгелмә дигән вилаяткә кунакка алып киттеләр. Тәрбия, кадер-хөрмәт бихисаптыр. Ашамаган аш, мәңге эчмәгән кымыз да калмады... Әмрикәдән Солтан Рәфыйк, Төркиядән

[8] (Инглиз.)—Алло, кем белән сөйләшәм мин?

Вәзир Нури кардәшләрем белән бергә булдык. Синнән соңра Чыңгыз белән Гөлмәрфугага да куңгыратам әле... Мин сөйләем дә, сөйләем, үз хәлдәрең кандай? Умарталар гамәлдәдер?

—Гамәлдә, Аллага шөкер!.. Күптән түгел безләрдә "Сарагосса" дигел өермә үтте кү, ике эвкалиптыбыз җыгылды, әмма умарталарга зыяны төшмәде... Ягъкуб илә Бәрбәрә күптән түгел генә кортларны куалап[9], бал суырттылар.—Мәдинәсе, хатын-кызларга хас булганча, шундук дөнья мәшәкатьләренә кереп батты.—Сент-Льюистан безләр берлә контракт төзегән теге балчы-сәүдәгәр килеп, ике йүз кила бал алып китте... Әй, кем, Иркен, балаларга куңгыратып маташма... Хәзер алар үзләре минга куңгыратырга тиешләр... Мин барчасын үзем төшендерермен...

Кортларының дөнья көтеп, "йон тетеп" ятулары турында ишеткәч, аның күңеле яңадан нечкәрде. Аның фикеренчә, бал кортлары—Ходай Тәгалә бөҗәкләре. Ул үзе бары тик ике нәрсәне генә илаһилаштыра һәм алар турында авыр сүз әйтә алмый—ул да булса хатын-кыз һәм бал кортлары.

—Ак кортлар нихәлдә?—дип сорамыйча булдыра алмады Иркен ага. "Ак кортлар" моннан ике ел элек кенә Чилидән кайтартылган Кордильер кортлары иде. Эре нәселле, агач кәүсәсендә оялый торган чолык кортлары.

—Ике тапкыр аердылар инде...—диде Мәдинә.—Ягъкуб күчләрне читкә җибәрмәде. Теге бакча читендәге агач умарталарга кундырды...

—Кышкылыкка сәлсәбилләре бардыр кү?

—Ба-а-а -ар, иншаллаһ.

—Галимулла берлә Шәркыйнур ни хәлдәләр?

—Һәйбәт. Әйтергә онытып торамын, Галимуллалар гаиләсендә артым!.. Уллары бар. Сәгыйтьҗан куштылар...

—Котлауларымны тапшыра күр!.. Сагынышымды тапшыра күр!.. Үзеннең хәлең кандай?

—Шул, кадимгечә...—диде тыны кысыла барган ягымлы тавыш элемтәнең теге очында.—Барамын да утыраман, барамын да утыраман... Хәерченең бөртек чәен җил очыра, дигәндәй, һавалар безләрдә дымланып, авыраеп торадыр кү...

Иркен ага Мәдинәсе өчен дә тын ала башлады. Гүя, ул аның йөрәге кардиограмасына карап сөйли иде. Мәдинәсенең тыны кысса, аныкы да кыса, җибәрсә, аныкы да җибәрә. Алар, чынлап та бер Җир шарының ике ярымшарлары иде. Иркен ага Мәдинәгә өйләнеп бәхетле булды. Ул шушы Җир шарында хатын-кыз тәрбиясенең Раббыдан төшкән нинди зур кадрия, нинди зур савап икәнлеген кичергән сирәк ир-атларның берседер. Мәдинәсе аның кайчан төчкерәчәген дә ике көн алдан чамалыйдыр. Әмма, бөек Толстой хәзрәтләре әйтмешли, иң бәхетле күренгән гаилә дә үзенчә бәхетсез.

Мондый бәхетсезлек Иркен агада да бар. Яшьлеге сәяси-хәрби көрәшләрдә, ир-егет чагы төрмә-сөргеннәрдә үткән Иркен ага бу җир йөзеннән туйганчы бала сөймичә китеп барачак. Ул яшь чагында биш, ун, хәтта унбиш бала үстерергә хыяллана иде. Булмады. Язмыш аны гаиләсеннән озакка аерды. Соңыннан Мәдинәсе аның өч баладан артык китермәде. Аларның берсе, Гөлфаныйлары, Һиндекышның Карлыгаш сыртындагы зәңгәр бозбиләвендә атасының килеп алуын һәм Казанга алып кайтуын көтеп ята... Иркененең бала яратуын яхшы белгән Мәдинә аңа икенче җәмәгатькә өйләнергә дә рөхсәт итте, мөселман хатыны буларак, моңа һич кенә дә каршы булмаячагына, киресенчә, нәсел хакына бары тик юл ачачагына ышандырды. Юк, бармады бу адымга Иркен ага. Бармады... Әйе, нәсел ишәйтү кебек изге бурыч хакына бу адымга барырга да кирәк

[9] Корт куу (төрки.)—умарта карау.

булгандыр? Авызыннан җил алсын! Мәдинәне алыштырырлык хатын бармы җир йөзендә?

Мәдинәсе барча яналыклар белән таныштырганнан соң, төпченә-төпченә Иркененнән уй-ниятләре белән кызыксынды. Мәдинәсенә озак сөйләшергә дә, артык дулкынланырга да ярамый. Ул ихтыярны үз өстенә алып, иркәсенә үзенең ике тәүлек кенә элек Бөгелмә якларыннан Чаллыга килеп, "Татарстан" дигән отельдә урнашуын, байтак яңа дуслар табуын, биредә халыкның ифрат та яхшы, кунакчыл булуын, аннан килеп, үзенә хас педантлык белән Чаллы шәһәре, аның гүзәл урамнары, корылмалары, Мәңгелек ут, Җәлил һәйкәлләре белән танышуын, зиратта булуын бәйнә-бәйнә сөйләде.

—Теге нәсел агачы...шәҗәрә табылмадымы?—дип сорады Мәдинәсе.

—Юк,—диде ул унайсызланып.—Әлегә юк, иркәм...

Почтамт күтәрмәсеннән төшкәндә генә көн үзгәрде дә куйды. Һава ничектер сәленкеләнеп авырайды, авызы бүлтәйгән әбигә охшап, чырайсызланды. "Көне дә нәкъ урысның татарга булган мөнәсәбәтен хәтерләтә. Җире-суы, байлыгы кирәк—үзе кирәк имәс." Шулай да көн пешенке җылы иде. Рәсәйнең кап уртасында, Идел-Урал арасында яткан Татарстанда, сентябрь башында шундый җылы булуга ул куанып куйды. Бу бит нәкъ клеверны яңа чабымга үстерә торган тымызык көн. Хәзер Висконсиндагы Kizlau яланнарында Ягъкуб белән Барбара клевер чабалар булыр. Икесе ике чапкыч белән чабалар, ә алар өстеннән Олы Күлләргә таба торналарның җырлы-моңлы ыргагы узып бара... Мәрхабә, торган-яшәгән ватан кайчагында туган һәм тарихи Ватаныңнан да якыная икән. Ана монсу булып китте. Ул җир асты юлына төшкән унайдан ыргак-ыргак булып очкан торналарны күрергә теләгәндәй, күкнең тоташтан соры тукыманы хәтерләткән гөмбәзенә текәлде. Анда, үкенечкә каршы, торрыйк-торрыйк дип очкан торналар ыргагы да, кыйгак-кыйгак дип юл сапкан киек казларның өтергә охшаган тамгалары да юк иде шул. Бу ниткән сагыну? Сентябрьнең мондый тымызык вә сәленке көнендә аның шундый тирән юксыну белән күктән очып барган торналар кәрванын бик тә күрәсе килә.

Җир асты юлында урнашып, чәчкә, вак мал, ашамлык, су-сыра белән сәүдә кылган кибетләр буйлап үтеп, ул Җәлил проспектының аргы ягына чыкты. Ана бер эшсез-мәшәкатьсез хәлдә таныш булмаган каланы карап йөрү ифрат та рәхәт иде. Ул үзе чыккан, каршы якта һәйкәл сыман нәрсә абайлады. "Лотфрахман кардәш әйткән һәйкәл шул булса кирәк",—дип уйлап, күңеле җилкенде. "Энергетик" мәдәният сарае, Тукай районы хакимияте биналарын карады, алардан арырак булган бинаһая йорт-куралар рәтеннән барды-барды да, аяклары сиздерә башлагач, кире борылып, яңадан җир асты юлына төште, таяклары белән шакы-шокы килеп, югары күтәрелде һәм, кош тотарга баргандай, ашыга-ашыга таш корылмага таба китте.

Һәйкәл дигәне чынбарлыкта ниндидер адәмзатның таш нигез өстендәге диварга элеп куелган һәм бер очы кыйралып төшмәсен өчен тимер терәк белән ныгытылган, ике ягыннан да бишәр шәмдәл ураткан кисек башының, тагын да дөресрәге, борынының сыны икән. Иркен ага баш эленеп торган өчпочмаклы таштактаны гильотинага, ә башны шул гильотинада киселгән татар башына охшатты. Бильярд шары кебек чиста шома, чынлап та Ленин башы кебек классик пеләш, ярты өлешен борыны биләп торган баш иде бу зәвекъсыз коелган баш. Бу башның ике урыннан терәүләрдә торуы һәм бу терәүләрнең хәтта көндезен, бер кирәкмәгәнгә ун шәмдәл белән яктыртылып торуы Иркен-аганы шактый аптыратты. Башның иясе тоташ сынлы һәйкәлгә лаек булмыйча, аны бары тик ошбу терәүләр генә тотамы? Терәүләре нидән гыйбарәт? Илаһи Рух, Ата-Ана, Милләт? Фирка-партия,

армия? Нигә урыс коммунист Ленин һәйкәле нигезле, татар коммунисты Беляев һәйкәле нигезсез, терәүле генә? Димәк, бу башның бер терәге кичә җимерелгән коммунистик партия булган булса, икенче терәге, Исхакый фаразлаганча, ике йөз ел—тарих күзлегеннән караганда "өч көннән җимереләчәк" татар милләте булып чыга?

Бер үк урамда, бер-берсенең күршесендә генә, Муса Җәлилнең башын да кертеп, ике киселгән, нигезсез татар башының һавада асылынып торуына чынлап та гаҗәпсенде мөһаҗир. Махсус эшләнәме бу? Нигә гел кисек безнең бу башлар, нигә тулы гәүдәле түгел бу сыннар? Бөек Тукайның кисекбашларына җавап мәллә болар? Тукай Кисекбашы тәрбияләгән кисекбашларга һәйкәлләрме? Нәрсә, тарихтан татар үзе дә "тулы сынлы, тулы санлы" булмаган мәллә? Татарның тездән кисек аягына, терсәктән киселгән кулына, билдән киселгән гәүдәсенә, муеннан киселгән башына, бик теләсә, кисек борыны, кисек колагына да куя ала һәйкәлне биредәге халык, тик тулаем килеш утырып, басып торган гәүдәсенә генә куймый иде... Әгәр бу баш Яңа Чаллыны эрзин итектә пычрак ерып төзегән теге Беляев дигән инсанныкы икән, нигә тарих аның эрзин итекле аякларын да һәйкәлгә кертмәгән? Ул итекләр татарныкы булган өчен генә түгелдер бит? Нигә бу һәйкәлдә күренекле дәүләт эшлеклесенең "борыны" гына урын алган?

Хәер, шөкер, татарга баскан килеш куелган һәйкәлләр дә бар. Казанда Конгресс барган көннәрдә аларга татар сынлы сәнгатенең олуг мирасы итеп үзәк мәйдандагы Тукай, бераз югарырак Мулланур Вахитов, Казан Керәмәле каршысындагы Муса Җәлил һәйкәлләрен күрсәттеләр. Бауман урамы буйлап Тукайга таба барганда, көтмәгәндә генә урыс җырчысы Федор Шаляпинның шушы көннәрдә генә куелган мәһабәт сынына тап булдылар. Хуҗалар бу һәйкәлне һәм аның рухиясен, авызларын чапылдата-чапылдата, татар иленең һәм татар сынлы сәнгатенең иң бөек горурлыгы итеп сурәтләделәр.

Тукай һәйкәле янына баргач, ул соргылт һавада эреп, ничектер югалып калган бу кечкенә һәйкәлне "таба алмыйча" иза чикте. Милли шагыйребезнең самавырчы малай кебек кечкенә, көзге җилләрдә саргайган усак яфрагы кебек ябык вә мискин гәүдәсе кыргый капитализм алып килгән янарыш фонында гүя төссезләнеп, үтә күренмәлегә әйләнгән иде. Татар җире, татар күге, татар суы, татар игене, татар сөте, татар нефтенең ни мәгънәсе калган бу һәйкәлләрдә?

Шаляпин һәйкәленнән соң Тукай һәйкәле белән танышу үзәкне өзә, җанны талый торган бер манзара икән. Их, Шаляпинны соңыннан күрсәткән булсалар!.. Болай ук рәнҗемәсләр иде ун-егерме мең чакрымнардан килгән кунаклар. Юк, алай итмәделәр. Шулай кирәк булгандыр, күрәсең. Әйтүләренчә, Шаляпин Казанның, барлык татарларның горурлыгы икән ул. Шулайдыр, әнә аның ат ботыдай симез ботлары үзләре генә дә бөек Тукаебызның сынына тора икән бит. Гүя махмырдан җәфа чиккән Шаляпин, Казан баскынчысының оныгы, тәлинкәсенә сыра шешәләре тезеп, Суконка ягыннан мәйдан аша аның башын төзәтергә йөгергән самавырчы татар малаен көтеп, гасаби кыяфәттә катып калган...

Бөек милли героебыз Муса Җәлилнең туган Ватанында тимер чыбыклар белән чорналып сынланган булуына да сәерсенгән иде чит мәмләкәт татарлары. Кем белә, Җәлил сынын ясарлык үз татарымыз табылмагач, сынчы Владимир Цигаль аны махсус шулай чәнечкеле чыбыкка чорнап сүрәтләгәндер?..

—Нишләп зынҗырда ул?—дип сорды бер миһман.—Нишләп аны Казан Керәмәленә, Гайсә Пәйгамбәр кебек, чатлы баганага тарттырганнар?!

—Сынчы дөрес сурәтләгән,—диде икенче берәү.—Җәлил, ярман

коллыгыннан исән-су кайткан да, һаман урыс коллыгында яшәгән халкына аптырап тора...

Әмма барыбер куанды Иркен ага беренче секретарь хөрмәтенә куелган сынга. Ни дисәң дә, безнең өчен киселгән башыбыз, безнең сыныбыз иде ул. Чаллыда әле житмешенче елларда ук мәчет төзетергә хыялланган, Вилдан Хаков дигән сәләтле сынчының "Ил-Ана" һәйкәлен шартлатудан коткарып калган баш иде. Кинәт сискәнгәндәй итте. Тукта, бәлки бу сын бөтенләй икенче адәмзатка куелгандыр? Иркен ага берәр язу-хәбәрнамә эзләп, сынны урап чыкты. Бер нинди дә язу тапмагач, диварны күзеннән кичерде һәм өстә, югарыда, бердәнбер язмага тап булды. Кеше күрмәсен, дигәндәй, яшереп, качырып, анда вак кына хәрефләр илә "БЕЛЯЕВ Р.К." дип кенә язылган иде. Шул, билхаккый, шул Беляевтыр бит бу!.. Кем бу "Р. К."? Исеме, атасының исеме? Вазыйфасы бардыр бит? Нигә мондый тупас рәсмилек? Егерме-утыз ел буе шәһәр, республика белән житәкчелек иткән атаклы инсаннарга һәйкәл куйганда, исемсез-атсыз, коры инициал гына язу бу нинди этикетка сыя икән?..

—Исемен-атын әйтмәссезме?—дип сораштырды ул үткенчеләрдән сынга ымлап.

Тегеләр иңнәрен сикертә салып китә бирделәр.

—Сөйләшкән сүзегез колагыма чалынды да, туктап калдым,—дип сөйләп китте күрер күзгә яше белән Иркен ага чамасында булса да, якты, зыялы чырае белән анардан яшьрәк күренгән аксакал.—"Кеше сүзе—кеше үтерә",—дигән әйтем бар татарда... Тукта, мин әйтәм, ачыклык кертик... Рәис Кыямович Беляев—Коммунистлар партиясенең Чаллы шәһәр комитетының беренче секретаре... Ышанасызмы...—Аксакал Иркен аганы бармагы белән үзенә чакырды һәм колагына пышылдады.—Йөз ел эчендә татарлар арасыннан миллион коммунист булгандыр, бәлки... Әмма коммунист татарлар арасыннан татар булып калганнары бик аз, аларны санау өчен ике кулның ун бармагы житкәндер, бәлки... Ул балыкларның кайнар суда, халыкларның кайнар уйда яши башлаганлыкларын беренче булып аңлый башлаган кешеләрнең берсе иде, мәрхүм... Бөек Татар иде ул!.. Татар авылының асыл, әле булса гадел бәя алмаган асыл баласы... Гадел, тугъры сүзләре һәм гамәлләре өчен кыйналган баласы... Әлбәттә, андыйларны гайбәткә батыралар...Ул шушы шәһәрне егерме мең халык белән кабул итеп, биш йөз меңгә житкереп киткән кеше... Чаллыга өч йөз мең яңа кеше кабул итү өчен ул ике миллион килмешәкне иләргә мәжбүр булды, төшенәсезме? Әгәр ул башка бер милләттә булган булса, әллә кайчан һәйкәл генә түгел, том-том китаплар язарлар, кинолар төшерерләр иде...

—Һәйкәле дә бик мискин... Кисек башлы...

—Кисек башлы. Монысы хак. Буйлы һәйкәлләр Чаллыда Тукайларга, Салих Сәйдәшләргә дә куелмаган...

—Ни сәбәпле?

—Сәгате житмәгән. Бер гасыр көткән Тукай белән Сәйдәш тагын бер гасыр көтәрләр.—Ул Ленинның пинжәк якасына беркетеп куйган калай билгесенә төртеп күрсәтте.—Ленин каләр Ленин Чаллыдан һәйкәлсез китеп барды. Минем күкрәктә генә калды хәзер Лениныбыз!..

—Ә нигә... бу һәйкәл шундый кечкәнтәй? Акча житмәйде?

—Юк. Үзләренә дигәндә боларның акчасы оке-а-ан...—Ул КамАЗ оффисына ишарәләде.—Һәйкәлне а л а р түгел, б е з, коммунистлар, куйдык... Без аны куймый булдыра да һәм үзебез теләгәнчә куя да алмадык, чөнки бүгенге коммунистларның ельцинистлардан куркулары Рәис Кыямовичка булган мәхәббәтләреннән көчлерәк иде...

—Ә сез кем боласыз?

—Төзүче-коммунист. Чаллының соңгы коммунисты.

—Исем-атыгыз кандай?

—Коммунист.

—Кызыклы!... Әйдәгез... Вакытыгыз булса, һәйкәл янына барып, сөйләшеп утыраек.

Юк, туктамады. Картның кипкән, җәйге аксыл пинжәктәге җинелчә гәүдәсе, ак күбәләкне хәтерләтеп, юк булды. Чаллының “соңгы коммунисты” җир астына керде дә чумды.

Бу минутта Иркен ага сөйләшеп торган кешесенең “Тәүбә” мәчетен генә түгел, барлык Чаллыны төзегән һәм үзе эзләгән “төп төзүче” Марат Тенишев икәнлеген һәм киләчәктә аның белән тагын да очрашачагын белми иде...

Иркен агага шыксыз вә күңелсез булып китте. Ул әле генә ишеткән фикерләр өермәсендә уйланып, янадан һәйкәлгә таба юнәлде.Арыган буыннары аяк тырнакларына кадәр ыңгырашып җырлый иде... Иркен аганы моңсу хис биләп алды. Аның янында йөзләгән Заһидулла Яруллин эскрипкәләрдә “Гөлҗамал”ны уя башлады. Мона түзүе читен иде. Ул өстәрәлеп кенә йөрәк сыман сары яфраклар каплаган таш нигезгә күтәрелде һәм комиссарның баш сынына текәлеп катты. Шушы кисекбашны күрер өчен Җир Шарының теге ягыннан килгән икән бит ул.

Башның сыны беркетелгән диварны җирдән төртеп чыккан тимер беләкләр тотып тормаган булса, коммунистлар фиркасе белән бергә, шул фирканың гаярь комиссарына куелган һәйкәлташ та җимерелеп төшкән булыр иде, мөгаен. Тагын да күпме гомер эленеп торыр бу тимер коршаудагы баш?! Аның үзенең башы да, Ватанына кайталмый, күпме йөрер икән кыйтгалар арасында адашып?! Иркен-аганың хәтеренә тагын да бөек Дәрдмәнд шигыре килеп төште:

Очып, кулләр кичеп, таулар ашып,
Килеп төшкән микән башкай адашып?

Башның бара-бара пеләшкә әйләнгән киң маңгае, куе кашлар астына тирәнгә яшерелгән күзләре, чиксезлеккә юнәлтелгән карашлары, борынгы юнан скульптураларын хәтерләтеп, җилкәсенә учма-учма булып яткан бөдрә чәчләре, шәүләсе үзеннән күпкә зуррак булган массив борыны—болар барысы да пеләш комиссарның кайчандыр гасырлар төпкелендә сирәк нәселдән туган сирәк вә титаник көч, сирәк акыл иясе булганлыгын раслый иде...

Юк, “соңгы коммунист” хакны сөйли—бу рәвеш, бу образ онытылмаска тиеш. Мендельнең борчаклар бөрттерү юлы белән китереп чыгарган генетик законнары татар борчагының шактый эредән булуын раслый иде. Юк, вакланмаска, онтылмаска вә онытылмаска тиеш бу нәсел борчагы!..

*Ахыры киләсе санда.*



Илсөяр
Иксанова

## КИЧЕР, ХӘЯТ...

### Август

1

Күңелемнең моңсу фасылы бу,
Гомеремнең моңсу фасылы.
Ак күбәләк булып җаннар оча,—
Җәй азагы.
Август ахыры.

Күтәрелә кошлар төркем-төркем—
Җыеналар ерак юлларга.
Канат очы кагылып-кагылып киткән
Болытлары әзер еларга.

Юатырга теләп, Кояш карый
Күксел болытларны аралап.
Яшь аралаш моңсу елмаюы
Йөрәгемне куя яралап.

Бөтерелә ап-ак күбәләкләр—
Җанкаемның җаны кайсыдыр?
...Мине ялгыз иткән август җирдә—
Күңелемнең моңсу фасылы.

2

Тып-тып итеп август алма коя—
Өзелеп-өзелеп куя үзәгем.
Җылы җәйнең соңгы сулышлары,
Тәүге сулышлары көзләрнең.

Сибелеп-сибелеп оча аерчалар—
Таҗ яфрагын җәйге гөлләрнең
Җилләр куа.
Күңелләргә тула
Хатирәсе бергә көннәрнең.

Илсөяр ИКСАНОВА—*шагыйрә; "Ышанасы килә", "Кышкы канәферләр", "Синязган язмышым", "Кырык кыл" исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

Тып-тын калган, тирәнәйгән күлләр—
Мөлдерәмә тулган күзләрем.
...Соңгы сулышлары җылы җәйнең,
Тәүге сулышлары көзләрнең.

3

Мин августка охшап барам бугай.
Әллә август минем ишеме?
Көне буе җылы өләшә дә
Төнгә кергәч, җаны өшиме?

Төне буе йолдыз коя-коя
Якты үткәненә юл саба.
Җылы җәйгә кайта,
Назлы җәйгә,
Хыялында гына булса да.

Иртәләрен адашасы килә,
Ап-ак томаннарда каласы.
Җәйләр белән көзләр арасы бу,—
Шатлык белән сагыш арасы.

Август миңа охшап бара бугай.
Әллә мин августка охшаган?
Шундый халәт:
Күңел талпынуы
Һич ким түгел китәр кошлардан...

## Туган телемә

Туган телем, газиз телем, син—үз телем.
Синдә—фәһем,
Синдә—гыйрфан,
Синдә—гыйлем,
Авазлары ерак-ерак бабамнарның.
Ишетсеннәр иде шуны балаларым!

Мең аһәңле дәрьяларның бер дулкыны,
Саклап тора, йотам, диеп мең упкыны.
Аксаң иде упкыннарга йотылмыйча,
Башка дулкын-агымнарга кушылмыйча.

Туган телем, газиз телем, син—үз телем.
Синдә даны,
Синдә аһы ерак Илнең.
Авазы син күңелдәге Илебезнең—
Офыклардан офыкларга җиребезнең.

Язсалар да нинди генә имлаларда,
Үз аһәңең,
Үз агымың дәрьяларда.
Югалтмыйча саф моң тулы тавышыңны,
Телим тере дулкын булып агышыңны!

## Казаным

Балачагым хыялы син,
Яшьлегемнең каласы.
Язмышыма тигән бәхет—
Сөю–сагыш арасы.
Татарымның башкаласы—
Күзебезнең карасы.
Ун гасырлык горурлыгы,
Биш гасырлык ярасы.

Серле–моңлы чорлар чыңы—
Борынгысы, яңасы.
Бөеклегең һәм фаҗигаң
Тарихларга каласы.

Туган илем—торган җирем—
Син гомерем каласы.
Казаным, дип куанасы,
Казаным, дип янасы!

Кайда гомер кичмә,
Булмый
Ил–Ватанның яңасы.
Язмыш читкә сипкәннәргә
Сагышларның дәвасы.

Меңьяшәрем,
                    җан шәһәрем—
Син язмышлар каласы.
Тарих төпкеленнән калкып,
Киләчәккә барасы!

## Туган илем

«Туган илем!»—диеп, туарылып
Кычкырганнар булды җан белән.
Җанның кылы кырык өзелгәндер,
Селкендеме икән бер үлән?!

«Туган илем!»—диеп өн салам да
Агач башларына бер багам.
Башын җилгә игән агачлар күк
Бөгелепләр төшмә, багалмам!

«Туган илем!»—диеп кабатлыйм мин.
Йөрәгемдә минем туган ил.
Боек түгел,
Бөек итеп кенә
Күрәселәр килә сине гел.

«Туган илем!»—диеп, туарылып
Кычкырулар, бәлки, сирәктер.
Туган илең барын тояр өчен
Бер сискәнү безгә кирәктер!

* * *

Күккә күтәрелгән күңелемнең
Чабуына җилләр ябышкан.
Җил иркенә җиңел буйсынганнар
Бөтенесен сылтар язмышка.

Язмыш, диеп,
Башны аска иеп
Сыгылып төшсәң бар ла сынаулар.
Җирдән аермый да күк катына
Алып менә ала Ак таулар.

Ак тауларга күтәрелә күңел,
Эзләреңне эзләп күкләрдән.
Бу юлларны кемнәр үтә алган,
Бу юлларны кемнәр үтмәгән...

Үткелләрне үтү—
дөнья көтү,—
Узмышлар юк, бәлки, язмыштан.
Узар булып барам. Күккә багам.
...Чабуыма җилләр ябышкан.

## Кадер

Кадерлесе идем кадерлемнең,—
Кадеремнән язмыш көнләште.

Ялгызлыктан җаным өшегәндә,
Җылы итеп миңа эндәштең.

Мин җылыга шундый мохтаҗ идем,
Арган иде йөрәк сагыштан.
Күкрәгеңә башым куйдым... ялгыш...
Мин генәме шулай ялгышкан?!—
Кадер өмет итеп ят ярлардан,
Аңлауларын теләп җанымны?

Карашларың җылы иде синең,
Эндәшүең шундый ягымлы...

Син бүген дә назлы эндәшәсең,—
Тиеш төсле күңел эрергә...
Мин сүзләрдән арыган...
Сүзсез генә
Кирәк кадеремне белергә!

* * *

Мин үземне өр-яңадан таптым.
Һәм яңадан җуйдым үземне.
Сагышларым кайтып сарылдылар,—
Йөрәгемә дәштем:
«Түз инде!»

Юк,

**Элеккедән үзгә бу сагышлар.**
**Ачы, утлы—**
**өтә бәгырьне.**
**Синсез киләчәккә китеп барам,**
**Синле үткән мең кат кадерле!**

**Бер җуелып, бер табылып торам—**
**Төрләндерә дөнья-куласа.**
**Табылмас та,**
**Җуелмас та идем,**
**Җаным тулы Сөю булмаса!..**

## Кичер, хәят!

**Бүре булып улыйсылар килә!**
**Улап булмый,**
**Булмый үкереп!**
**Бәгыремне айкап алганнармы,**
**Эчем яна,**
**Яна үтереп!**

**Бүре булып улыйсылар килә.**
**Урманнарның тапмыйм ешлыгын.**
**Күз яшенең ачы тозы гына**
**Ала алмас җанның юшкынын.**

**Бүре булып улыйсылар килә,—**
**Бүреләргә ят шул бу халәт!**
**Күкләр ярлыкамас гөнаһларны**
**Кичерә күр безгә, и хәят!**

---

## "Казан утлары" елъязмасы



50 ел элек (1958) **Әмирхан Еникинең "Йөрәк сере"** повесте дөнья күрә башлаган.

45 ел элек (1963) **Роберт Әхмәтҗановның "Йолдызстан"** поэмасы басылган.

40 ел элек (1968) **Эдуард Мостафинның шигырьләре** чыккан.

35 ел элек (1973) **Шәйхи Маннурның "Агымсуларга карап"** повесте, **Илдар Юзеевның "Таш диварлар авазы"** поэмасы.

Зәки Зәйнуллин

# КАВИ НӘҖМИ ДИГӘН ЯЗУЧЫ...

РОМАН

—Мин сиңа, чучка борын, «иптәш түгел, ә «гражданин следователь» булам. «Граж-дани-ин!»

—Гражданин следователь! Минем Сезгә соравым бар!

—Н-ну!

—Нигә сез минем белән «син» дип сөйләшәсез? Мин бит «сез» дип сөйләшәм.

—Һм! Әнә ничек? Син әле кая эләккәнеңне, кем алдында утырганыңны белеп җиткермисең икән. Чөнки бүгенге көнгә кадәр уздырган тормышыңда синең әле минем кебек кеше белән очрашканың булмаган. Һәм минем допросларны ничек итеп үткәргәнне син, чучка борын, әле дә күз алдыңа китерә алмыйсың. Чөнки синдә язучы башы гына. Ә язучы башы ул уйлый белә торган баш түгел. Уйлый белми синең башың. Синең теләкне үтәп, «сез» дип сөйләшүгә күчсәм, ун минуттан «син»гә күчүне миннән тезләнеп үтенәчәксең. Шуны бел, чучка борын! Допроска кайтыйк. Димәк, син, Кави Нәҗми, элекке Язучылар берлегенең рәисе, Гомәр Галине, Хәсән Туфанны, Фатих Әмирханны халык дошманнары дип танудан баш тартасың.

Кави ирексездән елмайды:

—Сез әйткән Фатих Әмирхан исемле “халык дошманының” вафат булганына унөч ел бит инде. Ул юк бүгенге көндә бу дөньяда...

Тикшерүче кып-кызыл булды. Азрак кына сүзсез утырды да, теге, сул ягында яткан кара күн папканы ачып, эчендә яткан кәгазьгә карап алды. Тавышы көр чыкты.

—Мин Фатих Кәрим дидем. Син, нахал, монда мине шантажировать итмә. Ә Фатих Әмирхан кем булган?

—Язучы. Габдулла Тукайның дусты.

—Кайсы Тукай ул тагын?! Теге Шүрәле Тукаймы?

—Әйе. «Шүрәле»не язган Тукай.

—Ярый әле үлеп котылганнар. Шлепнули бы обоих в подвале. Кабатлап сорыйм, ә син уйлап җавап бир: Хәсән Туфан, Гомәр Гали һәм Фатих... э-э-э... Кәримнәрнең халык дошманнары икәнлекләрен танудан баш тартасыңмы?

—Әйе! Алар берсе дә халык дошманы түгел.

—Алайса, Кави Нәҗми, әйдә, болай итим мин сине. Кире кайт үз камераңа. Шунда утырганнар белән киңәш, сиңа иртәгә нәрсә эшләргә? Мин сине иртәгә кече лейтенант Коргановка сдам! Исеңдә калдыр бу фамилияне. Корганов! Кабатла! Корга-а-анов!

*Ахыры. Башы журналыбызның 7 санында.*

—Корганов.

—Яхшы.

Өстәл кырыендагы кара төймәгә басып, озатучыны чакырды. Бер минут чамасы үтүгә Ворон керде.

—Кире камерасына илт бу ... язучы кисәген. Иртәгә иртәнге унда мин аны Коргановка бирәм. Яхшылап сөйләшкәнне аңлау дәрәжәсенә җитмәгән әле бу кеше. Иртәгә башкачарак җырлый башлар. Алып кит, илтеп яп кире.

Подвалдан чыгып, баскычтан күтәрелә башладылар. Ворон Кавиның колагына пышылдады:

—Корганов—палач. Кличкасы «Колун». Аның кыйнавына беркем дә түзә алмый. Бирә тек бирә инде. Син тикшерүче Усманов тәкъдим иткәнгә каршы килмә. Имгәтәчәкләр бит сине егет монда. Күпләр юкка чыкты Усманов, Корганов аша үтеп. Сразу риза бул, ул әйтү белән.

Кавиның камерага кайтуын көтмәгәннәр иде. Кавиның сөйләгәнен тыңлап Фазулланың йөзе каралганнан карала барды. Бик озак утырды уйланып базар буры. Һәм акрын гына Кави сөйләгәннәрдән нәтиҗә чыгарды.

—Эшләрең начар синең, Кави абый. Начар. Сорау алганда тикшерүчегә кирәк мәгълүмат бирмәгәннәрне яисә ул әйткәннәрне тыңлап, сорау алу протоколына кул куймаганнарны шул Коргановка бирәләр. Үзе татар ул. НКВД палачы. Кызыл Армиядә хезмәт иткәндә НКВД га күчергәннәр аны. Ә хәрби хезмәткә барып эләккәнче ул Казан базарында ит чабучы булып эшли иде. Мин беләм аны, ул да мине белә. Бердәнбер әнисе генә бар аның. Иске Бистәдә яши иде. Әле дә исән бугай. Прозвищесы Колун. Бетерә инде ул сине, Кави абый. Мин ана әйттереп карармын, сине кыйнамаска кушып. Белмим шул, файдасы тиярме икән. Кешене кыйнап, расколоть иткәнгә анарга аерым хак түлиләр дип тә сөйлиләр.

Тәҗрибәле, "төрмә профессоры"на әйләнгән кесә буры «Фаза» йөзе каралып, тезләрен кочаклап бик озак утырды. Өйләдән соң Воронга нәрсәдер пышылдап әйтеп, төрмә ишегалдын себерергә чыгып китте. Соң гына, азрак йөзе яктыргандай итеп кайтты. Топчанда яткан Кавиның колагына пышылдады:

—Иртәгә бирәчәкләр сине. Колунга. Кергәч тә «Әссәләмүгаләйкүм!» дип исәнләш тә, пышылдап кына: «Мин «Фаза»ның абзасы", диген. Аңладыңмы?

—Әйе.

—Йокла, Кави абый! Көч җый!

Фазулла бурның ярдәм итәргә тырышуы уңышсыз чыкты. Чөнки моңа кадәр Колун кулыннан бер генә тоткынның да үз гаебен «танымыйча» чыкканы юк иде. Колун үз маркасын тотып, шуның белән горурланучы палач иде. Һәм үз дәрәҗәсен төшерергә теләми иде. НКВДда үзенә бирелгән «Колун» исеме белән горурланып, подвалындагы бетон диварлы бүлмәсенә эләккәннәрне һушын җуйганчы кыйнап, таш идәнгә ыргытып, өстенә салкын суны чиләкләп коя иде. Кыйналган, һушын җуйган бәндә, салкын су койгач, унбиш-егерме минуттан һушына килә башлый. Шулчак Колун аны өстерәп алып барып, идәнгә беркетелгән махсус тимер урындыкка кертеп утырта да, аяк-кулларын тимер богауларга кидереп, дүрт йозак белән бикләп куя. Кеше һушына килеп беткәндә, үзенең тимер урындыкта анадан тума калганын тоя. Ә каршы диварда мич авызы ачык... Утлы күмер өстендә төрле тимер кораллар кыза. Очлы башлары да, яссылары да, кәкре башлылары да бар. Колун кыйналып, һушын җуеп, инде аңына килгән тоткынның ялангач тәненә кызган тимер басып «сорау ала» башлый.

—Следователь сораган өч кеше «халык дошман»нары икәнен син

танасыңмы, юкмы?

Тимер баса да, алгач тагын сорый:

—"Шулар халык дошманнары"—дип протоколга кул куям дип әйт...

Кави Нәҗми һушын җуя-җуя ыңгырашудан, «Алла!» дип кычкырудан башка бер сүз дә әйтмәде. Колунның җәзалау бүлмәсендә сәгатьтән артык аның «эшкәртүен» үтеп, тәмам һушын җуеп егылган Кави Нәҗмине карцерга өстерәп алып кереп ыргыттылар. Коридор буйлап тоткынны ялангач йөртергә рөхсәт юк икән. Колуннан алып чыгып китәр алдыннан ике надзиратель Кавиның өстенә киемнәрен кидерделәр дә, ике култыгыннан өстерәп алып чыгып киттеләр.

Казан НКВДсында өч палачтан торган тикшерүчеләр дип аталган җинаятьчел төркем Кави Нәҗмине июль уртасында «эшкәртергә» тотындылар.

Берничә көн буе тикшерүчеләр Сәгыйр Усманов белән Николай Зыков сорау алды. Беренче өч көнне Усманов бер үзе генә «эшләде» һәм сорау алу татар телендә барды. «Эшенең» нәтиҗәсе булмаганнан ачуы чыккан Усманов Кавины подвалга, кече лейтенант Коргановка озатты. Өч көн эчендә подвалда «эшләгән» палач Корганов Кавины кыйнап, йөри алмаслык хәлгә китерде. Аяктан язгач, «одиночка»га ыргыттылар. Авыртмаган җире юк иде. Биш көн узгач, аны ятагыннан типкәләп торгыздылар да, этә-төртә атлатып, Усманов бүлмәсенә керттеләр...

Өстәл артында юка, ябык, катып беткән гәүдәле Сәгыйр Усманов утыра. Аңардан сул якта, бүлмә диварына сөялеп, икенче кеше утыра. Таза, юан гәүдә, пеләш баш, кызыл бит. Чучканыкы кебек кечкенә, керфексез сыек яшел күзендә җылылык, мәрхәмәтнең әсәре дә юк...

Байтак вакыт узгач, Усманов башын күтәреп, Кавига текәлде. Урысчалатып телгә килде:

—А-а-а, Кави Наджми-и!

Дивар кырыенда утырганга борылды:

—Таныш бул, Николай! Татарский, сраный писатель Кави Наджми! Минем белән синең «эш объекты!»

Тегесе аягына басты. Папиросын авызыннан чыгармаган көе, ике кулын артка куеп, Кавига якынлашты. Базарда мал караган итче кебек, Кавины әйләнеп йөреп баштанаяк күз йөртеп чыкты. Алдында туктады. Карамыйча гына «Калай әтәч»тән сорады:

—Син моны Колунга биргән иденмени?

—Ну?! Күрмисеңмени?

—Күрәм.

Кавидан сорады:

—Колуннан кире кайттың. Усманов тәкъдим иткәнгә кул куясыңмы?

Кави акрын гына җавап бирде:

—Юк, куймыйм.

—Да, ну-у!—дип гаҗәпләнгәндәй булды да, Кавиның күзенә карап әйтте:

—Мин тикшерүче Усмановка ярдәмгә беркетелдем бүген. Кече лейтенант Зыков. Тагын бер тапкыр сорыйм: хәзер сорау протоколына кул куясыңмы?

—Минем бер гаебем дә юк. Кул куймыйм.

Зыков сул кулы белән Кавиның башын арттан эләктереп алды. Уң кулы белән янып бетә язган папирос төпчеген авызыннан алып, Кавиның маңгаена уты белән басты... Кави, ыңгырашып, ике куллап Зыковның папирос баскан кулына ябышты, аны читкә этәрде.

Зыковның калын иреннәре мыскыллы елмая иде. Ул кулын тартып

алды, аз гына арткарак чигенде, селтәнеп тә тормыйча, йодрыгы белән Кавиның ике каш арасына каты итеп китереп сукты. Күзләрдән көлтәсе белән утлар очты. Каты сугудан Кави бүлмә идәненә тәгәрәде. Идәндә яткан жиреннән борынын, авызын тотып карады. Кулы канга буялды. Борын тишекләреннән кан ага иде. Зыков хром итек башы белән Кавиның корсагына китереп типте:

—Сволочь писательская! Ничек итеп мина ябышырга өйрәтермен мин сине. Кара син аны, ике куллап минем кулга ябыша. Говно!!!

Шул көннән алып өч ай буе туктамастан сорау алулар, кыйнаулар, типкәләүләр, мәсхәрәләүләр китте. Болар Кавины мәнгелеккә имгәттеләр. Ике ел ярым төрмәдә көн-төн барган «физик һәм рухи метод» кулланулар аны үлгәнче авыру иттеләр. Өч ай буена Сәгыйр Усманов белән Николай Зыков бер-берсен алмаштырып та, икесе бергә дә Кавины сындырырга тырышып сорау алдылар. Сорау алулар туктамастан өчәр тәүлек буена бардылар...

Алдан, уннан, сулдан янган көчле электр лампалы урындыкка бәйләп куеп утыртылган Кавиның йөзенә төбәлгәннәр. Өч тәүлек буена йокларга ирек бирмичә, Усманов белән Зыков Кави Нәҗмидән алмашып сорау алалар.

Усманов сигез сәгать «эшләгәннән» соң, «ял итеп алырга» чыгып китә. Аны Зыков алмаштыра. Инде монысы сигез сәгать "эшләгәч", «ял итәргә» чыгып китә, аны Усманов алыштыра. Электр лампаларының көчле яктысыннан күзләр урыныннан чыга башлап зураялар, бернәрсә дә күрми торган булып сукыраялар. Йокысызлыктан баш мие ката, чатный башлый, колаклар "зыңлап", тоташ гүләүгә күчә. Тоткында бер генә теләк кала: "Их, малай, үләсе иде!» Һәм ул Алла барына ышанып, аңарга эчтән генә ялвара башлый: «Йә, Ход-дай. Синең барлыгың дөрес булса, ал зинһар, жанымны! Мин дә бит синең колың, нигә шушы кадәр җәфалыйсың мине. Ал!»

Сорау алуларга, Колун кабинетына, ут-су белән сынауларга, өчәр тәүлек йокламыйча электр уты алдында утыруларга бирешмәде, сынмады Кави. Намусы, исеме өчен көрәшүен дәвам итте!

***

«Халык дошманнары»н яклаган өчен дип кулга алынган Кави Нәҗми Кремль янындагы төрмәдә өч айдан артык утырды. «Кулга алыну гаебе» катлауланганнан катлаулана барды.

1937 елның август аенда Кырымда, Ялта шәһәрендә үпкә авыруыннан дәваланып табиблар күзәтүе астында яшәгән Галимҗан Ибраһимовны НКВД кулга ала. Ялта өендәге китапханәсен, язучының кульязмаларын конфисковать итеп, үзен төрмә кебек итеп ясалган арестант вагонында Казанга озаталар. Каты авыруның яшәү көннәре санаулы кала...

Галимҗан Ибраһимовны кулга алып, Казан төрмәсенә кайтарып япканнан соң, Кави Нәҗметдиновның «эше» тоташы белән үзгәрә. 1918 елга кадәр эсерлар фиркасендә булган Галимҗан Ибраһимовны буржуаз милләтчеләрдән торган заговорны житәкләүче итеп, Кави Нәҗмине исә аның беренче, иң актив ярдәмчесе "итә" башлыйлар.

Кави Нәҗми халык дошманнарын Язучылар берлегендә яшереп яткыру гына түгел, ә коммунистлар фиркасенә каршы буржуаз татар милләтчеләреннән торган оешма төзеп, шуның житәкчесе дә "булган" икән әле.

1937 елның гыйнварендә Плетән төрмәсендә Галимҗан Ибраһимов илле яшендә каты үпкә авыруыннан вафат була. 1938 ел буена Кави Нәҗмидән сорау алулар бара. Ниләр генә күрми, ниләр генә ишетми, нинди генә тән

җәзалары аркылы үтми Нәҗми.

Галимҗан Ибраһимов үлеп котыла. Анның үлеменнән соң Кавины Колун кушаматлы НКВД кече лейтенанты, элек базарда ит чабучы булган Корганов кулына бирәләр. Кыйналулар айдан артык бара. Тәүлек буена, ашау-эчүсез, йокысыз...

Уналтынчы камерага Кавины алырга тикшерүче Усманов Сәгыйр белән Зыков Николай үзләре килгәннәр. Надзирательдән ишекне ачтырып керделәр.

—Тор, Кави Нәҗми! Начальствога керәбез хәзер!

Коридорга алып чыктылар.

—Кулларыңны артка куй! Алга атла, Зыков артыннан.

Төрмәнең икенче катына тимер баскычтан менделәр дә, сулга борылып, искерә башлаган кызыл палас җәелгән коридор буйлап киттеләр. Берничә тоткын, тезләнеп, юеш чүпрәк белән паласны сөртә иде. Яныннан узганда берсе пышылдады:

—Исән кайт, браток!

Шул мизгелдә үк Кави артыннан килгән Усманов хром итек башы белән тоткынның авызына китереп типте:

—Сволочь!

Авызыннан кан киткән тоткынның корсагына тагын типте дә, туктап тормыйча юлын дәвам итте. Ун-унбиш адым чамасы узгач, унга бер ишекне ачып керделәр. Анда гимнастерка якасына сержант петлицалары таккан берәү, кабаланмый гына иреннәрен кыймылдатып, машинкада нәрсәдер басып утыра иде. Керүчеләрне күрү белән урыныннан торды:

—Язучы Кави Нәҗми?

—Так точно, он самый,—диде Усманов.

Сержант уң яктагы киң ишектән кереп китте дә, сакланып кына күн белән тышланган ишекне япты. Кави ишектәге язуны укыды: «Начальник НКВД ТАССР капитан Государственный безопасности Михайлов Н. Г.»

Ишек тавышсыз гына ачылды да, аннан арты белән чигенеп чыгып килгән сержантның аркасы күренде. Чыкты, азрак алга кәкрәя төшкән гәүдәсен турайтты, тавышы корыч кебек чыңлап китте:

—Керегез!

Кабинет зур иде, якты иде, биек иде...

Иң түрдә аяк-кырлары имәннән бизәкләп-сырлап, бик оста, матур итеп ясалган, кәрән төстәге борынгы өстәл артында ТАССРның НКВД башлыгы, дәүләт иминлеге капитаны Михайлов утыра иде. Яшел бәрхет белән ябылган өстәл... Бу кеше имән бармагы белән урта бармагы арасына озын, затлы папирос кыстырган уң кулы артлы урындыгының бизәкле култыксасында ята. Берниндн уй да чагылдырмаган ике күзе иренеп кенә кергәннәрне күзли. Усманов пышылдап Кавига әмер бирде: «Тукта!» Тоткынны урап үтеп, идәнгә җәйгән калын паласка каты-каты басып ике адым алга атлады да, итек үкчәләрен бер-берсенә бәреп (монысының тавышы «шык» итеп килеп чыкты) туктап, кулын фуражка козырегы янына куеп, «хәрби честь» биреп, «доложить» итте:

—Товарищ начальник НКВД Татарской автономной социалистической республики! Арестованный татарский писатель Кави Нажмутдинов по Вашему приказу доставлен в Ваш кабинет.

—Рәхмәт, Усманов! Өстәл алдына якынрак китереп бастырыгыз!

Кавины аркасыннан төртеп алга атлаттылар. Михайлов тагын бер карап торды да, иптәше белән сөйләшкән кебек сөйләп китте. Ул сөйли башлаган көенә Кавидан салкын тир бәреп чыкты:

—Бүген тикшерүчеләр таләп иткәнчә протоколга кул куймасаң, кичен

хатынынны, улынны кулга алырга боерык бирәм. Иртәгә иртән икесен дә бер-бер артлы кече лейтенант Курбановка тапшырабыз. Син үткәнне, син күргәнне—«физик воздействие» турында әйтәм мин—икесенә дә кулланачакбыз. Ә син, собака, шуны үз күзләрең белән, урындыкка бәйләнгән хәлдә карап торачаксың.

Папирос көлен сул ягында өстәлдә торган көл савытына төшерде...

—«Воздействие» узгач (НКВД да «пытка» дигән сүз кулланылмаган), ә син һаман да үзеннең эшләгән җинаятьләреңне танымасаң, хатынынны да, улынны да синең күз алдында атачакбыз, яисә «Минзәлә мичена» тыгачакбыз!..

Бүлмәдә авыр тынлык урнашты. Бераз вакыт узгач, Кавига сорау бирде:

—Аңладыңмы инде сезнең өчегезне нәрсә көткәнне?!

Кавиның дәшәрлек тә көче беткән иде.

—... синең күз алдында аларны аткач, сина бер генә юл кала—«Минзәлә миче»нә тыгабыз сине. Аңладыңмы?

Кавиның тавышы карлыгып чыкты.

—Хатыным белән улыма тимәгез. Минем үземне... бүген үк тыгыгыз «Минзәлә миче»нә. Тимәгез минем кадерле кешеләремә!

Михайлов елмайды гына.

—Мин ничек әйттем, шулай булачак.

Папирослы кулын селтәде: «Алып китегез!»

Арттан Зыков Кавиның уң беләгеннән тотып, аны ишеккә борды да, арт ягына тезе белән акрын гына төртте: «Атла!»

Коридорлар, баскычлар буйлап атлатып, хәле беткән, рухы сынган Кавины Усманов бүлмәсенә алып кереп, бүлмә уртасында идәнгә ныклап беркетелгән тимер артлы урындыкка утырттылар. Усманов өстәл артына керде дә, өстәлдәге төймәгә басты. Бер минут та үтмәде, бүлмәгә Ворон килеп керде. Усманов аңа боерык бирде:

—Кулларын урындык артына бәйлә. Утырсын. Без Николай Иванович белән ашханәгә төшеп, ашап менәбез. Үзең ишек төбендәге урындыкка утыр, сакла моны без ашап менгәнче! Үтә!

—Есть!

Кавины кулларын артка каерып урындыкка беркеттеләр. Киттеләр ашханәгә. Алар да кеше бит—ашарга тиешләр! Бүлмә беренче катта иде. «Ашау байдан, үлем Ходайдан!». НКВДда тикшерүче булып эшләгәннәргә һәм төрмә надзирательләренә төшке аш белән кичке аш түләүсез. Тик, дәрәҗәләре аерылып торганлыктан, ашау аерым залларда...

Төнге уникe тулып узгач кына ишектән Усманов күренде. Ул Кавига мыскыллап карады:

—Без Зыков белән өч ай эшли алмаганны НКВД начальнигы иптәш капитан Михайлов ун минутта майтарып ташлады. Әгәр без куйган шартка ризалашмасаң, оперативная төркем өенә китә. Ул машина эчендә безнең кушканны көтеп утыра. Ярты сәгатьтән алып киләләр хатының Сәрвәр белән улың Тансыкны. Протоколга үзеннең гаепләреңне танып кул куясыңмы?

—Куй-йам!

—Алай түгел. Үземнең гаепләремне танып протоколга кул куям, дип әйт!

Усманов Кави әйткәнне хәлсез-битараф тавыш белән бермә-бер кабатлады.

—Кил өстәл янына. Утыр! Укы!

Кави укый башлады:

"Язучы Галимҗан Ибраһимовны гаепләү акты".

Эсселе-суыклы булып китте.

Актның сул почмагындагы дүрткел мөһергә язылган датаны карады: «1937 ел, 20 июль».

Димәк, Кави кулга алынгач ук, Галимҗан Ибраһимовка тотынганнар.

“Татарстанда Совет хакимиятенә һәм ВКП(б) га каршы төзелгән троцкийчыл-зиновьевчыл-бухаринчыл блокка идеология буенча житәкчелекне элекке сул эсер булган бүгенге татар язучысы Галимҗан Ибраһимов алып бара... Галимҗан Ибраһимов 1920 елда контрреволюцион милләтче төркемне тәшкил иткән “сул” эссерлар татар партиясенә кушылып китте һәм шул оешманың актив бер әгъзасы булды. 1925 елда контрреволюцион милләтче оешма төзеп, шуның житәкчеләренең берсенә әверелде һәм культура-идеология фронтында катгый контрреволюцион эшләр башкара башлады. Галимҗан Ибраһимов үзенә көрәштәшләр итеп, киләчәккә алмаш булсын өчен, тиешле кадрлар әзерләү белән дә ныклы шөгыльләнә. Аның игътибары бу өлкәдә бик ныклы һәм нигезле итеп Татарстан Язучылар берлегенә юнәлтелгән булган. Үзе дә язучы буларак, Галимҗан Ибраһимов, язучының әсәре кешеләргә ничек тәэсир иткәнне яхшы аңлап, язучылардан торган контрреволюцион, троцкийчыл-зиновьевчыл-бухаринчыл блок төзегән. Үзенә алмаш булырлык кадрларны 1925 елдан бирле бик тырышып, төрле яктан уйлап әзерләгән.

Галимҗан Ибраһимов Г. Нигъмәти, К. Нәҗми, Г. Галине контрреволюцион блокка җәлеп иткән. Алар ярдәмендә Г. Ибраһимов язучылар арасында Советларга каршы контрреволюцион оешманы киңәйтүдә агитация эшен җәелдереп җибәрә. Утызынчы еллар башында бу оешма эшенә язучылар Хәсән Туфан, Фатих Кәрим, Мирсәй Әмир җәлеп ителәләр. Югарыда санап кителгән язучылар Г. Ибраһимовны һәм бер-берсен беркайчан да тәнкыйть итмичә, бары тик мактау белән генә шөгыльләнделәр.

Югарыда санап үтелгән кешеләрнең барысы да һәрвакыт Г. Ибраһимовтан киңәшләр, конкрет күрсәтмәләр алып, аны матбугатта бердәнбер чын язучы дип күп мәртәбәләр язып, мактап чыктылар. Кави Нәҗми, мәсәлән, Г. Ибраһимовны, аның 1918 елга кадәр үк «сул» эсерлар партиясендә торганын белмәмешкә салынып, ул революциягә кадәр үк марксист-тәнкыйтьче булган, дип язып чыкты. Ә бит «марксист-тәнкыйтьче» Г. Ибраһимов үзенең «Пролетар әдәбияты турында» исемле китабында, ВКП(б) ның астыртын дошманнары булган Троцкий һәм Бухариннан өзекләр китереп, аларны мактап чыккан...»

Акт азагында, шунда «язылганнар белән «мин тулысынча риза» дип... Галимҗан Ибраһимовның имзасы салынган.

...Кави Нәҗми, актны азагына кадәр укып чыгып, иплəп кенә өстәлгә куйды.

—Ну-у-у-с!—диде Усманов.—Күрдеңме атаманың Галимҗан Ибраһимовның имзасын? Акт астындагы? Ә?!

—Күрдем.

—Бөтен гаепләрен дә таныды татар халкының классик язучысы. Моңа аның ярдәмчесе һәм дусты Кави Нәҗми нәрсә әйтә инде хәзер?

—Өч ай бит инде миннән дә шундый ук имза таләп итәсез. Куймыйча түзә алмагандыр.

—Исеңә төшерәм, НКВД начальнигы, иминлек капитаны Михайлов сиңа иртән нәрсә диде, ә? Хатының, улың, диде. Ә ул безнең кебек йомшак кеше түгел. Үз күзең белән күрдең!

Торып басты. Гайрәтлерәк күренәсе килде, ахрысы. Кобурасын чишеп, револьверын тартып чыгарып, шакылдатып, ишеттереп өстәлгә салды.

—Без биргән сорау алу протоколына кул куясыңмы, юкмы? Уйларга ярты

минут вакыт сиңа. Опер, синең хатыныңны, малаеңны алып килергә дип, машина эчендә минем боерыкны көтеп утыра. Ну! Кул куясыңмы?

Кави башын күтәрмичә генә ризалыгын белдереп башын селкеде.

—Кул куям. Нәрсә генә язган булсагыз да. Тик минем Сәрвәрем белән улыма гына тимәгез. Мин риза.—Шулай диде дә сорау алу беркетмәсенә үзенең халык дошманы икәнлеген раслап имзасын куйды.

Револьверын кобурасына кире тыга-тыга, Усманов нәтиҗә ясады:

—Өч ай буена Колун подвалында, аның изүе астында ятарга кирәк идемени инде? Юләр син, Кави Нәҗми дигән язучы...

Чакырып керткән Воронга боерык бирде:

—Уникенче камерага күчер. Ял итсен бер ун көн чамасы. Уйлансын үзенең хәзер инде кем булганы турында.

Кавига мыскыллап карады:

—Ял ит! Беттең син хәзер монда, бездә шәхес буларак. Без синең белән хәзер ни телибез, шуны эшләячәкбез. Бар, чыгып кит. Сиңа камера топчанында бер урын бар. Эзләп кереп ят шундагылар арасына...

Кави төрмә топчанында тормастан диярлек көне буе ятты. Тик ике мәртәбә «параша» янына барып бушанып кына килде.

Кичен камера ишегенең аш бирә торган капкачы ачылды. Аннан надзирательнең тавышы ишетелде:

—Нәҗметдинов! Передача!

Кави күршесе ярдәмендә торып, көч-хәл белән ишек янына барды. Надзиратель аңа чүпрәккә төрелгән кайнар кружка белән гәҗиткә төрелгән төргәк тоттырды. Пышылдады:

—Унҗиденче камерадан синең дустың бирергә үтенде. Фазулла исемле.

Кружкада хуш исле сөтле мәтрүшкә чәе иде, гәҗит төргәгеннән кечкенә ак күмәч килеп чыкты. Бу кесә карагы Фазулла—«Фаза»ның камерадаш булган татар язучысы Кави Нәҗмигә азык һәм рухи ярдәме иде. Кыйналган, изелгән, ике күкәйсез дә калган Кавиның күзләреннән яшьләре атылып чыкты... «Бисмилласын» укый-укый, Фазуллага мең-мең рәхмәтләрен әйтә-әйтә тәмләп кенә, күмәч кисәген чәйләп чәйни башлаган иде, тәмле итеп әллә нәрсә сытылды. Сул кулының бармак очы белән «әллә нәрсәне» авызыннан алып карады да, елмаеп җибәрде. Урталай өзелеп чыга язган төстәге йөзем иде бу. Елмайды—чөнки исенә төште.

Алты-җиде яшьләр чамасы гына иде Кавига. Әнисе бер телем кара ипи өстенә тары боткасы салып, кунактан «күчти» алып кайткан. Кавига бирә моны:

—Менә, улым. Лотфыйкамал әбиеннәргә ашка барган идем, шулардан алып кайттым. Инде тары боткасы пешергән Лотфыйкамал әбиең тәмлеләр иттереп. Телеңне йотарлык! Аша, бәбкәм. Мә, тот!

Кави сәкедә баскан хәлендә «күчтине» ике куллап алды да, яраткан урынына, урам якка караган тәрәзә янына барып утырды. Үзе дә көтмәстән кычкырып җибәрде:

—Ән-нникә-ем! Боткасы тараканлы бит!

—Нинди таракан ди тагын! Сөйләмә юкны.

Кави боткалы ипине әнисенә сузып күрсәтте:

—Әнә бит, ботка эчендә сары тараканнар! Әнә, әнә, әнә!

Әнисе көлеп җибәрде:

—И-и, бала, бала! Синең моңарчы күргәнең дә, ашаганың да юк шул. Таракан түгел бит, йөзем бит бу. Сары йөземнәр. Тары боткасына, дөге боткасына, тәмле булсын дип, шундый сары йөзем салып пешерәләр, балам. Аша, бәбкәм, аша.

Шул кара ипи өстенә салынган сары йөземле ботканың тәмен Кави гомере буена онытмады. Ул ботка хәлле кешеләр, байлар ашый торган ризык, матур истәлек булып калды аның күңелендә. Менә хәзер инде, сасы, тынчу, салкын камера эчендә Кави Фазулла биргән йөземле күмәч ашап, сөтле мәтрүшкә чәе эчә. Чәй кайнар, шикәре булмаса да, бик тәмле иде...

Шул 1937 елның 16 октябреннән соң дүрт айга якын Кави Нәҗмине тикшерүчеләр "оныттылар". Шулай да көненә бер мәртәбә кырлары, өсте тимер рәшәткәләр белән уратып алынган, бик зурдан булмаган, «собачник» дип аталган мәйдан кебек җиргә ярты сәгатькә «прогулкага» алып чыгып, кире куып кертәләр иде.

Атна тирәсе вакыт узгач, бер көнне кулларны артка куеп, кабаланмый гына «собачник»та түгәрәк буйлап акрын гына атлап барган иде, арттан татарчалап дәштеләр:

—Кави абый, исән икәнсең әле! Әссәламмүгаләйкү-үм! Борылма! Мин бу, Фазулла энең. Шатмын сине күрүгә!

—Исәнме, Фазулла!—диде акрын гына Нәҗми.—Рәхмәт сиңа, камерага биргән чәй белән ак күмәчең өчен!

—Исәнлеккә-саулыкка булсын. Галимҗан абый Ибраһимов монда. Хәле бик начар. Төрмә вагонында алып кайтканнар Ялтадан. Ятып кына тора, йөри алмый.

—Ул да «халык дошманы»мы?

—Ул сезнең татар контрреволюционерларының ин зур җитәкчесе, оештыручысы икән...

«Прогулка» бетте. Мәйдан уртасында басып торган «Аршин» кушаматлы (озын гәүдәле булганы өчен) надзиратель боерык бирде:

—Разводи-ить по камера-ам!

Камерага кереп топчанына яткач, Кави озак уйланды, узган еллар истәлегенә бирелде. Ул Галимҗан белән 1922 елда, Казан татар-башкорт хәрби мәктәбендә укыта башлаганда ук танышкан иде. Танышлык дуслыкка әйләнеп, әдип үпкә авыруыннан дәваланырга дип Ялтага китеп яши башлагач та дәвам итте. Кави, Галимҗан Ибраһимовның Казандагы күзе-колагы булып, атна саен аңа хатлар язды, гәҗит-журналлар җибәрде һәм хатыны Сәрвәр белән бергә берничә мәртәбә Ибраһимов яшәгән Ялтага барып, аның өендә озак-озаклап әдәбият турында, тормыш-яшәеш турында сөйләшеп утырдылар. Кави Нәҗми үзе нужа-михнәтне күп күргән, шунлыктан кешеләрнең кайгы-нужасын да үзенеке кебек итеп аңлый, белгән кеше, Галимҗан абыйсының авыру көннәрен, яшәешен кулыннан килгән кадәр җиңеләйтергә тырышты. Татар вәзгыятеннән, аның кайнап-гөрләп көн саен үзгәреп торган көчле әдәбиятыннан аерылып Ялтада япа-ялгыз яшәгән Галимҗан абыйсының бик күп төрле үтенечләрен, кушкан эшләрен Кави армый-талмый Казанда үтәде. Галимҗанның энҗе бөртекләре кебек асыл, әдәби яктан кыйммәтле әсәрләрен төрле гәҗит-журналларга илтеп тапшырды һәм аларның басылу хәлләрен тикшереп, тизрәк чыгуларын тәэмин итте. Галимҗан Ибраһимов өчен үзенең барлык танышлыкларын кулланып, сирәктән булган кыйммәтле, дефицит дарулар эзләде, тапты, Ялтага барып җитүләрен тәэмин итте. Казаннан өлкә комитеты аркылы академик Вишневский да катнашкан врачлар төркемен оештырып Галимҗан исәнлеген тикшереп, карап, консультация ясап, дарулау ысулларын ачыкларга дип озатты. Нәшрият белән аның китапларын бастырып чыгару турында сөйләшүләр алып барды һәм бастыруга килешүләр төзеде. Һәм шушы Галимҗан Ибраһимов белән булган дуслыгы язучы Кави Нәҗмине төрмәгә тыкты.

1937 елда Татар язучыларының НКВД карашы астына эләккәннәренең йөз проценты диярлек НКВД тикшерүчеләре тарафыннан куркытылып, сындырылып, алар ничек тели шуна буйсынып күрсәтмә биргән. Безгә килеп җиткән мәгълүматлар буенча тик бер Шамил Усманов кына бирешмәгән, сынмаган. Түзәрлеге калмагач, "үзенең гаепләрен" танып кул куярга риза булган. Тикшерүче биргән каләм белән үзенең уң күзе аша баш миенә чәнчеп, үзен-үзе үтергән, дигән фараз бар. Бик тә дөрескә ошаган... «Ирекә йөргән» язучыларның күпчелеге бер-берсе өстеннән НКВДга, өлкә комитетына шикаятьләр язган. Шулай итеп, «уяу булып», «халык дошманнары»н фаш итеп, исән калырга тырышканнар. Кайберләре максатларына ирешкәннәр, ә иптәшләрен, дусларын НКВД подвалларына, «кувалда»ларга тапшырганнар.

Менә хәзер, утыз җиденче елларның палачлары, «тиски»лары, «янган мичләре» турында укыганда, азга гына булса да уйлап карагыз: «Кави Нәҗми фаҗигасе мина эләксә нәрсә эшләр идем икән?».

...Ялтадан төрмә вагонында Казанга кайтарып Пләтән төрмәсенә ыргытылган Галимҗан Ибраһимовка медицина ярдәме күрсәтү туктатыла. Үпкә туберкулезы көннән-көн көчәеп, ул йөри алмаслык хәлгә килә.

Бер контрреволюцион оешмада торган һәм Галимҗан Ибраһимовны оешманың җитәкчесе дип таныган Кави Нәҗмине 1937 елның ноябрь аенда Пләтән төрмәсенең хастаханәсенә алып килеп, аларның икесен очраштыралар.

Инде үлем бусагасында торган Галимҗан, күзләрен Кавидан алмастан, бик озак карап тора. Кави да, сагыш, уй тулы күзләрен остазыннан, дустыннан читкә бормыйча, туп-туры аның күзләренә карап басып тора...

Бик озак шулай күзгә-күз карап торгач, Галимҗан акрын гына тавыш белән әйтә:

—Кави әйткәч, дөрестер инде дип уйлыйм мин дә...

Азрак дәшми карап тора да, өсти:

—Ходай ташламасын сине... Кави! Хуш! Мин озакламам инде... Хуш... Кави!

Кавины ишек ягына борып алып чыгып китәләр. Ул ишек төбендә туктап борыла:

—Хуш, Галимҗан абый! Гафу ит мине! Хуш!

Чыгып барган Кави артыннан ишетелеп кала:

—Хуш, Кави! Хуш!..

Гаебен «таныган» Кавины өр яңадан «эшкәртергә» тотыналар. Галимҗан Ибраһимов белән бер үк дәрәҗәдә Кави Нәҗми дә Татариядагы «халык дошманнары», «татар милләтчеләре» төзегән яшерен оешма җитәкчеләренең берсе икән. Шуны яшерер өчен, җинаять кылуының аз гына өлешен танып кул куйган икән.

1937 елның 26 декабрендә Кавины кулларын артына куйдырып, камерадан алып чыгып киттеләр. Йөрәкләргә куркыныч шом салып, Воронның камера ишеге төбеннән тавышы ишетелде:

—Нәҗметдинов! Допроска!

***

Бик тә күңелсез генә яңа 1938 ел килде. Юкны бар итеп, чарлактагы бүлмәдә өчәүләшеп яңа елны каршы алдылар: унбере белән барган Тансык, әнисе Сәрвәр һәм Хәтирә апалары. Чарлактагы өч карават көчкә генә сыйган кечкенә бүлмә иде аларның яшәгән урыны.

Хәтирә апа бәрәңге пәрәмәче пешергән. Тимер мичне ягып, бүлмәне җылыткан. Су—урам колонкасында.

Барлык дус-ишләре арасыннан тик Салих Сәйдәш кенә курыкмады, дуслыгын онытмады, аз-маз гына булса да, матди ярдәм дә күрсәтергә тырышты. Тик, дусты драматург Кәрим Тинчуринны кулга алып, Пләтән төрмәсенә атканнан соң, ул да эшсез йөри иде.

Кави утырганнан соң гаиләне нужа басты. Берлекнең рәисе чагында, аның белән аралашырга, дуслашырга тырышып, аңа яраклашучылар да хәзер инде Сәрвәр Әдһәмованы күрмәмешкә салышып үтеп китәләр. Урамнан каршы килгән чакларында, урамның икенче ягына чыгып "юк булалар".

Язучылар берлегендә 1937 елның 13-14 июнендә барган җыелышта Хәсән Туфанны гаепләп, Кәрим Тинчурин да, Шәриф Камал да, өлкә комитеты инструкторы Имаметдинов кушуы буенча, Хәсән Туфанны «батырырга» ярдәм итәләр.

Кәрим Тинчурин:

—Туфан бик талантлы шагыйрь. Ләкин ул үзенең талантын безгә каршы куеп, безгә каршы куллана. Аның иң көчле шигырьләре—«антисоветскийлар»...

Шәриф Камал:

—Мин Тинчурин белән аның: "Туфан—талант"—дигәне белән килешмим, мин моңа ышанмыйм. Ул кайбер куплетларын бик оста итеп, мастерларча яза. Ләкин ул куплетларны ике төрле анларга була. Һәм ул моны уйлап, аңлап эшли. Ул аңлап яза антисоветларча булган әсәрләрен... Бу аның «таланты»...

Озакламый Кәрим Тинчуринның үзенә дә «халык дошманы» ярлыгы тагылып, НКВД тырнагына эләгеп «утыртыла» һәм төрмәдә атыла.

Шәриф Камалга тимиләр. Тик ул үзенең иманына, вөҗданына каршы чыгып, каләмдәшләренә, коммунистларга кирәгенчә яла ягып, шуңардан йөрәге бозылып, 1942 елда вафат була. Кызганыч ки, үзе белән ихтирам күрсәтеп исәнләшкән Сәрвәр Әдһәмовага урамда очраганда да Шәриф Камал дәшмичә, карамыйча да үтеп китә торган булган. Түбән Осланда Кави Нәҗми оештырган ял итү йортларында 1934-36 елларда ял итеп, бергәләшеп балык тотып, кечкә учак янында уха пешереп ашаганнар исенә төшкәләп, йөрәккәен сыкратмады микән атаклы язучы, Каспий диңгезе балыкчысы Шәриф Камалның.

1938 елның 4 гыйнварында Сәрвәр Әдһәмованы НКВД кулга ала...

Кичке унбер үтеп киткән иде инде. Тыштан каты итеп ишек шакыйлар. Хәтирә апа авыз эченнән генә дога укый-укый ишек янына килде. Куркудан калтыранган, утырган тавыш белән сорады:

—Кем... кем... бар анда?

—Ачыгыз! НКВД!

Күн куртка кигән, зәңгәр фуражкалы дүрт хәрби килеп керделәр. Берсе, утәргә урын булмаганнан, карават янына басты:

—Кем була Әдһәмова Сәрвәр?

—Мин.

—Сез, контрреволюционерка, кулга алынасыз! Менә сезгә арест ясарга бирелгән ордер.

Сәрвәр биргән кәгазьне алып, укып чыкты. НКВДшник Сәрвәргә тагын бер кәгазь суза.

—Монысы сезнең улыгыз Нәҗметдинов Тансыкны яше бәләкәй булган халык дошманы балалары өчен төзелгән спецраспределительгә озату өчен бирелгән ордер. Улыгыз кайда?

Сәрвәр йоклап яткан балага күрсәтте.

—Әнә! Караватта. Йоклый инде ул.

НКВДшник мәрхәмәтлелек күрсәтте.

—Ярар, йокласын инде, уятмыйк. Иртәгә иртәнге сәгать тугызда килеп алырлар. Мәктәпкә җибәрмәгез.—диде.

—Аларның яна ел каникулы бит. Укымыйлар.

—Тем более.

Тентүне өстән-өстән генә ясадылар да, Сәрвәрне алып киттеләр...

Иртәнге сәгать сигез тулмас борын Хәтирә апа Тансыкны ипләп кенә аркасыннан сөеп уятты:

—Тор, бәбкәм! Тор! Хәерле иртә сина!

Бала уянды. Тик торасы килми иде.

—Нәнәй! Мин тагын аз гына ятыйм инде. Әти белән җәтмә өстерәп балык сөзә идек төштә. Шуны карап бетерим инде.

—Тор, балам! Төш бит ул сина кино түгел, уянгач, аның дәвамы кире керми төшкә.

Икеләнеп торды да, барыбер яшереп булмый инде дигән нәтиҗәгә килеп әйтте:

—И, бала, бала! Бигрәкләр дә бәхетсезгә чыгып барасың инде син.

Тансык бик нык курыкты. Агарып чыкты.

—Ә мин? Әнисез дә хәзер кая барам инде? Мине кем карый?

Хәтирә апа торып утырган Тансыкны сыйпады:

—Хәзер сине дә алырга киләләр, балам. Йөрәгенә курку кертмичә генә әзер булып тор.

—Мине дә төрмәгә алып китәләрме?

—Юк, төрмәгә түгел, Тансык! Карл Маркс урамында «Детский распределительный пункт» дигән урын ясаганнар. Сине шунда алып китәләр дә, аннан ятимнәр өчен оештырылган берәр балалар йортына бирерләр инде.

Тансык сыктап елый башлады:

—Хәтирә нәнәй! Мине бирмә аларга! Әтием, әнием төрмәдән кайтканчы минем синең янында торасым килә. Тансык-янчык—дип шелтәли идең. Мин бик тыңлаучан булырмын—бирмә мине НКВДларга. Нән-нәй! Зинһар!..

Иртәнге тугызларда чарлак бүлмәсенең ишеген шакыдылар. Хәтирә апа сорамый гына ишекне ачты. Анда бер хәрби басып тора иде. Телгә килде:

—Начальство боерыгы буенча Нәҗметдинов Тансык дигән унбер яшьлек малайны алырга килдем мин. Кайда ул?

Хәтирә апасының артында куркып басып торган Тансык алга чыкты.

—Мин ул Тансык исемле малай.

—Әһә, киенеп үк куйгансың икән. Молодец! Әйдә, киттек.

Хәтирә апа Тансык кулына бер төенчек тоттырды:

—Өчпочмаклар, бәләкәй бәлешләр. Бер шешә сөт, ашарсың. Ал!

Сержант бәхетсез баланы баскычтан алып төшеп китте. Ишегалдындагы ябык машинага кереп утырдылар. Яшьләрен тыярга тырышкан Тансыкка киңәш бирде сержант:

—Апаң биргән ризыкны, күпме булдыра аласың, аша хәзер. Сөтен эч. Карл Марскстагы йортка керү белән андагы ач малайлар синең ризыгыңны талап алачаклар. Кабаланмый гына аша шушында. Шофер белән мин көтәрбез...

Карл Маркс урамында, авиаинститут каршындагы йортта Тансыкны бер атна тоттылар. Бер зур бүлмәдә, яшькә Тансык чамасындагы 17 малай бар иде. Араларында биш яшь чамасындагы алты малай да күренә. Кергән көенә шул кечкенә малайлар Тансык янына җыелып, аның кулындагы төенчеккә карап тавыш-тынсыз гына басып тора башладылар. Ике куллап төенчеген

тотып бүлмә уртасында басып торган Тансык янына үзеннән зуррак ике малай килде. Берсе татарча сорады:

—Төенчегендә нәрсә?

—Нәнәй биргән өчпочмаклар.

—Менә бу бәләкәчләргә берәрне өләш тә, калганнары безгә.

Тансык төенчекне малайга сузды.

—Мә, үзең өләш.

—Минем исемем Марат!—диде малай, кечкенәләргә өчпочмаклар өләшә-өләшә.—Ә синең исемең ничек?

—Тансык.

—«Халык дошманы» малаемы?

—Түгел. Минем әтием язучы Кави Нәҗми.

—Ә минем әтием—физика укытучысы. «Халык дошманы» дип исем тагып төрмәгә яптылар. Әниемнең йөрәге ярылып үлде. Сеңлем белән мине монда китереп яптылар.

Сак кына карангалап алды. Пышылдады:

—Монда өч урыс малае верховодить итә. Бергәләшеп каршы торыйк. Синең килүең әйбәт булды бит әле. Югыйсә, безнең аларга көч җитми иде. Ризамы?

—Әле алар кая?

—Кухняда идән юалар. Шуның өчен кухняда ашаталар да. Андый жиргә безне якын да җибәрмиләр алар.

Кичке аш вакытында ашханәдә бәрелеш булды. Таза гына өч урыс малае ашап утырган татар малайларының тәлинкәләреннән боткаларын алып йөри башладылар. Коля Нос дигән урыс малае дүрт яшьлек кечкенә Вахитны елата-елата тәлинкәсеннән боткасын үзенең тәлинкәсенә бушатып алды да, Марат янына килде:

—Бир ботканны, француз!

Исеме Марат булганга “француз» дип исем кушканнар икән. Марат боткалы алюмин тәлинкәне уң кулына тотып торып басты.

—Син, бәләкәй Вахитның боткасын кире бир.

Коля, уң кулының ике бармагын тырпайтып сузып, Маратның күзенә төртергә дип үрелде. Марат, кыска гына кизәнеп, тәлинкәдәге ботканы Коляның күзләренә китереп чәпәде дә, буш алюмин тәлинкәнең кырые белән аның борынына аркылыга каты итеп китереп сукты. Коляга ярдәмгә ташланган өч урыс малаеның юлына бер өер татар малае аркылы төште. Маратның татарча боерыгы ишетелде:

—Малайлар! Тәлинкә белән бәргәләгез. Кырые белән битләрен ярыгыз!

Бәрелеш кыска һәм канлы булды.

Борыннары, битләре алюмин тәлинкә кырыйлары белән ярылып, канга баткан урыс малайларын ашый торган өстәлләр астына тутырдылар. Марат үрелеп Коляны өстерәп чыгарды:

—Бүгеннән алып талауны, бәләкәйләрне җәберләүдән туктыйсыз. Кухняга эшкә, азык машинасын бушатуга чиратлап йөрибез. Мин чиратны тәртипкә салып, тикшереп торучы булам. Аңладыңмы?

Коля ярык борынын җиңе белән каплаган хәлдә, дәшмичә басып каткан иде. Марат аның күлмәк изүеннән бөтереп тотты:

—Ишетмисеңмени? Нигә дәшмисең? Аңладыңмы дип сорыйм бит мин синнән. Н-ну?!

—Аңладым...

Кулбашыннан кочаклап, Марат Тансыкны ятак бүлмәгә алып чыгып китте:

—Шәпсең, курыкмыйсың, чын татар малае икәнсең син, Тансык. Шулай бергә булыйк!

—Бергә булыйк, Марат.

Бер атна узгач, төрле яшьтәге егермеләп малайны «телячий вагон» га тутырып поезд белән Казаннан алып киттеләр. Малайларның иң зур дигәне унике яшьләр чамасында иде. Вагон эчендә ак такталардан сәндерәләр ясалып, аларга калын итеп салам түшәлгән. Уртасында ике тимер мичкәне бергә утыртып утын яга торган мичләр эшләнгән. Түшәм аша төтен чыгарга вагон башына ике мичкә бер моржа чыгарылган. Кайсыдыр рәхмәт төшкере бәндәсе кисеп, ярып, вагон диварына терәп күп итеп ягар өчен утын өеп куйган.

Өч тәүлек буена дангыр-донгыр килеп сугыла-бәрелә, туктый-туктый билгесезлеккә бардылар да бардылар. Өч тәүлектән артыграк узгач, бер иртәне вагон ишекләре ачылды. Ике милиционер зур "параша"ны күтәреп алып, вагон артына алып китеп түктеләр. Марат бик ерак булмаган ике катлы бина өстенә эленгән язуны укып өлгерде: «Станция Ирбит!» Свердловск. обл." Менә кая алып килгәннәр икән аларньп Свердловскига!

Парлап тезеп станция алдындагы зур мәйданга алып чыктылар малайларны. Өсте брезент белән ябык йөк машинасына төяделәр дә, алып та киттеләр. Ярты сәгать чамасы үтүгә, ике катлы кызыл кирпечтән төзелгән озын гына йорт ишегалдында машиналардан төшерделәр. Өйгә алып кереп, бишмәт-туннарын салдырып, ашарга утырттылар. Матур гына сакал-мыеклы, күзлек кигән бер абзый ашханә өстәлләре арасында туктап, балаларга мәгълүмат бирде:

—Сез, балалар, Свердловск өлкәсендәге Ирбит каласындагы балалар колониясендә. Сез монда яшәячәксез, укыячаксыз, эш-һөнәргә өйрәнәчәксез. Тәртип бозмасагыз, сезне монда беркем дә җәберләмәс! Мин—директор Сергей Сергеевич Тихонов. Ашагыз, үсегез, укыгыз!

Икенче көнне балалар урнашкан бүлмәгә 12-13 яшьләр чамасындагы бер малай белән чибәр генә бер кыз керделәр. Сөйләшеп утырган Марат белән Тансык янына килеп жылы гына итеп исәнләштеләр.

—Исәнмесез! Сезнең белән танышырга кердек. Сезне монда каян китерделәр?

—Казаннан,—диде Марат.

Кергән малай сорады:

—Сез әллә татарлармы?

—Әйе. Без—татарлар.

—Әйдәгез, таныш булыйк. Мин—Петя Якир, ә менә бу кыз—Светлана Тухачевская. Маршал Тухачевский кызы. Ә минем әтием Беренче ранг армия командиры Якир Иона. Яһүд мин, сез татар булсагыз.

Күнелсез генә өстәп куйды:

—Светаның әтисе дә, минем әти дә халык дошманнары итеп атылдылар. Июнь аенда.

Малайлар дәшмәде. Петя үткер малай иде, ахрысы. Тынмады:

—Сезнең әтиләрегез кемнәр? Безнең әтиләр кебек аларны да халык дошманы иттеләрме?

Малайлар икесе дә баш кактылар. Тансык өстәде:

—Минем әтием—язучы. Татар язучысы Кави Нәҗми.

—Аттылармы?

—Юк. Төрмәдә утыра. Әниемне дә алып киттеләр. Ул да төрмәдә.

Якир аңлатма бирде:

—Әтиләр «халык дошманы» булгач, әниләргә дә иректә яшәргә ярамый. Сталинга каршы көрәшүләре бар бит. Алар куркыныч тудыралар ирктә булсалар.

Аннары, туп-туры карады да, әйтеп куйды:

—Мин моннан качар идем, тик качкач яшәргә урыным юк. Минем әти бит хәрби командир иде. Исән булыгыз. Бер-беребезгә зыян китермичә, ярдәм итәргә тырышып яшик.

Светлана белән Петр китеп бардылар. Алар икесе дә башта балалар колониясендә, аннан соң унсигез яшьләре тулгач, ГУЛАГ лагерьларында 1956 елга кадәр—унтугыз ел утырачаклар. Унбер яшьтән алып утыз яше тулганчы. Петр Якир, 1956 елда концлагерьдан чыгарылгач, коммунистлар партиясенә НКВДдан КГБ итеп үзгәртелгән, кешене юк итү белән шөгыльләнгән оешмага каршы көрәшеп карый. Һәм тагын кулга алынып, төрмәгә утыртыла. Гомере буена бәхетсезлектә, хәерчелектә гомер кичерә бу бичара җан. 1982 елда 56 яшендә вафат була. Леонид Брежнев белән бер көнне.

Петр Якир белән танышканнан соң Тансык тәүлеккә якын дәшмичә, нәрсәдер уйланып йөрде. Икенче көнне иртән төн буена әнисен чакырып, эсседә янып-тирләп яткан дүрт яшьлек Вахит үлде.

Атасыз-анасыз, йортсыз, назсыз калган, янарак кына бәхетле, тук, матур киемле, күп уенчыклы тормышта яшәгән, кичә генә әти-әниләре «зур хуҗалар» булып яхшы эштә булган, инде «халык дошманы»на әверелгәннәрнең эреле-ваклы балалары, дүрт яшьлек Вахитның үлемен күреп тетрәнделәр.

Уйларын беркемгә дә сөйләмәскә өйрәнә башлады Тансык. Тагын дүрт көн узгач, балалар колониясеннән качты. Биек коймага ишегалдындагы бәдрәф артында аунап яткан озын тимер торбаны сөяде дә, шуңа үрмәләп менеп, койманың икенче ягында үсеп утырган каен агачына сикереп, аның ботагына ике куллап ябышты. Каен кәүсәсе буйлап җиргә шуып төште дә, паровоз гудоклары ишетелгән якка йөгерә-атлый кабаланып китеп барды. Тимер юл вокзалы шул якта иде... Качканына тәүлек тулып үткәндә Тансык инде Казан урамнары буйлап үзләренең өенә карап йөгерә иде. Качканнан бирле авызына валчык та ризык капмаган малай кичен соңлатып кына, бик тә сакланып, фатир ишегең какты. Ишекнең теге ягыннан Хәтирә апаның кадерле, йомшак, җылысы сизелеп торган курыкынган тавышы ишетелде:

—Әй, Ходай-йым! Кем бар анда?

—Мин бу, нәнәй! Тансык улың!

—Йә, Ход-дай! Мәрхәмәтләреңнән ташлама без бәхетсез җаннарыңны!

Калтыранган куллары белән ишекне ачып, елый-елый Тансыгын кочаклап алды.

—И-и, баллакай-йым минем! Каян син? Исән икәнсең, исән-сау икәнсең! Ходайның мең-мең рәхмәтләре төште безгә. Тансыгым исән-сау бит. Менә бит!

Чут-чут китереп битләреннән үпте. Кочаклады, сыйпады.

Тансык та аның җылы гәүдәсен кочаклап, үзенең өшегән гәүдәсен, кулларын җылыта башлады.

—Нәнәй!—диде Тансык ялварып.—Син миңа кечкенә бер кисәк ипи бир инде. Тәүлектән артык ашаганым юк—үләм инде, ашыйсым килә. Юынгач, күп итеп ашатырсың...

Хәтирә апа бер кисәк ипи тоттырып, Тансыкны плитә янына утыртты. Су җылытырга куйды. Мич янында азрак җылынган малайны, кер кайната торган бак эченә утыртып, сабынлап ышкып юды да, өстәл янына утыртып, ике мәртәбә салып, тәмленең тәмлесе булган татар токмачы ашатты.

Үзен-үзе онытып йоклап киткән Тансыкның караваты янында догалар укып бик озак утырды Хәтирә апа. Бәхетсезлеккә дучар булган кияве Кавига, сеңлесе Сәрвәргә, аларның бердәнбер уллары Тансыкка Ходаеннан

мәрхәмәт һәм ярдәм сорый иде:

—... Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиймә вә галәә әли Ибрааһиймә иннәкә хәмийдүм-мәҗийд...

—... Раббәнәә әәтинәә фид-дүнйәә хәсәнәтәү-үәфил әәхыйрати хәсәнәтәү-үәкыйнәә газәәбән-нәәр»...

Бер атна узгач, утын күтәреп подвалдан чыгып килгән Тансык, ишегалдына кереп килгән милиционерны күреп, аяклары белән сәрмәнә-сәрмәнә иелә биреп, кире подвалга төшеп китте. Подвал ишегенең тактасы ярыгыннан милиционерның үзләренең подъездына кереп киткәнен чамалады. Аның югарыга итек үкчәләре белән шак-шок басып күтәрелгәне ишетелә иде. Тансык аз гына көтте дә, бау белән бәйләгән утын агачларын идәнгә тавыш чыгармыйча гына куеп, аяк очларына гына басып подвалдан чыкты. Өй диварына сыена биреп ышыкланып урам якка атлады. Урамны аркылыга йөгереп узды да , якындагы Ленин исемендәге паркка, тар сукмактан агачлар арасына ыргылды. Тик кышкы парк үтәдән-үтә күренә иде. Өстәвенә, көне дә суык. Озак уйлап тормады, парктан Ленин урамына чыкты да, сәгатьтән артык бер кибеттән икенчесенә кереп, вакыт уздырып җылынып йөрде...

Өйләренә караңгы төшә башлагач кына кайтты ул. Подвалга керде. Утын бәйләмен аркасына салып күтәрде дә, аяк астындагы баскыч бүлекләрен саный-саный өскә, үзләренең фатирына менеп китте. Утын күтәреп килеп кергән Тансыкны түтәе елый-елый кочаклап алды.

—И-и, йөрәк май-ый-ым! Сине алып киттеләр, ахрысы, дип мин кайгы-хәсрәт эчендә йөзәм монда. Сине эзләп милиция килгән иде. Мин инде анарга: "5 гыйнварда алып киткәние НКВД, шуннан бирле кайтканы юк",—дидем. Милиционерлар әйтә, ул егет колониядән качкан, ди. Татар үзе—күзләре елмая. Мин инде кайгыга төштем, анарга: «Берәр җирдә туңып үлгәндер инде, сабый—кыш көне җылы җирдән кеше качамы соң инде?!—дип әйттем, кайгырдым. «Кайтса, безгә хәбәр итегез!»—дип китте. Хәзер менә, хәбәр итмини, итте ди. Тотыгыз капчыгыгызны!

Әтисе «халык дошманы» дигән исем белән НКВД кулына эләгеп, төрмәгә утыртылганның иртәгәсендә үк, Тансыкның ишегалдындагы яшәү, уйнау, малайлар белән аралашу шартлары үзгәрә. Халык дошманы малае белән берәүнең дә уйныйсы, аралашасы килми. Өстәвенә, үзеннән зуррак «патриотик» пионер малайлар Тансыкны төрткәләү, аны этеп егу, маңгаена чиртү кебек җәберләүләрне күп кулланалар. Әтисе «утырганнан» соң ай үтәр-үтмәстә Тансык үзләренең ишегалдына уйнарга чыгудан туктап, анда малайлар берәр уен оештырсалар, тиз генә ишегалдыннан йөгереп үтеп китәргә өйрәнә.

Беркөнне, базардан сатып алган биш кило бәрәңге күтәреп кайтып килгән чакта, әтисе кибет директоры булып эшләгән Витя-Виталий Тансыкның юлына аркылы төшә:

—Ну, халык дошманы токымы. Букчаңда нәрсә синең? Ә? Иптәш Сталинны шартлата торган бомбамы, минамы, гранатамы?

Тансыкның уң колагыннан эләктереп алып, аны каты итеп бора башлый. Тансык, бәрәңге тутырган букчасын җиргә ташлап, ике куллап Витекның кулларына ябыша, шатырдап борган колагын коткарырга тырыша.

—Ә, халык дошманы малае-е! Авыртамы-ы?

Икесен уратып алган малай-шалай, кыз-кыркынга кызык: «Шулай кирәк «халык дошманы» малаена»!

Шулчак Витекның колагыннан дәү гәүдәле бер абзый эләктереп алды да, аны азрак һавага күтәргән кебегрәк итеп, Тансыктан аерды. Витек чинап кычкырып җибәрде:

—Ой-ой-о-ой! Авырта бит, җибәр!

Шулчак төркем янында Витекның әтисе, кибет директоры пәйда булды:

—Җибәр минем малайны! Төрмәдә черисең киләме?

Теге кеше малайның колагын ычкындырып, янап торган «директор»га борылды:

—Син кем булдың әле?

—Мин бу малайның әтисе. Кибет директоры. Ә син кем?

«Кеше», азрак үрелебрәк, «директорга» пышылдап кына берничә сүз әйтте. Тегесе ап-ак булды.

—Бар! Кереп кит көчегеңне алып өеңә. Юкса, малаеңның колагын борган кебек мин синең колагыңны башың белән бергә борып алырмын. Пошел вон!

Директор, малаен җитәкләп, таю ягын карады.

Бу кеше төрмәдән чыккан кесә буры Фаза—Фазулла иде. Яше дә кибеп бетмәгән Тансыкны кочаклап, үзенә кысты. Үзләрен уратып алган малайларга, кызларга көлгән күзләре белән карап елмайды.

—Мин Казандагы иң зур төрмәнең нәчәлнигы. Кем дә кем минем дус Тансыкны җәберли икән төрмәгә алып китәм дә, иң караңгы камерага ябып куям. Тиеп кенә карагыз минем Тансык дуска!

Тансыкны кочаклаган килеш фатирына алып менеп китте. Бик озак утырмады—Хәтирә апа белән сөйләште:

—Син, апа, НКВДга бар, курыкма. Шунда дежурныйга әйт: «Кави Нәҗмидән сорау алган тикшерүче Усмановка әйтәсе фактлар бар. Кави Нәҗми турында, диген. Сине шунда ук кабул итәчәк ул. Кергәч утырып та торма, турыдан-туры әйт: «Әгәр Кавиның улы Тансыкны эзәрлекләүдән тукмамасаң, кулга алганчы Кави Нәҗми янына, өенә килеп йөри иде дип мин синең өстеңнән донос язам, диген. Кавины «халык дошманы» дип гаеплисез икән, аның янына килеп йөргәнгә син дә «халык дошманы» булып чыгасың! Шулай диген.

—Әй, иркәм! Бик куркам бит мин НКВДдан.

—Куркасыңмыни? НКВДга барып эләксә, Тансык аннан исән чыкмаячак. Бел шуны, белмәсәң.

—Өйрәтүен өйрәтәсең дә үзең кем булдың соң әле син?

—Казан каласының иң бәхетле егете мин. Исемем—Фазулла. Шул җиткән сиңа. Кави абый белән бер камерада утырдым мин июль-август айларында. Кирәкмәгәнгә, чыгарып җибәрделәр мине. Дуслар без Кави абый белән. Гади дуслар гына түгел—төрмә дуслары.—Шулай диде дә урыныннан тора башлады.

—Хәз-зер, чәем өлгерә, Фазулла. Бер генә чынаяк булса да эчәрсең.

—Яса, алайса. Татар апаларының чәеннән дә тәмлерәк чәй—төрмәдәге кайнар чәй генә ул.

Ап-ак тигез тешләре белән кисәкле шикәрне китеп каба-каба, ике чынаяк чәй эчте дә, китәргә кузгалды.

—Бисмилланы укып ятим малай Тансыкка хәер итеп ал, Хәтимә апа. Азрак акча сезгә миннән.

Каушый төшкән Хәтимә апаның кулына кызыл төстәге өч утызлык тоттырды да, бетмәс-төкәнмәс базар кәсебен башкарырга дип чыгып китте мәрхәмәтле йөрәкле элекке бай малае, бүгенге кесә буры Фаза—Фазулла.

Әтисез-әнисез тормышлары авырайганнан-авырайды. Хәтирә апаның кибет идәннәре себереп, юып алган алтмыш тәңкә акчасы юклы-барлы ашауга тоташы белән китеп бетә торды. Милиция кулына эләкмәс өчен, Тансык күбрәк вакытын аулак урамнарда, парк-бакчаларда йөрде. Шулай

юкны бушка аударып йөргән бер көнне анын күзе паркка керә торган капка төбендә утырган, үзеннән азга гына зуррак өч малайга төште. Малайлар кәсеп итәләр иде. Алар өчесе дә алларында аяк куяр өчен ясалган кечкенә тартмага ике щетка белән барабан каккан тавыш чыгаралар да сөрән салалар:

—Бот-тинки. Туфли-и! Сап-поги-и чистим! Черные, коричневые кремы имеются. Чисти-им сап-поги-и! Чистим—ботинки! Подходите по одному.

Кешесенә карап (акчалымы икәнен чамалап инде) бер пар аяк киемен гуталинлап тазартканга малайлар 20-30 тиен акча алалар икән.

Кызыкты бу малайларга. Ниятен Хәтирә апасына сөйләде.

—Ул шүтке, гутаминнар алырга акча кирәктер инде?—диде апасы.—Әййеме?

—Кирәк инде.

Ул Тансыкка өч сум акча тоттырды.

—Хәзергә шүткене икене генә ал. Кара гуталинга кара кыллысын, сары гуталинга ак кыллысын ал. Югалта күрмә акчаңны!

Ике көннән Тансык, акча эшләргә исәпләп, Ленин исемендәге бакча-паркка кергән җирдә теге малайлар янына барып утырды. Малайлар бер-берсенә карашып алдылар. Зуррагы сорады:

—Син кем? Исемең ничек?

—Тансык.

—Әтиең бармы?

—Юк.

—Кайда?

Әтисенең кайда икәнен әйтәсе килми иде.

—Белмим...

—Кем белән торасың? Әниең бармы?

—Әнием дә юк. Нәнәй белән генә яшибез.

—Ятиммени син?

Тансыкның күзе әчетә башлады.

—Ятим.

Малай иптәшләренә карады да, алардан сорады:

—Утырсынмы?

Берсе җавап бирде:

—Утырсын, Хәмит. Ятим бит. Ул ботинка, итекләр барыбызга да җитәр!

1938 елның май башыннан җәй, көз үтеп, кыш башланганчы Тансык шул урында аяк киеме чистартып, акча эшләде. Кайбер уңышлы көннәрдә өч тәңкә тирәсе акча җыела иде. «Нужа печән ашата!»—ди татар. Ун яшенә кадәр нужа-михнәт күрмичә, балда-майда йөзеп кенә үскән иркә малай нужа-михнәт белән көрәшкә кереп китте.

Ишегалдында Фазулла абыйсы «директорны» куркытканнан соң, Тансыкка тиюче булмады. Тик бер көнне, өйләдән соң гына, тартмасын күтәреп эштән кайтып килгәндә аңа каршы йортта яшәгән бер малай фатир тәрәзәсеннән кычкырды:

—Әй, син, дошман малае! Әтиенне атканнар. Бүген радиодан әйттеләр.

Җиргә төшеп киткән тартмасын кулына алды да, күз яшьләрен тыя алмыйча, Тансык өенә кереп китте. Кергән уңайга ук тартмасын ишек төбенә ташлады да, караватына йөзтүбән тәгәрәп, үкси-үкси елый башлады.

—Әй, Ход-дайы-ым!—диде куркынган Хәтирә апасы.—Тансык! Балам, ни булды? Нигә елыйсың? Тукта!

—Нән-н-н-ә-әй! Безнең әтине атканнар, тәрәзәдән шулай дип кычкырды әле генә бер малай.

—Каян белгән инде ул?

—Радиодан әйткәннәр.

—Алдый ул, балам. Алдый. Сина начар булсын дип. Мин дә бит радионы тыңладым. Әйтмәделәр алай дип. Әйтмәделәр. Тынычлан.

Караваt янында азрак басып торгач, өстәде:

—Әнә, Тухачевскийларны суд ясап аттылар. «Тройка» судить итте аларны. Әтиенә әле суд булганы юк. Нинди ату ди судсыз?

***

Уйлый белә торган Мирсәй Әмир Тухачевский төркемен аткач ук аңлады: «Бу хакимият бик күпләрне юк итәчәк!» Чөнки Маршал хәтле Маршал Тухачевскийны, аның белән бергә илнең иң зур, иң батыр, иң тәвәккәл командирларын кулга алып, бер атна эчендә юк иткәч, безнең кебек вактөякне болар санап та тормаячаклар...

Кабинет ишеген эчтән бикләп, Мирсәяф япа-ялгызы кичкә кадәр утырды. Уйлады да уйлады. Һәм башына килгән бик хәвефле бер уйдан арына алмады: «Әгәр кызулыгы өстенлек алып, башы эшләүдән туктап, Сәрвәр минем өстән язып НКВДга шикаять тапшырса? Бетте бит минем баш! Кавины бер гаепсезгә илтеп тыктылар. Өстәп Сәрвәр, минем өстән язса, мине дә илтеп тыгачаклар. Баш бетә бит!

Куркудан коты очкан Мирсәй Әмир, Сәрвәр өстеннән шикаять язып, икенче көнне иртән НКВДга тапшыра. Шикаятьтә язылганны укып чыккач, Сәрвәр белән «эшне» НКВД тикшерүчеләре кыска тоталар: халык дошманы хатыны бит! Сорау алган чакларда Сәрвәр Әдһәмова үзен бәйсез итеп, курку белмичә, тикшерүчеләр белән «баш бирмичә» сөйләшә белә. Куркытып та, юмалап та сөйләшергә маташкан тишерүчеләргә Сәрвәр: «Беткән баш беткән!»—дип, бер генә мизгелгә дә алар әйткән, алар кушкан белән килешми. Халык дошманы Кави Нәҗми түгел, ә менә сез, аны батырып юк итәргә маташканнар, халык дошманнары! Сез үзегез!

Мирсәяф үзенең куркудан ясаган кара эшенә гомере буена бик тә үкенә. Сәрвәрнең судында аны шаһит итеп чакыралар. Һәм судда Мирсәяфнең Сәрвәр өстеннән язган шикаятен укыйлар. Суд 1938 елда 11 августта уздырыла. Суд барышында Сәрвәр Әдһәмова каушамыйча, еламыйча, үзен батырларча тота. Тагылган гаепләрнең берсе белән дә килешми, барысын да кире кага. Үзе биргән сораулар белән шаһитлар биргән ялган күрсәтмәләрне фаш итә. Шаһит итеп судка чакырылган Мирсәй Әмир язган шикаятеннән баш тартып карый. Тик эш узган—суд аны исәпкә алып та тормый. Батыр йөрәкле хатынны Мирсәй Әмирнең куркудан язган шикаяте аркасында ун елга лагерьга озаталар һәм биш елга хокукыннан мәхрүм итәләр. Суд карарын ишеткәч, Сәрвәр сикереп тора да, ике кулын өскә йодрыклап бар көченә кычкыра: «Минем бер гаебем дә юк! Дөреслек барыбер җиңәчәк! Оят сезгә!»

Суд залында елый-елый Хәтирә апа белән Тансык та утыралар.

Сәрвәр Әдһәмованы Себергә лагерьга озаталар. Судтан соң аны Кремль янындагы төрмәдән Бишбалтадагы Петрушкин разъездындагы (Пересыльная) озату төрмәсенә күчерәләр.Үзенең шунда икәнен төрмәдә аш пешерүче аркылы Сәрвәр Хәтирә апага хәбәр итеп өлгерә. Хәтирә апа Тансыкны иярә тәп төрмәгә бара. Тоткыннарның ишегалдына «һавага» чыкканын алар икәү капка төбеннән китмичә көтеп алалар. Тансык әнисен ерактан ук танып алып: «Әнием!» дип кычкыра. Капка төбендә сакта торган милиционер Тансыкны кызганып, әнисе янына кертеп җибәрә:

—Йөгер, бар! Озак тормаска тырыш, улым, йөгер!

Тансык бик нык йончыган, ябыккан әнисен күреп тетрәнә. Йөгереп барып әнисен кочаклый да, елап та җибәрә.

—Әни! Әнием минем! Әние-ем!

Сәрвәр, улын җитәкләп, төрмә дивары янына алып китә. Көн җылы. Тансыкның өстендә ямалган, тузган күлмәк, тез башлары ямаулы иске кыска чалбар, тишек ботинка. Үзе ябык, муены озынайган, колаклары зурайган, күзләре тулы яшь. Алар бертуктаусыз агалар да агалар... Кочаклашып бик озак утыралар. Капка саклаучы милиционер әйбәт кеше булып чыга.

Сәрвәр өстендәге җылы калын кофтасын салып, Тансыкка бирә.

—Хәтирә апана бир! Базарда сатсын да, сина мәктәпкә йөрерлек кенә булса да азрак юньле кием алсын.

—Әнием! Ә син үзең кофтасыз каласын бит.

—Озатыр алдыннан безгә җылы киемнәр бирәбез диделәр. Кайгырмагыз минем өчен.

Кочаклашкан килеш капка төбенә кадәр бара. Сәрвәр елый-елый сөекле улын битләреннән берничә мәртәбә үбә дә, башыннан сыйпап капкадан чыгарып җибәрә. Аерылышалар...

Ана белән бала шул көннән соң бер-берсен ике ел ярым күрмәделәр...

***

Казанга СССР прокуратурасыннан Коперник фамилияле юрист җитәкләгән комиссия килеп төшә. 1939 елның 8 гыйнварында Татарстан өлкә комитетында Коперник чыгыш ясый: "НКВД органнарын социалистик кануннарны бозучылардан «чистартырга» кирәк",—ди ул. Аның күрсәтмәсе буенча берничә дистә тоткын иреккә чыгарыла. Шулар арасында Казан университеты ректоры Г. Камай, зур галим Б. Арбузов та була.

1938 елның 21 гыйнварында бөек язучы Галимҗан Ибраһимов үлеме НКВД җитәкчеләренә һич тә көтелмәгән мәшәкатьләр китереп чыгара. Кешене кыйнап, атып юк итүдән башканы уйлый белмәгән миләрен «эшкә җигәргә» мәҗбүр итә. Нишләргә «халык дошманнары» белән? Татарстандагы контрреволюционерлар, «халык дошманнары», «троцкий-бухаринчылар», татар милләтчеләре "җитәкчесез" торып калдылар бит! Тырыша-тырыша ямап, тегеп, ябыштырып, юктан бар иткән хакимияткә каршы булган оешма җитәкчесез калып юкка чыга бит?!

Һәм, Галимҗан Ибраһимов үлгәннән соң бер ай чамасы узгач, НКВД «машина»сы яңадан «дошманнар оешмасы» төзергә тотына. Бу юлы «контрреволюцион оешманың җитәкчесе» итеп ... Кави Нәҗми билгеләнә. Татарстан партия өлкә комитеты секретаре итеп билгеләнгән Алемасов яңа халык комиссары итеп куелган капитан Михайловны «үзе тынлый». Ике НКВД палачы киңәш итәләр: ни эшләтергә язучы Кави Нәҗметдиновны? Һәм Алемасов Михайлов тәкъдим иткән «яңа вариантны» хуплый:

—Саграк кыланыгыз! Нәҗметдиновны Ибраһимов кебек кыйнап үтереп куймагыз! Нәҗметдинов тулысы белән сезнең кулда инде. Сез тәкъдим иткәнгә риза булмаган очракта шул актларны укытыгыз сез аңа.

Кави Нәҗми милләтче, контрреволюцион, халык дошманнарының яшерен оешмасының җитәкчесе булырга тиеш! Һәм дөрес икәнен танып кул куярга тиеш!

Кави Нәҗмине ярты елдан артык сорау алып, «эссе һәм салкын мунчалар» кертеп, ике күкәен сытып, күрмәгәнен күрсәткән Усманов белән Зыков аңарга тагын тотыналар...

Февраль урталарында җәзалаулардан котылып, азрак кеше төсе керә башлаган (төрмәдәге тоткынга кеше төсе каян килсен инде?!) Кавины тагын

Усмановка алып керәләр.

Сәгыйр Усманов кеше җәзалаудан, аны интектереп, акыртып сорау алудан үзенең вак, мәкерле җанына рухи ризык таба иде. Кавины күргәч, корбанын тоткан ач ябык бүре төсле күзләре ялтырап-ялтырап китәләр.

—Утыр, Кави Нәҗми! Татар халкының исемле язучысы исән калса, аның классик язучы да булыр әле ул. Шулаймы?

Кави дәшмәде. Башын аска таба ия төшеп, алдында тын гына басып тора бирде.

—Утыр, Кави! Бүген сорау алу булмаячак. Мин сиңа Галимҗан Ибраһимов үлгәннән соң килеп чыккан ситуацияне аңлатам хәзер. Во-первых, Ибраһимов, үлеп, сине бик авыр хәлдә калдырды. Шунлыктан, во-вторых, синең контрреволюцион эшең, «халык дошманы» һәм «татар милләтчесе булуың» тоташы белән башкача бәяләнергә тиеш. Аңлыйсынмы?

—Юк.

—Алайса, утырып тыңла. Утыру аңларга ярдәм итә ул.—Урындык аркасына терәлеп, тураеп утырды. Озак кына Нәҗмигә карап, сүзсез генә нәрсәдер уйларга маташты. Тик уйлар түземе житмәде—«эшкә тотынды»:

—Менә нәрсә, Нәҗметдинов. Галимҗан Ибраһимов, мишәрләр әйтмешли, «катты». Ну и черт с ним! Төп җаваплылык хәзер синең җилкәңә төшә, дус кеше. Син контрреволюцион оешма белән җитәкчелек итүне үз өстеңә алырга тиешсең.

—Аңламыйм.

—Шәп аңлыйсы-ың! Еще как! Оказывается, контрреволюцион, татар милли оешмасын син оештырып, син җитәкләгәнсең икән. Ә Галимҗан Ибраһимов сине, җитәкчене прикрывать итеп, НКВДга допроста үзен җитәкче итеп күрсәткән икән. Менә бит ничек икән, ә?!

—Мин җитәкче түгел.

—Түгел икән, итәрбез. Колунга бирсәк, ризалашырга синең срогың өч көн! Сытарга Күкәйләрең юк-югын. Тик, Колунга эләксәң, әйбер табачак ул. Сытарга, диюем...

Басып өстәл артыннан чыкты да, бүлмә буйлап арлы-бирле йөренә башлады.

—Хатыныңны кулга алдык. Улың Тансык та безнең кулда. Так что, сытарга тагын ике күкәй бар бездә. Хатыныңны пытка астына синең күз алдында тыгачакбыз...

Аннары Кави алдында тукталды:

—Иң акыллысы синең өчен, Кави, менә болай булырга тиеш. Син җитәкчелекне тулысы белән үз өстеңә аласың. Шулай эшләсәң, хатының белән улыңа тимибез. Бар, кайт камераңа, уйла. Бер тәүлек сиңа уйларга. Иртәгә шушы вакытта сөйләшүне дәвам итәрбез...

Ярты елдан артык төрмәдә ятып, «колуннар» кулыннан күргән җәзалардан, сорау алулардан Кави рухи яктан да, физик яктан да сынган иде инде. «Ворон» озатуында төрмә коридоры буйлап атлаган чагында башында куркыныч уй туды: «Үземне үзем бетерергә кирәктер, ахрысы!» Шул уй белән төрмә камерасына, шул уй белән топчанына менеп ятты. Уй ныгыды һәм Кави аңа буйсынып, үзалдына: «Ничек итеп?»—дигән сорау куйды. Тик дөнья белән хушлашырга көче дә, рухы да җитмәде... Күз алдына улы Тансык килеп басты. Озын муенлы, ике зур колаклы, тыныч холыклы, укуга да тырыш кына малай... Әтисе китеп барса, аны нинди язмыш көтә инде? «Төрмәдә үзен-үзе үтергән «халык дошманы» улы булып кала бит инде мәңгегә. Күзләрен мөлдерәтеп Тансык үзенә карап торган кебек тоелды...

Икенче көнне Кавидан кабаттан сорау алулар башланды...

Хатыны Сәрвәр белән улы Тансыкны палачлар кул астына бирмәс өчен Кави үлемгә дә әзер иде. Һәм ул карар кылды: Усманов таләп иткәннәргә риза булырга һәм нинди генә гаеп өстәп язсалар да, протоколга кул куярга. «Беткән баш беткән инде!»—дип, өметен өзеп Кави кул селтәде.

Алты айга якын барган сорау алуларда Кави үзе дә батты һәм байтак язучы дусларын да батырды...

Нәтиҗәдә Кави Һибәтулла улы Нәҗметдиновны гаепләү акты төзелде.

Гаепләү актыннан: "Совет хакимиятенә каршы 1922 елдан бирле контрреволюцион эш алып барган. Хәрби контрреволюцион мятеж әзерлеге уздырган, контрреволюцион хәрби оешманың бик тә актив әгъзасы һәм баш житәкчесе.

Уздырылган тикшерү нәтиҗәсендә түбәндәгеләр ачыкланды: К. Һ. Нәҗметдинов 1922 елда Казанга кайтып Галимҗан Ибраһимов белән элемтә урнаштыра. Галимҗан Ибраһимов Советларга һәм Коммунистлар партиясенә Нәҗметдиновны каршы котыртып аны эшкәрә һәм 1924 елның көзендә аны контрреволюцион оешмага җәлеп итеп кертә. Хәрби татар-башкорт мәктәбендә укытучы буларак, контрреволюцион оешманың әгъзасы буларак, Нәҗметдинов, буржуаз, татар милләтчесе Усманов Шамилнең контрреволюцион төркемендә исәпләнә һәм аның эшләрендә катнаша.

1925 елда Нәҗметдинов Галимҗан Ибраһимов белән берлектә «Татар һәм башкортлар Кызыл Армиясе сафларында» исемле китап бастырып чыгара. Ул китапны чыгаруның максаты Гражданнар сугышы чорында татар һәм башкортларны урыслардан да батыр сугышкан итеп күрсәтеп, аларның милләтче йөзен яшереп куюда.

1927 елда К. Г. Нәҗметдинов контрреволюцион «Җидегән» оешмасында, ВКП(б) ҮКының Татарияда яналиф кертү карарына каршы чыга.

1931 елда контрреволюцион татар милләтчеләре оешмасының житәкчесе буларак, шул контрреволюцион буржуаз, татар милләтчеләре оешмасына язучылар Мирсәяф Әмирне, Фатих Кәримне һәм 1932 елда Гыйльфанов Сафаны, Хәсән Туфанны җәлеп итә.

Нәҗметдинов 1933 елда Татариядә уң троицкийчыларның милләтчел татар блогын оештыра һәм үзенең контрреволюцион эшен Татариянең Язучылар берлегендә киң итеп җәелдереп эш алып бара башлый. Шул Берлектә милләтчеләрне оештырып, аларның ВКП(б)га каршы контрреволюцион эшләре белән житәкчелек итә.

Сорау алганда Кави Һибәт улы Нәҗметдинов әлеге актка кул куеп, гаепләүләрне тулысынча таныды.

Гаепләү акты 1939 елның 11 мартында К. Г. Нәҗметдиновка тапшырылды. Бернинди дә килешмәгәнлек белдермәде".

1939 елның 14, 17 һәм 19 март көннәрендә (өч көн) Татарстан Югары Советының Суд коллегиясе Кави Нәҗмине хөкем итә. Судның рәисе Аитов, суд утырышчылары Рәхимов һәм Сәмигуллин дигән кешеләр була. Шул судның ябык утырышында кулга алынган Кави Нәҗметдинов һәм Мирсәяф Әмировның эшләре карала.

16 һәм 17 мартта суд барышында Нәҗметдинов үзенә карата күрсәтелгән гаепләрнең барысы да дөрес дип, үзенең ризалыгын белдерә һәм бер-бер артлы һәр гаепләүдә тукталып киң аңлатмалар бирә.

«Халык дошманы» Галимҗан Ибраһимов белән булган мөнәсәбәте турында аңлатма бирә. «1922 елда Ибраһимов «Безнең юл» журналының редакторы иде. Шул Ибраһимов киңәше буенча мин Гражданнар сугышында Кызыл Армиядә сугышкан һәм исән калганнарның истәлекләрен җыйдым. 1925 елда шул истәлекләр альбом итеп чыгарылды.

Галимҗан Ибраһимов белән мин 1937 елга кадәр, кулга алынганчы,

элемтәдә булдым. Ялтага анын янына бардым. Авыру Галимҗан Ибраһимов янына барып йөрүне мин контрреволюцион эш икәнен анламаганмын ул чакта...»

16 һәм 17 мартта суд барышында Нәҗметдинов үзенә карата тикшерүчеләр тарафыннан күрсәтелгән гаепләрне тулысы белән таный һәм барлык күрсәтелгәннәр буенча тулысынча анлатмалар бирә.

Татар алфавитын латин хәрефләренә күчерүгә каршы чыгуы турында судта Нәҗметдинов түбәндәге анлатманы бирә.

"Әйе, мин Кави Нәҗметдинов, латин графикасына каршы чыктым һәм жиде кешедән торган төркем эчендә ВКП (б) Үзәк Комитетына ризасызлык белдереп язган хатка кул куйдым. Бераз вакыт узгач, мин үземнен хатамны анлап, шул турыда матбугатта мәкалә язып чыктым. Шунлыктан латин графикасы турында ясаган хатамны төзәттем дип уйлыйм".

Суд залына керә торган ишек төбенә Кави Нәҗми белән Мирсәяф Әмирне алданрак алып килеп, ишек төбендәге эскәмиягә утыртып куялар. Ике милиционер аларны саклап шунда басып тора. Коридорның аргы очыннан тикшерүче Сәгыйр Усманов белән Николай Зыков күренә. Аларны күреп калган Кави урыныннан сикереп тора да, «смирно» басып, кулларын «по швам» төшереп, атлап килгән Усманов ягына башын борып үрә ката. Бөтен тәне вак кына итеп калтырый. Усманов белән Зыков тоткыннарга күз дә салмыйча, суд залына кереп китә.

—Син нигә сикереп тордын, Кави абый?—дип акрын гына сорый Мирсәяф.—Әллә курыктын инде Усмановтан?

—Куркам шул мин. Бик нык куркам ул Усмановтан. Син анларлык түгел минем куркуның сәбәбен.

—Әйтеп кара, бәлки, анлармын.

—Тынла, алай теләген булса. Сине, Мирсәяф, сорау алырга алып чыгып китәләр. Ике-өч сәгатьтән син Усманов кабинетыннан, үзебезнен камерага үз аякларың белән атлап кайтып керәсең. Ә мине 2-3 тәүлек сорау алганнан сон, камерабызга өстерәп китереп ыргытып китәләр. Мин бүген дә анлый алмыйм—Усманов бит сина «физическое воздействие»ләрне кулланмый. Сине бүген камерадан алып килделәр, ә мине карцердан. Икебез ике сортлы арестантлар без. Син—бер, ә мин—икенче. Хәзер уйла инде, минем ни өчен курыкканны...

Мирсәяф җавап биреп өлгерми, кырыйда басып торган милиционер пышылдый:

—Кави абый! Тукта инде сөйләшүеннән! Не положено бит, инструкция буенча.

Тагын ун минут чамасы сөйләшмичә утыргач, икесен дә суд залына алып кереп, ин алдагы эскәмиягә утырталар.

Суд 19 мартта 13 сәгать 30 минутта башланды. Судья: «Суд ачык!»—дип игълан итү белән Кави Нәҗметдинов аягүрә торып баса да, тәвәккәллеге янгырап торган тавыш белән сөйли башлый:

—Гражданин судья! Мине ун көннән артык инде тикшерүче Усманов боерыгы буенча салкын карцерда тоталар. Һәр иртән Усманов минем янга карцерга кече лейтенант Коргановны алып кереп кыйнатып чыга. Үзеннен күрсәтмәләреннән судта баш тартсан, сине Минзәлә төрмәсендәге мичкә озатабыз дип куркыта.

Мин, Кави Нәҗметдинов, СССР гражданы буларак, судтан мина гадел суд ясавыгызны һәм тикшерүче Усмановтан мине яклавыгызны таләп итәм...

Судья, аптыравын яшермичә, Кавинын әйткән сүзләрен кабатлап сорый:

—Сез... тоткын... таләп итәсез?

—Таләп итәм. Бу минем тоткын буларак та хокукым.

—Ярар, утырыгыз.

—Мин утырмыйм. Бу әйткәннәрем минем бүген сөйли торганның башы гына. Хәзер мин үземнең иң мөһим уйларымны, чынбарлыкны сөйлим.

Судья:

—Тыңлыйбыз сезне, Кави Нәҗметдинов.

Сул як дивар янында утырган тикшерүче Усманов сикереп тора:

—Сүз бирмәгез Нәҗметдиновка, гражданин судья. Ул халык дошманы, татар милләтчесе. Үзе кул куйган сорау алу протоколларын гына укыгыз.

—Утырыгыз... иптәш Усманов. Без бит монда Нәҗметдиновтан сорау алучылар түгел. Ә аның гаепләме, түгелме икәнен ачыклап, суд алып баручылар. Утырыгыз урыныгызга.

—Сөйләгез, Нәҗметдинов! Кави тамак төбен кыргалап ала да, кабаланмыйча гына, һәр сүзен уйлап, үлчәп сөйли башлый:

—Мин үзем житәкләгән контрреволюцион оешма барын тикшерүче Усмановтан гына белдем. Бернинди контрреволюцион оешма юк, димәк, мин, Кави Нәҗметдинов, аның житәкчесе дә була алмыйм. Тикшерүчеләр Усманов, Зыков, Корганов алып барган сорау алулар миңа карата мораль яктан да, физик яктан да куркытулар, басым ясаулар, физик җәзалар кулланып үткәрелде. Җәзалауларга түзәрлек түгел һәм мин шулардан котылу өчен, юк гаепләремне бар дип танып, протоколларга кул куйдым. Усманов миңа, әгәр дә мин кушканча үз гаебеңне танысаң, гафу итүне сорап язсаң, сине, судимостең алып ташланды, дип ирекка чыгарачаклар, дип алдалады мине. Тикшерүче миңа әйтте: "Без таләп иткән "Барлык гаепләрне танып заговорда торганнарның исемлеген төзеп бир. Сиңа судта яклаучы кирәкми, аны таләп итеп маташма да. Син үзеннең контрреволюционер икәнлегеңне судта расла, үзеңне һәм башкаларның дошманлыгын санап чык. Һәм Совет суды синең үкенгәнлегеңне, ялгышканлыгыңны аңлап, корал ташлаганны күреп, ирекка чыгарачак. Гаиләңә кайтырсың!"—диде.

Дәшмичә хәл җыеп алды. Судья һәм ике утырышчы да Кави сөйләгәннәрдән бик нык гаҗәпләнеп дәшмичә утыралар иде.

—Тикшерүчеләр тарафыннан елдан артык вакыт эчендә мин шулкадәр махсус «эшкәртелдем», соңгы вакытта башым уйлый белү сәләтен дә югалта башлады. Мин бүген иртән килгәч кенә үземне Совет хөкүмәте судына эләккәнемне көч-хәл белән аңлый алдым. Чөнки соңгы ел ярым вакыт эчендә кыйнаудан, мәсхәрәләүдән, мыскыл итүдән, физик һәм мораль изүдән башканы күрмичә, кешеләрдә була торган кешелек сыйфатларын югалтып бетерә яздым инде. Тикшерүчеләр мине хатыным Сәрвәрне, улым Тансыкны, апаны кулга алып, синең күз алдында "физик воздействие аша үткәрәбез дип куркыттылар. Хатынымны кулга алып, спецлагерьга озатканнар инде. Ул да бер гаепсезгә утыра хәзер.

Тикшерүче Усманов мине куркытып, кыйнап язучылар Фатих Кәримгә, Мирсәй Әмиргә, Ләбиб Гыйльмигә, Хәсән Туфанга яла яктырды. Ул язучыларга мин яккан ялаларның берсе дә дөрес түгел.

Нык итеп сулыш алды да Кави, соңгы сүзен әйтте:

—Әйткәнемчә, тагын бер мәртәбә кабатлыйм: барлык күрсәткән ялганнарымнан мин, Кави Нәҗми, баш тартам. Бернинди дә контрреволюцион оешма юк, мин ул юк оешманың житәкчесе түгел. Минем гаебем берәү генә. Мин үземә ясалган төрле төрдәге басымнарга түзә алмыйча үз-үземә, дусларыма, язучы иптәшләремә яла яктым. Бу ялган күрсәтмәләр тикшерүчеләр басымы астында, көчләп эшләтелде. Мин беркемне дә вербовать итмәдем, язучылар Фатих Кәримнең дә, Мирсәй Әмирнең дә

бер гаепләре юк. Аларга яла ягып биргән күрсәтмәләрем өчен миңа оят һәм мин алардан баш тартам...

Суд дәвам итә һәм соңыннан карар кыла:

"Мирсәяф Әмировның бер гаебе дә юк дип табарга һәм аны суд залыннан ирекккә чыгарырга".

Кави Һибәт улы Нәҗметдиновны 58-10, 58-2, 58-11 РСФСР җинаять кодексының статьялары буенча гаепле дип табарга һәм 10 елга төрмәгә утыртырга, шуңа өстәп 5 елга хокукыннан мәхрүм итәргә..."

Мирсәй Әмир суд залында басып торып кала, Кавины кулын артка куйдырып, ике милиционер алып чыгып китә. Суд залыннан чыгу белән коридорда утырган Тансык әтисенә ташлана:

—Әтием! Әт-тие-ем!

Малай үксеп елый. Күңеле тулган милиционер аркасыннан сөя-сөя Тансыкны әтисеннән аерып алып, елап басып торган Хәтирә апасына тоттыра.

—Апа, җаным! Зинһар, җибәрмә инде бу малайны кулыннан.

Аның өчен безгә дә әләгә бит инде. Зинһар!

Кавины коридор буйлап алда булачак ун еллык төрмә тормышына алып китәләр...

К. Һ. Нәҗметдиновка суд карарын 21 мартта тапшыралар. Һәм Кави Нәҗми яклаучы Бабаджан аркылы кассацион жалу бирә.

1939 елның 22 июнь көнендә (төп-төгәл ике елдан Германия белән сугыш башланачак) рәисе Калеев, әгъзалары Кропачев һәм Ефимова булган РСФСРның Югары суд коллегиясендә янадан Нәҗметдинов К. Һ.ның «эше» карала:

«Докладчик Калеевны тыңлаганнан соң, яклаучы Санникова китергән дәлилләрне исәпкә алып, РСФСР прокуратурасы хезмәкәре Пресняковның ясаган нәтиҗәләренә таянып, суд карарын кире кагып, Нәҗметдинов «эшен» яңадан шул ук судта карарга кирәк дип табылды...

Суд коллегиясе суд карарын шул хәлдә калдырырга ярамый дип таба һәм күрсәтмәләргә таянып, аны танымаска дип карар кыла"

1939 елның 5 октябрендә карар кылына: «К. Һ. Нәҗметдинов «эшен» ТАССР НКВДсының тикшерү бүлегенә тапшырырга".

ТАССР НКВДсының тикшерү бүлегендә 1939 елның 29 декабрендә күрсәтелгәнчә, бер генә шаһит та Нәҗметдиновның Советларга каршы көрәшү фактын әйтә алмый. «Шаһитлар китергән фактлар һәм тикшерүчеләр кулындагы башка материаллар Кави Нәҗметдиновның Советларга каршы булган контрреволюцион эшләрен дәлилли алмый. Элек китерелгән «гаепләр» тик буш уйдырма гына булып чыга. ТАССР НКВДсының тикшерү бүлеге карар кыла: «1901 елда туган Кави Һибәт улы Нәҗметдиновны гаепләү дәлилләре җитмәгәнлектән, «эшен» туктатырга, гаепләнүчене сак астыннан азат итәргә".

Азат итү көне «эшендә» күрсәтелмәгән. Болардан башка Фатих Кәрим «эшендә» суд утырышының 13, 14 марттагы беркетмәсендә күрсәтелгәнчә, Кави Нәҗми шул судта шаһит булып чыгыш ясаган.

1939 елның 19 июлендә Кави Нәҗми СССР прокуроры исеменә гариза язган. Шунда түбәндәгене күрсәткән:

"Мин, татар совет язучысы Нәҗметдинов (Кави Нәҗми) һәм яшь, талантлы язучы шагыйрь Фатих Кәрим, һәркем аерым РСФСРның Югары судына кассацион жалу җибәрдек.

Тикшерүләр вакытында тикшерүчеләрнең мораль, психик, физик җәзаларына, басымнарына түзә алмыйча, мин алар кушканга буйсынып, алар уйлап чыгарган беркетмәләргә кул куярга мәҗбүр булдым.

Мина карата физик, психик, мораль көчле басымнар, минем эшем Югары судка озатылгач та туктамады. Фатих Кәрим судында да, үзем өстеннән башланган суд чорында да мин тикшерүчеләр уйлап чыгарган гаепләүләрне кабатларга мәҗбүр булдым.

Минем белүемчә, Югары суд безнен «эшләребезгә» гаепләү ягыннан гына караган. Шулай икәнлеге Фатих Кәримгә карата чыгарылган карардан ачык күренә.

Мин тагын бер кат кабатлап әйтәм: яшь совет шагыйре Кәримов Фатихның "Кызылармеец" редакциясендәге контрреволюцион оешмага бер катнашы да юк, чөнки андый оешманың булганы да юк..."

Фатих Кәримнең Кави Нәҗмигә мөнәсәбәте шагыйрьнең 1940 елның 12 май көнендә СССРның Югары суд рәисенә язган гаризасында бик ачык күренә. Ул болай дип яза: «...Сез сорап алдырган һәм бүгенге көндә сезнең карамакта булган минем «эшемдә» Нәҗметдинов К. Һ. нын ике гаризасы бар. Шул гаризаларда Кави Нәҗметдинов үзенең тикшерүчеләр тарафыннан көчләп кул куйдырган минем «эшем» турындагы ялган күрсәтмәләреннән баш тартуын язган. Ул анда антисоветчыл оешманың һичкайчан да булмаганын, ул күрсәткән кешеләрнең, шулай ук Фатих Кәримнең андый оешмаларда катнашмавын белдереп яза"...

1939 елның 30 декабрендә Хәтирә апа, һәм Тансык кичке ашны азрак бәйрәмчә итеп ашарга утырдылар. Бер көннән яна ел бит! Өстәлдә—ак ипи, хәлвә, чәй. Акрын гына ишек шакыдылар. Милициядән качып йөрүдә инде бик тә тәҗрибәле булган «халык дошманы улы» Тансык тиз генә өстәл артыннан чыкты да, караватт астында торган фанер тартма эченә керә дә башлады. Куркынган Хәтирә апа ишек янына барып, акрын гына сорады:

—Кем ул анда?

Ишек артыннан сагындырган, кадерле тавыш ишетелде:

—Мин бу, Кави!

Тартмага кереп бетә язган Тансыкка Хәтирә апа көлеп кул селтәде:

—Чык тизрәк, балам! Әтиең кайтты бит! Менә куаныч, шатлык безгә!

Ишекне ачып җибәрделәр.

—Әт-ти-и! Ниһаять, кайттын! Әтиебе-без!

Өй эче шатлык белән тулды. Кави авыр гына атлап бүлмәгә узды да, өстәл янына килеп утырды. Өстендә күп ямаулар салынган соры солдат шинеле. Иске, йоннары коелган бүрек, аякта арттан куныччлары ак җеп белән тегелгән итек. «Конвейер» узган чакта тәүлекләр буена палачлар алдында басып торып, аяклар гөбе кебек шешкән. Сорау алудан кайткач, итек салдырырга бернинди көч ярдәм итми. Кеше ярдәме белән дә салынмый. Шунлыктан, арттан ерып җибәреп кенә Кави итекләрен сала алды. Әтисенең кочагында утырган Тансык аңардан ниндидер ят ис килгәнен сизде. Түзмәде, сорады:

—Әти! Нинди ис килә ул синнән?

Күңелсез генә улының башыннан сыйпады.

—Төрмә исе ул, улым! Төрмә исе.

Кесәсенә тыгылып, кульяулыкка төргән кечкенә кара ипи кисәге алды:

—Менә сезгә төрмәдән күчти.

Тансык җавап бирде:

—Кирәкми, әти! Безнең төрмә ипиен ашыйсыбыз килми.

Әтисенең күңелен китәсе килмәде, ахрысы, өстәде:

—Әйдә, әти, песигә бирик. Ипи бит, әрәм булмасын.

Песине чакырып ипине бирделәр. Песи иснәп-иснәп карады да, ипигә

тимичә, караватастына кереп китте, иртәнгә кадәр шуннан чыкмады. Песинең дә төрмә ипиен ашыйсы килми иде күрәсең...

Котылып кайтуына берничә көн үткәч, Кави кабаланмый гына кырынып, бик яңадан булмаган, бәлки шуңа кулга алган чакта фатирда торып калган соры костюмын үтүкләп киде. Ап-ак күлмәк киеп, галстук такты да, көзге демисезон пальтосын алып, Язучылар берлегенә китте. Кабаланмый гына үзе яшәгән урам белән барып Бауманга төште. Бауманга керү белән уң якта дүрт катлы, соры-кара төстәге озын бинада Язучылар берлеге иде.

Дулкынлануын басарга тырышып, икенче катка күтәрелде. Рәис бүлмәсенең ишеген шакыды. Ике ел ярым элек ул шушы бүлмәдә рәислек итеп эшли иде...

Бүлмә эченнән көр, күңелле тавыш ишетелде.

—Ишек ачык! Керегез!

Кави ишектән күренү белән өстәл артында утырган кеше житез генә күтәрелде дә, ике кулын шатланып җәеп җибәрде:

—И-и! Кав-ви аб-бы-ый! Жан кисәк-кәйе-ем! Теп-тере, менә дигән! Исән-имин кайтуың белән сине!

Бу—шагыйрь Муса Җәлил иде. Ничек каршы алыр икән дип сагаеп кергән Кавины Муса кочаклап алды да, алга, өстәле янына алып барып, артлы урындыкка утыртты, Кави каршына үзе дә утырды. Урындык алып.

Тавышын баса төшеп, Кавиның күзенә карап әйтте:

—Ничек анда дип мин сорамыйм, син сөйләмә, Кави абый. Юньле булса, аның исеме «өтермә» булмас иде. Исәнлегең ничек, бик нык измәделәрме? Ай-һай, анда хәтәр кыланалар диләр...

Кави көрсенде:

—Изделәр мине, Муса энем. Бик каты имгәттеләр. Син сорашма, мин сөйләмим. Чыккач, сөйләнеп йөрмә дип бер кәгазьгә кул куйдырдылар әле шулар өстәвенә.

—Ярар. Черт с ними! Мин, Муса энең буларак, Союз рәисе буларак, сиңа ничек итеп ярдәм итә алам?

—Сәрвәр—спецлагерьда. Яшәү—чардакта, бер кечкенә бүлмәдә. Ашарга кирәк, ягарга утын кирәк, утка түләргә кирәк.

—Әһә! Сиңа ярдәм кирәк? Акчалата?

—Кирәк, Муса! Ярдәм итә алмасагыз, миңа 400-500 сум тирәсе бурычка булса да биреп тор инде син. Бухгалтерия аша булса, мин гонорар ала башлагач түләрмен. Улым тоташ иске, тузган, бәләкәйләнгән киемнән йөри. Үземә дә кирәк, Сәрвәргә посылка салырга кирәк. Кыскасы, нужа бабайны ашатырга кирәк инде.

—Син утырып тор, Кави абый! Мин бухгалтериягә кереп чыгыйм әле. Хәз-зер!

Җиңел генә атлап чыгып китте дә, берничә минут юк булып торгач, килеп тә керде:

—Тапты бухгалтер! Җиде йөз таңкә, безвозмездный ярдәм сиңа. Гонорар алгач та түләмәссең. Монысы ярар.

Азрак уйланып утырды да, сөйләп китте:

—Димәк, болай итәбез. Дүшәмбе көнне иртүк монда киләсең. Безнең идарәнең иртәнге унда утырышы була. Сине шунда кире Язучылар берлегенә алабыз. Партия секретаре белән мин бүген үк сөйләшермен. Шул дүшәмбе көнне кичке 4-5 тирәләрендә партия җыелышы оештырып, сине партиядә восстановить итәрбез. Хәзер үк идарәгә дә, партия оешмасына да гариза яз.

Коридорга озата чыкты:

—Бухгалтериягә кереп акчаны ал. Тот, кызганма. 15-20 көннән мин

тагын җаен табып, сиңа акчалата ярдәм итәрмен. Ашавыңны кысма. Союз белән, партия белән аңлашыйк та, сиңа үз фатирыңа кире кайту чарасын күрербез. Дүшәмбе җыеннар белән узар. Ә сишәмбе иртүк мина кил. Ничек итеп Сәрвәр апаны коткару турында сөйләшербез, киңәшләшербез.

Исәнләшергә кул бирде дә, тавышын акрынайтты.

—Синнән яшьрәк булсам да, мине тыңла. Ике ел ярым син монда булмый торгач, вәзгыятьне аңлап бетермәвең бар. Сиңа начарлык эшләгәннәрдән үч алам дип ыгы-зыгыга кереп китә күрмә. Төкер син аларга! Йөрәгең бик әрнесә, күрмәмешкә салышып үт тә кит. Син аларга бәйләнерсең, ә алар хакимияткә бик тә якын булулары ихтимал. Син юкта бик күп нәрсә үзгәрде монда. Сак бул!

***

1940 елның март башында Кави Нәҗмигә Мәскәүдән хат килеп төшә. Хатны аның кияве, бертуган сеңлесе Ламиганың ире Лотфый язган. Менә ул хат:

«Мәскәү—Казан, 26.02.40 ел.

Кадерле һәм яраткан туган Кави абый. Синең язган хатың безгә иксез-чиксез шатлык китерде. Без... ут эчендә яшн идек.

«Атылган халык дошманы Кави Нәҗми аның якын агай-энесе иде һәм язу эше буенча укытучысы да иде»,—дип мине бу елларда бер җиргә дә эшкә алмадылар, Язучылар берлегеннән куып чыгардылар.

«Аны халык дошманнары үстерделәр. Аңарга: «Язма!»—диясе урынга, аны күтәрергә тырыштылар...» Менә шулай дип минем турыда «Әдәби гәҗит»тә язып чыктылар. Эх, яраткан Кави абыем! Безнең күргәннәрне язсаң, 100 томга да сыеп бетмәс.

Дошманлашкан яла ягучыларның миһербансыз ялганнары безне кысуда да бик нык тәэсир ясадылар. Сине кулга алу бездән дә «җинаятьчеләр» ясады, безнең бөтен яшәешебезне үзгәртте.

Мәскәүнең татар язучылары, кичә генә синең белән иҗат эшләрен алып баручылар, синең кулга алынганыңны ишетеп, иксез-чиксез куандылар, минем аска да «казый» башладылар. «Ни эшләп бүгенге көнгә кадәр Лотфины кулга алмыйлар, ул бит Кавиның бердәнбер яраткан кияве? Аның барлык язганын Кави нәшриятта бастырып бара иде... Шуңлыктан аны тизрәк Язучылар берлегеннән куарга кирәк...»

Шулай дип чыгышлар ясап, алар ... мине сират күперенннән тәмугка ыргыттылар...

Мин ул кешеләр турында башкача язарга да теләмим, чөнки син үзең дә аларны яхшы күз алдына китерә аласың...»

Кави Нәҗминең хатыны Сәрвәр Әдһәмованы, 1938 елның 11 августында суд ясап, 10 елга махсус лагерьга озаталар. Шуңа өстәп аны биш елга хокукыннан мәхрүм итәләр. Себергә, Красноярск тимер юлындагы Суслово станциясе янында урнашкан концлагерьга илтеп тыгалар.

Сәрвәрнең лагерьдан язган 53 хаты бүген дә улы Тансыкта саклана. Ул хатларны тетрәнмичә укып булмый. Сәрвәр Әдһәмова лагерьда ире язган хатларны да саклап кала алган һәм Казанга алып кайткан. Алар да уллары Тансыкта саклана. Ул хатларны бастырып чыгарсаң, үзе бер китап булыр иде. Хатлар татарча язылган. Киленe Сания апа тырышлыгы белән ул хатлар Казанда 2004 елда: «...Сильнее смерти и страха жизни» исемле китап итеп бастырылган. Китап эшләнеше белән бик матур. Китап Тансык Нәҗметдинов һәм Сания Әхтәмова тарафыннан төзеп чыгарылган. Болар инде—Кави абый һәм Сәрвәр апаның улы белән килене.

Сәрвәр. 1939 ел, 10 апрель ст. Суслово: «Ун ел—ун ай түгел. Азагына

барып житмәвен дә бик мөмкин».

«Хәзер көннәр бик матур, фиалкалар, умырзаялар чәчәк ата, тиздән утчәчәкләр дә атачаклар...»

«...Төрле урыннарда эшлибез—урман аударабыз, чучка асларын һәм силос чокырларын тазартабыз».

«Бу хатны мин үзебез яшәгән землянка тышында, аның саламнан ясалган диварына таянып (саламнан балчыкка катырылып төзелгән землянка ахыры—автор) язам. Миннән 8-9 метр гына арырак, безне уратып алган чәнечкеле тимерчыбык. Ә аның теге ягында... ямь-яшел кырлар башлана, шунда кошлар сайрыйлар...»

21 май, 1939 ел

«...Сездән килгән хатларны бик күп укып ләззәтләнәм, уйланам...»

«Авырмаган чагымда мин төшенкелеккә бирелмим. Тик бу ике елның сынаулары, кичерешләре эзсез үтмәделәр һәм үзләренең тамгаларын калдырып киттеләр...»

Телеграмма (урысча бирелгән—автор)

Ст. Суслово, Новосибирской область

п/я 247 «б» Адгамовой С. С.

Сегодня освобожден полным оправданием, ходатайствую немедленном твоем освобождении. Береги здоровье. Подробности почтой.

Горячо целую твой Кави. 31. XII. 1939 г.

Сәрвәр: «Кичә синнән телеграмма алган минутлардан алып, минем йөрәгем тулы тойгылар—шуларны сөйләргә сүзләр табып булмый. Болар бар да шатлыктан һәм шатлыктан, кадерлем минем!..”

«... Иген тазарта торган веялканы әйләндерә башлаган чакта миңа бик авыр була. Әйләндерергә кирәк! Менә әйләндерә башлыйсың, башта бар да әйбәт кенә барган кебек. Үзең белән бергә әйләндергән иптәшеңә авырлыкны салмаска тырышып әйләндерәсең. Инде синең өлешеңә иген тутырылган соңгы тартмалар эләгә—ә көч бетеп бара. Һава житми, тын алу авырлаша, вакыт туктап калган кебек тоела”.

11 гыйнвар 1940 ел, Суслово ст.

Сәрвәр: «... син усал ялган, яла ягулар нәтиҗәсендә бик озак тоткынлыкта җәфаланып, әкияттәге батыр кебек, үзеңне богаулаган чылбырларны өзгәләп ыргытып, якты көнгә чыктың, үзеңнең саф, намуслы исемеңне барлык пычраклардан арындырдың”.

9 гыйнвар 1940 ел. Казан каласы.

Кави: «...сине тизрәк күрәсем килә. Синең язган хатларыңны бергә җыеп, кат-кат укып чыгам һәм син күз алдыма килеп басасың. ... Син ешрак яз! Мин дә язармын. Һәм без шулай итеп безнең азат, бәхетле көннәребезнең килүен тизләтербез.

Күп тапкырлар үбеп синең Кавиең».

12 гыйнвар 1940 ел. Казан каласы.

Кави: «Сәрвәрем! Бердәнберем минем! Балалар белән бергә аларның каникулларын үткәрдем. Иртәгә III чирекләрен башлыйлар. Мин дә алар белән бергә үземнең яраткан иҗат эшен башлыйм. Шулкадәр сагындым эшемне—яңа әсәрләр башлыйм инде...»

17 гыйнвар, Суслово ст.

Сәрвәр: «...мин өйдә чакта Тансык (улым!) минем агара башлаган чәчләремне кечкенә кулларына алып, миннән сорый: «Әти аркасында агардымы, әнием, чәчләрең?» Синең «карчыгың», кадерлем минем, чын карчыкка әйләнеп бетеп бара инде...

...Киләчәктә без бәхетле булып яшәрбез! Шулай бит!»

Күп тапкырлар үбеп Сәрвәр.

2. II. 1940 ел, Казан каласы

Кави: «Хәзер яна көч һәм дәрт белән яна әсәрләр язарга тотынам.

Тапсак сина тәмәке, май, шикәр, конфетлар һәм тагын кирәк-ярак әйберләр жыеп, өстәмә посылка салырбыз.

Балалар яхшы укыйлар. 30 гыйнварда мине иреккә чыгарганнарына ай тулды. Кунаклар жыйдык. Бар да үзебезнекеләр: Сажидә, кодалар, Мәрьям апа гаиләсе һәм Хәдичә. Барысыннан да сина күп сәлам.

Күп тапкырлар үбеп синен Кавиен».

7 февраль, 1940 ел, Суслово ст.

Сәрвәр: «Монда яши-яши кайчакта пычрак, тәнгә генә түгел, жанга да ябышкан кебек тоела. Пычрак, вәхши тойгы. Куып жибәрәсе килә. Төрле-төрле типларны күрергә туры килде. Горькийнын «На дне» пьесасындагыларны күреп кенә түгел, шулар арасында, алар белән аралашып та яшәргә туры килде...

Синен Шатлыгын!»

19 февраль, 1940 ел, Суслово ст.

Сәрвәр: «Көне буе кар көрәдек. Кояш язларча жылыта, яктырта. Эшләве күнелле! Телогрейканы салып очырасы килә! Кайтуга синнән хат бар—кәефләр күтәрелеп китә!»

26 апрель, 1940 ел, Суслово ст.

"Хәзер хатлар салуны бездән генә түгел, сездән килгәннәрен дә кыстылар. Айга бер генә хат бирәләр. Посылка алмау да, хат килмәгән кебек авыр түгел. Хат көтү үзе күнелне юата торган иде. Хәзер ул хат килү өмете дә сүнде. Землянкага, үлек чыккан өйгә кайтасы килмәгән кебек, керәсе килми. Ярый әле эш бар—шул азрак юата. Тәүлегенә 13-14 сәгать эшлибез.

Көннәр матур түгел: жил, салкын, яз булганга ошамаган да.

Барыгызны да үбәм. Синен Шатлыгын".

14 сентябрь, 1940 ел, Суслово ст.

Сәрвәр: «...Кадерлем минем! Кайвакытта минем өстемдәге кием генә түгел (ә ул кием этләр талаган кебек, күп урыннардан иске, пычрак мамыгы күренеп, чыгып тора, ул киемнәрне мина кадәр кемнәр генә кимәгәндер, телогрейканын урыны әллә кайчан чүплектә булырга тиеш, төсе дә, формасы да югалган, башта әллә нинди малахай, аякта чабаталар, алар инде нинди генә пычракларны измәгәннәр, нинди генә янгырларда чыланмаганнар), жан да тоташ пычракка, нәжескә буялган кебек тоела. Син, рухынны югалтма, дип язасын, пессимизмга бирелмә, дисен. Бу пессимизм түгел, анын нәрсә икәнен шайтан да белмидер, тик мин үземнен элекке нужасыз, кара уйсыз булган тормышым булганга ышанмыйм инде, мина тагын бәхетле тормыш булмас ахрысы һәм минем түземлегем бетеп килә...»

18 октябрь, 1940 ел

"Кадерлем минем! Шатлыктан башым эшләүдән туктады...

16 октябрьдә иртәнге унда иреккә чыгам... Документлар әзер, тик китеп булмый—акчалары юк. Алмыйча ташлап китәргә уйлаган идем, акча алмыйча жибәрмиләр...

Нәрсә генә булса да, очрашуга күп калмады.

Күп-күп итеп үбеп Сәрвәр".

Омскидан телеграмма.

Казань, Международная,19.

Кави Наджми

27. Х. Еду семьдесят первым. Сарвар.

Сәрвәрне каршы алырга Кави, Хәтирә апа, Тансык тимер юл вокзалына төшәләр. Туктый башлаган бер вагон тәрәзәсеннән Сәрвәрне күреп калып, йөгерешә башлыйлар. Кави да, Тансык та елыйлар. Бик ерак булмаса да

такси белән кайталар. Бүлмәгә кергән унайга ук Сәрвәр урындык алып утыра. Каршы алучылар шунда гына күрәләр: Сәрвәрнең аяк-куллары шешенгән...

Ике ел ярым дигәндә имгәтелеп, туздырылып, юк ителә язган кечкенә тату гаилә, көч-хәл белән бергә җыелып, янадан бергәләшеп яшәүгә зур өметләр баглап, кечкенә генә бүлмәдә шатланышып, елмаешып утыралар.

Хәтирә апа өстәлгә чәй әзерли башлый...

***

Яңа, 1941 ел килеп житте.

Төрмә камералары, төрле-төрле физик җәзалар аша үтеп, рухы сындырылган язучы Кави Нәҗми үзенең вөжданына, намусына каршы килеп биргән күрсәтмәләреннән, башын үзе балта астына салган кебек тәвәккәллек күрсәтеп, үзендә көч табып, тикшерүче палачларны җиңеп, ирекка чыга алды. Елга якын төрле урыннарга язып, гаебе юклыкны исбатлап, хатыны Сәрвәрне дә спецлагерьдан коткарып, Кави аны Казанга кайтарта алды. Кечкенә генә бүлмәдә биш кеше яна 1941 елны каршы алырга әзерлек алып баралар.

«Биргән Биктимереңә бир!»—дигәндәй—Яңа ел алдыннан Кави Нәҗми бергә җыелганнарына куанып үзен бик бәхетле тоя иде.

***

Кави Нәҗминең НКВД кулыннан исән чыгуына дуслары да, дошманнары да ышанмыйлар. Аның имгәтелгән булса да, исән көенә Казан урамнарында күренүе күпләр өчен көтелмәгән һәм сәер күренеш була. Әшәке телләр, Кавиның зур язучы талантыннан көнләшеп яшәгән «каләмдәшләре» арасында имеш-мимеш, гайбәт тарала башлый: «НКВД» кулында утырганда күпләрне саткан ул! Шуңа күрә исән калган, шунлыктан безнең арага шымчы итеп чыгарганнар инде. Сак булырга кирәк безгә...»

1941 елның 22 июнендә сугыш башланды... Сугыш башлану белән Мәскәүдә яшәгән урыс язучыларының күпчелеге, тылга, үзләре сайлап алган Казанга, Чистайга качтылар. Ә татар язучыларын мобилизация белән сугышка озаттылар. Кави фронтка китәргә дип гариза яза һәм аны дивизионный комиссар итеп Кызыл Армия сафларына алалар. Ай үтәр-үтмәстә аны бронь белән азат итеп, Казанга кайтаралар. Беренчедән, исәнлеге бик шәптән түгел, икенчедән, ул тылда кирәк.

Сугыш башлангач гайбәт сөйләп, бер-беренне «чәйнәп йөрергә» вакыт калмый. Немец танклары, авиациясе, автоматлы пехотасы белән башкалага, Мәскәүгә ыргыла...

Теләсәң, теләмәсәң дә илне сакларга кирәк!

Сугыш елларында Кави Нәҗми Татарстан радиосында агитация һәм пропаганда бүлеге мөдире булып бик зур эшләр башкара. Аның тәкъдиме белән 1943 елның март аенда «Фронтовик татарларга татар халкыннан сәлам хат»ы оештырыла. Менә ул хаттан өзекләр: «Татар халкының курку белмәс, артка чигенмәс намуслы уллары һәм кызлары! Сезне хәләл сөте белән туендырган, жылы кочагына сыендырган шәфкатьле аналарыгыз, сезгә үзләренең иң яхшы сыйфатларын биреп тәрбияләгән аталарыгыз, туктаусыз алга барырга һәм явыз дошманнан рәхимсез үч алырга үзләренең фатихаларын биреп, изге «язгы кояш кебек якты сәламнәрен тапшыралар...»

«... Кадерле туганнарыбыз!

Барлык татар халкының өмете сезгә текәлгән. Халык йөрәге сезнең белән тибә...»

Бу хатка татар халкы исеменнән Татарстан Республикасының атаклы 48 шәхесе кул куйган. Хат 1943 елның март башында Татарстанның барлык газеталарында бастырыла. Хатны урысчага Константин Федин тәрҗемә итә.

Хатның тәэсире фронтта сугышканнарга бик көчле була. Казанга килгән чакларында хәрби хәбәрчеләр Константин Симонов һәм Михаил Шолохов Кави Нәҗминең фатирында еш кунак булалар. Шул хакта бик җылы итеп Кави Нәҗминең улы бүген дә исенә төшерә:

«Мин заводта эшли идем кырык өченче елны. Кич сменадан өйгә кайтсам, бездә Мәскәү язучылары утыра иде. Алар: Фадеев, Щипачев, Федин, Толстой, Алигер иде. Әти Щипачев белән 1922 елда Мәскәүдә хәрби педагоглар институтында укыган. Дуслыклары шуннан бирле килә иде. Кичен—шау-шу, фронт хәлләрен, әдәбият хәлләрен тикшерүләр, сөйләшүләр бара. Минем өчен гаҗәп иде бу күренеш—урыс әдәбиятының иң зур, талантлы язучылары безнең өйдә утыралар! Искитмәле бит!»

***

1943 елның октябрь аенда Мәскәүдән СССР Язучылар берлеге рәисе Александр Фадеев Казанга Кави Нәҗмигә телефоннан шалтырата:

—Кави, исәнме!

—Исәнмесез!

—Срочно командировка ал да, Мәскәүгә кил. Иртәгә үк юлга чык. Мин Переделкинода яшим.

—Нәрсә булды, Александр Александрович?

—Бернәрсә дә булмады. Син бик кирәк монда. Сорау биреп торма—тиз килеп җит.

—Ярар, алайса. Берсекөнгә барып җитәрмен.

—Мәскәүгә китәсеңне сөйләнеп йөрмә бер җирдә дә. Тиз кил!

—Ярар.

Икенче көнне Кави Нәҗми Переделкинода Фадеев яшәгән йортның ишеген какты. Ишекне аңа Фадеев үзе ачты:

—Хәерле киләсең, Кави! Уз өйгә!

Бер сәгать тирәсе Фадеев кабинетында сөйләшеп утыралар. Александр Александрович җентекләп Татарстан Язучылар берлеге турында сораша, аерым язучылар белән дә кызыксына. Аннан күрше бүлмәгә алып чыга. Чибәр генә хатын өстәлгә пары бөркелеп торган борщ куя. Фадеев күңелсез генә аңлаткандай итә:

—Мин, Кави, син ашагач йөрергә алып чыгып китәм. Шуннан кайткач, азрак салырбыз. Әлегә кирәкми. Урамда синең белән сөйләшәсе сүз бар...

Сөйләшмичә генә ашап, киенеп урамга чыгалар. Фадеев Кавины урман эченә сузылган сукмактан алып кереп китә. Дәшми генә биш минутлар чамасы бара да туктый. Кави да туктый. Аның күңеленниндидер билгесез шом били. Ничәмә-ничә еллар инде белеп, ул Фадеевны шулай борчулы хәлен беренче мәртәбә күрә. Туктагач, түзмичә, сорыйсы итә:

—Кәефегез юк кебек, Александр Александрович? Берәр начар нәрсә бармы әллә?

—Бар шул, Кави. Сезнең өчен бик тә начар вакыйга булуы мөмкин.

—Кем ул «сезнең өчен» дигәнегез?

—Сез татарлар өчен. Тыныч кына тыңларга тырыш инде син мине. Бу көрәшү безнең соңгысы булуы да бик мөмкин.

Кави тынычланырга тырышып, акрын гына тавыш белән әйтә:

—Бик зур игътибар белән тыңлыйм сезне.

—Син, Кави, Муса Җәлил, немецлар төзегән татар легионы турында нәрсә беләсең?

—Бик аз. Имеш-мимештән башканы белмим дә. Чөнки информация юк дәрәҗәсендә бит бездә.

—Алайса, тынла. Шәфи Алмас исемле эмигрант татар милләтчесе немецларга буйсынган "Урал—Идел" исемле комитет төзегән. Ул комитетның максаты Иделдән алып Урал тауларына кадәр булган җирләрдә, Германия протекторатына буйсынган «Идел—Урал» исемле татар штаты булдыру. Хакимияте төзелгән һәм Шәфи Алмас шуның президенты булачак.

—Ә Муса Җәлилнең монда ни катнашы бар?

—Бар икән шул. Шул булачак штатның хакимиятендә Муса Җәлил мәдәният министры итеп билгеләнгән. Германия гәҗитләрендә берничә мәртәбә аның гомум очрашуларда төшерелгән фотолары бирелгән. Шул гәҗитләр Сталинга тапшырылган. Советлар Союзына каршы сугышыр өчен татарлардан, башкортлардан торган легион төзелгән:

Кави «саламга» ябыша:

—Бәлки ялгандыр, Александр Александрович! Муса чын коммунист һәм бик тә патриотик шәхес. Мин аның сатлык булуына ышанмыйм.

—Мин дә ышанмыйм. Ләкин татар легионы факт бит. Мусаның министр булуы да гәҗитләрдә бирелгән.

Әйдә, без сөйләшүне башкачарак алып барыйк. Сатлыкмы Муса, түгелме—вакыт ачыклар. Монда шушы татар легионы белән бәйләнгән башка бик зур һәм куркыныч проблема килеп чыкты. Бүгенге көнне Муса проблемасы вак мәсьәлә. Ә иң куркынычы, Кави, менә нәрсә...

—Нәрсә?—Кавидан бу сүз пышылдап кына чыкты.

—Үзәк Комитет Политбюросында сезне, Идел һәм Кырым татарларын, депортация ясап, Урта Азиягә, Себергә, Ерак Көнчыгышка, Якутиягә, Камчаткага бүлгәләп-бүлгәләп куарга дигән сүз бара. Бу депортация 1944 елның май-август айларында үткәрелергә тиеш.

—Безне... татарларны Иделдән, туган илдән куала-ар?! Җәен?

—Әййе. Кырык дүртенче елда. Сезне генә түгел, тагын берничә мөселман халыкларын...

—Алар кемнәр?

—Әйтә алмыйм, Кави. Болай да мин сиңа баш китәрлек эш эшләп, сезне, татарларны, депортацияләргә җыенулары турында әйттем. Бу бит дәүләт сере. Минем сиңа сөйләгән Берияга, Сталинга барып җитсә—икебезнен дә баш бетәчәк.

Тирә-ягына каранып алды:

—Әйдә, азрак урман эчендә сөйләшмичә генә йөреп килик. Син бу информацияне хәзер үк эшкәртергә тырыш башыңда. Аннан соң нәрсә эшләү турында кинәшеп карарбыз. Ничек итеп сезне депортациядән коткарып алып калырга? Иң мөһим сорау бу бүгенге көндә. Менә без хәзер икәү шул мәсьәләне ничек чишәргә һәм сезне, татарларны, ничек итеп коткарырга дип уйларга тиеш. Синең белән миннән башка сез татарларны коткарыр кеше юк дөньяда. Шуны белеп уйла.

Урман эченә сузылган сукмактан атладылар. Ярты сәгать чамасы баргач, Фадеев туктады:

—Беләсеңме, Нәҗми, сезгә, татарларга, хәзерге көннән башлап нәрсә эшләргә кирәк?

—Тынлыйм, Александр Александрович.

—Тарихта сез, татарлар, безне, урысларны басып алып өч йөз елдан артык буйсындырып тотып тора алган халык. Чыңгыз ханның «Ясак» кануннары буенча ясакны сез халыкның эшләп тапкан байлыгының тик уннан бер

өлешен генә алгансыз. Русьта кенәзләрнең үзара сугышулары, талашлары туктатылган. Күршеләренә басып кергән кенәзләрнең, татар ханы әмере белән, башларын чапканнар. Православие динендә булган чиркәүләр, монастырьлар берсе дә налог, ясак түләмәгәннәр. Татарлар юллар төзеп, ям хезмәтен безгә, русларга да, өйрәткәннәр. Белемле, зур мәдәниятле, сәнгатьле халык сез, татарлар. Без урыслар сездән өйрәнеп кенә Алтын Урда яулап алган җирләрне үзебезнеке итеп, зур, Бөек Русия төзи алдык. Сезне Себергә, Казакъстанга, Якутиягә сөреп чыгарып юк итсәләр, Русия үзе дә бетәчәк. Сез бар җирдә һәрчак тәртип, эш, төзеклек. Без урыслар сезнең эшләгәнне карап, сезнең тәҗрибәне файдаланып, үзебез дә сизмичә, сездән үрнәк алып яшибез.

Азрак дәшмичә торды да, кабаланмый гына тагын сөйләп китте:

—Казанга кайткан көненнән үк башлап син, Кави, Татарстаннан чыккан Советлар Союзы Геройлары турында китап чыгару өчен материал җыярга тотын. Бу эшкә күпме язучыларны, активистларны туплый аласың, барысын да җый, эшләт. Син эш башлаган көенә, мин монда, Мәскәүдә, сезнең батырлар турында шундый китап чыгарачагыгызны җәмәгатьчелеккә барып җитәрлек итеп сөйләп, язып чыгармын. Радиодан, гәҗит-журналлардан тапшырулар, мәкаләләр бастырып халыкка җиткерербез. Сугышта Татарстанда туып-үскән Геройларның кыюлыкларын күрсәтербез. Сезнең «Батырлар» китабына материал җыя башлаганыгыз турында мин инде атна-ун көн эчендә иптәш Сталинга җиткерермен. Фронттагы татарларга язган хатыгыз бик ошады иптәш Сталинга. Ул аны бик хуплады.

Син тотын бу эшкә. Оештыру сәләтең зурдан синең, менә дигән китап булачак. Син үзең барлык фронт командующийларына хат яз һәм алардан үтенеп сора—татарларның фронтларда ничек сугышулары, аларның нинди солдат булулары турында үз уйларын, фикерләрен сиңа җибәрсеннәр. Китапта фронт командующийларының татарларга биргән хәрби бәяләрен дә бастырырсыз.

—Җибәрерләрме икән?

—Җибәрерләр. Мин аларга шалтыратып, сез чыгара торган китапның бик мөһим политик эш икәнен аңлатып әйтермен. Сталин кадрлар сайлый белә ул. Безнең фронт командующийлары берсеннән-берсе акыллылар да, шәпләр дә алар.

Елмаеп Кавига карады Фадеев:

—Беләсеңме, хәрбиләр арасында бер гайбәт йөри, тик дөреслеген исбат итеп булмый.

—Нинди гайбәт?

—Армия генералы Коневны керәшен татары диләр. Үземнән дә алардан сораганым бар. Сезне татар диләр, дөресме, дип? Яңакларының чыгып торуы тач Себер татарларыныкы кебек бит инде. Юк ди үзе, тик шуны әйткән чагында күзләрен читкә яшерә.

—Кызык бу. Конев бит чыннан да бите-кыяфәте белән чын татар инде.

—Тагын берәү бар әле андый кеше.

—Анысы кем тагын?

—Сталинград янында немецларны уратып алып тар-мар итү планын төзегән Антонов фамилияле генерал бар. Генеральный штаб начальнигының урынбасары ул хәзер. Шушы елның февраленнән бирле. Ул инде чын керәшен. Әтисе Татарстаннан. Кавалериядә ат белгече, бик озак еллар вахмистр булып эшләгән. Улы—бүгенге генерал Антонов. Үзенең татар икәнен яшермичә яши. Татарча да белә...

Көлде.

—Мин аның белән бер мәртәбә очраштым. Илләмә дә учакка күмгән бәрәңге ярата инде...

—Мин ана да хат языйм алайса?!

Фадеев азга гына туктап уйланып алды.

—Язма. Җавап бирмәячәк.

—Сәбәбе бармы?

—Бар. Жуков һәм Кызыл армия генералитеты Генераль штаб башында татар торган белән риза түгел. Сталин бик хөрмәт итә Антоновның талантын. Һәм уйлый белүенә югары бәя бирә. Сталиннан куркалар маршал-генераллар һәм хәзергә Антоновка тимиләр. Әгәр берәр зуррак хата ясаса, икенче көнне үк ул инде штабта булмас. Сталин да белә анын татар икәнен. Шунлыктан, официально Генераль штаб начальнигы итеп Маршал Василевский күрсәтелеп килә. Ә штаб дигән йөкне кырык икенче елның декабрь аеннан бирле генерал Антонов өстери.

—Бу бит гаделлек түгел.

—Сезне, татарларны, Себергә сөрсәләр, гаделлек буламы?

Кави нәрсә дип тә җавап бирергә белмәде. Фадеев үзе җавап бирде:

—Сезне Волгадан Себергә, Якутиягә кусалар, бу иң зур гаделсезлекләрнең берсе булачак. Сталин татарларны яратмый. Мирсәет Солтангалиев турында ишеткәнең бармы?

—Бар. Сатлык җан бит ул.

—Сатлык дип әйтмәс идем мин аны. Ул иң акыллы татарларның берсе иде. Ленин үлгәч, Сталинның сыйнфый сәясәтенә каршы чыккан беренче коммунист ул. Солтангалиев теориясе буенча милли сәясәтне тормышка ашырып кына социализм төзеп була. Аның уйлавынча, язуынча, сыйнфый социализм төзү СССРда урыстан башка милләтләрне юкка чыгарачак. Һәм сыйнфый сәясәткә нигезләнеп төзелгән СССРдагы социализм 50-60 еллар чамасы вакыт узгач җимереләчәк, таркалачак. Сезне, татарларны, Себергә озатып юкка чыгарырга тырышу Солтангалиев теориясенең дөреслеген исбатлавы мөмкин. Бөтен СССРда урыс теле генә өстенлек итеп, барлык халыклар урыс милләтенә әйләндерелсәләр, бу безнең ил өчен катастрофа булачак.

Кави сорыйсы итте:

—Солтангалиев исәнме әле ул? Төрмәдәме?

—Минем белүемчә, кырык беренче елның гыйнварында Лубянка подвалында коридордан сорауга алып китеп барганда, арттан лепкәсенә револьвердан атканнар аны, юк иткәннәр...

Фадеев уң кулы белән Кавины кочаклады:

—Ярар, Кави! Без синең белән баш китәрлек эшкә—изге эшкә тотынабыз. Гомерем буена мин, Фадеев, сез татарларга сокланып һәм яратып карадым. Ярдәмем тиеп, сез Волга ярларында урнашкан туган илегездә яшәргә калсагыз, мин инде үлгән чагымда да сезгә ярдәмем тигәнгә куанып үләчәкмен!

Александр Фадеев тәкъдиме белән Кави Нәҗми «Батырлар китабы»н бастырып чыгару өчен җиң сызганып эшкә керешә. Ул язучылардан, журналистлардан татар өчен янып-көеп йөргән шәхесләрдән «Батырлар китабы»н чыгару өчен бик бердәм коллектив төзи.

Китап Гани Сафиуллинның батырлыгы белән башланып китә һәм барлыгы илле алты герой турында мәгълүматны үз эченә алган. Шул батырларның 41е—татар, калган 17се урыс, чуаш, мордва, мари милләтеннән. Китапны төзүче һәм редакторы—Кави Нәҗми. Ул 1945 елның июнь аенда басылып чыга. Китапның беренче битендә Г. Жуков, И. Конев, К. Рокоссовский, Р. Малиновский, Л. Говоров һәм армия генералы А. Еременконың татар

сугышчыларына биргән бәяләре чыккан.

Александр Фадеев белән аның дусты Кави Нәҗминең тырышлыгы, тәвәккәллеге һәм аларның курыкмыйча төптән уйлап хәрәкәт итә белүе аркасында Идел буе татарлары туган илләреннән сөрелмичә калалар. Вакытлыча калдыра аларны Сталин—сугыш тәмаланып, татар кулыннан корал алынганчы...

Сугыш тәмамлангач, җимереклекне торгызуда Татарстан нефте белән тагын татар халкы кирәк. Шахтада, руда, нефть чыгаруда, урман кисүдә, балык тотуда—тагын татарларны илтеп тутыралар. Вербовка белән. Ин авыр, иң кара эшкә! Ат кебек эшли белгән чыдам татарлар... Татар шуна кирәк, татар мона кирәк дия-дия, 1953 ел килеп житә. Татарны депортацияләү вакыты 1954 ел якынлаша. Тик...

Алла бар ул!

1953 елның 3 март иртәсендә кабинеты идәнендә аның җуйган «бөек» Сталинны табалар. Ике көннән ул вафат була. Бик «бөек» булса да, әҗәлдән ул да котыла алмый.

***

Сорап алгандырмы, яисә берәрсе Кави Нәҗмигә махсус биргәндерме, 1946 елда аның кулына Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» килеп эләгә. Һәм Кави Нәҗми, Мусаның әсирлектән кайткан күп кенә шигырьләренә тәрҗемә эшләп, Мәскәүгә, «Новый мир» журналы редакторы Константин Симоновка җибәрә. Константин Симонов Мусаның шигырьләрен үзе тәрҗемә итеп, «Новый мир»да бастырырга хәзерләп куя.

Тик...

Кави Нәҗми, саксызлык күрсәтеп, «Новый мир» журналына Җәлилнең шигырьләрен җибәргәнен берәрсенә үзе ычкындырганмы, яисә башкачамы бүген инде аны ачыклап булмый...

Шигырьләре инде җыярга тапшырылгач, Константин Симонов Казаннан, Татарстан НКВДсыннан хат ала. Татарстан НКВДсы җитәкчесе Симоновка «сатлык» шагыйрь Муса Җәлилнең шигырьләрен бастыруны тыя. Берничә көн узгач, Константин Симонов кисәтелә: «Сатлык Муса Җәлил шигырьләрен бастырмаска!» Бу 1948 елда була. Кавиның дусты Мусага ярдәм итәргә тырышуы нәтиҗә бирми. 1946 елда Александр Фадеев белән бергә Кави Нәҗми КПСС Үзәк Комитеты уполномоченные Поликарповка керәләр. Бер генә мәсьәлә белән: «Шагыйрь Муса Җәлил сатлык җан түгел һәм ул акланырга тиеш!» Бу хакта Фадеевның Мусаның хатыны Әминә Җәлиловага язган хаты бар. Шуннан күренгәнчә, Кави Нәҗми—«сатлык» ярлыгы тагылган шагыйрь Муса Җәлилне реабилитацияләү, акларга кирәк икәнне сорап, таләп итеп йөри башлаган иң беренче кеше.

1948 елның февралендә чыккан «Совет әдәбияты» журналында 30-40 елларда атаклы тәнкыйтьчеләрнең берсе саналган Маһинур Фәйзуллинаның Гражданнар сугышы чорында булган татар поэзиясе турында мәкаләсе басылып чыга. Шул мәкаләдә бөтен СССРны шаулатып, «сатлык» ярлыгы тагылып фаш ителгән Муса Җәлил шигырьләре дә күрсәтелгән. Ул мәкалә аяз көнне күк күкрәп, яшен яшьнәп шифалы яңгыр яуган кебек итеп укучыларга унай тәэсир ясый. Ул елда (1948 ел) «Совет әдәбияты» журналының баш редакторы язучы Кави Нәҗми була. Шул мәкаләне чыгаруда «бергә ясаган батырлык» турында Маһинур Фәйзуллина менә нәрсә яза: «1948 елның февраль номерында «Совет әдәбияты» журналында минем Гражданнар сугышы елларындагы татар шигъриятенә багышланган мәкаләм чыкты. Мин ул мәкаләдә Муса Җәлил иҗатына да тукталдым. Мәкаләне бастырып чыгарырга баш редактор, язучы Кави Нәҗми ярдәм

итте. Мәкалә басылып чыккач, Кави Нәҗми Татарстан обкомы тарафыннан да һәм Язучылар берлегеннән дә бик нык шелтә алды. Шуңа карамастан, мәкалә басылып чыккач, без үзебез бик канәгать булдык».

Егерменче еллар азагында Кави Нәҗми, зурдан тотынып, вакытлыча исеме «Гарнизон» булган тарихи роман яза башлый. Тик, эш өстенә эш өстәлеп, төрмәләргә эләгеп, сугышлар башланып ул романны ныклап дәвам итеп яза да, бетерә дә алмый. Еллар буе, калган эшкә кар ява дигәндәй, роман язылмыйча ята бирә.

Маһинур Фәйзуллинаның мәкаләсе басылып чыккач, Кави Нәҗмине Татарстанның партия өлкә комитетына чакыралар. Анда «сатлык шагыйрьнең» шигырьләрен «мактаган» өчен Кави белән бик каты сөйләшәләр, нык кына кисәтеп, шелтәләп чыгаралар.

Аек фикер йөртә белгән Кави атна-ун көнгә якын үз уйларында, фикерләрендә йөзеп йөри.

Кави Нәҗми ат кебек җигелеп эшләп, күп архив материаллары казып чыгарып, крепостное право бетерелгәннән башлап, 1917 елның Октябрь революциясенең Казанда булган көннәренә кадәр чорны эченә алган теге роман өстендә эшли. Романда язылган шәхесләрнең көчле холыклары аша бай татар теле белән оста, сәләтле язучы Кави Нәҗми тарих вакыйгаларын берсе артыннан берсен тезеп, кызыклы, аянычлы, батыр, эшчән көннәрне, елларны роман битләрендә тасвирлый. Идел-су буенда яшәгән урыс, татар, чуаш һәм башка халыкларның патша хакимияте, урыс, татар фабрикантлары, заводчиклары, байлары тарафыннан эш белән ватылуларын, рухи һәм матди яктан изелүләрен романда күрсәтә. Кави Нәҗминең шәп тел белән язылган бу романы, фактларга, тарихи вакыйгаларга тәңгәл килеп, узган гомер, көрәш турында бай мәгълүмат бирә.

Кави Нәҗминең яңа исем белән «Язгы җилләр» дип аталган романы татар әдәбиятында бик зур вакыйгага әйләнә.

Көнчелек уты белән янып, романга каршы чыгучы язучылар да табыла. Тик бернинди киртәләргә, каршы чыгуларга карамастан, «Язгы җилләр» романына 1951 елның язында Сталин премиясе бирелә. Бу инде авыр иҗат еллары, НКВД төрмәләре, җәзалауларын үтеп, кыйналган, ватылган, изелгән язучы Кави Нәҗминең авыр тормыштагы иң зур рухи җиңүе була.

1956 елга кадәр сузылачак Муса Җәлилне аклау эшләре. 1952 елның гыйнвар аенда Кави Нәҗми хатыны Сәрвәр һәм килене Сания белән Мәскәүдәге «Москва» кунакханәсендә туктала. Килгәннәренә ике көн дигәндә, болар яшәгән бүлмәнең ишеген кагалар. Ишекне киленнәре Сания ача. Ишек төбендә яхшы киенгән, бик тә зәвыклы ике кеше басып тора.

—Сез кемгә?—дип сорый Сания.

Чибәр, яшь татар кызы килгәннәргә бик нык тәэсир ясый. Тегеләр, бер-берсенә карашып алалар да, буйга озынрагы аптыраганрак тавыш белән, урысчалап:

—Безгә язучы Кави Нәҗми кирәк иде. Без әллә ялгыш шакыдыкмы?—ди.

Сания елмая:

—Дөрес шакыдыгыз. Керегез. Кави Нәҗми монда тора.

Тегеләр таптаналар ишек төбендә. Икенчесе сорый:

—Ә сез кем буласыз Кави Нәҗмигә?

—Мин, Кави Нәҗминең килене Сания булам.

—Ә-ә! Алай икән!—дип шатланып икесе дә елмаялар.

Кереп, өсләрен сала башлыйлар. Түрдәге бүлмәгә үтеп, Сания кемнәр килгәнен Кави белән Сәрвәргә җиткерә. Өчәүләшеп кунаклар янына чыгалар. Исәнләшү, кочаклашулар... Бу ике кунакның берсе—СССР

Язучылар берлеге рәисе Александр Фадеев, икенчесе урыс әдәбиятының олуг язучысы Михаил Шолохов була.

Өч язучы кунакханәнең зур бүлмәсендә берничә сәгать бик тә житди темага сөйләшеп кинәшләшәләр, гәп коралар. Алар сөйләшкән арада Сәрвәр белән Сания буфетка төшеп эчемлек, ашамлык алып менеп өстәл әзерлиләр.

Хәтирәләрдән соң Фадеев белән Шолохов килүләренең төп максатына күчәләр. Икесен дә нык борчыган мәсьәлә: "Гаепсезгә «сатлык» шагыйрь Муса Җәлил исемен ничек итеп акларга?

Шул очрашудан соң, бу өч язучы Муса Җәлилне аклау өчен ныклап эш җәелдереп җибәрәләр.

Авырлыклары, сикәлтәле эш юллары, күп кайгы-михнәт, нужалары, азмаз гына килгән шатлык-куанычлары белән тормыш дәвам итә.

1954 елда Советлар Союзы язучыларының II съездында Татарстан Язучылар берлеге исеменнән Мәскәүдә Кави Нәҗми доклад ясый. Съездда катнашкан язучы Луи Арагон Кави Нәҗми чыгышы турында түбәндәгеләрне язып чыга:

"Егерме елдан соң Кави Нәҗми, каләмдәшләре каршысына үзенең туган ил әдәбияты исеменнән килеп, эшчәнлеге ике съезд арасында дәвам иткән Шәриф Камалны ихтирам белән искә алып үтә, аннары Муса Җәлил турында, Фатих Кәрим турында сөйли: «...Совет ватанына соңгы шигъри юлларынача тугры хезмәт иткән шагыйрь һәм солдат. Аның Казан музеенда изге реликвия буларак саклана торган шинеле генә түгел, кульязмаларының соңгы битләренә кадәр пулялар белән тишкәләнеп беткән». Кави Нәҗми гомере хәрби госпитальдә өзелгән Гадел Кутуй турында сөйли. Ул—Маяковский поэмасының бормалы-сырмалы юлларында кайчандыр бервакыт мин очраткан иске таныш булып чыкты:

Килеп керә татар:
«Мин
татарча
«Сул марш»ны
укыйм
сезгә»,—

ди.

Кави Нәҗми бу сүзләрнең әле генә искә алып үтелгән шагыйрь турында булуын безгә әйтте. Татар әдәбиятында монарчы күрелмәгән жанрның тууы турында сөйләде: Фәйзинең Тукай турындагы романыннан башлап тарихи роман; Газиның «Онытылмас еллар»ы; шулай ук Гыйззәтнең, Мөхәммәт Галинең, Уразиковның, Исәнбәтнең тарихи драмалары. Ул үз иле әдәбиятындагы Сталин премиясе белән—Гомәр Бәшировның «Намус» романына бирелгән премия белән горурланды... Аннары шагыйрьләрнең исемнәрен атады: Хәким, Маннур, Баттал, Садри, Арсланов, Давыдов... Бу исемнәрдән, безне Моабит җырларына илтеп житкергән әдәбияттан, боларның барысыннан чыгып без нинди нәтиҗәгә килә алабыз? Язучыларын без белеп бетермәгән уннарча халыкларның берсе шушы түгелмени? Ничек алар белән ныграк танышырга?"

***

Кырыгынчы еллар азагы иде. Мин, йотылып татар әдәбятын укып, анардан зур ләззәт табып, унъеллык мәктәпнең өлкән сыйныфында укып йөрим. Шул елларда Шәриф Камалның «Акчарлаклар» повестеның асылын аңладым. Кави Нәҗми, Габдрахман Әпсәләмовның әсәрләрен яратам. Ә менә Гомәр Бәшировның «Сиваш»ы миңа бик ошаса да, аның Сталин

премиясе алган «Намус» романы миңа ошамады. Мин ул әсәрне бүген дә тәмләп укый алмыйм. Чөнки анда дөреслек юк. Ә менә Кави Нәҗминең «Язгы җилләр» романы минем бүген дә яратып укый торган әсәрем. «Ул анда Сталинны мактаган!»—дип аңа таш ыргыталар. Мин дә риза моның белән, чыннан да Кави абый Сталинны романында мактаган. Әйе, мактаган! Чөнки Сталин заманы өчен иң көчле революционерларның берсе булган.

Бүгенге көндә мин, язучы Зәки Зәйнуллин, инде картаеп барган, җитмешне узган бабай кеше. Байтак яшәп, бик катлаулы тормыш узып, зур тәҗрибә туплаган шәхесмен. Шул тормыш тәҗрибәсеннән чыгып, үзем өчен нәтиҗә ясадым.

Кави Нәҗми—батыр ихтыярлы, йөрәкле, язучы буларак таланты зур шәхес. 1937-39 елларда аны Казан НКВДсы подвалларында җәзалап рухи яктан сындырганнар, имгәтеп чыгарганнар. Шуңа күрә дә тиз үлгән дә Кави Нәҗми. Акыллы, башлы, уйлап эш итә белгән кеше булган ул. Шунлыктан, үзе яшәгән чор өчен коммунистлар партиясе башында торган лидерларга каршы барсаң, гомерең өзеләчәген аңлап, мәҗбүр булып шуларга тугры хезмәт иткән ул. Шул чорда минем дә бала чагым узды. Тоталитар курку эчендә үстем мин дә. Шунлыктан, чор рухын үз күзем белән күреп, тоеп үскәнгә, НКВД кулына эләгеп, бер-берсе өстеннән шикаять язган бичараларны мин әрли дә, сүгә дә алмыйм. Тик мин аларны кызганам һәм НКВД подвалларындагы шикелле җәлладларга эләкмәсәм генә ярар иде, дип Ходайдан ялварам.

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кульязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)



Рөстәм
Мингалим

# ЯНМЫЙ КАЛГАН ШИГЫРЬ ЭЗЛӘП...

## Картлыгым—шатлык өстенә шатлыгым

**Җир астында юллар юк,
Юк анда яктылык...
Якты җир өстендә яшәүнең
Картлыгы да—шатлык!**

**Илле яшемне атлап чыгып,
Алтмышымны сыртына егып,
Җитмешемә барган мәлем,
Җирдәшләрем!
"Картлык шатлык түгел" дигән фикергә
Кушылмадым әле.**

**Шушы шактый шакшы
Дөнья каршылыкларын аударып,
Алга бара алу—
Ничек инде шатлык булмасын?!
Чиксезлектән эзләп тапкан
Парың белән бергә бара алу—
Ничек инде шатлык булмасын?!**

**Дөрес анысы:
Олыгая бару—килеп бару түгел.
Олыгая бару—китеп бару—
Шунысы гына бераз моңсурак.
Ераклардан ишетелгән "Карурман" җыры сыманрак...
Каршыдан ишетелгән "Туган тел" җыры сыманрак...
Адашканда шундый моңга якыная бару –
Ничек инде шатлык булмасын?!**

**Мин үземне тормыш учагына
Ягам бугай артык тутырып, йа Аллам!
Тагын күпме барсам да
"Картлык шатлык түгел",—дип әйтә алмам.**

Рөстәм МИНГАЛИМ (1937) – *шагыйрь, драматург; егермедән артык китап ("Эзләр", "Дәрт чүлмәге" һ. б.) авторы. Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Бу тормышның миңа булган
Мәрхәмәтенә сокланырлык:
Яшьлегем—шатлык иде,
Картлыгым—шатлык өстенә шатлык!

## Өмет гөлем

Ак кар яуды кабат-кабат,
Яуды ла килеп-килеп;
Һәм ал гөлем калды әле
Ак карларга күмелеп.
Йөрәгемнән ул гөлемә
Карлар аша көч бирәм—
Бик сизәм лә, кыш озын ла,
Кар салкын ла, кар тирән.
Яз җитүгә карлар эрер,
Ал гөлем чыгар көлеп,—
Юк, сулмый да, коелмый да.
Ул—минем өмет гөлем!

## Учакларым яхшы яна

Һәр узган ел—учак: яна...
Яна йөрәгем өстендә...
Учакларым яхшы яна,
Минем йөрәк түзсен генә.
Җитмешенче елымны да
Ягып куйдым әле генә.
Учакларым яхшы яна:
Әйтерсең лә җир өстендә
Янмый калган шигырь эзләп,
Актарынам көлләрендә...

## Гел кабатлыйм шулай

Ялан тәпи узган көннәргә
әйләнәм дә кайтам сагынып,
Талларымнан телгә бал тама,
елгаларга йөрим табынып.

Йолдызым, Камышлым,
гел кабатлыйм шулай, гел генә.
Йолдызым, Камышлым,
әй туган яккынам, бергенәм.

Тәкъдиремә язган икәнсез
адашмаска миңа читләрдә.
Җиргә сыймас олы шатлыгым,
кычкырасы килә күкләргә.

Йолдызым, Камышлым,
гел кабатлыйм шулай, гел генә.
Йолдызым, Камышлым,
әй туган яккынам, бергенәм.

Әнкәм исе килә гөлләрдән,
исләренә җаным исерә.
Кәгъбәләрдән изге җир булса,
сез генә ул аннан изгерәк.

Йолдызым, Камышлым,
гел кабатлыйм шулай, гел генә,
Йолдызым, Камышлым,
әй туган яккынам, бергенәм!

***

...гә

Юлдан бара идек икәү бергә,
Кинәт кенә китеп югалдың.
Эңгер төште җиргә, кояш качты,
Әллә кояшны да син алдың?
Суынып китте күңелем, бушап китте,
Бер саңгырау бушлык—күз алды.
Юкка чыкты бугай әле җир дә,
Әллә үзең белән җирне алдың?
Син кояшны миңа калдыр инде,
Калдыр, сеңелем, миңа җирне дә.
Юкса күңелең тынгы таба алмас,
Яшәү туры килмәс җиңелгә.
Кояш төсе хәзер саф төс түгел,
Минем караш белән аралаш.
Җирдә—эзләремне очратырсың,
Узганыңа борылып карагач.

## Миңа ничек ышанырсың?

Тау артында бер ут булыр,
Таш эчендә чәчәк булыр.
Аны барып алырсың.
Эчендә чәчәк күрмәсәң,
Миңа ничек ышанырсың?!

Яр өстендә бер таш булыр,
Таш эчендә бер кош булыр.
Аны барып алырсың.
Эчендә кошын күрмәсәң,
Миңа ничек ышанырсың?!

Су төбендә бер таш булыр,
Таш эчендә кеше булыр.
Аны үрелеп алырсың.
Эчендә кеше күрмәсәң,
Миңа ничек ышанырсың?

Бер ташыңнан чәчәк ясыйм,
Бер ташыңнан кош ясыйм,
Бер ташыңнан кеше ясыйм,
Шунда миңа ышанырсың.



Ләбиб
Лерон

## КИЧЕРӘЛСӘҢ, КИЧЕР...

ИКЕ ПӘРДӘЛЕ МЕЛОДРАМА

**Катнашалар:**
Газинур (Нургази)
Нәфисә
Гөлчирә
Райнур
Фәнүсә
Фәннур
Хәдичә
Илнур
Сәрия

### БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

*Егерме беренче гасыр башы. Иртәнге як. Шәһәр читендәге бистә. Төзелеп бетеп килүче коттеджның диварына, капкасына кояш һәм пар күгәрчен рәсемнәре ясалган. Ишегалдының бер өлешенә җәй көннәрендә ашау-эчү, шулай ук килгән-киткән кешеләр белән сөйләшеп-гәпләшеп утыру өчен дип беседка сыман бер нәрсә корылган. Бер читтәрәк таган тора. Шул таганда бер ир агачтан нидер юнып утыра. Ир дигәнебез—Газинур. Биредә аны билгеле бер вакытка кадәр Нургази дип йөртәләр.*

*Жиңел машина килеп туктаган тавыш ишетелә. Бераздан, кәрәзле телефоны аша кем беләндер сөйләшә-сөйләшә, Райнур керә.*

Райнур. Фәнүсә апаң үзе килә! Үзе—за рулем! Минем вакыт юк! Сиңа әнине генә алып киләсе була. Аңладыңмы? *(Газинурга).* Сәлам, Нургази абый!

*Газинур башын кагып исәнләшә.*

Бензиның бармы? Булмаса, үз акчаңа заправить ит! Егерме литр! Акчасын килгәч бирермен!

Газинур. Райнур, әйт әле шоферыңа, берәр йөрәк даруы да алсын! Корвалолмы, нитроглицеринмы шунда...

Райнур. Ә? Хәзер! Марсель, слушай... Йөрәк даруы да ал! Карволол дисеңме, Нургази абый?!

Газинур. Әйе. Нитроглицерин да ярый...

Райнур. Марсель! Карволол, и нитроглицерин ал! *(Газинурга дәшә.)* Валидол да кирәкмиме?

---

*Ләбиб ЛЕРОН (1961)—шагыйрь, прозаик, драматург; «Сине генә сөям», «Чыктым аркылы күпер», «Сөяксез тел» һ.б. китаплар авторы. М. Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Газинур. Алсын!

Райнур. Ал! Валидол да ал! Нинди май алыштыру инде ул бүген! Йөреп тора бит әле машина. Иртәгә алыштырырсын! Әнине алып киләсе бар дидем бит! "Коттеджны күрәсе килә!"—дип бер ай тинтерәтә инде... Все! Акаеп чапма! Кара аны, янында әни барын онытма! Гутбай! Мерси боку! *(Телефонын кесәсенә тыга.)* Көн шәп бүген, ә?! Жырлап кына йөрерлек! *(Жырлый.)*

Хатын алдым, коттедж салдым,
Машинам да өр-яңа.
Заманның артына тибеп,
Яшәү кирәк дөньяда...
И-и-их!..

*(Аякларын тыпырдатып биеп ала.)* Йә, хәлләр ничек, Нургази абый? Коттеджны шәп сакладынмы? Бомжлар, төсле металл чәлдерүчеләр иснәнеп йөрмәдеме?

Газинур. Аллага шөкер, сынар эт тә күренмәде. Барысы да тәртиптә!

Райнур. Маладис син, Нургази абый! Син монда булганда, минем жан тыныч. Нәрсә, йөрәген бүген дә шалить итә мәллә? Дарулар, дисен...

Газинур. Юк, борчымый әлегә. Әмма гарантия биреп булмый. Мотор эштән чыгып килә. Клапаннар туздыі...

Райнур. Ничего! Медицина көчле хәзер! Клапаннарынны момент алыштырып куярлар... *(Нургази кулындагы агач кош сынына ымлый.)* Күгәрченне ясап бетерден мәллә?

Газинур. Юк әле. Күзләренә нур индерәсе калды.

Райнур. Бик озак маташтын инде монын белән.

Газинур. Бүләккә ул.

Райнур. Кемгә?

Газинур *(хәйләкәр елмаеп).* Монысы—сер. Әлегә.

Райнур. Буяп та жибәрсән, нәкъ чын күгәрчен була инде бу!

Газинур. Буявын малай буяр инде. Рәсемгә кулы ята анын...

Райнур. Сүз дә юк! Менә бит коттеджны нинди картинка иттегез! Молодцы, Нургази абый! Карале, минем башка бер гениальный фикер килде. Әйт Илнурга, ясасын картина. Сатып алам! Өйнен ин шәп жиренә үзегез эләрсез!

Газинур. Эләрбез! Анысы гына бездән тормас. Кичә малай бер картинасын ясап бетерде. Мина бик ошады!

Райнур. Алам! Бүген үк алып килсен! Әни дә күрер!

Газинур. Ул аны сатмас инде...

Райнур. Минамы? Мин бит аны сатып алам! Күпме сорый—акчасын шулхәтле бирәм!

Газинур. Малай аны бүләк итмәкче була...

Райнур. Кемгә?

Газинур. Сезгә. Фәнүсә белән икегезгә. Яңа коттедж белән котлап бүләк итмәкче була ул!

Райнур *(бүләкне хәзер үк кулына алгандай куанып).* Үһ-һу-һу! Рәхмәт, Нургази абый! Бүләккә каршы түгел мин! Акчага да ала идем. Үзен беләсен—мин деловой кеше! Ну, искусствоны яратам да инде мин, Нургази абый! Шишкин! Пушкин! Салават! Буяу! Картон! Карандаш!.. Әни килгәч, мәҗлес ясап аласы булыр. Курыкма, Нургази абый, чит-ят кеше булмый. Үзебез генә гүләйт будем! Илнурны да чакырырсын!

Газинур. Рәхмәт чакыруын өчен, иптәш мафиозник.

Райнур. Мафиози?! Минме мафиози?! *(Рәхәтләнеп, кычкырып көлә).* Нинди мафиози булыйм мин, Нургази абый? Алар янында мин—ерунда!

Но... байлык бар! Бусын отрицать итмим! *(Йодрыгын төйнәп).* Хватка да бар! Ерт...ерт... татарча шундыйрак нинди сүз бар әле, Нургази абый?

Газинур. Ертлачлыкмы?

Райнур. Вот, вот! Ерт-лачлык! Менә шул бар миндә. Үземә тиешлене алмыйча калган юк! Мин әтисез үскән малай, Нургази абый!. Мине әни үстерде... Әни! Һәм... и... урам кеше итте! Урам мине бернидән дә, беркемнән дә курыкмаска өйрәтте. Урам ул—искусство! Шишкин! Пушкин! Салават! Этләр янында—эт, төлкеләр янында—төлке, бүреләр янында бүре булырга өйрәндем мин!

Газинур *(шаяртып).* Каян гел сиңа гына очрап торды сон ул төлкеләр, бүреләр?.. Зоопарктан качканнарые мәллә? Якын-тирәдәге урманнан килеп, адашып йөриләрме?

Райнур. Көлмә, көлмә, Нургази абый. Кешеләр турында сүз барганны син бик яхшы аңладын...

Газинур. Ахмак түгел идем кебек

монарчы.

Райнур. Кеше—дөньяда иң заразы ерткыч!

Газинур. Бөтен кеше дә ерткыч була алмый инде, Райнур.

Райнур. Бөтен кеше дә—ерткыч, Нургази абый. Мин беләм инде... Уһу-һу! Мин бит шулар арасында кайнашам! Шулар белән бергә яшим! Ерткычлар арасында миңа да ерткыч булырга туры килә! Барыбыз да—ерткыч!

Газинур. Берүк ачуланма, Райнур... Әниең... Әниең дә ерткычмы?

Райнур. Әниме?! Әни ул... әни! Ул—святой человек! Ангел! Фәрештә!

Газинур. Фәрештәләр бала тапмый бугай бит?! Гафу...

Райнур. Мине тапкан бит әле! *(Көлеп жибәрә).* Шәп әйттемме, Нургази абый?!

Газинур (көлә). Ничава!

Райнур. То-то! Әтигә килсәк... Әти дә ерткыч! Баласын ташлап качкан ерткыч! Настоящий ерткычлар да алай итми! Ну, ничего... андый әтиең булганчы, булмавы яхшы!

*Газинур дерт итеп куя. Кулындагы күгәрчене жиргә төшеп китә яза—чак тотып кала.*

Райнур *(сүзен дәвам итә).* Манка агызып елап ятмадым... Үстем, кеше булдым! Менә нинди шәп коттедж салдым! Чудо бит!

Газинур. Чудо инде, чудо!

Райнур. Әйдә, Нургази абый, госкомиссия председателе килгәнче, әнине әйтәм, өй эчләрен тагын бер карап чыгыйк. Мактанышып та алырбыз!

Мактаганны яратам мин!

Газинур. Мактаганны кем яратмый инде... *(Урыныннан кузгала).*

*Сәрия керә.*

Сәрия. Күршеләр!

Райнур *(йорт болдыры янында тукталып).* Оһо!

Сәрия. Исәннәрмесез, күршеләр?!

Газинур. Исән әле, Сәрия сеңлем.

Райнур. Сәлам, сәлам, чибәр күрше! Кер әйдә, Сәриюшка! *(Сәрияне яратып күздән кичерә.)* Үзең—чудо! Күлмәгең—чудо! Импортный икәне күренеп тора!

Сәрия *(мактаганга күнеле булып).* Үзем тектем... дисәм, барыбер ышанмассыз!

Райнур. Супер! Классно выглядишь, Сәриюшка! *(Сәрия янына килә).*

Газинур. Мин кайтыйм булмаса. Кирәкмимдер бит әле, Райнур?

Райнур. Юк, юк, Нургази абый. Бар, үз эшләреңне эшли тор. Илнурга әйтергә онытма. Бергә киләсез, яме?!

Газинур. Әбизәтелне киләбез!

Сәрия. Нургази абый, син ясаган менә бу кояшка, күгәрченнәргә карап сокланып туя алмыйм. Бигрәк матур! Кулың алтын икән!

Газинур. Алтын дип... гап-гади куллар инде... Крестиянский!

Райнур. Нургази абый маладис кеше ул. Аның куллары гына түгел, ул—үзе алтын! Высшая проба!

Газинур. Бу хәтле мактауга... Кайтып салмыйча булмас, ахры!..

Райнур. Син бит салмыйсың, Нургази абый!

Газинур. Салган чаклар була!.. Шутка!

Сәрия. Нургази абый, Илнур кайда соң әле, бер дә күренми.

Газинур. Иртән иртүк су буена киткән иде. *(Чыгып китә).*

Райнур *(аның артыннан карап калып, Сәриягә).* Самородок! Шәп кеше! Минем әти шундый кеше булган булса... Кем булыр идем микән мин? Глава правительства?! Юк, президент! *(Тавышын калынайтып).* Президент Райнур Шәйхиев! Минтимер Шәймиев кебек шәп яңгырый бит фамилия, ә?!

Сәриюшка?!

Сәрия *(чытлыкланып).* Супер! Классно, үзең әйтмешли!

Райнур. Чибәр син, Сәрия! Күзләрең, карашың ут синең! Яндыра, көйдерә! Шул күзләреңә карап, жырлыйсы килә! *(Жырлый.)*

Кайларда гына булмадым,—
Айда гына йөрмәдем.
Синең кебек гүзәлкәйне
Бер жирдә дә күрмәдем...

Сәрия. Хатының килсә, күрсәтер әле сиңа "гүзәлкәй"не...

*Машина туктаган тавыш ишетелә.*

Сәрия. Әнә, Фәнүсә килде дә бугай инде...

Райнур. Кажется, да... *(Сәриягә.)* Болай гына кермәгәнсендер бит, Сәриюшка? Йомышынны әйтеп кал!

Сәрия. Йомыш дип... Мина Илнур кирәк иде дә инде... Су буена киткән икән бит.

Райнур. Анлашылды-ы-ы, мадумазель-туташ...

*Фәнүсә, Хәдичә һәм Фәннур керә. Фәннур кулында зур сумка. Фәнүсәнең көмәнле икәне беленеп тора.*

Хәдичә *(әүвәл Сәрияне күреп)*. И-и, бу дөньяның тарлыгы! Нишләп йөрисең монда, Сәрия? Әллә син дә Райнурның хатынымы? Хи-хи-хи... Фәнүсәкәем, бер дә көндәшең барлыгын әйткәнең булмады. Хи-хи-хи... *(Райнурга)* И-и, хәзерге байлар яшәп тә күрсәтә инде. Бер үзенә—ике хатын! Хи-хи-хи... *(Фәннурга)*. Ә син бердәнбер хатынынны да асрый алмыйсың, жан көеге!..

Сәрия. Мин... ни... Илнур...

Райнур. Нинди ике хатын? Фәнүсә—минем бердәнберем. *(Фәнүсәне кочып, битеннән үбеп ала)*.

Фәннур. Башта исәнләшергә кирәк, Хәдичә!.. Исәннәрмесез!

*Фәннур, сумкасын бер читкә куеп, Райнур белән күрешә. Аннары Сәрия белән исәнләшә.*

Фәнүсә *(Хәдичәгә)*. Менә шушы була инде безнең коттедж! Райнур тырышты! *(Райнурга сыена)*.

Хәдичә *(сузып)*. И-и-и-и! Без дә кеше булып яшәгән булабыз! *(Фәннурга)*. Менә, күр, кешеләр нинди хан сараенда яшәп ята!

*Райнур, башын югары чөеп, горурланып басып тора.*

Фәнүсә. Райнур йокы күрмәде инде, көне-төне чапты.

Райнур. Чабасың инде, бер генә яшибез бит! Яшәп калырга кирәк!

Хәдичә (Фәннурга). Ишеттенме, директор кисәге, Райнур нәрсә ди әнә! Яшәп калырга кирәк, ди. Ә син "Мәктәп! Мәктәп!" дип өтәләнгән буласың! Юкны бушка аударып йөрисең шунда! Өйгә кайтып та кергәнең юк! *(Башкаларга карап әйтә.)* Жиде укучыга унсигез укытучысы бар аның! Хи-хи-хи!.. Шуларның тамагын туйдырам дип йөри, үзе ач—авызын ачса, үпкәсе күренеп тора! Хи-хи-хи... Макаренко несчастный!..

Фәннур. Жиде түгел, йөз дә егерме жиде укучы!..

Хәдичә. Барыбер инде. *(Сәрия янына килә)*. Син дә бу тирәдә яшисең мәллә? Фәнүсәләр белән бергә ничек туган-мазар түгелдер бит? И-и-и, йортлары матур да инде, име?!

Сәрия. Гажәп инде, гажәп!

*Райнур Фәнүсәне бер читкәрәк алып китә. Фәннур, болдыр янына килеп, агач-бизәкләрне сыйпаштырып-караштырып йөри.*

Райнур *(Фәнүсәгә генә ишетелерлек итеп)*. Кемнәр бу? Кайдан таптың боларны?

Фәнүсә. Хәдичәне танымадың мәллә? Минем группадашым бит! Университетта бергә укыган идек, синең аны күргәнең бар.

Райнур. Хәтерләмим бер дә.

Фәнүсә. Ничек инде—хәтерләмисең?! Группадашлар белән бер очрашканда син дә бар идең бит! Ресторанда бергә утырдык. *(Фәннурга ишарәли.)* Ә бу—аның ире, Фәннур исемле. Хәдичәне узган атнада Казанда очраткан идем, коттеджны күреп китәрсез дип, кунакка чакырдым. Менә бүген автовокзалдан каршы алдым үзләрен.

Райнур. Машиналары юкмыни?

Фәнүсә. Бар, диләр... "Москвич". Иске икән. Юлда ватылыр дип курыкканнар...

Сәрия *(Хәдичәгә)*. Мин дә бит монда яшим. Әнә тегендә генә безнең коттедж. Безнең дип, Раил абыйларның коттеджы инде...

Хәдичә. Раил?! Ул да монда яшимени?

Сәрия. Әйе. Әле менә... хатыны белән икесен... чит илгә, Анталиягә жибәрдем. Балаларыгыз белән ял итеп, дөнья күреп кайтыгыз, минәйтәм! Үзем дә бер атна элек кенә Гарәп Әмирлегеннән кайттым...

Хәдичә. Да-а-а... Гомер буе тирескә чумып яшәгән чая Фатыйма белән Габдерәүф балалары да кеше булган диген, ә! Дистрофик абыең белән кайчандыр бер партада утырган идек... Дәрес буе йоклар ие... Да-а-а... Дөнья

бу, диген... Әйтәм аны бер дә авылга кайтканыгыз юк...

Сәрия. Эти белән әни үлгәч, кемгә кайтасың инде?! Авылда бүтән туган-тумачалар да калмады.

Хәдичә. Шулай инде, шулай. Якын туганың булмагач, чит кешегә кайталмыйсың, дөрес! Күңелем кин дип кенә булмый әле ул... Бөтен нәрсә кыйммәт бит хәзер. Сөт-каймагы да үзеңнән артмый!

Сәрия. Елга ике-өч мәртәбә чит илгә чыгып керәм... Как-никак, туристик агентствода эшлим бит! Путевкалар белән эш йөртәм!

Хәдичә *(кинәт үзгәреп, дәртләнеп).* Кит аннан! Чынлапмы? Фәннур, ишеттеңме? Сәрия чит илләргә ял итәргә җибәрә торган җирдә эшли икән бит! Әстагым! Менә бит, ә! Сәриякәем! Кадерле авылдашкаем! Авылдаш кына түгел, чыбык очы тиешле туганнар да бит әле без, Сәриякәем! Фатыйма апаның туганнан туган абыйсы безгә дә җизни тиешле бит!

Райнур. Табын әзерләргә кирәктер ич, Фәнүсә? Булышыйммы, матурым?

Фәнүсә *(Хәдичәнең тавышына охшатыбрак).* Хәдичәнең сайраганын тыңлап, онытылып киткәнмен. Әйе шул, әйдә өйгә керик әле, Райнуркаем!

Райнур. Сез сөйләшә торыгыз, без момент! *(Өйгә кереп китәләр).*

Хәдичә. Менә бит, ә! Көтмәгәндә-уйламаганда ... бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына! Шушыдыр инде ул дөньяның хикмәте! Без дә , Фәннур белән икәү, берәр чит илгә барырга дип уйлап кына торадырыек! Болай булгач, барабыз! Иң якын туганың путевкалы урында эшләп тә бармасаң... Безгә путевканы ярты бәясенә эшләрсең инде, җаныкаем, Сәриякәем! Ничек тә җаен табарсың?

Фәннур. Тинтерәтмәле Сәрияне! Бетмәде инде шул соранууларың!.

Хәдичә. Нинди сорану булсын! Нинди сорану булсын!!! Соранумыни бу?! Әй, ике туган сөйләшкәндә бака ботын кыстырып тормасана! Үзенең сыңар туганы да юк... Сәриякәем! Кайчанрак бару мәсьәләсен хәл иткәч, тагын конкрет сөйләшербез әле, име?

Сәрия. Авылдашларга кулдан килгәнчә булышмыйча булмас инде...

Хәдичә. Авылдашлар гына түгел... Туганнар дим бит инде, туганнар без! Туп-туры безгә кайт!

Сәрия. Рәхмәт чакыруын өчен!

Хәдичә. Рәхмәтне без дә әйтербез... Алла боерса! Чит илгә барып кайткач... И-и-и-и!.. *(Сәрияне кочаклап ала).* Шундый туганнарың булганда, иллә рәхәт дөньяларда яшәве!

*Илнур керә. Бер кулында—пакет-сумка, икенчесе белән кармак сабы тоткан. Барысы белән дә баш кагып кына исәнләшә.*

Сәрия. Исәнме, Илнур җаным!? *(Кармакка ишарәле).* Балык тоттыңмы әллә? Килькиләр эләгәме, минтайлармы?

*Илнур, елмаеп, юк, дип, башын селки. Хәдичә аңа сәерсенеп карап тора. Фәннур Илнурны игътибар белән күзәтә.*

Хәдичә. Телсез мәллә бу чибәр егет?

Сәрия. Әйе.*(Илнурга).* Бүген дә рәсем ясадыңмыни, Илнур?

*Илнур, әйе, дип баш кага. Тагын ниндидер ым-хәрәкәтләр ясый.*

Фәннур. Эти монда түгелме, дип сорый ул?

Хәдичә аңа гаҗәпләнеп карый.

Сәрия. Нургази абыйммы? Баягынак китте шул. Өйгә кайтам, диде.

*Илнур китмәкче була. Өйдән Райнур чыга.*

Райнур. О-о, Илнур! Сәлам, рыбак! Салют!

*Илнур баш кагып исәнләшә.*

Райнур *(ишарәләр белән дә сөйли).* Нургази абыйга да әйттем, сиңа да әйтәм! Сине дә ждем-с! Понял, Илнур?

*Илнур, әйе, дип баш кага да, "киттем" дигән ишарә ясый.*

Райнур. Яхшы. Көтәбез! Ждем-с!

Сәрия. Мин дә кузгалыйм әле. Озак тордым. Күршеләрнең хәлен белеп чыгыйм, дип кенә кергән идем. Әйдә, Илнур жаным, киттек! *(Илнурны култыклап ала.)*

*Бергә чыгып китәләр.*

Райнур. Әни килгәч, син дә кер, Сәрия!

Сәрия *(тавышы гына ишетелә).* Ярা-а-ар! Рәхмәт!

Хәдичә. И-и-и... Нинди чибәр егет! Теле юк диген, ә?! Ата-анасына гомерлек хәсрәт инде бу, мәңгелек хәсрәт!

Райнур. Әнисез үскән ул.

Хәдичә. Менә бит, ә! Әнисез дә икән, өстәвенә телсез дә! *(Фәннурга).* Син баягынак аңлап сөйләшкән кебек булдың... Кайдан беләсең син телсезләр телен?

Фәннур. Мин институтта укыганда телсезләр мәктәбендә практика уздым. Дөнья бит, кайвакыт телсезләр телен белүнең дә кирәге чыгып куя. Әле менә син беренче тапкыр авызыңны ял иттердең... Миңа сөйләшергә жай чыкты!

Хәдичә. И, хәчтерүш! Полиглот булган берәү! Бер жөмләне көчкә әйләндердең... Сөйләшергә жай чыкты дип, авыз тутырып әйткән буласың тагы... Каяле, Фәнүсәкәемә булыша торыйм, ичмасам! Кара инде бу баскычны! Кара инде бу ишекне! И-и-и! Галәмәт инде, галәмәт! *(Сөйләнә-сөйләнә керер китә.)*

Райнур. Әйдә, Фәннур дус, хатыннарсыз гына сөйләшеп утырыйк әле. Кайчан безгә мондый жай чыга...

*Беседкага кереп утыралар.*

Фәннур. Коттеджың шәп булган! *(Йортка карап).* Моңа бит бик күп агач кирәк, акча турында әйтмим дә инде. Анысы—само собой!. Күренеп тора, йорт хуҗасы—булдыра торган кеше!

Райнур *(мактаганга күңеле булып).* Байлык үзеннән-үзе килми, диләрме әле?! Укырга, укырга... и эшләргә, эшләргә кирәк! Иң главные—уйлап эш итә белергә кирәк! Ә-ә-з генә ...ошибка, малейший ялгышлык жибәрденме—беттең... Конец! Гутбай, Америка! Сау бул, Кәжә бистәсе!

Фәннур. Хатынның... Хәдичәне әйтәм, сөйләгәне колак очында эленеп калган... Син—крупный бизнесмен бит әле?! Машиналар белән эш йөртәсең бугай?!

Райнур. Крупный дип... Ну да! Известный бизнесмен... да! Райнур Шәйхиевне чит илләрдә дә яхшы беләләр! Уважают!

Фәннур *(гажәпләнеп).* Шәйхиев!? Син... Шәйхиевмени?

Райнур. Ну да! Шәйхиев! Райнур Шәйхиев!

Фәннур. Мин дә... минем дә фамилиям... Шәйхиев бит!

Райнур. Да? Не может быть! Неужели Шәйхиев?

Фәннур *(Райнурча әйтә).* Ну да!

Райнур. Без бит адашлар, алайса! Тезки! Тот бишне, адаш! *(Фәннурга кулын суза.)*

*Кул бирешәләр.*

Фәннур. Агай-энеләр дә түгел микән әле без? *(Көлә).* Ха-ха-ха...

*Икәүләп көлешәләр.*

Райнур. Ә нигә?! Все может быть! Ха-ха-ха! Синең ...отчествоң ничек? Ха-ха-ха!..

Фәннур. Ха-ха-ха! *(Көлү аралаш).* Газинурович!..

Райнур *(кинәт очкылык тоткандай).* Ыйк! Ничек... Газинурович?! Правда, што ли?

Фәннур *(көлүеннән туктый алмыйча).* Ха-ха-ха... Ну да!..

Райнур. Постой! Мин дә ... Газинурович бит!

Фәннур. Вәйт, әкәмәт! Әллә чынлапмы? Икеләтә адашлар булып чыктык түгелме соң? Тот тагын бишне!

*Янә кул бирешәләр. Көлешәләр.*

Райнур. Без әле братлар түгел микән? Анекдоттагы кебек, ә?! Ике мишәр очрашкан ди бит. Шәһәр мунчасында. "Син кайсы яктан?"—дип сорый икән берсе. "Ульяннан!"—ди икән икенчесе. "Мин дә Ульяннан бит!"—дигән сорау биргәне. "Кайсы авылдан?" "Кулаткадан". "Вай, мин дә Кулаткадан". "Син кем малае?" "Фәлән

әзи малае!” “Кит аннан! Мин дә Фәлән әзи малае бит! Бак! Без братлар икән, вай!” “Исәнме, брат!” “Саумы, брат!” “Атай нишләп ята?” “Катты!” “Ничек ... катты?” “Паталукка бакты да катты!” Ха-ха-ха!..

Фәннур. Ха-ха-ха... Менә бит, ә! Менә бит, ә! Братлар диген! Ха-ха-ха!

*Һәйбәт кәчтүм-чалбар, ап-ак күлмәк кигән, галстук таккан Газинур керeп килә.*

Газинур. Тук-тук!

Райнур. Кер әйдә, Нургази абый! Кил әле монда тизрәк!

Газинур *(Фәннур белән күрешә).* Исәнме, энекәш!

Фәннур. Фәннур булам. Исәнмесез, абый!

Газинур. Бик каты көлешәсез... Анекдот сөйлисездер әле?!

Райнур. Точно, Нургази абый! Каян белдең?

Газинур. Ир-атлар очрашса, йә анекдот сөйлиләр инде, йә хатын-кызларның гайбәтен саталар... Икенең берсе! Шулай түгелмени?!

Райнур. Пачти! Ха-ха-ха!..

*Көлешәләр.*

Фәннур *(Газинурга)* Абый, ботинкагызның шнуры сүтелгән...

Газинур. Хәтерсез баш! Бәйләргә онытмыйм микәнни?! *(Ботинкасына иелә).*

Райнур. Нургази абый, без монда... Ха-ха-ха... Фәннур белән... адашлар булып чыктык бит әле!.. Юк, пачти быратлар!.. Ха-ха-ха!..

*Өйдән Фәнүсә чыга.*

Райнур. ... Фәннур да, мин дә... *(Сүзен әйтеп бетерә алмый).*

Фәнүсә *(кесә телефонын тоткан кулын алгарак сузып, Райнурга карап).* Шәйхиев!

*Шулчак гаҗәп-мәзәк хәл була. Газинур башын кинәт калкыта, Райнур белән Фәннур Фәнүсәгә таба борыла.*

Өчесе бергә. Ә?

*Райнур белән Фәннур башта Газинурга, аннан бер-берсенә карап, дәррәү көлеп җибәрәләр. Аларга Фәнүсә дә кушыла. Газинур, ярамаган эш өстендә тотылган малай кебек, бер мәл нишләргә белмичә тора, кәчтүмен рәтләштергәндәй итә, кулларын буташтырып ала...*

Газинур. Мин... Мина әйтәсең дип торам, Фәнүсә! *(Бармагын колак тишегенә тыгып, селкетеп ала).* Яшь бара, колак та дөрес ишетми башлады...

Фәнүсә *(көлүеннән туктап, Райнурга).* Телефонынны өйдә калдыргансың, Шәйхиев! Сиңа Марсель шалтырата!. Мә, сөйләш!

*Телефонны Райнурга бирә дә өйгә кире керeп китә.*

Райнур. Әйе, Марсель! *(Сәгатенә карый).* Яхшы! Молодец! Хәзер каршы алабыз! Карале, анда... безнең урам башында... кемгәдер бүрәнәләр китереп аударганнар... Сак бул, кума! Понял? Ярый, давай!... Хәзер каршыгызга чыгабыз. Связь окончен. *(Телефонын кесәсенә тыгып куя).* Коттеджны кабул итәргә госкомиссия килә! Нургази абый, бар, иренмә, Илнурны алып кил!

Газинур. Кайтмады бит әле ул!

Райнур. Кайтты инде, кайтты! Әле генә монда сине эзләп килгән иде.

Газинур. Каршыга очрамады.

Райнур. Шулайдыр. Илнурга әйт, картинасын алып килергә онытмасын!

Газинур. Әбизәтелне!

Райнур. Давай, Фәннур... адаш! Быраt! Без икәү әнине каршы алыйк!

Фәннур. Әйдә, быррат! Анайны каршылаек!.. Ха-ха-ха!

*Көлешә-көлешә чыгып китәләр. Газинур, житдиләнеп, бер мәл алар чыгып киткән якка карап тора. Аннан, таган янына килеп, аны атындырып җибәрә. "Күк күгәрчен" көе яңгырый. Ерактан (яшьлектән) Газинурның җырлаганы ишетелә:*

Күк күгәрчен күктә уйный,
Күләгәсе җирдә уйный...

*Җыр ераклаша бара. Ут сүнә. Музыка.*

***

*Үткән гасыр. Житмешенче еллар башы. Бер-берсенә сыенып, салмак кына атлап Нәфисә белән Газинур керә. Нәфисәнең жилкәсендә Газинурның пинжәге. Газинур белән Нәфисәнең үз-үзләрен тотышы яшь ир белән яшь хатынны хәтерләтә. Газинур мыек жибәргән, Нәфисә чәчләрен жыеп-өеп, житмешенче елларга хас булган прическа ясап куйган.*

Нәфисә. Без гел шулай, кешеләрдән качып-посып, яратышып яшәрбез микән, Газинур?

Газинур. Борчылма, Нәфисә. Тиздән бергә булырбыз! Гөлчирә белән аерылышыйм инде... Аннан соң мин— мәңге синеке!

Нәфисә. Гөлчирә апа сине... ычкындырмас шул!

Газинур. Ычкындырыр, нибуч! Яратмыйм мин аны, хет үтер, яратмыйм!

Нәфисә. Нигә өйләнден соң алайса?

Газинур. Үзе бит... Гөлчирә бит...

Нәфисә. Характерың йомшак синең, Газинур. Жебегән син! Шуңа күрә Гөлчирә апага өйләнден дә! Дөресрәге, Гөлчирә апа сина өйләнде!

Газинур. "Апа" димәле шуны.

*Бер мәл тын торалар.*

Нәфисә. Мин көн саен елыйм, Газинур... Ишетәсенме, көн саен! "Кайчаннан бирле?"—дип ник сорамыйсың, Газинур?

Газинур. Без... Гөлчирә белән ... бергә ...яши башлаган көннән бирледер инде.

Нәфисә. Юк шул... Тагын да алдарак! Син армиядән кайткан көнне елый башлаган идем мин... Хәтеренләме, шушы урында очрашкан идек?

Газинур. Истә.

Нәфисә. Гөлчирә апа... Гөлчирә апа ...сине өйгә хәтле култыклап кайтты. Ә мин... сезнең арттан... күз яшьләремә буылып... атладым... Аннары лапас өстендәге печәнлеккә менеп... төне буе илереп еладым . Кулымнан бәхет кошы ычкынганын сизеп, шуны аңлап еладым мин... Мин хәзер дә елыйм... Газинур.

Газинур. Елама, Нәфисә! Телисеңме, мин сиңа хәзер бер шигырь сөйлим?

Нәфисә. Үзеннекеме әллә?

Газинур. Юк инде...

Нәфисә. Син бит... шигырьләр укырга яратмый идең, Газинур!

Газинур. Соңгы вакытларда күңелем әллә нишләде... Шигырьләр укып, алардан юаныч эзли башладым... Сагышлы шигырьләрдә безнең язмыш чагылып ята кебек... Менә... тыңлале...

Елыйсың. Нигә еларга?
Елама, кирәк түгел!
Юкса бит ир-егеттә дә
Шау тимер йөрәк түгел.

Беләм, әйе, ялгышканбыз—
Ак һәм кара буталган.
Безгә тиешле учактан
Чит кешеләр ут алган.

Назлар кире кайтсалар да,
Язлар кайтмас кабаттан.
Без гөнәме үз канатын
Давылларда канаткан?

Ялгышканда көлгәнбез бит,
Елмайганбыз бит әле!
Хәзер дә көлик, капланып,
Күз яшьләре үтәли...

Елыйсың... Нигә еларга?
Елама, кирәк түгел!
Миндә дә бит шау тимердән
Ясалган йөрәк түгел.

*(Күз яшьләрен сөртеп ала.)*

Нәфисә *(елый)*. Жылата торган шигырь. Кем язган икән моны?

Газинур. Зөлфәт дигән шагыйрьнеке... Беренче тапкыр укыган чакта ...сине уйлап... минем дә күзләремә яшьләр килгән иде... Жебегән, дип... дөрес әйттең син миңа, Нәфисә. Әйе, жебегән мин! Елак мин! Слабак! Аумакай! Үз бәхетемне үзем аяк астына салып таптый... яздым...

Нәфисә. Таптадың бугай инде син аны, Газинур...

Газинур. Алай димәле, Нәфисә! Әле соң түгел...

Нәфисә. Соң инде, Газинур... Бергә булсак та, без барыбер бәхетле булалмаячакбыз...

Газинур. Ничек? Нигә? Алай димәле, Нәфисә...

Нәфисә. Син Гөлчирә апаны ташлап китсәң дә ... улыңны... ташлый алмаячаксың, Газинур! Яратасың син улыңны, үлеп яратасың!

Газинур (*урыныннан торып*). Син... шушы сүзләрне әйтергә дип алып килдеңмени мине монда, Нәфисә? Нәфисәм, күгәрченем.

Нәфисә. Күгәрченнәр парлы була, Газинур...

Газинур. Гел елыйм , дип ялганлыйсың син, Нәфисә. Яратмыйсың син мине. Яратсаң мондый сүзләр сөйләмәс идең... Бергә булыйк, дияр идең...

Нәфисә (*сикереп тора*). Яратам, Газинур, яратам! Ләкин кеше ярын сөяргә хакым юк минем! Без адаштык, без зур гөнаһ кылдык, Газинур!.. Ходай кичерер микән безне ?

Газинур (*Нәфисәне кысып кочаклый*). Нәфисә!

Нәфисә. Без бүгеннән соң кабат очрашмабыз, ахрысы.

Газинур. Алай димәле, Нәфисә!

*Ашыгып-кабаланып Гөлчирә керә. Ул шәһәрчә киенгән.*

Гөлчирә. Гулящийлар! Заразылар! Себеркеләр! Ишеттергәннәр иде аны, дөрес икән! Оятсызлар! Ябышып каттыгыз мәллә? Мине күргәч тә аерыла алмый торасыз... Чәнчелгереләр!..

*Нәфисә Газинурның кочагыннан чыга.*

Газинур. Чәпчемәле, Гөлчирә. Күрдең инде... Әйбәтләп кенә сөйләшик!

Гөлчирә. Чәпчемәм менә! Артыңны кысып, тик кенә тор, сөйрәлчек тәре! Синә сүз бирелмәгән! Авылга качып котылмакчы булган берәү!

Газинур. Качмадым мин синнән. Чыдарлык... түзәрлек хәл калмагач... киттем. Яратмыйм мин сине!

Гөлчирә. Мин синнән "Яратасыңмы?" дип сорамыйм... Тик кенә тор!

Малаең больницада ята, ә син себерелеп йөрисең, имгәк!

Газинур, Нәфисә. Райнур больницадамыни?

Гөлчирә (Нәфисәгә). Бәреп үтергәнче, югал күз алдымнан!

Газинур. Кычкырма Нәфисәгә! Аның бер гаебе дә юк! Монда ... көтмәгәндә очраттым да үзем сүз каттым...

Гөлчирә. Әкият сөйләмә! Мин монда әкият тыңларга килмәдем.! Син тәрәнең, (*Нәфисәгә ымлап*) бу тәрәнең дә... икегезнең дә сволочьлар икәнегезне бик яхшы беләм! Арттан пычак кадаучылар сез! Кабәхәтләр! Бүген разборка ясап торырга вакытым юк! Машина көтеп тора. (*Газинурга.*) Киттек, хәшәрәт! Райнур сине таптыра! (*Нәфисәгә*). Ә син, кеше семьясын бозучы, исеңдә тот: моннан соң... әгәр икегез турында ялгыш бер кыек сүз ишетсәм,., капут сиңа! (*Газинурга*). Аңладыңмы, жирбит?!

Газинур (*Нәфисәгә карап*). Нәфисә... Райнур бит... больницада икән бит...

Нәфисә. Хуш, Газинур...

Гөлчирә. Алдыңа кара! (*Газинурны эткәләп-төрткәләп диярлек алып чыгып китә.*)

*Нәфисә, куллары белән битен каплап, тораташ булып, басып кала. Ут сүнә. Музыка.*

Беренче пәрдә тәмам.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

*Беренче пәрдәдәге коттеджлы күренеш. Фәннур күтәреп кергән зур сумка бая ничек куелган булса, урынында һаман шул килеш тора. Өйдән көлешә-көлешә Фәнүсә белән Хәдичә чыга.*

Хәдичә. Бәхетең бар икән, Фәнүсәкәем... Кайнанаңнан уңгансың! Бик сирәк киленнәргә генә тәти мондый бәхет! Но... яхшы кайнана белән яшәүнең бер авыр ягы бар! Рәхәтнең дә бер михнәте бар дигәндәй, бар бер авыр ягы! Рәхәтләнеп! ду китереп! кара яндырып!., талашалмыйсыз инде түлке! Ә талашасы килә-ә-ә!.. Табак-савыт юган чакта юри генә бер тәлинкәне идәнгә төшереп

челпәрәмә китерәсен... Кайнананың шунда бер ялгыш сүз ... ычкындыруы житә... Шундук мәшхәр кубачак югыйсә! Юк! "Сөенечкә булсын!"—дигән сүзе белән синең гениальный планыңны жимерә дә ташлый... Гөлт итеп кабынам дип торган бөтен ачуың шул минутта юкка чыга да куя. Дөньядагы бөтен әшәке сүзне пулемет кебек сиптерергә торган авызыңның жырылганын сизми дә каласың... Бик акыллы, бик затлы, бик укымышлы, үзе гомер буе сыер сауса да , бик интеллегент хатын иде минем кайнана да!..

Фәнүсә. "Иде" дисең, үлдемени?!

Хәдичә. Әйе. Урыны жәннәттә булсын! "Жәйләүләрдә сыер сауды Гөлмәрьям..."

Фәнүсә. Нишләп бик иртә үлде соң ?

Хәдичә. Әйтсәм ышанмассың, Фәнүсәкәем! Аны ...яшьлек мәхәббәте гүргә кертте.

Фәнүсә. Аңлап бетермәдем... Ничек? Нинди яшьлек мәхәббәте?

Хәдичә. Яшь чакта ул безнең авылдагы бер егетне үлеп яраткан булган. Кавыша алмаганнар. Хәлләр булган инде анда. Телевизордан барган хәзерге сериаллар аларның мәхәббәте янында пүчтәк кенә!

Фәнүсә. Нигә бергә була алмаганнар?

Хәдичә. ... бер туган апасы... егетенең башын әйләндергән дә... үзенә өйләндереп, шәһәргә алып тайган!..

Фәнүсә. Сөйгәнен сагынып яшәгәнме?

Хәдичә. Мәхәббәтен сагынып яшәве, башка кешегә кияүгә чыкмавы хак...

Фәнүсә. Нык яраткан икән егетен. И язмыш диген, ә!? Фәннурның тууын ... әтисе белде микән соң?

Хәдичә. Юктыр. Белмәгәндер. Баласы барлыгын белгән булса, йөрәге түзмәс иде—хет бер кайтып күрер иде. Фәннурга атасыз үсәргә насыйп булган инде... Ярты ятим! Кирәк чакта ата назын, кирәк чакта ата каешын татымаганга күрә, хужалыкчан булып үсмәгән дә инде ул менә. Гаиләдәге бөтен эш, бөтен авырлык минем жилкәдә хәзер! Күтәр, Хәдичә! һоп-па! Тарт, Хәдичә! На! На! "Ял ит, Хәдичә! Тыр-р-р!" диюче юк!

Фәнүсә. Безнең Райнур да ятим үскән инде анысы...

Хәдичә. Ул хет чын хужа булып үскән. Әнә нинди коттедж салдырып куйган! Патша сарае диярсең!

Фәнүсә. Фәннурың төпле кешегә охшаган... Сиңа аның белән тормыш итүе жайлыдыр.

*Фәннур, чыгып, тыңлап тора.*

Хәдичә. Наоборот! Ана минем белән жайлы! Булган хатын электе үзенә. Әйтәм бит, өйдәге бөтен эш—минем жилкәдә! Кибеттән товарны мин алып кайтам! Сатам! Ярый әле кызыбыз Суфия кул арасына кереп килә... Берәрсенә укол кадатырга кирәк булса, мин чабам. Кем массаж ясый? Мин! Туйларны кем гөрләтеп алып бара? Хәдичә! Шәһәрдәге балаларына, оныкларына дип, кемгә оекбашлар бәйләргә заказ бирәләр? Алтын куллы Хәдичәгә!

Фәннур *(кинәт телгә килеп)*. Акчаны бик ярата инде ул безнең Хәдичә!

Хәдичә. Әстәгым! Тыңлап торган икән! Ышпион! Кем акча яратмый инде?! Тиле!

*Фәнүсә белән Фәннур кычкырып көлә.*

Фәнүсә *(Фәннурга)*. Карыныгыз ачтымы әле? Түзегез инде бераз. Нургази абыйлар килеп житсен, ди бит Райнур. Көткән-көткән... көтик булмаса!.. Әллә капкалап аласызмы соң?

Фәннур. Мин тук. Рәхмәт, Фәнүсә.

Хәдичә. Берүзем ашап утырмам инде. Килешеп бетмәс. Бая сиңа ризык әзерләшкәндә тегесен-бусын капкандай иткән идем... Ашказаны тынычланган кебек булды...

Фәнүсә *( Фәннурга, өйгә ишарәләп)*. Райнурлар нишли әле анда?

Фәннур. Госкомиссия рәисе бик таләпчән булып чыкты. *(Көлә.)* Гөлчирә апаны әйтәм... һаман тикшерә. Өйрәтә. Киңәшләрен бирә. Бер дә гомер буе столовойда эшләгән кеше димәссең! Йорт салу эшен белеп сөйләшә.

Фәнүсә. Исең китмәсен. Минем кайнанам шундый инде ул! Белмәгән нәрсәсе юк. Фатирына сантехник та чакырмый ул. Берәр нәрсәсе ватылса,

Райнурга да әйтеп тормый, үзе рәтли дә куя.

Х ә д и ч ә. Нәкъ минем төсле икән!

*Газинур белән Илнур керә. Илнур да киенгән-ясанган, кулына чүпрәк белән капланган картина тоткан. Газинур кара күзлектән.*

Г а з и н у р. Коттердекме? *(Хәдичәгә.)* Исәнме, сенелем?

*Хәдичә баш кагып исәнләшә.*

Ф ә н ү с ә. Юк, зыян юк. Әйдәгез, узыгыз! Райнур! Нургази абыйлар килде!

Х ә д и ч ә. Абзый кеше кара күзлек киеп җиппәргән әле! Килешеп тора үзенә!

Г а з и н у р. Кояш күзне чагылдыргач... кигән булдым әле менә...

*Сәрия керә. Ул да яңа, матур күлмәк кигән.*

С ә р и я. Мин дә килеп життем әле!

Ф ә н ү с ә. Әйдә, уз, Сәрия!

*Сәрия Илнур тирәсенә барып баса. Өйдән башта Райнур, аннан бераз гына калышып, Гөлчирә чыга. Гөлчирә дәрәҗәле урында эшләгән хатын-кызлар төсле заманча киенгән.*

Р а й н у р. Оho! Все в сборе! *(Гөлчирәгә борылып.)* Әни! Таныш бул! Нургази абый! *(Газинурга.)* Бу минем әни була инде. *(Илнурга карап.)* Ә бу—Илнур. Искусство кешесе! Рәссам! Киләчәктә Шишкин, Пушкин, Салават кебек очень известный буласы кеше. Коттеджны алар бизәкләп чыкты инде, әни! *(Райнур таныштырганда Газинур, Илнур һәм Гөлчирә баш кагышып исәнләшәләр.)* Ә менә бу гүзәл туташ—безнең яңа күршебез Сәрия! Сәрия, бу—минем әни!

*Сәрия белән Гөлчирә кул бирешеп күрешәләр.*

Х ә д и ч ә *(үпкәләгән булып).* Райнур, ә мине кем таныштыра?

Р а й н у р *(кыланып).* Глубоко извиняюсь, мадам!.. Хәдичә! *(Фәннурга ишарәләп).* Фәннурның чибәр хатыны! Үзем белән таныштырып тормыйм... *(Фәнүсәне кочаклап алып.)* Фәнүсә! Минем хатын! Все похвальные слова—мне, претензии—к ней! Ха-ха-ха! Шутка! Таныштыгызмы? Әйдәгез, хәзер барыбыз да өйгә керәбез...

Г а з и н у р. Райнур, без башта бүләкне тапшырыйк инде...

Р а й н у р. Бүләк?! Ах, да-да..

Х ә д и ч ә *(кинәт).* Стоп-стоп-стоп! Туктагыз әле, сез ашыкмый торыгыз!! Без бүләк бирмәдек бит әле! Фәннур! *(Сумкасы янына килә).* Мәрткә киткән кеше кебек басып торма, кил, җәтрәк! Чыгар бүләкне!

*Фәннур сумкадан җиз самавыр ала.*

Х ә д и ч ә. Коттедж өчен үтергән бу самавыр! Антиквариат! Мондый самавырлар бик кыйммәт тора хәзер! Беләсегез килсә, Кукмара байлары... бертуган Комаровлар эшләткән самавыр бу! Менә монда язуы да, пичәте дә бар. *(У к ы й).* "БР. КОМАРОВЪ"... Братья Комаровы, яъни...

Г ө л ч и р ә *(самавыр янына килә).* Авылда... безнең дә шундый самавыр бар иде...

*Фәннур сумкадан кечкенә чәйнек ала да Хәдичәгә бирә.*

Х ә д и ч ә. Бусы—чәй пешерергә... Бергә укыган чакта Фәнүсә чәйсез торалмыйдырые... Шуны уйлап алып килдем ... Мә, Фәнүсәкәем! Эчегез рәхәтләнеп! ( Чәйнекне Фәнүсәгә тоттыра).

Г ө л ч и р ә *(Самавырны күтәреп, төбен карый, кинәт кычкырып җибәрә).* Әстәгым! *(Самавырны кулыннан төшереп җибәрә язып, кире куя.)*

Х ә д и ч ә. Бәтәч! Гөлчирә апа да безнеңчә сөләшә белә икән бит! Әстәгым, ди...

Р а й н у р, Ф ә н ү с ә *(икесе бергә).* Нәрсә бар, әни?

Г ө л ч и р ә. Безнеке... а-ә-э, безнекенә охшаган... кебек... димме соң?! Астындагы язуы да нәкъ шундый... Сәер...

*Хәдичә самавырның астын карый.*

Хәдичә *(язуны текәлеп укый)*. Әх-мәт-... нур... Әхмәтнур?! (Фәннурга). Синен бабаңның исеме бит бу! Тапкан урын! Самавыр төбенә исемен язып куймаса... Урлап китәрләр, дип курыккандыр инде... И-һи-һи... Фәннур, нәрсә карадың соң син? Башкасын алгансың бит! Бутагансың... *(Башкаларга карап алып)*. Бездә мондый самавыр икәү иде. И-һи-һи-һи... Астын карап тормаганбыз инде ...

Фәннур. Икәү дип... Мин бүтән самавыр күрмәдем өйдә...

Хәдичә. Нәрсә генә күрәсең соң син! Оятлы иттең бит мине...И-һи-һи-һи... Кире алып китәрбез инде алайса.... Янадан тегесен алып килербез әле бер килгәндә...

Райнур. Бүләкне кире алып китмиләр инде, Хәдичә. Рәхмәт! Барыбер тегесе дә шундый, дисең... Бүген үк тәмләп чәй эчәрбез, шулай бит, Фәнүсә!

Фәнүсә. Әйе. Борчылмагыз ул хәтле, Хәдичә, Фәннур...

Райнур. Бу самавыр антиквариат кына түгел. Искусство бу! Шедевр! Шишкин, Пушкин, Салават! И...—братья Комаровы! Хәзер үзен уважать иткән кешеләр мондый редкий әйберләрне бик оценить итә. Рәхмәт сезгә бүләгегез өчен! Вот это—подарок!

*Райнур самавырны беседкадагы өстәлгә куя. Гөлчирә самавырга карап-карап ала.*

Газинур. Безнең бүләк антиквариат түгел инде, Райнур. Берүк гаеп итмәгез... Каяле, Илнур, күрсәт әле картинаны!

Райнур. Син нәрсә, Нургази абый! Нинди сүз ул?!

*Илнур, картинаны төрелгән чүпрәгеннән арындырып, барысына да, хәтта тамашачылар да күрерлек итеп бер җайлы урынга сөяп куя.*

Сәрия. Бигрәк матур ясагансың, Илнур җаным! Авылны искә төшерә... Безнең авылда да шундый өй бар иде элек. Күптән кайтканым юк, хәзер бар микән?

Райнур. Мин шәһәрдә туып үскән кеше. Но... авыл да минем өчен бик якын. Әни авылдан булгангадыр инде... Шәп картина булган бу, Илнур! Молодец!

Фәнүсә. Гаҗәеп булган бу, Илнур! Рәхмәт, Нургази абый, рәхмәт, Илнур!

*Башкалар да картинаны сокланып карыйлар. Газинур Гөлчирәне күзәтә. Гөлчирә картина янына килә. Кинәт дерт итеп куя.*

Гөлчирә. Ничек! Бу бит... бу бит... безнең өй! *(Артка чигенә).*

Фәннур *(әле картинага, әле Гөлчирәгә, әле Хәдичәгә карап)*. Юк... бу...бу—безнең өй!

Хәдичә. Әйе шул!

Райнур. Как так?! Ничек... безнең өй? Ничек... сезнең өй? Сез нәрсә! Бу ... картина бу! Искусство! Комаров! Пушкин! Салават!

Гөлчирә. Бу... мин үскән өй! *(Хәлсезләнә).*

Райнур *(әнисен тотып)*. Фәнүсә, урындык бир! Стоп, үзем алып киләм, сина ярамый.

*Райнур өйдән тиз генә урындык алып чыга.*

Райнур. Утыр, әни.

Хәдичә. Фәннурларның элекке өе дә нәкъ шушындый иде. Күптән сүттек инде...

Фәннур. Охшаш өйләр һәр авылда да буладыр инде ул. Кем белә, бәлки бер үк оста эшләгәндер...

Сәрия. Әйтәм аны, мина да бик таныш... Каян беләм микән моны дисәм... Әйе шул, Фәннур, сезнең өй бит бу!

Райнур. Хет убейте, ничего не пойму! Әни?! Что за чертовщина?!

Сәрия *(нәрсәнедер исенә төшергәндәй)*. Пар күгәрчен! Кояш!!

Райнур. Ну и что! Моның белән нәрсә әйтмәкче буласың, Сәрия?

Сәрия *(Коттеджга, капкага ишарәләп)*. Боларда да шул ук бизәкләр... *(Картинага төртеп күрсәтеп)*. Монда да! Гаҗәп!

Хәдичә. Нәрсәсе гаҗәп инде! Күгәрчен тек күгәрчен, кояш тек кояш! Болары—агачтан, болары буяп ясалган...

Фәнүсә. Охшаш икән шул.

Гөлчирә *(картинага караган килеш)*. Мин... бу өйдә үстем!

Райнур. Ни сөйлисең син, әни? Син яшәгән өйне Илнур кайдан белсен! Шулай килеп чыккан инде... Илнур үзе дә белмичә, син яшәгән өйгә похоже өй ясаган... Вот и весь секрет! Талант эше дип атала бу, әни бәгърем! Илнур—великий талант! Великое искусство! Шишкин!..

Фәнүсә *(көлеп)*... Пушкин!..

Хәдичә. ... Салават!..

Сәрия. ... и братья Комаровы!.. *(Илнурга яратып карый, төртеп ала)*... Һәм Илнур! Шулай бит, Илнур!

Гөлчирә *(Илнурга)*. Кайлардан алып ясадың син бу рәсемне?

*Илнур әтисенә ишарәли.*

Газинур *(кесәсеннән фотосурәт чыгара)*. Менә бу карточкага карап ясады ул. *(Сурәтне Гөлчирәгә бирә, аны Райнур ала).*

Райнур. Похож... очень похож! *(Сурәтне әнисенә бирә).*

*Фәннур, Фәнүсә, Сәрия һәм Хәдичә, Гөлчирәнең артына басып, әле картинага, әле карточкага карыйлар.*

Сәрия. Копия!

Хәдичә. Тач ошатып ясаган! Әстәгым!

Фәнүсә. Картинадагы өй тагын да матуррак!

Фәннур. Безнең өй бу... Точно!

Гөлчирә *(Фәннурга текәлеп карап торгач, Газинурга)*. Сезгә... каян килеп эләкте бу карточка?

Нургази. Каян дип... Кайчандыр бер танышым биргән иде...

Гөлчирә *(шикләнеп)*. Ул танышыгыз... әллә...Газинур исемле идеме?

Газинур. Әйе. Газинур исемле иде.

Гөлчирә. Сал күзлегенне... Газинур. Танадым мин сине...

*Газинур күзлеген сала. Барысы да, сәерсенеп, аңа карап тора.*

Райнур. Ни сөйлисең син, әни. Бу бит—Нургази абый!

Гөлчирә. Ялгышасың, улым... Бу кеше—Нургази түгел... бу...бу...

Сәрия *(үзалдына сөйләнә)*. Нур... гази... Гази...нур... Гази... нур... Нур... гази...

Гөлчирә. ... бу—сиңа ата тиешле кеше!

Райнур. Черт побери! Нинди ата? Нургази абый дип торам бит инде мин сиңа, әни! Нургази абый бу!.. Плотник! Ә бу—Илнур!

Гөлчирә. Илнуры кемдер, белмим... Ә бу кеше чынлап та ... сиңа ата тиешле кеше!

*Фәннур белән Хәдичә бер-берсенә карашып алалар. Фәннур да үзен сәер тота башлый: тиктомалдан жилкәсен сикертә, кулларын һавада болгап ала, әле картинага, әле Газинурга карый.*

Райнур. Черт побери! Ышанмыйм! Ни сөйлисең син, әни? *(Газинурга)*. Әйт, Нургази абый, бер сүз! Алай түгел, диген! Әниең ычкынган, Райнур, диген!

Газинур. Әниең ... дөрес әйтә... Райнур... Әйе, мин... синең әтиең!

*Авыр тынлык.*

Райнур. Черт побери! Не верю! Юк минем әтием! Юк! Алдашмагыз! *(Газинурны жилтерәтә)*. Син минем әти түгел, шулай бит, Нургази абый?! Әйт, шулай, диген! *(Газинур дәшми, башкаларга карап)*. Сез ышандыгызмы болар сүзенә? Фәннур, син ник дәшмисең? Аңлыйсыңмы син монда берәр нәрсә?

Гөлчирә *(Газинурга)*. Монарчы бар дип тә белмәдең... Утыз елдан соң... малаең кирәк булдымы? Кирәк булгандыр шул! Байлыгы бар бит!

Газинур. Син ни сөйлисең... Гөлчирә?! Кирәк түгел миңа бернинди дә байлык!

Гөлчирә. Алдашма! Безне, эшчеләр тулай торагында ач-ялангач калдырып, ташлап качтың син!

Газинур. Качмадым мин... Өйдән китүемнең сәбәбен үзең бик яхшы беләсең...

*Ут Фәннур белән Хәдичәне генә яктырта.*

Хәдичә. Син берәр нәрсә аңлыйсыңмы, Фәннур?

Фәннур. Аңлашыла башлады... Гөлчирә апа—әнинең апасы! Ә бу абзый...

Хәдичә. ... синең атаң! Әстәгыфирулла! Райнур...—синең бертуганың... Әк-кәмә-әт!...

Фәннур *(бармагын авызына куеп).* Тссс! Белгәненне сиздермә!

*Алар янына Сәрия килә.*

Сәрия. Фәннур, Нургази абый, то есть ... Газинур абый... синең әтиең булып чыга түгелме соң?

Фәннур. Тссс! Тавышланма!

Сәрия. Ә нигә? Анладым! *(Авызын учы белән каплый.)* Молчу!

*Сәхнә тулысынча яктыра. Райнур, иелгән башын тотып, беседкада утыра. Фәнүсә болдырга сөялгән. Илнур Газинурга "Мин китәм" дигән ишарә ясый.*

Газинур. Китми тор. Бу сөйләшү сина да кагыла...

*Илнур таганга барып утыра. Сәрия аның янына килеп баса.*

Гөлчирә. Әйе... икенче улыбыз... Райнурның энесе... авыру булып туды. Тугач та үлде.

Райнур *(башын күтәреп).* Мин бу турыда в первый раз слышу! Черт побери! Кругом тайны веков!

Гөлчирә. Мин бик каты стресс кичердем... Мин дә үләсе идем Ә син... мине... безне... шул хәлдә калдырып качтың!

Газинур. Әйттем бит инде. Качмадым мин! Синең коточкыч кеше икәнлегеңне аңлаганга киттем.

Райнур. Ничек коточкыч?! Минем әни—фәрештә! Ул мине берүзе үстерде! Кеше итте! *(Торып басып, Газинурга кычкыра.)* Ә син! Минә әти тиешле кеше! Син кайда идең мин үскәндә? Ишегалды малайлары мине "Казанская сирота" дип кыйнаганда син кайда идең? Хәзер дә помню: бервакыт базарда йөргәндә бер сатучы хатынның алмаларына кызыктым. Берсе шундый кып-кызыл иде! Авыздан сулар килә... Озак басып торганмындыр, наверно. Анысын не помню! Помню сатучы хатынның " Вор! Мальчишка—вор!" дип акырып җибәргәнен... Помню, грузчикларның мине тотып алганнарын, с удовольствием кыйнаганнарын!.. Син кайда идең шул чакта?

Гөлчирә. Син мина ник дөресен әйтмәдең, улым? Хәтерлим, син бит "Таныш түгел малайлар кыйнады" дидең.

Райнур. А какая разница! Син барыбер бер нишли алмый идең.

Гөлчирә. Алма сатып алып биргән булыр идем.

Райнур. Ул барыбер мин кызыккан алма булмас иде... И потом ... мин бит дурак түгел... Синдә акчаның барлыюклы гына икәнен чамалый идем. Кырык ямаулы чалбарымнан ничек туйганымны үзем генә беләм! Яңасын алмассынмы, дип кайларга гына яшермәдем мин аны! Батарей артыннан да тартып чыгардың, шифоньер астыннан да табып алдың. Караватастында яткан киез ката эченнән дә...

Газинур *(Гөлчирәгә).* Мин бит алиментны вакытында җибәреп тордым. *(Райнурга).* Кием-салым гына алырлык иде.

Гөлчирә. Җибәрдем, имеш! Суд аша койрыгыңнан тотып тормаган булсам, җибәрер идең микән?

Газинур. Нишләп җибәрмәскә! Ятимлекнең ни икәнен беләм мин. Үзем дә яшьли әтисез калган кеше.

Гөлчирә. Бутама! Авыл ятиме белән шәһәр ятиме—икесе ике кеше. Аерма—җир белән күк арасы!

Газинур. Алай аерма бик зур булгач, ник малайны авылга алып кайтып яшәмәдең соң? Кайтырга оялдыңмы? Әллә курыктыңмы?

Гөлчирә. Минме? Кемнән? Нәрсәдән? Әйт, авылга кайтып кеше күзенә күренмәслек нинди начарлык эшләдем мин?

Газинур. Анысын син үзең беләсеңдер инде...

Райнур. Әй, әй! Кояштан тап эзләмә!

Гөлчирә. Җаны пычрак кеше башкалардан кер эзләр, диләр... Сина тач туры килә бу сүз!

Газинур. Ул сүзне кем әйтә бит әле! Ананны кояшка ук тиңләп ялгышмыйсыңмы, Райнур? Дөрес, ул сине караган, үстергән... Үзең әйткәндәй, кеше иткән!.. Ләкин... Ләкин... Син белеп бетермәгән нәрсәләр дә бар әле...

Райнур. Не темни!..

Газинур. Анаң да ... кайбер

нәрсәләрдән минем хәбәрдар икәнемне төшенеп житми әле...

Гөлчирә *(сагаебрак).* Күзгә төтен жибәреп... ни сөйләгән буласың син?

Хәдичә. Төтен дә төтен , дип... Тәмәке тарткан кеше юк... Сез бирәр нәрсә анлыйсызмы соң?

Фәннур *(коры гына).* Хәдичә! Тик кенә тор!

Хәдичә. Тик кенә торып булмый бит, аяк арыды.

Сәрия. Жиргә утыр, Хәдичә.

Хәдичә. Әстәгъым, монысы да командовать иткән була... *(Башын читкә борып , әллә кая карагандай итә).*

Газинур *(Илнурга карап алганнан соң, Гөлчирәгә).* ДЦП дигән идеңме әле?

*Гөлчирә дәшми.*

Хәдичә. ДСП? *(Фәннурга).* Нәрсә әле ул? Теге ниме?

Фәннур. Нәрсә..." теге ниме"?

Хәдичә. Ну инде... теге ни инде... Без веранда эченә кактык бит әле... Ни инде! Пычкы чүбеннән катырып эшләнгән фанер сыман нәрсәне әйтәм... Ул да ДСП дипме, ДВП мы, ВВПмы дипме атала түгелме соң?

Фәннур. Яп инде авызыңны, ә!

Хәдичә. Булды, булды, яптым! *(Уйлаган кыяфәт чыгарып үзалдына сөйләнә).* ДСП...ДСП... ДВП... ВВП... Искә төшми, нәгаләт!

Газинур *(Гөлчирәгә карап сөйли).* ДЦП. Әйе, шулай дигән идең. Детский церебральный паралич, дигән идең. Син бусын алдамагансың. Врачлар, чыннан да, шундый диагноз куйганнар. Ә менә синең "Бала үлде" диюең?!

*Гөлчирә, кинәт торып баса да , кире "лып" итеп урынына утыра.*

Бусы коточкыч ялган булып чыкты! Ни йөрәгең белән әйтә алдың син аны?

Фәнүсә *(шаккатып).* Бала... исән булып чыктымыни?! *(Корсагын, кадерләп, сыйпап ала).*

Райнур. Син нәрсә? Ничек исән булсын! "Үлде" диде бит әни! *(Гөлчирәгә.)* Әни, шулай дидең бит?!

*Гөлчирә дәшми.*

Газинур *(Гөлчирәгә).* Син... үзең тудырган баладан!., исән баланнан!., ваз кичкән кеше... Гөлчирә!

Гөлчирә. Мин... мин аны... ул баламны... гомер буе эзләдем... Гомер буе! Урамда, хастаханәдә берәр гарип бала күрсәм, йөрәгем "жу" итә. Шул чакта "Минем бала түгел микән бу?" дигән уй үзәкләремне өзеп ала иде... Ярый әле шундый чакларда Райнур юаныч булды... Райнур да ...булмаса... Белмим, мин бу сүзләрне сөйләп утыра алган булыр идем микән?..

Газинур *(тавышы гына ишетелә).* Матур сөйлисең, Гөлчирә. Сүзләрең кәнфит кебек. Үкенгән дә сыман үзең... Әйт әле миңа: бераз гына булса да яраттыңмы син мине?

Гөлчирә. Алдашудан хәзер ни файда. Әйе, мин сине яратмадым! Син дә яратмадың мине!

Райнур *(тавышы гына).* Яратышмагач, нишләп өйләнештегез соң сез, черт побери?

*Ут Газинурны да яктырта.*

Газинур. Мин жебегән булганга күрә! Үз бәхетем, үз мәхәббәтем өчен көрәшергә кирәк булган да бит... Ялгыштым...

Гөлчирә. Син ялгыштың... Мин ялгыштым... Ялгышмыйча яшәгән кеше бар микән бу дөньяда?

Газинур. Син сукыр түгел идең, безнең яратышканыбызны күреп тордың!

*Ут сүнә.*

***

*Кабат янган ут шәһәрнең аулак бер аллеясын, андагы эскәмияләрне яктырта. Якында гына тимер юл вокзалы икәнлеген искәртеп, поезд кычкырткан тавыш ишетелеп ала. Икесе ике яктан чыккан Газинур белән Нәфисә (кулына сумка тоткан), бер-берсен танып, үтеп киткәч кенә, кинәт тукталып калалар.*

Газинур *(артына борылып).* Нәфисә! Синме соң бу? Исәнме?

Нәфисә *(бермәл дәшми торганнан соң).* Мин—исән. Син дә исән икәнсең әле, Газинур...

Газинур. Күземә күренәсең мәллә, дип торам...

Нәфисә *(барасы ягына карап алып).* Электричкага ашыгам...

Газинур. Ничек соң хәлләрең, Нәфисә?!

Нәфисә. Шәһәрдә тынчу ... һавасы һава түгел... Авылдан киткәннәр ничек чыдыйдыр... Мин монда ярты көн дә тора алмыйм икән.

Газинур. Яши-яши ияләшәсең инде...

Нәфисә. Шәһәрдә күгәрченнәр юк, ахры... Берне дә күрмәдем, дисәм... *(Газинурга туры карап ала).*

Газинур. Нишләп булмасыннар!.. Базарда, көнбагыш сатучылар янында бик күп алар! Вокзал тирәсендә чүпсыз! Көнбагышны бик яраталар инде...

Нәфисә *(китәргә итә).* Электричкага билет аласым бар... Онытa язганмын!...

Газинур. Ашыкмале, Нәфисә... Электричкалар күп йөри алар... Сөйләшик әле... Күрешмәгәнгә ничә ел бит! *(Бераз уйланып).* Жиде елдан артып киткән инде...

Нәфисә. "Күк күгәрчен күктә уйный, күләгәсе җирдә уйный..." Кызык, шәһәр күгәрченнәре күктә уйный микән?

Газинур. Сәерләнгәнсең, димме?! Ачуланма, зинһар, шулай дигәнгә. Мин синең хәлеңне сорыйм, син күгәрченнәр турында сөйлисең... Күгәрчен кайда да күгәрчен инде ул!

Нәфисә. Шәһәр күгәрченнәре авылныкылар шикелле жырлый белмиләр әле...

Газинур. Нишләп белмәсеннәр! Авылдагы гөлдерү шәһәрдә дә гөлдерү инде ул! Карале, Нәфисә... ни... күгәрченнәрне онытып торыйк әле... Үзебез турында сөйләшик... Нишләп без...

Нәфисә. Соң инде... аңлашырга, Газинур. Син безнең мәхәббәтебезгә хыянәт иттең, Газинур.

Газинур. Ничек...мин? Киресенчә... син үзең ...мине...мина... ну..мин армиядә чакта... Рәшит белән йөргәнсең...

Нәфисә. Рәшит белән? Кайчан? *(Нидер исенә төшереп).* Аh!.. Әйе шул... Аңлашылды...

Газинур. Нәрсә... аңлашылды?

Нәфисә. Рәшит белән ... йөргәнем аңлашылды. *(Кинәт.)* Ни сөйлисең син, Газинур?

Газинур. Балага узган булгансың... төшерткәнсең...

Нәфисә. Ә? Мин киттем... *(Китә башлый.)*

Газинур. Дөрес сүзгә җавап юкмыни, Нәфисә?

Нәфисә. Кем әйтте сиңа бу сүзләрне? Син шуңа ышандыңмы?

Газинур. Апаң әйтте... Гөлчирә.

Нәфисә. Шулайдыр дип уйлаган идем аны. Менә бит ә?! Үзем дә белмичә... Рәшит белән йөргәнмен. Рәшит...Рәшит...синнән балам була язган бит... Бер тапкыр клубтан бергә кайткан идек... Гөлчирәгә сүз ясарга шул житкән икән... Рәхмәт, күземне ачтың... Синең хыянәтеңне дә кичерә алмаган идем... инде бу сүзләрне дә ишеткәч... *(Китмәкче була).*

Газинур *(Нәфисәне тотып).* Туктале, Нәфисә... Минем нинди хыянәтем турында сөйлисең син?

Нәфисә. Онытқан булсаң, исеңә төшер... Исеңә төшмәсә, Гөлчирәдән сора—ул әйтер...

Газинур. Гөлчирә?..

Нәфисә. Ул белә, ул әйтер сиңа...

Газинур. Нәрсә дип?

Нәфисә. Үзеңне белмичә, бер гаепсез, мескен Рәшиткә, миңа яла яккан буласың... Мин синең сүзләреңә ышанып, очынып йөрдем. Бергә булуыбызны, бәхетле яшәвебезне күз алдына китереп, татлы хыялга бирелә идем... Ә син ике куянны бергә тотмакчы булгансың... Гөлчирәгә дә кызыккансың икән... Мине дә алдалап йөрткәнсең... Яратам, сөям, имеш!

Газинур. Ни сөйлисең син! Кызыкмадым мин Гөлчирәгә! Яратмадым да!

Нәфисә. Кызыкмагач, яратмагач... ник өйләндең соң?

Газинур. Сине бит... Рәшит белән дип...Гөлчирә әйткәч, сиңа үч итеп өйләндем инде!

Нәфисә. Шул гына микән? Ай-һай! Ник әйтмисең, койрыгым да бозга каткан иде, дип?

Газинур. Нинди койрык, нинди боз тагы?

Нәфисә. Өйләнешкәнче... син... Гөлчирә белән... Үзе әйтте... Корсакка уздым, диде...

Газинур. Ә?! Елки...зеленые!.. *(Үз-үзен кая куярга белмичә, әрле-бирле*

*йөрenә).* Елки зеленые! Бу бит... бу бит... Сүз табалмыйм әйтергә! Син... син шуңа ышандыңмы?

Н ә ф и с ә. Ышандым! Син дә ышангансың бит!

Г а з и н у р. Гөлчирәдән мин моны ук көтмәгән идем! Нишләп шул вакытта ук бу турыда әйтмәдең, Нәфисә? Аңлашкан булыр идек!

Н ә ф и с ә. Соң инде дип уйладым. Аннан соң... ашыктыгыз бит... Шәһәргә киткәнегезне мин белми дә калдым...

Г а з и н у р. Авылга кайткач та әйтмәдең. Гөлчирәне ташлап, синең янга дип кайткан идем бит югыйсә...

Н ә ф и с ә. Балагыз тугач, хак булган икән, дип уйлап куйдым да... бу турыда бүтән сүз кузгатып торуны кирәксенмәдем. Искене янартудан ни файда? Аннары ...Гөлчирә артыннан кайтты да... тагын китеп бардың...

Г а з и н у р. Бала, диде бит... Райнур авырый, диде. Авырмаган иде... Алдаган гына булган, Гөлчирә. Безнең бергә булудан, кавышуыбыздан курыккан... Шуңа коты очкан булган. Ирен сеңлесе тартып алса, оят бит!

Н ә ф и с ә. Ә миңа ул тартып алгач, шундый ... "рәхәт" булды! Нинди хәлдә калганымны үзем генә беләм! Әмма мин шул чакта да синең бәхетле булуыңны теләдем! Ходайдан ялварып сорадым...

Г а з и н у р. Күрәсең, доган кабул булмаган, Нәфисә... Мин киттем инде... Гөлчирәдән...

Н ә ф и с ә. Беләм, Газинур...

Г а з и н у р. Сиңа да кайталмадым...

Н ә ф и с ә. Икенче балагыз турында да ишеттем... Минем рәнҗеш төшкәндер дип ялгыш уйлый күрмә, Газинур. Мин... рәнҗемәдем сиңа, Газинур! Дөрес, бик каты үпкәләдем анысы. Әмма рәнҗемәдем! Син... бәхеткә лаек идең, Газинур!

Г а з и н у р. Син дә лаек идең, Нәфисә! Бәлки ... әле соң түгелдер безгә...

Н ә ф и с ә. Соң инде, Газинур... Мин... минем... балам үсә! Мин... ялгыз түгел инде...

Г а з и н у р. Бала?

Н ә ф и с ә *(Газинурга сынаулы караш ташлагандай).* Әйе, балам бар...

Г а з и н у р. Димәк... Гөлчирә күпмедер хаклы булган икән...

Н ә ф и с ә. Кем хаклыдыр, Гөлчирәме, синме, минме... Хәзер бу минем өчен ул хәтле мөһим түгел . Ин мөһиме—син һаман да үзгәрмәгәнсең икән, Газинур! Һаман да элекке Газинур булып калгансың... Хуш, Газинур! *(Китә башлый).*

Г а з и н у р. Нәфисә, мин озатыйм сине...

Н ә ф и с ә. Кирәкми, Газинур. Мин адашмыйча бара беләм инде хәзер... Хуш! *(Китә).*

*Аның соңгы сүзләре үз тавышы белән кабат яңгырый:—Мин адашмыйча бара беләм инде хәзер... Хуш!*

Г а з и н у р. Нәфисә!

*Газинур кайсы якка китәргә белмичә, басып кала. Музыка. Ут сүнә.*

***

*Кабат ут яна.*

*Сәхнәдә—шулар ук: Газинур, Гөлчирә, Фәнүсә, Фәннур, Хәдичә, Илнур, Сәрия. Барысы да бер мәл тын калып тора. Газинур Илнур янына килә.*

Г а з и н у р. Күгәрченне алып килергә оныттык бит! Әллә кайтып алып киләсеңме? Буявы да кипкәндер инде...

*Илнур урыныннан кузгалып, һәммәсенә дә карап ала да, бер сүз дәшмичә генә чыгып китә.*

Г ө л ч и р ә *(аның артыннан карап калып).* Бу егет бер дә сөйләшми. Телен йоткан мәллә?

Г а з и н у р *(авызын ачып, нидер әйтергә җыенгач кына, Сәрия телгә килә).*

С ә р и я. Ул... ул ...телсез ул, Гөлчирә апа!

Г ө л ч и р ә. Шулаймыни?! И-и, бахыр... бигрәк сөйкемле егет үзе!..

*Газинур, эчке бер ярсу белән, кинәт таганны атындырып җибәрә. Сәрия аны атындыруыннан туктата да утыргычка утыра.*

С ә р и я. Атындырыгыз әле мине, Газинур абый!

*Газинур таганга арты белән борыла.*

**Гөлчирә.** Бая игътибар итмәгән идем... син бу таганны ... Аны уйлап ясагансың икән!.. Нәфисәне алып килеп, атындырасын гына бар инде!..

**Фәннур** *(үз-үзен белештермәс дәрәҗәдә ярсып кычкыра).* Житте! Туктагыз!

*Барысы да сискәнеп, өнсез калып, Фәннурга карыйлар.*

**Хәдичә.** Фәннур! Син нәрсә? Тынычлан әле!

**Фәннур** *(үзен кулга алып).* Гафу итегез, мин... мин... сездән әнинең рухын рәнжетмәвегезне сорыйм!

**Гөлчирә.** Монда синең әниеңнең нинди катнашы бар?

**Хәдичә.** Гөлчирә апа... Син әле телгә алган Нәфисә... безнең әниебез! Фәннурның әнисе!

*Барысы да Хәдичә белән Фәннурга шаккатып карап тора.*

**Райнур.** Я уже... ничего не понимаю!

**Гөлчирә** *(Фәннурга).* Син... *(Урыныннан тармакчы була да, кире утыра).* Син... Нәфисәнең улымы?

Газинур бер-ике адым атлый да туктап кала.

**Газинур** *(Фәннурга текәлеп).* Йа, ходаа! *(Йөрәген тота).*

*Райнур, кесәсеннән дару алып, Фәнүсәгә суза.*

**Райнур** *(Газинурга ишарәләп, Фәнүсәгә).* Мә, тизрәк бир... ана...

*Фәнүсә, беседка өстәлендәге шешәдән су агызып ала да, Газинур янына килә.*

**Фәнүсә.** Мәгез, Нургази абый... Газинур абый... йөрәк даруы бу! Су белән эчеп җибәрегез!

**Райнур.** Йөрәк даруына су кирәк түгел... Аны тел астына гына куялар!..

**Газинур** *(даруны авызына каба).* Рәхмәт!..

**Фәннур.** Мин сезне ... сине ... бик озын буйлы итеп күз алдыма китергән идем... Киң җилкәле итеп... Ә син... бәләкәй кеше икәнсең!

**Газинур.** Яшь чакта... озын идем мин!..

**Хәдичә** *(киеренкелекне җинеләйтергә теләгәндәй).* Хи-хи-хи... Менә таныштыгыз да! Хи-хи-хи!.. *(Фәннурның житди карашын күреп).* Уф! *(Кулын җилпәзә итеп, чырае тирәсендә селки).* Чыдар әмәлләр юк бу эссегә!.. Мунча кебек... пәрәме!

**Газинур** *(Фәннурга).* Син... Нәфисәнең улымыни? Хәлләре ничек... Нәфисәнең... әниеңнең?

*Бер-берсенә текәлеп карап торалар.*

**Хәдичә.** Ул... ул... сезнең дә улыгыз! *(Фәннурга).* Әллә... ялгыш ... ычкындырдыммы?! *(Авызын учы белән каплый).*

*Фәннурдан, Хәдичәдән, Сәриядән кала, барысы да шок хәлендә.*

**Газинур.** Син... минем улыммы? Ничек инде? Нәфисә мина бу хакта берни дә әйтмәде...

**Фәннур.** Кирәк дип тапмаган, димәк!

**Райнур.** Братья Комаровы, черт побери! Вот это—сюрприз! Әни, син ник бер сүз дә әйтмисең? Язык проглотила что ли? Күрмисеңмени, минем родной брат та нашелся! Радоваться надо! Әле берсе дә юк иде... И вдруг... әти!., брат!..

**Гөлчирә** *(Газинурга зәһәр караш ташлап).* Адәм тәганәсе! "Хәлләре ничек Нәфисәнең?" дип торган була, житмәсә! Хәлең белгәнсең бит инде... Күрмисеңмени нәтиҗәсен!

**Фәннур.** Мин сездән тагын бер кат үтенеп сорыйм... Рәнжетмәгез әнинең рухын!

**Газинур.** Рухын? Ул... Нәфисә... *(Башын тота).*

**Фәннур.** Әйе...

**Газинур.** Кайчан?

**Хәдичә.** Кырыгын уздырдык инде... Күмгәндә бөтен авыл халкы җыелды...

**Газинур** *(үз алдына).* Кичер... Нәфисә... Белмәдем... кайталмадым... *(Күз яшьләрен сөртә).*

**Сәрия** *(урыныннан кузгалып, әле Газинурга, әле Гөлчирәгә карап ала).*

Әкәмәт кешеләр булып чыктыгыз әле сез... авылдашлар!

*Гөлчирә дә, Газинур да аңа гаҗәпсенеп карый.*

Сәрия *(әле Газинур, әле Гөлчирә янына килеп сөйли).* Без туган авылыбызга юлны бөтенләй оныттык түгелме соң? Синең дә, Газинур абый, синең дә, Гөлчирә апа, авылга әллә кайчаннан бирле кайтмаганыгыз аңлашылды. Сез авылдан ваз кичкәнсез бит! Бу мина да кагыла... Минем дә байтактан кайтканым юк... Әни үлгәннән бирле. Йа, хода!.. Әти-әниләребез каберенә зыярәт кылып килүне дә... онытып барабыз икән бит! Искә төшкәндә генә... шәһәр мәчетләренә кереп, муллаларга хәер биреп, үлгәннәр рухына дога укыткан булабыз да булуын... Ләкин... Минем ни әйтергә теләгәнемне анлагансыздыр инде... Сез "Кем соң әле син шулхәтле акыл сатарга?" дип уйлыйсыздыр... Сез хаклы. Мин сезнең өчен беркем дә түгел. Бары—авылдашыгыз гына... бары Фатыйма кызы гына...

Гөлчирә, Газинур *(икесе бергә).* Кайсы... Фатыйма кызы?

*Гөлчирә белән Газинур бер-берсенә карашып алалар.*

Сәрия. Төсмерләп танымыйсыздыр инде. Чая Фатыйма кызы мин!

Газинур. Чая Фатыйма?!

Гөлчирә. Ул да... үлдемени?

Сәрия. Ходай безне монда тикмәгә генә бергә очраштырмаган, ахрысы... Фәннур белән Хәдичәне бүген күрмәгән булсам, мин дә Нәфисә апаның вафаты хакында белмәгән булыр идем әле... Оныттык без авылны, оныттык андагы кешеләрне!.. Кем исән, кем юк—белмибез... Бары үз дөньябыз гына—дөнья... Әйе... авылга кайтмау сәбәбен һәркем үзенчә аңлата ала... Сез "Сәбәбе—тирәндә!" диярсез, ялгышыгызны сылтау итәрсез... Мин дә "Авылда туганнарым калмады.... нигезебез таралды..." дип аклана алырмын... Без шулай үз-үзебезне юата алабыз анысы... Ләкин... ничек кенә акланcак та... без... без ...барыбер... әллә кемнәр без! Нәфисә апа да... җанашым... китеп барган икән!.. Урыны җәннәттә булсын!.. Кичер мине, Фәннур! Кичер, Хәдичә! Кичерегез безне, гарип җаннарны, авылдашлар!

Гөлчирә. Кыяфәтен генә түгел, сөйләшүең дә әниең төсле. Матур сөйлисең... Тик мин сина минем өчен сөйләргә кушмадым, сенелкәем.

Газинур. Яшь кенә булса да ... дөресен сөйли! Нигә, шулай түгелмени?!

Гөлчирә. Минем үз авызым бар. Нәрсә турында сөйләргә, кемнән кичерүен сорарга мин үзем,белермен!.. Фатыйма кызының авылга кайтмавын мин гаепләп сөйләмим бит әле!

Сәрия. Сез мине дөрес анламадыгыз, Гөлчирә апа. Мин сезне гаепләргә җыенмыйм. Гаепләргә уйлаганым да юк. Сез күргәнне—мин күрмәгән. Күрергә дә язмасын!..

*Илнур керә.*

Газинур. Улым, алып килдеңме?

*Илнур "Әйе" дигәнне аңлатып баш кага. Гөлчирә "дерт" итеп , Илнурны беренче күргәндәй текәлә. Илнур Газинурга "күгәрчен "не бирә.*

Газинур *(Райнур белән Фәнүсә янына килеп).* Бу сезгә!

*Райнур белән Фәнүсә, бер-берсенә карашып алып, нишләргә белмичә торалар.*

Гөлчирә. Ул жансыз кош белән нишләсеннәр алар?

Газинур. Алыгыз, ал! Бу—сезгә... дөресрәге... туасы балагызга... оныкка...

*Райнур башын читкә бора. Фәнүсә, читенсенеп кенә, "күгәрчен"не ала.*

Фәнүсә. Рәхмәт, Нур... Газинур абый!

Гөлчирә. Барысын да алдан уйлагансың икән! Хәер, Күгәрчен Сафа малаеннан ни көтәсең инде... Кушаматың ук кычкырып тора бит... Атаң безнең өйне салганда бөтен жирне күгәрченнәр белән чуарлап бетергән иде... Инде син монда күгәрченнәр тутыргансың!.. Үзенчә, мине мыскыл итәргә теләвеңдер... Шуларны көн саен күреп, жаны газаплансын диюеңдер...

Газинур. Ничек аңласаң, шулай аңла. Әмма минем көнелемдә яман уйның булганы юк! Ә инде..." Барысын да уйлагансың" диюендә күпмедер хаклык бар. Әйе. Ләкин мин уйлаганча гына килеп чыкмады. Хәтта... *(Фәннурга карап ала).* Көтелмәгәнчә үк килеп чыкты. Бу минем генә түгел, Ходай эше дә ахыры. Шулай тиеш булган, димәк... Әйе, мин синең белән бүген очрашасымны белгән идем! Очрашмаган да булыр идем, әмма җитди сәбәп бар.

Райнур. Чувствую, кажется безне тагын нindидер сюрприз көтә!

Газинур. Минем әйтеп каласы сүзләрем бар.

Гөлчирә. Үләргә җыенмыйсындыр бит әле?.. Йөрәк дисәң... йөрәк кемнең авыртмый ул хәзер!? Мин дә көн саен дару эчеп кенә торам...

Райнур. Әни, аз гына туктап тор, ә! Тынлыйк. Сөйләсен...

Газинур. Дөнья хәлен белеп, булмый. Үлеп китүем дә бар. *(Райнурга).* Мин сезнең ... Илнур белән икегезнең... юк, *(Фәннурга да карап)* өчегезнең бергә ... дус булуыгызны телим!

Райнур. Без болай да...почти... дуслар. Әйе бит, Илнур?! Шулаймы, Фәннур?! Йә, шул гынамы? Мин нindидер сюрприз көтәм тагы!

Газинур. Алай әйтергә яраса... сюрприз да бар! Илнур—сезнең энекәшегез! Илнур—синең бертуган энекәшең!

*Көтелмәгән хәбәрдән, Илнур белән Райнур, бер-берсенә карашып, ни әйтергә белмичә торалар. Илнур, беренче кат күргәндәй, Гөлчирәгә текәлә.*

Гөлчирә *(шок халендә).* Бертуган... энекәше?!

Газинур *(Илнурга).* Мин сиңа ... әниең сине тапкан чагында... роддомда үлде, дигән идем... Кичер мине, улым! Синең өчен шулай яхшырак булыр дип уйладым. Менә ул—синең әниең!.. Ул исән!

Гөлчирә *(дулкынланып).* Улы-ым! Балам!

Илнур *(бер-ике адым атлый да тукталып кала). Ән-нә! (Кинәт ашкынып, Гөлчирәне кочаклап ала).* Ә-ни!

*Кешеләрне тетрәндерерлек мизгел.*

Сәрия *(бераздан).* Хикмәт! Барыгызның да исемнәрендә "нур" бар... Гази-нур!.. Рай-нур!.. Фән-нур!.. *(Әнисен кочаклаган Илнур янына килеп, аның аркасыннан сыйпагандай итә).* Ил—нур!..

Фәнүсә *(Райнурга).* Син—бүген дөньяның иң бай кешесе, Райнур!

Райнур *(бер мәл учы белән күзләрен каплап тора да, учын кире алып).* Кажется... әй-йе!.. (Кулын Фәнүсәнең җилкәсенә сала).

Хәдичә *(Фәннурга).* Син бер дә тирләми торганыең, Фәннур?!..

*(Фәннурның кулмәк кесәсеннән кулъяулык алып, аның маңгаен, күз төпләрен сөртә).*

Фәннур. Кояш бит... кыздыра!..

*Газинур Райнур белән Фәнүсә янына килә.*

Газинур *(Райнурга).* "Бирде дөнья кирәкне, еламаска өйрәтте... Кайсыгызның кулы җылы? Бәйлисе бар йөрәкне"... *(Икесенә дә карап).* Яратышып яшәргә язсын сезгә! Берүк ялгышмагыз! Безнең язмыш сабак булсын... *(Райнурның иңсәсенә кулын куя).* Кичерәлсәң... кичер... улым!..

*Райнур Газинурны кочаклый. Бераздан Газинур, башын игән хәлдә, Фәннур белән Хәдичә янына килә.*

Газинур. Фәннур... Мин... синең барлыгыңны... белмәдем. Синең алдыңда да гаебем зур минем! Әниең алдында да... мин бик гаепле... Нишлим? Хаталарны төзәтергә соң инде... Миңа шундый язмыш насыйп булган, күрәсең... Син дә ... кичер мине... улым!.. *(Фәннурны кочаклый).* Син бәхетле булырга тиеш! *(Хәдичәгә карап).* Сез бәхетле булырга тиеш! Арагызга берүк чит-ятларны кертмәгез! Аңлыйм. Сез минем үгет-нәсихәткә мохтаҗ түгел... Шулай да... шулай да... Бәхетле булыгыз!

*Пәрдә*



Луиза Янсуар

# ҖӘЙРӘП ЯТА ГОМЕР—АЛДЫБЫЗДА...

***

**Җилләр итәгендә җәйне көтәм...
Син кайдадыр озатасың кышны...
Өметләнмим, берни өметләнмим...
Кадерлерәк җанга тынсыз бушлык...**

**Оясыннан кошлар бага үрелеп,
Дәрвишләрнең санын белгән төсле..
Бер пәрдәсез ялан тәрәзәләр—
Синсез көннәремнән үксез күзге...**

**Язлар итәгендә җәйне көтәм...
Ә ул узар безне танымый да...
Өметләнмим, берни өметләнмим...
Син кал шулай—хәтта табылмый да.**

***

**Кирмәннәрнең йөрәгендә дәһшәт—
Онытылмас, тынмас, җуелмас...
Тыгызлана гына бара Хәтер,
Ташлар бәгыренә уелгач...**

**Кызлар толымына күмелгән җир
Уфтаныргa тора сагаеп...
Әле һаман... Күзләреңнән бага
Дөнья биләмәсе—тараеп...**

**Күзләреңнән тора ваемланып
Егерменче йөзнең аръягы.
Толымнары җилнең тураклана...
Әлегеме өмет? Баягы?..**

**Тәшвишләнә Дөнья һәр аваздан...
Кан да, җан да—кыргый алышта...
Ак Кирмәннәр үзәгендә—Хәтер
Дәшә: "Мине генә... алышма..."**

Луиза ЯНСУАР—*шагыйрә; "Мин күкләргә кайтам", "Болан кызы", "Без җан өргән учак" исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

***

Җәйрәп ята гомер алдыбызда...
Насыйп та ул безгә, тиң дә төсле...
Хәрабәләр тулы Хәтер генә
Гел көчлерәк бездән һәм... гел үчле...

Бу ничәнче Җәйгә алкышыбыз
Һәм чигенү аннан ничәнче кат?
Җәйрәп ята алдыбызда Бәхет...
Нигәдер ят кебек, нигәдер ят...

Хәрабәләр тулы данлы калам,
Бер фаҗигаң, моңың без дә бүген...
...Ни сүтелми, ни үрелми учта
Ничә язмыш ята—бүлем-бүлем...

***

Тәрәзләрнең аръягында—язгы Казан...
Шомыртларның җилгә очкан күләгәсе...
Анда кемнәр кемне җуйган... Кемне тапкан,
Һәм кемнәргә ни хак белән түләнәсе?..

Берни белмим... Мәңгелекнең өнсез мәле...
Күрәзәләр—бүген түгел, түгел әле...
Тәрәзләрнең бу ягында—җөйсез Язмыш...
Һәм... өметләр—никтер үтә күренмәле...

***

Бер Яшәүме?.. Әллә йөзенчесе?..
Меңенчесе?.. Өзек чылбырлар...
Без бу җирдә бер-беребез өчен
Сәбәп кенә... Түзсен чыгырлар...

Түзсен таш шәһәрнең тере җаны
Җәйдә... яшеннәрнең явына...
Казан бүген тик икебез өчен
Ничәнче кат яулап алына...

Бер кайтумы?.. Әллә меңенчесе—
Кыны бушлыгына укталып?..
Без бу Җирдә—бер-беребез өчен!!!—
Галәм тиңлегедәй уртаклык...

***

Таныйсыңмы?
Мин—киләсе Көздән...
Әле яшәлмәгән гомердән...
...Тик... талпынма!
"Чалымнары гына
Таныш төсле..."—диген.
Үтенәм...

"Тавышында гына
Аның чыңы
Ишетелә..."—диеп уфтан да,

Күзләремне минем
Танымый уз,
Кагылмый уз...
Берүк тукталма!

...Капкалары Көзнең
Ачык тора...
Җилләр исеп тора—үтәли...
Тик син китмә,
Икебезнең антын
Бер гомергә сузып
Үтәми...

Без бергәләп тибрик
Монда түгел,
Мәңге яшәлмәслек Чынлыкта...
—Танийсыңмы?
...Кылган чәчләрең бу...
һәм сулышың дымы—Тынлыкта.

***

*Туры кара.*
*Бу шәһәрдә җилдән кала*
*берни дә юк...*

Й. Миңнуллина

Каралама—язма битләр түгел,
Чын бу Язмыш—кагыл... сора хакын...
Ачысыннан йөрәгеңә тамар
Әрем тәме—хыянәткә тартым...

Бер сәбәпсез җилләр йолкыныр да,
Калыр шәһәр бу уенда отып...
Шомыртларның күләгәсе генә
Саклап торыр бакчаларның котын...

Уяу торыр безнең тәрәзәләр—
Җиһан сулышына тәңгәл булып...
Син кайдадыр айны сүндергәндә...
Мин куярмын пәрдәләрем корып...

Каралама битләр генә түгел,
Чын бу Язмыш... Сөрт корымлы эзен...
Бу шәһәрдә икебездән кала
Ак шомыртлар гына—җилгә түзем...

***

Сискәнде ярларның хәтере—
Дулкыннар яу булып калыкты...
Син исем табачак Хыялга
Җан кадәр җан үзе зарыкты...

Җилкәнсез язмышлар эзеннән
Йөгергән җил бакты—үрелеп...
Бу—чоңгыл түренә ымсыну,
Киереп дулкыннар күреген...

Бу—түзем хисләрне туарып,
Күмелү югалту сутына...
Дерелди тамчылар керфектә
Һәм юрый: "Котылма... Отылма..."

...Ә Хәтер талымсыз сукбайдай
Баш ия һәр каршы дулкынга...
Мин исем тапмаган Хыялның
Йөгәнен тапшырам кулыңа...

***

*Меня осталось на согрев чернил,*
*на перекличку вздоха и каверны...*
Сесар Вальехо

Сулыш авырлыгы кадәр гомер
Сыеп бетсә шагыйрь карасына,
Бер хәсрәтсез калыр иде Җиһан,
Йомылыр да соңгы ярасына...

Җиргә яткан саксыз күләгәләр
Җилгә очар иде тәмам өркеп,
Тамчылаган сагыш диңгезеннән
Табылуга кинәт энҗе бөртек...

Җилгә очар кадере юк назлар...
Бар ялганнар, антлар—кочак-кочак.
Чигәдәге дөнья кайнавыннан
Җан тергезер беркөн шигъри учак...

Каурый җиңеллеге кадәр язмыш
Сыеп бетсә сүзләр ярасына,
Ходай тәңгәллеген тойган Шагыйрь
Бакмас иде каләм-карасына...

## Без

Күзгә йокы кермәс Төн бу...
Җил дә дәшми, җил дә тынган.
Шигырь белән күзгә-күз без—
Яуга чыккан ирләр сыман.

Хис кыллары җәя булып
Тартыла һәр караш, ымнан...
Шигырь белән җанга-җан без—
Парын тапкан ярлар сыман.



*Милләт бишеге сагында. Казандагы мәшһүр Аитова (Аитова Фатиха Габделвәли кызы—1866-1942) мәктәбе укучылары. Араларында булачак композитор һәм җырчы Сара Садыйкова да бар. 1914 ел.*



*Борһан Шәрәф (җәмәгать эшлеклесе, язучы, нашир) хатыны Зифа Шәрәф белән. 1927 ел.*



*Гомәр Галинең (язучы, тәнкыйтьче, мөхәррир) кызлары Гүзәл, Алсу һәм оныгы Лилия. 2000 ел.*



*Сердәш туташлар. 1915 елгы фото.*



*Фатих Кәрим 1945 елны Сугышчан Дан ордены белән бүләкләнгән була. 21 ел узгач ул орден шагыйрьнең хатыны Кадрия ханымга тапшырыла. 1966 ел.*



Фәүзия
Бәйрәмова

# СЕБЕР ИЛЕНӘ СӘЯХӘТ

## Тубыл каласы таш кала...

Себер мине әллә нәрсәсе белән үзенә җәлеп итте, һаман тартып тора, чакыра, барган саен яңа яклары, яңа кешеләре белән ачыла. Әлбәттә, бирегә татарлар тарта, татар тарихы дәшә, чөнки милләтебезнең Ана Ватаны шушында булган, борынгы төрки-татар теле шушында туган, һәм ул хәзер дә себер татарларының сөйләмнәрендә яңгырап тора. Мин инде Себердә күп тапкырлар булдым, бу хакта дистәләгән мәкаләләр, тарихи очерклар яздым, Себер ханлыгы тарихын өйрәнеп, "Күчем хан" дип аталган роман иҗат иттем, ул аерым китап булып басылып чыкты һәм Себер буйлап таралды. Хәзер исә мин себер татарларының икенче бер бөек шәхесе—күренекле мәгърифәтче, милли сәясәтче, дин галиме Габдрәшит Ибраһимовның тормышын һәм иҗатын өйрәнәм, шуның өчен менә тагы Себер якларына барып чыктым. Моңа өстәп, мин кая барсам да, татар авыллары тарихын, аларның бүгенге хәлләрен өйрәнәм, проблемаларын хәл итүгә үземнән аз булса да өлеш кертергә тырышам.

Бу юлы да Себер Иленә сәяхәтемне Тубыл шәһәреннән башладым. Чөнки заманында Тубыл /Тобольск/ себер татарларының гына түгел, урыслар басып алганнан соң да бөтен Себер Иленең башкаласы булып торган. Бирендә, Карлыгач /Подчуваш/ тавы дип аталган текә ярда, Иртыш итәге буйларында Күчем хан белән башкисәр Ермакның хәлиткеч сугышлары булган, шушы урынга, татар хәрабәләре өстенә, урыслар 1587 елда үз кальгаләрен китереп салалар. Тубылның тарихы шуннан исәпләнә башлый. Әмма себер татарларының сөйләвенчә, әлек бу урында татар шәһәре булган, бүген урыс кремле урнашкан урында татар ханнарының таш кирмәннәре булган, андагы архиепископ йорты урынында агач мәчет торган. Кремль урнашкан тау бүген дә Алафей таулары дип, ягъни Алып хан җирләре дип атала. Тубыл кирмәнен Искәрдәге хан сарайларының ташларыннан һәм мәчет диварларының ак мәрмәрләреннән торгызалар.

Тубыл соңгы гасырларда урыс шәһәре булып исәпләнсә дә, анда татарлык беркайчан да бетмәде һәм бетмәс тә, иншаллаһ! Бирендә иң кара елларда да ислам нуры сүнмәде, хәзер дә мәчет эшләп тора, Себер мөселманнарының үзәге булып Тубыл санала. Бирендә татар мәгърифәте дә көчле була, заманында татар мәктәпләре бар, 1953 елда Тубыл педагогия институтында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачыла, әмма ул 90нчы елларга хәтле ябылып тора. Хәзер исә татар теле һәм әдәбияты кафедрасы тагы эшли, анда Казаннан да күренекле галимнәребез килеп, татар балаларына белем бирә. Әмма татар бүлегенә

---

Фәүзия БӘЙРӘМОВА – *язучы һәм җәмәгать эшлеклесе, тарих фәннәре кандидаты; татар һәм рус телләрендә дөнья күргән 20 дән артык китап авторы. Г. Исхакый исемендәге премия лауреаты. Чаллыда яши.*

килүчеләр саны елдан-ел кими бара, чөнки институтны тәмамлап чыккач, эш юк, татар мәктәпләре юк. Соңгы елларда Төмән өлкәсендә 150 татар мәктәбе ябылды. Тубылда нибары бер мәктәптә татар теле предмет буларак укытыла, югыйсә бит шәһәр халкының яртысына якыны—татарлар!

Тубылда менә 20 ел инде себер татарларының Мәдәният үзәге эшләп килә, алар каршында музей, бай китапханә һәм телестудия бар. Өлкәдә яңа бер гайрәт белән "Мирас" иҗтимагый оешмасы эшләп китте, алар бөтен көчләрен халыкны тарихи яктан агартуга бирәләр. Себернең борынгы башкаласы Искәрне яңадан торгызу өчен тырышалар, анда мәчет, музей комплексы ачтыру артыннан йөриләр. Шулай ук Бөтендөнья татар конгрессының Төмән бүлеге дә Тубылга йөз белән борыла башлады, милли һәм дини оешмаларга кулларыннан килгәнчә ярдәм итәләр. Әмма болар, себер татар мәдәни үзәгеннән кала, барысы да халыкның үз хисабына эшләнә, дәүләтнең монда ярдәме юк, шул ук вакытта Тубыл чиркәүләре гөмбә кебек үсә, аларга бөтен Россия урыслары һәм хөкүмәт үзе ярдәм итә. Күрәсез ки, Күчем хан белән Ермак башкисәр варислары арасында моннан дүрт гасыр элек башланган көрәш һаман дәвам итә, көчләр, элеккечә үк, тигез түгел, урыс Тубылы артында Мәскәү тора, ә татар Тубылы артында кем бар? Бик тә "Казан!" дип әйтәсе килә дә, әмма моның өчен бик күп эшләргә кирәк шул әле!


Тубыл шәһәре мәчете.

Мин Тубылга килгән саен, кремльгә бармыйча калмыйм, һәрхәлдә, үзенең чиркәү төреләре һәм шомлы чаңнары, кап-карадан киенгән поплары һәм семинаристлары белән ул гайрәтне чигереп торса да. Чөнки бу урында мин татар каласы һәм мөселман мәчетләре булганлыгын беләм, көчләп чукындырулар чорында бирәдә меңләгән татарның чылбырларга асылып газаплануын, җан бирүләрен укып беләм, әмма Тубыл кремлендә хәзер дә музей һәм архивлар урнашкан булуы бирегә кат-кат килергә мәҗбүр итә. Хәер, озак вакытлар көрәшкәннән соң, архиепископ йортына урнашкан Тубыл дәүләт музеен аннан куып чыгардылар инде, дирекциясе генә янәшәдә утырып калды. Бай иде ул музей, анда бик яхшы татар бүлеге дә бар иде, язучы Ершов, дөньякүләм танылган галим Менделеев заллары бар иде, хәзер бу кадерле экспонатлар тартма-төенчекләрдә төрле биналарның почмакларында ауный инде...

Бу музей-тыюлыкның бик бай китапханәсе бар иде, мин килгән саен анда берничә көн утырып, берничә гасыр элек бирәдә генә язылган һәм бирәдә генә саклантан китаплар һәм кульязмалар белән таныша идем. Китапханәче ханымнар бирәдә гарәпчә язылган бик күп китаплар һәм кульязмалар барлыгын, үзләренең аларны укый алмаганнарын да әйткәннәр иде. Мин бу хакта Тубылның дин әһелләренә, милли хәрәкәт вәкилләренә дә җиткердем, гарәпчә китапларның исемлеген төзергә тәкъдим иттем. Безнекеләр бу эшне башкарганчы, урыс руханилары музейны Тубыл кремле территориясеннән куып та чыгардылар, хәзер ул китапларның кайдалыгын да белүче юк. Һәм 18 гектарга сузылган Тубыл кремле, дистәләгән таш бинал ары, чиркәү һәм монастырьлары, семинарияләре һәм епархияләре белән, мәңгелеккә урыс православ чиркәвенә тапшырылды. Бирегә Россия президенты Владимир Путин да килеп киткән һәм Тубыл каласын, Тубыл кремлен бөтен Россия буенча православие үзәгенә әйләндерергә кушкан, һәм ул шуңа әйләнеп бара да...

Менә мин бу юлы да Тубыл кремленә таба барам, чөнки Төмән өлкәсе дәүләт архивының Тубыл филиалы аның янәшәсенә урнашкан. Элек бу тирәләр тоташ

төрмә булган, заманында Фонвизин, Радищев, Достоевский, Чернышевский, Короленко Тубыл төрмәсендә утырып чыкканнар, Россиянең соңгы патшасы Николай II дә большевиклар тарафыннан кулга алынганнан соң гаиләсе белән шушында бикләп тотылган. Шулай итеп, татарларның җәннәттәй җирләрен басып алып, урыслар аны төрмәләр иленә әйләндергән. Биредә һәр адымда чиркәү дә төрмә, әйтерсең лә дөнья шулардан гына тора, хәер, Россиядә ул нәкъ шулай да инде...

Тубыл архивына килүемнең ике сәбәбе бар, беренчесе—Габдрәшит Ибраһимов турында мәгълүмат эзләү, икенчесе—көчләп чукындыру буенча материал туплау. Габдрәшит Ибраһимов турында мәгълүмат эзләп аның туган якларында—Омск өлкәсе, Тара шәһәре архивында булган идем инде, әмма анда 1921 елдан соңгы архив материаллары гына саклана булып чыкты, аңа кадәргеләре йә Тубылда, йә Омскида диделәр. Габдрәшит Ибраһимов 1857 елда туган, ул вакытта Тара шәһәре Тубыл губернасына караган, димәк, Тубыл архивыннан нидер табып булыр дип өметләндем. Әмма ул заманда мәчетләрдә тутырылган метрика кәгазьләренең Уфадан туп-туры Омскига җибәрелгәне билгеле булды, монда исә Тара шәһәре буенча 1897 елгы халык санын алу мәгълүматлары гына саклана икән. Ул вакытта Габдрәшит Ибраһимовның Тара шәһәрендә яшәмәгәнлеге, Төркия, Алмания, Франция һәм Швецарияләрдә сәяхәт кылып йөргәнен белсәм дә, мин бу халык санын алу нәтиҗәләрен карап чыгарга булдым. Бу вакытта Тарада җиде меңләп кеше яшәгән, шуның меңгә якыны—татарлар. Әлбәттә, татарлар тагы да күбрәк булыр иде, әмма алар, XVIII гасырда көчләп чукындырулардан соң, диннәрен—православлау, телләрен—урыс дип яздырганнар, шулай итеп, Тарада Минин, Ахматов, Курбатов, Байкишев кебек урыска әйләнгән татарлар барлыкка килгән...

Ә Габдрәшит Ибраһимовның нәсел фамилиясен йөрткән Ибраһимовлар һәм Ахуновлар берәр генә очрады, аларның да мәгърифәтче-галимгә кагылышы юк иде. Чөнки Габдрәшит Ибраһимов яшьтән ятим кала, атасы ягыннан туганнары Тара янындагы Уыш авылында, ә анасы ягыннан туганнары хәзерге Курган өлкәсенең Әлмән авылында яшәгән булалар. Ә бердәнбер энесе Исмәгыйльне ул үзе белән Хиҗазга укырга алып китә, Мәккәгә алып барып урнаштыра, шуңа күрә аны да Тара исемлегендә табып булмый. Ул вакытта Габдрәшит Ибраһимовның инде үз гаиләсе һәм өч баласы була, димәк, халык санын алуга кермәгәч, алар да Тарадан киткән булып чыгалар. Тарада йөз ел элек халык санын алганда иң күп очрый торган татар фамилияләренең Айтикиннар, Шөгеровлар һәм Шиховлар икәнлеген күрәсең, соңгы икесе бүген дә бу якларда иң күп таралган һәм иң укымышлы нәселләр икәнлеген әйтеп китәргә кирәк.

Габдрәшит Ибраһимов 1885—1892 елларда Тара шәһәрендә имам һәм мөдәррис булып тора, мәчет-мәдрәсә тота, балалар укыта. 1897 елгы халык санын алу вакытында ул ачып калдырган Тара мәдрәсәсендә 52 ир кеше хисапка алына, муллалары Иноятов Изатулла Мөхәммәт улы була, үзе якындагы Рәҗәп авылыннан, бохарлы. Шәһәрнең Нерпинская урамына урнашкан бу мәктәп-мәдрәсәдә 9 яшьтән 20 яшькәчә татар балалары укыганлыгы билгеле булды, аларның күпчелеге заманында Габдрәшит Ибраһимов шәкертләре булган булырга тиеш. Шунысы кызык, халык санын алу вакытында кайчандыр Бохара якларыннан күчеп килгәннәр "сословие" дигән сорауга "бухарец" дип язганнар, ә җирле себер татарлары исә "инородец" дип теркәлгән, барысының да диннәре—ислам, телләре—татар теле дип язылган. "Умеете ли читать?" дигән сорауга барлык шәкертләр дә, "Да, по татарски", дип җавап биргәннәр. Күрәсезме, гарәпчә укысалар да, "татарча" дип җавап биргәннәр! Тарада яшәүче Кавказ мөселманнары телләрен үзләренекен күрсәтсәләр дә, укый-яза белүне "татарча" дип теркәткәннәр. Бу үзе үк Россия мөселманнарының ислам динен татарлар аша кабул иткәнлекләрен, шунлыктан гарәп язмасын да татарча дип тануларын күрсәтә.

Бер караганда, Габдрәшит Ибраһимов дөньякүләм танылган кеше, ул архивның шәхесләр исемлегендә дә булырга тиеш иде, әмма ул юк. Себер архивларында татарлар турында, бигрәк тә аерым шәхесләр турында мәгълүмат табу бик авыр, бигрәк тә элеккерәк чорларга карася. Шуңа күрә бер мәгълүмат табу өчен төрле юнәлештәге күп фондларны, эшләрне карап чыгарга туры килә.

Архив хезмәткәрләре бөтен сәбәпне гарәпчә язылган метрика кәгазьләрендә күрәләр, үзләренең аларны укый алмауларын әйтәләр. Гарәп хәрефләре белән татарча язылган белешмәләр биредә гомумән эшкәртелми дә, әйләнешкә дә кертелми, ахрысы. Шәһәр җирендә туган шәхесләр белән бигрәк тә авыр, чөнки ул халык санын алганда йә читтә булырга, яки башка урында яшәргә мөмкин. Габдрәшит Ибраһимов буенча нидер табу өметен Омск архивына калдырып, чукындыру турында материал эзләргә тотындым.

Көчләп чукындыру үзәгенең Тубылда булганлыгын һәм чиркәү судларының эшләре биредә саклануын белгәнгә күрә, мин архив директорының үзенә кердем һәм "Тобольская духовная консистория" дип аталган оешманың эшчәнлеге белән танышырга рөхсәт сорадым. Бездә шәригать судлары булган кебек, чиркәүнең дә үз суды булган һәм ул консистория дип аталган. Биредә чиркәү тәртибен бозган, эчеп-исереп сугышкан православ дин әһелләрен һәм попларны гына түгел, яңа чукындырылган башка милләт кешеләрен, шул исәптән, татарларны да хөкем иткәннәр. Тубыл архивында бу чиркәү судының 1722 елдан башлап 1760 елга кадәрге эшләре саклана, алар өч мең бәрәмлек тирәсе һәм шактый өлеше татарларга кагыла. Аларның тасвирлау исемлеген генә карап чыккач та, чәчләрең үрә торырлык,—XVIII гасырда Себердә көчләп чукындыруның ни дәрәҗәдә рәхимсез, мәкерле һәм киң масштабта алып барылганлыгын күрәсең, урыс халкының башкалар хисабына ничек йөз миллионга җиткәнлеген аңлыйсың!

"Фонд № 156" дип аталган бу уникаль фондта Россия империясенең, православ чиркәвенең урыс булмаган халыкларга карата алып барган явыз сәясәте ярылып ята. Әмма, электрон вариантка күчерәбез дигән сылтау белән, бу фонд вакытлыча ябылып тора, шушы вакыт эчендә фондка ревизия дә ясалачак, һәм, әлбәттә инде, материалларның бер өлеше электрон вариантка күчмичә дә калырга мөмкин. Без, һәрвакыттагыча, соңга калабыз, югыйсә татар тарихчылары бу архивтан чыкмыйча утырырга һәм бу фонд материалларын яттан белергә тиешләр иде! Урысның үзенә каршы эшли торган бу материалларның 300 ел буе саклануы үзе бер могҗиза бит, Аллаһның хикмәте, гыйбрәт һәм сабак!

Бу фондта, көчләп чукындырылган татарлардан тыш, остяк-вогуллар/ханты-мансы/, калмыклар, кыргызлар, башкортлар һәм урыс булмаган башка халыклар турында да мәгълүматлар бар. Әмма безне беренче чиратта татарлар язмышы кызыксындырганга, шул турыдагы материалларны барладык. Әйтик, 1722 елда Ефимия Григорьева исемле яңа чукындырылган татар хатынын татар иренә кияүгә чыккан өчен хөкем итәләр, чөнки ул вакытта, патша указы белән, чукынган татарлар урыслар белән тормыш корырга тиеш булганнар. Хәтта чукынган татарларга чукынган татарлар белән тормыш корырга да рөхсәт ителмәгән, чөнки алар үз телләрендә сөйләшеп, православ диненнән чыгарга мөмкиннәр дип уйлаганнар. Чукынган татарларга үзара гаилә корулар берничә буыннан соң, тәмам урыслашып беткәч кенә рөхсәт ителгән.

Фондта шулай ук яңадан үз диннәренә кайткан татарлар турында да хөкем эшләре теркәлгән һәм алар шактый. Гадәттә бу хәлләр турында христиан дине әһелләре синодка хәбәр иткән һәм консистория хөкем карары чыгарган. 1744 елны Уват священнигы Пыхов әләге буенча чукындырылган татар һәм остякларны яңадан үз диннәренә кире кайткан өчен хөкем иткәннәр, бу эш бик саллы һәм 116 биттән тора, шундый ук эш 1750 елны Екатеринбургтан татар сотнигы Булатка карата да кузгатылган. Фонд материалары белән танышкач, урыс булмаган халыклар кәтүләре белән христиан диненә килгәннәр икән дип уйлыйсың, әйтик, 1751 елда 60 Тара татарының үз теләкләре белән христиан динен кабул итүе теркәлгән. Әмма бу алай җиңел генә булмаган, күп очракта татарларны һәм остякларны башта төрле сәбәпләр белән кулга алганнар, аннан төрмәдә христиан динен кабул итәргә мәҗбүр иткәннәр.

Әйтик, шул рәвешле 1746 елны Кузнецк татарларын, шул ук елны колодниклар Кулаш Бикулин һәм Давыт Самаланиевны, 1747 елны Тубыл янындагы Сүзген-Йорттан Саганчин Сурунгуловны, шул ук елны Иртыш буендагы Бегиш-Йорттан Яныш Кучуковны чукындырып, Бориска әйләндерүне, 1748 елны татарларны шулай күпләп көчләп чукындыруны, 1749 елны Салым-Йорттан Мәмәт Миасовны чукындыруны һәм фондта теркәлгән күп фактларны китерергә

була. Имеш, бу татарлар барысы да үзләре "изге христиан динен кабул итәргә теләгәннәр" икән! Тубыл кремленә ябып, канга батырып кыйнаганнан соң муеннарына көчләп тәре асулары турында җәза бирүчеләр дәшмәскә тырыша. Әмма бу очракта тарих үзе телгә килә. Әйтик, 1751 елда Тубыл, Төмән, Тара татарлары һәм бохарлы Мурат Кучумов һәм аның иптәшләре үзләрен көчләп чукындырулары турында патша хакимиятенә шикаять язалар һәм бу эшне дә чиркәү суды карый.

Чукындырылган татарларның православ дине белән бергә урыс исем-фамилияләрен алуын, шулай итеп, аларның татарлыклары бөтенләй юкка чыгуын архив материаллары буенча күзәтүе үзе бер фаҗига. Әйтик, чукындырылганнан соң Сәитовның Стефан Бабкинга, башка татарларның Кирилл Радионовка, Иван Головинга, Ульян Рудаковка, Мавра Худалеевага, Елена Кирилловага, Михаил Янбаевка, Давид Максимовка, Никифонт Юдинга, Федор Щелудяковка, Иван Куличкинга, Иван Зверевка, Иван Сухаревка, Федот Игнатьевка, Сидор Атамановка, Татьяна Порфирьевага, Сайнчак Юлышевның чукынгач Петр Кисловка әйләнүе—милләт өчен фаҗига түгелмени?! Мондый мисалларны йөзләп, хәтта меңләп китерергә булыр иде, архивта алар теркәлеп калдырылган. Әмма боларны мисалга китерүдән ни мәгънә, без ул татарларны инде мәңгегә югалттык, алар хәзер урыс булып йөриләр, бары тик каракучкыл йөзләре, бераз кысык күзләре генә аларның кайчандыр татар булганлыгын сөйләп тора...

Чукынган татарларны урыс поплары даими күзәтеп торган, православ диненнән аз гына читкә тайпылсалар да, аларны җәза көткән. Әйтик, Тубыл ямщигы Матвей Нелюбинны /татарча фамилиясе Батырев/ 1750 елны ике хатын тоткан өчен хөкем иткәннәр, чөнки христиан дине буенча бу тыелган гамәл. 1751 елда Красноярскиның яңа чукынган татарларын урыс постында ит һәм сөт ашаганнары өчен хөкемгә тартканнар. Бергамак бистәсеннән Мавра Худалееваны чиркәүгә буйсынмаганы өчен /1753 ел/, тылмач Михаил Янбаевны чиркәүгә тәүбәгә килүчеләр турында мәгълүмат бирмәгәне өчен /1753 ел/, Ай авылыннан чукынган татар Максим Давыдовны муенында тәре йөртмәгәне һәм мөселман китаплары саклаганы өчен /1754 ел/, Күшел-Йорттан яңа чукынган татар И.Мамышатовны һәм аның улы Григорийны иконаны мыскыллаганнары өчен /1754 ел/, шул ук елны Темшеняк татарларын иконаны мыскыллаулары өчен, 1755 елда Тубылдан чукынган татар Иземетьевны иконаны амбарда яшереп тотканы өчен, 1759 елда Тубылның яңа чукынган татары Григорий Зуевны чиркәүгә йөрмәгәне өчен хөкем итәләр һәм җәза бирәләр.

Тубыл янындагы Сабанак авылы башлыгы Абызбакый Сабанаковның өендә яңадан ислам диненә кайтырга теләгән чукынган татарлар качып ятуы билгеле була һәм аларның барысын да 1755 елда чиркәү судында тикшереп, җәза бирәләр. Ә җәза билгеле—ислам диненә яңадан кайткан өчен, патша указы нигезендә, тереләй утта яндырып үтерү, җиңелрәк "гөнаһлар" өчен—мәңгелек каторга, сөрген, иң җиңеле—мәңгелеккә монастырьга ябу. Архив материалларын өйрәнгәндә шунысы да билгеле булды, көчләп чукындырылган татар кызлары, урыс егетләренә кияүгә чыгып кяфер нәсел калдырмас өчен, үзләре теләп мәңгелек монастырьларга киткәннәр һәм шунда үлеп калганнар... Җирле халыкның сөйләве буенча, Тубылдан ерак түгел Көмешле авылы янында "Керәшен кыры" дип аталган бер урын бар икән, анда заманында көчләп чукындырылган татарлар яшәгән. Алар үлемнән куркып чукынганнар, әмма нәсел калдырмас өчен, хатын-кызлары кияүгә чыкмаган, ир-атлары өйләнмәгән, ягъни алар христиан нәселе калдырырга теләмәгәннәр. Алар шулай барысы да буйдак килеш картаеп үлгәннәр һәм "Керәшен кыры"на күмелгәннәр. Шул ук вакытта христиан дине әһелләре арасында Бабайлов, Сәйдәшев, Мишарин, Бухарцев, Туесов, Кучумов кебек татар фамилияле поплар барлыкка килә, чукынган татарлар өстеннән күзәтчелеккә һәм миссионерлык эшләренә инде аларны билгелиләр. Моны милләт фаҗигасе димичә тагы ни дисең?!

Тубыл архивы үзендә менә шундый коточкыч серләр яшереп тота, әле бу өскә чыкканның меңнән бере генә. Шушы көчләп чукындыру чорларында, Ермактан алып XVIII гасыр азагына кадәр Себернең җирле халыклары, шул исәптән, татарлар да күпчелеге христианга һәм урыска әйләнә. Бу—тарихи факт, моны урыс галимнәре үзләре дә беләләр, әмма бу хакта дәшмәү ягын

карыйлар. Әмма без, татарлар, дәшми кала алмыйбыз, чөнки сүз безнең борынгы әби-бабаларыбыз турында бара, аларның дин өчен күргән газаплары, тереләй утларда янулары, бозлы суларга батырылып үтерелүләре, мәңгелеккә монастырьларга ябылулары турында бара! Ватикан урта гасырлардагы инквизицияләре өчен христианнардан гафу үтенде, ә урыс праваслау чиркәве, Россия империясе көчләп чукындырулар өчен кайчан татарлардан гафу үтенер?! Бер көнне телевизордан Чечняда булган бер урыс попы сөйли, имеш, христиан-урыслар алар изге җаннар икән, чөнки алар үзләренә хәтле яшәгән изге чиркәү әһелләренең дәвамчылары икән, һәм бүгенге урыс милләтен аларның догалары саклый икән... Башка милләт кешеләренә көчләп үз диннәрен, телләрен, яшәү рәвешләрен таккан, кабул итмәгән өчен аларны тереләй утта яндырып үтергән кавем ничек итеп изгеләр исемлегендә йөри ала икән?! Хәер, аларның бөтен максатлары -Россиядә бер дин, бер тел калдыру бит, ул—христиан дине һәм урыс теле, әлбәттә...

Тубыл архивыннан мин әнә шундый шомлы уйлар, авыр кичерешләр белән чыктым...

## Сазлыктагы татар авылы

Тубылдан 70-80 чакрым ераклыкта, көнбатышка таба, тоташ сазлыклар эчендә утырган бер татар авылы бар, ул Лайтамак, дип атала. Җәен монда бернинди юл юк, очкыч белән генә килергә мөмкин, ә кышларын чана юлыннан йөриләр. Халык сөйләвенчә, татарлар көчләп чукындырудан качып шушы сазлыклар арасына барып урнашканнар, шул ук вакытта авылның бик борынгы булуын, Алыплар заманында ук биредә кешеләр яшәгәнлеген дә сөйлиләр. Лайтамактан ерак түгел тагы Тәпкен, Тәпкенбаш, Янкүтүм, Вәрмәхле дип аталган татар авыллары бар, әмма араларында иң зурысы Лайтамак икән һәм ул үзенә күрә үзәк ролен үти. Без менә хәзер кышкы юлдан җиңел машина белән шул Лайтамакка барабыз, аз гына буранласа да юл күмелә икән, ә читкә чыгып булмый, чөнки ак кар астында кышын да катмый торган сазлык дерелдәп ята... Тирә-якта кәрлә куаклар, бераз калкурак урыннарда—сыек кына катнаш урман, ә инде сазлыкларда берни үсми, алар биредә "топка" дип атала, ягъни төпсез сазлык...



*Лайтамак авылы кешеләре шушы бозны эретеп эчә.*

Себернең үз сәерлекләре һәм матурлыклары бар—монда кышын да катмый торган мәңгелек сазлыклар, шул сазлыклар арасына энҗе бөртекләре кебек сибелеп киткән төпсез күлләр, Тубыл, Иртыш, Тара, Тура, Обь кебек тирән елгалар, һәм, әлбәттә, йөз еллык карагайлары, эрбет агачлары белән шаулап утырган кара урманнар... Түмән өлкәсендә генә дә сазлыклар 2 миллион 370 мең гектар җирне били, бу үзе бер Европа иле зурлыгындагы мәйдан дигән сүз. Һәм шушы сазлыкларда яшәүчеләрнең 95 проценты—татарлар, алар 19 авылда көн күрәләр. Әлбәттә, "көн күрү" дигән сүзебез тартып-сузып кына, чөнки XXI гасырда да газы, суы, даими электр уты булмаган урыннарда яшәүне җан асрау дип кенә әйтергә мөмкин.

Әмма Лайтамак авылы безне күз камаштырырлык ап-ак карлары, авыл башыннан ук шаулап утырган урманнары, елга ярларын тау итеп чана шуган татар балаларының күңелле чыр-чуы белән каршы алды. Халык үзенең сазлык эчендә яшәвенә ияләнгән, һәр ел фасылыннан үзенчә файдаланырга өйрәнгән, һәм гасырлар буе ничек яшәсә, шулай гомер итеп ята иде. Авылда 171 хуҗалыкта 568 кеше яши булып чыкты, 120 укучылык урта мәктәп, балалар

бакчасы, медпукт, клуб бар, мәчет төзелеп ята. Лайтамак—саф татар авылы, халык әйтүенчә, бирегә чукындыру булмаган, мөгаен, саз арасыннан таба алмаганнардыр. Халыкның төп шөгыле—балыкчылык, аучылык, гөмбә-җиләк, мүк җиләге җыеп сату; элек утрау кебек калку җирләрдә иген кырлары булган, хәзер инде аларны урман баскан. Әлбәттә, һәркем мал тота, халыкның үз азыгы үзенә җитә.

Алайса, сазлыкта яшәгән татар авылының бер проблемасы да юкмыни? Бар, әлбәттә, һәм алар шактый. Авылга юл юклыгын әйттек инде, очкыч бәясе кыйммәт булгач, халык җәйләрен су юлын үз иткән, көймәләр белән елгадан-елгага күчеп, кирәк җирләренә барып җитәләр. Су юлы—бик борынгыдан калган юл, елга юк җирдә халык үзе канаулар казып, күлләрне тоташтырган, шулар аша дөнья белән элемтә тоткан. Авылның икенче зур проблемасы—эчәргә чиста су юк, халык Лаймы елгасы суын эчә, кышларын аның бозын әрдәнә итеп чабып өя, җәйләрен дә салам астында күләгәдә яткан шул бозны эретеп эчәләр. Кое казысаң, аңа саз суы чыга, ә ул эчәргә яраклы түгел. Лайтамакның өченче зур проблемасы—даими электр уты булмау, ягъни ул җирле дизельләр тарафыннан кичке дүрттән соң, берничә сәгатькә генә бирелә, шуңа күрә кешеләр суыткыч тотмыйлар, телевизор да берничә сәгать кенә эшләп ала. Табигый газ юк та юк инде, кешеләр йөз ел электәге кебек, утын яга. Шушындый хәлдә булып та, авыл халкына үзләренең сазлыкта яшәүләрен исбатлау авыр, шунлыктан, өлкәнең саз авыллары программасына керү дә проблемалы булып тора. Җирле үзидарәдә очрашу вакытында авыл халкы безгә менә шуларны сөйләде, моңа өстәп, күп кешеләр хезмәт ветераны статусы ала алмыйлар икән, ул хакта да әйттеләр.

Безнең белән Лайтамакка Тубыл районы депутаты Сулкарнаев Таип әфәнде дә барган иде, социаль мәсьәләләр буенча сорауларга җавапны ул бирде. Үзе дә "Сибнефтепровод" оешмасында җитәкчелектә эшләгән Таип әфәнде бу проблемаларны белә һәм күптән инде аларны хәл итү юлларын эзли икән. Аның фикеренчә, бирегән 40 чакрым гына ераклыкта үткән газ торбалары һәм электр линияләреннән Лайтамакка да газ һәм электр уты уздырырга мөмкин икән, ул инде бу хакта район хакимияте каршында сүз кузгатып караган. Димәк, хәл алай ук өметсез түгел, бу мәсьәләләрне ничек тә өлкә программасына кертергә һәм район хакимияте ярдәмендә ахыргача җиткерергә кирәк. Югыйсә авыл башыннан гына бөтен Европага Себер газы һәм нефте үтә, ә җирле халык һаман утын яга һәм чыра яктысында тормыш итә! Безнең белән Тубылдан Лайтамакка килгән "Мирас" иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Луиза Шәмсетдинова да халыкка социаль проблемаларны, бигрәк тә, ветеранлык статусы мәсьәләсен хәл итүдә ярдәм күрсәтәчәген әйтте.

Әмма авылда, социаль проблемалардан тыш, әхлакый мәсьәләләр дә шактый булып чыкты. Шуның иң авыры—эчкечелек, үтерешләр, үз-үзеңә кул салулар. Аучылар булгач, һәр ир-атта диярлек утлы корал, бер бәхәс килеп чыкса, мылтыкка ябышалар икән, шуңа күрә авылда атасыз, ятим балалар шактый. Эчкән баштан асылынып үлүчеләр артканнан-арта баруын да әйттеләр. Узган җәйдә ата-анасының туктаусыз эчүенә түзә алмыйча 14 яшьлек малай асылынып үлгән, ул өч көн чарлакта асылынып торган, исерек ата-анасы белмәгән дә, балага җеназа укып күмәргә мулла үзе дә исерек булган, җеназаны абыстай укырга мәҗбүр булган... Бер караганда, зур дөньядан читтә торган, сазлыкта йомылып утырган бу татар авылына кайдан килгән мондый замана чирләре? Моңа да җавап бик өстә ята—динсезлек шушы хәлгә китереп җиткергән авыл халкын, иман зәгыйфьлек кешеләрне яңадан хайванга әйләндерергә мөмкин икән. Бирегә дин элек тә шактый йомшак булган, халыкның бер өлеше мәҗүсилектә яшәп, курчакларга табынучылар да булган диләр. Әмма мәчет тә булган бит! Бирегә мулла вазифасын үтәгән Хәнәфи Барсуковны 1938 елны Тубыл НКВДсы атып үтерә, мәчетне кызыл комиссарлар җимереп ташлыйлар. Авыл ярты гасырдан артык мәчетсез яшәгән... һәм хәзер дә мәчетсез.

Дөрес, Лайтамак уртасында төзелеп бетмәгән мәчет тора, аны атып үтерелгән Хәнәфи мулланың оныгы Шәрифә ханым Бабаева салдыра башлаган. Ул Тубылдагы өч бүлмәле фатирын сатып, туган авылына кайткан булган, балаларга дин сабагы укыта башлаган, туганнары һәм авыл халкы ярдәме белән мәчетне түбәсенә хәтле күтәргән...һәм авылдан китеп барган. Сәбәбе—үзәккә

үтә торган сүз, гайбәт, нахак яла булырга тиеш, ягъни шайтан бу авылны үз кулыннан ычкындырырга теләмәгән. Күрше татар авылларында да шушы ук хәл икән, кереп кунарга әчмәгән гаилә табып булмавын әйттеләр. Менә шундый хәлләр, җәмәгать! Миңа моны саз авылларындагы өметсезлек, даими чолганышта яшәү, чикләнгәнлек нәтиҗәсе дип тә аңлатырга тырыштылар. Бәлки шулайдыр да, әмма сазлыктан чыгу юлы үз-үзеңә кул салуда булырга тиеш түгел бит!

Югыйсә авыл шулкадәр матур урынга урнашкан, урман дисәң—урманы, елга дисәң—елгасы бар, ул күлләрдә нинди генә балыклар юк, мүк җиләге, гөмбәне җыеп бетерерлек түгел диләр! Телләре дә бик саф, татарча, бозылмаган, җырлап тора. Җырлап дигәннән, татар халкының иң борынгы дастаннары шушы авылда язылып алынган! "Сәйфелмөлек", "Бүри хан", "Алпамша", "Йиртөшлек" кебек хан заманнардан калган дастаннарны галимәбез Флора ханым Әхмәтова-Урманче әле 1972 елда ук шушы Лайтамак авылы халкыннан язып алган иде.

*Бүри хан, әй Бүри хан,*
*Тастарында татлы хан.*
*Халаек өчен әүвәрә булды,*
*Шәһит үлде Бүри хан.*

*Мөселманнар мең кеше,*
*Кафырлар сансыз кеше.*
*Мөселманнар шәһит булды,*
*Ул һәм Ходаның эше.*

Милли хәтерендә мөселманнарның һәм кяферләрнең сугышларын истә тоткан Лайтамак авылы шул чорларны да күргән, димәк. Шул ук вакытта Алыплар турында иң борынгы дастаннарның шушы авылдан язып алынуын да онытмаска кирәк. Аларда да сүз хан заманнары турында бара, төп каһарманнар да хан балалары, Алыплар, пәһлеваннар. Бу дастаннарда антик шагыйрь Гомерның "Одиссея" поэмасы мотивлары бар, димәк, себер татарларының үз Титан-Алыплары, үз борынгы мәдәниятләре, дөньяга үз карашлары булган. Алыплар турында Лайтамак авылына бәйле яңа риваятьләрне мин моннан берничә ел элек Тубыл шәһәрендә Арыслангәрәй абый Арангуловтан да ишеткән идем. Ул миңа Еләк Алып һәм Мәңкер белән Нәкер Алыплар турында риваятьләр сөйләгән иде. Еләк Алып шушы Лайтамак авылында яшәгән, имеш, ул атасыз булган, әнисе аны җиләк ашагач тапкан. Ул бик озак йоклый торган булган, Лайтамак авылы халкы аны яу килгәндә уята торган булган. Ә Мәңкер белән Нәкер Алыплар елга тамагында ятканнар, алар чирү иштәкләре белән сугышканнар, авылны саклаганнар, аларның каберләре әле дә Ләнце авылы янында икән, борынгы шәҗәрәләрдә аларның исемнәре Зәңгир һәм Мәңгир бабайлар дип күрсәтелгән. Шулай ук авылдан ерак түгел Олы бәй белән Кече бәй исемле Алыплар ук атышып уйнаганнар, тау башына йомырка утыртып, бер чакрымнан аңа ата һәм тидерә торган булганнар. Күрше Янкүтүм авылында да шундый пәһлеван батыр яшәгән, имеш, урыс гаскәре килгәнен белеп, аны уятканнар һәм ул яуда җиңеп, елга яры буена урысларның башларын тезеп чыккан. Халык әле дә менә шундый легендалар һәм риваятьләр сөйли, зур гәүдәле Алыплардан тыш, биредә карсак буйлы кәрлә кешеләр яшәгәнлеген дә әйтәләр, имеш, алары "сыпыр" дип аталган һәм себер татарлары шулардан башланган икән...

Борынгы шәҗәрәләрдән күренгәнчә, моннан 900-600 еллар элек Себергә ислам динен кертергә килгәч үлеп шәһит киткән дөнья мөселманнарының, сәид һәм шәехләрнең кайберләре бу тирәләрдә дә күмелгән. Әйтик, бу язмаларда Лайтамак авылында Иләкалып батыр зираты булганлыгы, күрше Янкүтүмдә Иләктора, Бабасир, Төпкенбашта—Моңгы бәй әүлия кабере, күлләр буенда билгесез астаналар булганлыгы әйтелә. Кыскасы, бу тирәләрдә ислам дине өчен зур сугышлар барган, күп мөселманнар шәһит киткән, бу җирләр изгеләр каны белән сугарылган... Шуңа күрә монда динсезлек берничек тә кичерелми, дин өчен ерак Себер илендә шәһит киткән изгеләр бирәдәге татарлардан дога

өмет итеп яталар, бу якларга иминлек һәм бәрәкәт яңадан ислам дине белән генә киләчәк. Ә хәзергә авыл уртасындагы манарасыз ятим мәчет ак кар эчендә бер ялгызы утыра...

Әйе, хәзер Себер урманнарында Алыплар да, кәрләләр дә юк инде, ислам дине өчен җиһадка чыккан сәид-шәехләр дә юк, шушы риваятьләрне хәтерләрендә саклаучы саз татарлары гына бар. Тарихлары Алып кешеләрдән, ханнардан башланган себер татарлары аракы сазлыгына батып харап булмаслар, иншаллаһ, чөнки авылда әле милли интеллигенция, укытучылар, эшмәкәрләр, җирле хакимият бар, алар тормышны алып бара. Гөрләп мәктәпләре эшләп тора, анда татар теле дә укытыла, бик кызыклы музейлары бар, анда агач кайрысыннан ясалган зур-зур савытларны, балык тоту җайланмаларын, суккан капчыкларны, борынгы тимер җамаякларны күреп, үзеңне Алыплар заманына килеп эләккән кебек хис итәсең. Лайтамак авылы, әлбәттә, табигать музее булырлык, изоляциядә милли, этнографик үзенчәлекләрен саклап калган татар авылы, бәлки, аны алга таба шушы юнәлештә үстерергә кирәктер, әчкечелек булмаса, бирегә теләсә нинди туристларны алып килеп күрсәтергә була.

Лайтамак авылыннан бүгенгесе көндә дә талант ияләре чыгып торуын әйтеп үтәргә кирәк. Әйтик, Тубыл шәһәрендә яшәүче, халык арасында "Себер сандугачы" дип йөртелгән атказанган җырчы Зәкинә ханым Арангулова шушы Лайтамак авылында туып-үскән. Шулай ук бу авылдан җирле шагыйрәләр Фәрзәнә Барсукова, Галия Абайдуллина чыккан, шагыйрь Гали Җәлилов биредә эшләгән. Авыл үзенең Россия күләмендә танылган чаңгычылары белән дә данлыклы. Димәк, саз арасында яшәргә мәҗбүр булса да, бу авылда әле рух сүнмәгән, яшәү дәрте бар, милли хисләр ургып тора. Бары тик әхлакны төзәтергә, иманга кайтып, ныклы татар тәртибе белән яши башларга кирәк. Башкача мөмкин түгел, чөнки каһарман Алыплар яшәгән, сәид-шәехләр күмелгән, хан заманнарыннан сакланып килгән авыл бит ул—Лайтамак!

## Тарихларга кергән Әримҗан

Тубылдан ерак түгел төньяк тарафта, Иртыш елгасының түбән агымында зур гына бер татар авылы бар—Түбән Әримҗан дип атала. Аннан ерак түгел Югары Әримҗан дигәне дә бар, анысында инде урыслар яши, заманында биредә атаклы галим, химик Дмитрий Менделеевның әнисе ягыннан бабалары туган булган. Урысларның татар исемен йөрткән авылда яшәвен елга исеме белән аңлаталар, имеш, Әримҗан елгасының югары өлешендә—Югары Әримҗан, түбән өлешендә—Түбән Әримҗан урнашкан икән. Әмма урыслар үз авылларына теләсә нинди башка исем бирә алалар иде бит, телләрен сындыра-сындыра нигә аларга татар исемен үз авылларына кушарга иде? Сәбәп башка, әлбәттә, һәм монда вакыйгалар чукындыру чорларына барып тоташа.

Тарихта башта бер генә Әримҗан булган—татар Әримҗаны һәм без хәзер шунда барабыз. Тарихи китаплардан бу авыл турында шактый укыганым бар иде, шуңа күрә бу очрашуны дулкынланып көттем. Әримҗан турында беренче хәбәрләрем узган гасыр башы галиме Николай Катанов хезмәтләре аша булды, ул исә борынгы шәҗәрәләргә таянып, биредә ислам миссионерлары күмелгәнлеген язган иде. Ягъни моннан 900-600 еллар элек ислам динен тарату өчен бөтен дөньядан иң тәкъва һәм иң тәвәккәл мөселманнар Себергә килә, аларның күпчелеге дин өчен изге сугышларда бу якларда үлеп кала. Борынгы шәҗәрәләрдән күренгәнчә, Әримҗанда Искәндәр углы Даут бабай зираты бар, ул имам Хөсәеннең оныгы, диелгән, ул бик данлыклы шәех булган. Җирле халык телендә "астана" дип йөртелгән бу каберлекләр шәҗәрә хуҗалары тарафыннан карап торыла икән.

Омскида яшәүче тарихчы-галим Н. Томилов бу тирәдә "Иримҗан" яки "Илимҗан" дип аталган татар шәһәре булганлыгын яза: "...известны такие городки и селения тобольских татар XVI в. ...по Иртышу, ниже Искера—Атиков городок (Заостровные юрты), городки Аремзянские (Иримчан, Илимчан), Тургайский, Демьянский, а также Насбалак, Крянчи, Караче и др." (Тюркоязычное население Западно-Сибирской равнины в конце XVI—первой четверти XIX вв.") Ягъни Әримҗан исеме Галимҗаннан алынган булырга мөмкин, чөнки себер татарлары да, мишәрләр кебек, сүз башындагы "г"

авазын төшереп калдыралар, "җ"не "ч" белән алыштыралар. Бу исә Әримҗанда заманында бик зур гыйлем иясләре яшәгәнлеккә ишарә ясый.

Себер ханлыгы чорында исә Әримҗан татар дәүләтенең бер хәрби кәлгәсе булган, Ермак бандитлары белән сугышканда зур батырлыклар күрсәткән. Бу хакта урыс елъязмалары да, тарихчылар Г. Миллер, Һади Атласи һәм башкалар да яза. Һади Атласи үзенең "Себер тарихы" дип аталган хезмәтендә: "Аримдзянка елгасына чаклы булган татарлар казакларга әүвәлдән үк итагатьтә булганлыклары өчен, алар илә казаклар орышмадылар. Ләкин ул елганың тамагындагы кечкенә бер шәһәрчектәге татарлар казакларга бик нык карышып, алар илә сугыштылар. Шунлыктан Богдан ул шәһәрне көч белән яулап алды. Киләчәк сәфәрдә карышучыларга гыйбрәт булсын өчен ул, шәһәрдә казакларга баш бирмәскә өндәгән башлыкларны җыеп, барысын да аякларыннан астырды. Шуннан соң калган кешеләрне тугры булучылыкка канланган кылыч үбү илә ямин иттереп, һәрбер кешегә ясак салды." *(Һади Атласи. Себер тарихы. Сөенбикә. Казан ханлыгы.—Казан, 1993, 94-95 б.)*

Минем үземнең "Күчем хан" дип аталган тарихи романымда да Әримҗан өчен барган сугышка шактый урын бирелгән иде:

"Кышкы Иртыш буйлап төшеп, беренче зур каршылыкны казаклар Әримҗан татар шәһәрендә очраттылар. Борынгы затлы татар нәселләре, зур байлары, укымышлы шәехләре белән аерылып торган Әримҗан шәһәре казакларга нык каршылык күрсәтте, беркем дә җиңелергә дә, бирелергә дә уйламады. Кирмәнгә кереп бикләнгән татар сугышчылары көне буе дошманга каршы тордылар, әмма баштанаяк утлы корал белән коралланган казакларны җиңә алмадылар. Казаклар кирмәнгә көч белән бәреп кергәннән соң, әсир төшкән татарларга карата ерткычлыклар күрсәтә башладылар.

Башта атаман Никита Пан иң каты сугышкан мәргәннәрне сайлап алды һәм аларны аякларыннан асып куярга кушты. Кышкы салкында асылынып торган татарларга казаклар төрле яктан ук ата башладылар, үлмәгәннәренең башларын кылыч белән чабып өзделәр. Бу хәлләрне күреп коты чыккан халык Ермакка буйсынырга ризалашты, әмма тәре үбүдән баш тартты. Казак атаманы әле кан тамчылары да кибеп өлгермәгән кылычын татарларның борын төбенә төртте, коллыкка кылыч үбеп ант итәргә боерды.

—Тәре үбәсегез килми икән, кылыч үбегез, басурманнар, югыйсә ул кылыч үзе башыгыздан үбәчәк!—дип кычкырды ул, ак кар өстенә тезләнгән халыкка.

Әле генә туганнарының, аталарының, балаларының башын кискән канлы кылычны күпләр үпмәде, һәм аларның да башлары ак кар өстенә тәгәрәде...

Затлы Әримҗан каласы шулай итеп утка тотылды, бар малы талап алынды, исән калганнарны көчләп чукындырулар башланды... *(Күчем хан.—Казан, 2007, 103-104 б.)*

Авылның бер өлеше Ермак чорында көчләп чукындырылган булса, бер өлеше XVIII гасырда чукындырылган һәм икенче урынга күчерелгән булырга тиеш. Тарихтан билгеле булганча, XVIII гасырда Себердә җирле халыкны көчләп христиан диненә кертү дәүләт дәрәҗәсендә алып барыла һәм бик рәхимсез, мәкерле төс ала. Петр I дән башланган бу явыз сәясәт тәхеткә Екатерина II килгәнче дәвам итә, төньякта яшәүче күпчелек халыклар, вогул-остяклар, кыргыз-кайсаклар, калмык-башкортлар һәм себер татарларының бер өлеше чукындырылып кына калмый, урыс милләтенә дә әйләнә. Чукындырылган "инородец"ларны милли мохитләреннән аеру өчен башта аларны икенче урынга күчерәләр, соңрак исә чукынганнарны түгел, чукынмаганнарны үз авылларыннан башка җиргә куып җибәрә башлыйлар. Патшабикә Анна Иоановнаның 1 740 ел, 11 сентябрь указы нигезендә яңа чукынганнарны урыс арасына күчереп утырту, алар өчен Саратов белән Царицын арасында аерым бистәләр салу турында сүз бара. Чукындырылган себер татарларын исә алай ерак җибәреп тормыйлар, елганың бер башыннан икенче башына гына күчерәләр. Менә шушы вакытта, ягъни XVIII гасырның уртасында Әримҗан исемен йөрткән икенче бер авыл—Югары Әримҗан барлыкка килгән булырга тиеш.

Тубыл шәһәрендә яшәүче тарих фәннәре докторы Вячеслав Софронов үзенең "Село Верхние Аремзяне" дигән мәкаләсендә моның шулай икәнлеген раслый да: "С татарского языка Аремзяны можно перевести от производного

Гарифзян, что значит, "грамотный" или "мудрый" хан,—дип яза ул.—Вспомните мусульманское имя Гариф. И уже русские жители переиначили Гарифзян в Аремзян на свой манер. Основано село Верхние Аремзяны, судя по документам, около 1750 года." *(Тобольский хронограф. -Омск, 1993, стр. 109.)* Ягъни XVIII гасыр урталарында татар Әримҗаныннан аерылып чыккан чукынган татарлар авылы—Югары Әримҗан барлыкка килә һәм алар еллар үтү белән үз диннәрен генә түгел, телләрен, татарча исемнәрен, нәсел фамилияләрен дә югалталар...

Инде әйтеп үткәнебезчә, галим Дмитрий Менделеевның әнисе ягыннан нәселе шушы Югары Әримҗан авылына барып тоташа. Аның әнисе Мария Дмитриевна Корнильева байлар нәселеннән була, алар Югары Әримҗан авылында пыяла һәм кәгазь фабрикалары тоталар, сәүдә итәләр. Дмитрий Менделеев Тубыл шәһәрендә туса да, аның балалык еллары Югары Әримҗан авылында үтә, ул яшьтән тол калган әнисенең беренче ярдәмчесенә әйләнә. Менделеевның татар нәселеннән булуы турында аның туганнан-туган сеңлесе Н. Губкина болай дип язып калдыра:

"По семейным преданиям один из прадедов Дмитрия Ивановича был женат по страстной любви на красавице киргизке или татарке; он так любил ее, что когда она умерла, то и он умер с горя. Так что в чисто велико-русскую кровь Корнильевых вошла струя крови монгольского племени, некоторые потомки их имеют даже что-то восточное в типе, хотя у Дмитрия Ивановича этого не было, разве немного высокие скулы и разрез глаз." *(Памяти Дмитрия Ивановича Менделеева. Семейная хроника в письмах.—Петербург, 1908, стр.3.)*

Тарихи хатирәләргә бирелеп, Түбән Әримҗан авылына килеп җиткәнне сизмичә дә калдык. Авыл чыннан да бик матур җиргә урнашкан икән—Иртыш буенда, карагай-эрбет урманы янында, куе әрәмәләр һәм болынлыклар арасында таралып ята ул. Безне бирегә алып килүче—Тубыл район советы депутаты, эшмәкәр Таип әфәнде Сулкарнаев тумышы белән шушы авылдан икән, ул безгә аның тарихын да, бүгенгесен дә белгәненчә сөйләп бирде. Күренеп тора, авыл нык булырга охшаган—асфальт җәелгән, табигый газ авылга хәтле сузылган, өйләргә генә кертәсе калган. Халыкның төп өлеше нефть кудыру станциясендә эшли икән, шулай ук пилорамда, янәшәдәге сөрген-поселениедә эшләүчеләр дә бар.

Матди яктан шактый нык күренсә дә, рухи яктан бу авылда күңелне рәнҗетерлек нәрсәләр барлыгы да ачыкланды. Кайчандыр саф татар авылы булган Түбән Әримҗан соңгы елларда янәшәдәге урыс авылы белән кушылган һәм миллилеген җуя башлаган икән. Моның беренче билгесе—урта мәктәптә татар теленең бөтенләй укытылмавы, хәтта факультатив түгәрәкләрнең дә булмавы. Югыйсә авылдагы меңнән артык кешенең күпчелеге—татарлар, йөз укучылык мәктәпнең дә яртысыннан артыгы татар балалары бит! Әллә соң заманында Ермакка тәре үбеп ант итәргә мәҗбүр булган Түбән Әримҗан халкы һаман шул халәттә яшиме, яки Иртыш буйларына тагы башкисәр Ермак заманнары әйләнеп кайтканмы?

Узган елда Тубыл шәһәреннән поп килеп, балалар бакчасына йөрүчеләрне чукындырып китүләрен ишеткәч, Иртыш буйларына яңадан Ермак заманнары килеп ятканына ышанасың. Безнең белән авылга килгән "Мирас" иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Луиза Шәмсетдинова түзмәде, бу хәлне ачыкларга балалар бакчасына кереп китте. Аны күргәч курка калган мөдир маржа түтәй бакчага мулланы да чакыртып, Коръән укытырга вәгъдә биргән. Ә авыл халкы, татарлар нигә бу чукындыруга каршы күтәрелмәгән соң?! Ни өчен мәктәптә тел юкка да, сабый балаларын чукындырып китүгә дә ризалашып яталар алар? Мин бу сорауларны мәчеткә җыелган халыкка бирергә уйлаган идем, әмма монда да ниндидер кара көчләр арага килеп керде, очрашу булмыйча калды. Югыйсә кичтән авылга шалтыратып, мәчеткә ягарга, өйлә турына татарларны җыярга әйтелгән иде бит! Сүз җомга көн мәчеткә җыелу турында бара, җәмәгать, язучы белән очрашу турында гына бармый! Әмма телен җиңел генә башкаларга биргән халык динен дә шулай суга салып ята икән...

Без Түбән Әримҗан авылына килеп төшүгә, мәчеткә киттек, әмма ак кар өстендә эзләр юк, мәчет ачылмаган да, ягылмаган да булып чыкты, күңелгә иң авыры—аны ачарга җыенучы да юк иде! Без авылның мулласы Әхмәт әфәнде

Таҗиев янына өенә киттек. Баксаң, аның үзендә дә мәчет ачкычы юк, аның үзен дә мәчеткә кертмиләр икән! Бу авылда гаҗәп хәлләр булып ята—мәчет бар, мулла бар, әмма мәчет ачкычы башка кешеләрдә, ул җәй көне, кайдадыр төньякта эшләүче ир-ат Түбән Әримҗанга кайткач кына ачыла икән. Югыйсә авылда муллалык вазифаларын барыбер Әхмәт Таҗиев башкара—никахын, җеназасын укый, балаларга исем куя, әмма "теге кеше"дән башка мәчеткә керә алмый! Кем килсә дә мәчетне ачмыйлар, җәйне, "теге абзый"ны көтәләр... Күрәсез, заманында мәчетне төзүдә зур активлык күрсәткән кешеләр, аны кыш буе бикләп тотып, зур гөнаһ эшлиләр! Чөнки мәчет синеке дә, минеке дә түгел, Таҗетдиннеке дә, Ашировныкы да түгел, ул—Аллаһ йорты, гыйбадәт урыны, бигрәк тә аның җомга көн бикле торуы әйтеп бетергесез авыр хәл иде... Шушыларны белгәч, ни өчен попларның Тубылдан килеп, балалар бакчасына йөрүчеләрне чукындырып китүләрен аңлыйсың инде! Татарлар мәчет өчен үзара талашып ятканда, бөтен авылларын да чукындырып чыгып китәргә мөмкиннәр әле, Аллам сакласын!

Авылда намаз укучы юк икән, Әхмәт хәзрәт белән икебез генә җомга намазын өйлә намазы итеп укыдык. Әхмәт хәзрәт дингә үзлегеннән килгән кеше, Пермь һәм Первоуральский шәһәрләренә барып, башлангыч дини белем ала, аннан читтән торып Казан шәһәренең "Мөхәммәдия" мәдрәсәсенә укырга керә. Анда укыганнары, анда алган гыйлеме, укытучыларының яхшылыгы, акылы турында ул сөйләп бетерә алмый. Аның өендә ислам китаплары, дини матбугат, дини видеокассеталар да күп, теләгән кешегә авылдан чыкмыйча да файдалы мәгълүмат алырга була. Әхмәт хәзрәт Таҗиев үзе бу якларныкы түгел икән, ул Башкортстанның Ишембай районыннан, әмма Иртыш буйларында күптән яши һәм аны үз иткән. Ул Түбән Әримҗан тарихы белән дә кызыксына, бу турыда материал туплый, җирле газеталарга хәбәрләр биреп тора.

Әйтик, аның сөйләве буенча без Түбән Әримҗанда 1890 елда мәчет ачылганлыгын белдек, аны салдыруга Тубылның ул вакыттагы атаклы бае Тохтасын Айтмөхәммәтов төп өлешне керткән. Ул, имеш, урманда ауда йөргәндә учак янында утыручы хантыларга юлыккан һәм корым белән капланган казанга игътибар иткән. Янында булган бөтен акчасын биреп, Тохтасын Айтмөхәммәтов хантылардан ул казанны сатып алган, ә ул казан алтын булып чыккан. Тохтасын бәй алтын казанны шәһәрдә сатып җибәргән, ә аның акчасына Тубылда һәм Түбән Әримҗанда мәчет салдырган. Кызганычка каршы, хакимияткә большевиклар килгәч, мәчетне конфисковать итәләр, ул ярымҗимерек хәлдә озак еллар буе тора һәм берничә ел элек янып китә. Аның урынына яңа мәчет салалар, ә ул кыш буе йозакта...

Мәчеткә кереп булмады, мәктәптә укучылар һәм укытучылар белән очрашырбыз дип шул якка таба юнәлдек. Әмма... мәктәп ишегендә дә йозак булып чыкты, нык кирпечтән салынган бу бинага керерлек түгел иде! Без килгәндә авылда суыклык 25 градуслар тирәсе генә булса да, имеш, салкын булу сәбәпле бүген балаларны укытмаганнар икән. Ни хикмәт, укытучыларның да эзе юк, кайсы Тубылга киткән, кайсы авырый, кайсы өендә качып ята булып чыкты. Моңа кадәр үзен Екатерина Михайловна дип атап йөрткән мәктәп директоры Хафизә Төхфәтулловна Айтмөхәммәтова да каядыр китеп барган иде, югыйсә аңа да район советы депутаты, Тубылдан "Мирас" оешмасы җитәкчесе һәм Татарстаннан язучы киләсе әйтелгән булган бит! Без, әлбәттә, беренче сүз итеп мәктәптә татар теле укыту мәсьәләсен күтәргән булыр идек, ә директорның моңа җавабы юк! Туган авылы балаларын татар теленнән мәхрүм иткәне өчен дә җавабы юк аның! Болай булгач, Тубыл попларының киләсе адымы мәктәпне килеп чукындырып китү булыр инде, чөнки Хафизә Төхфәтулловналар үз теләкләре белән Екатерина Михайловнага әйләнгән авылда моңа каршы торучылар булмаячак икән...

Менә шундый милли һәм дини каршылыклар, үзара аңлашылмаучылыклар булса да, Түбән Әримҗан авылы милләткә һаман акыл ияләрен һәм талантлы кешеләрне бирүен дәвам итә. Бу авылдан чыккан югары белемле кешеләр, галимнәр һәм эшмәкәрләр шактый булган. Әйтик, Казанда яшәүче опера җырчысы Сәид Раинбәков шушы Түбән Әримҗан авылыннан икән, Тубылда яшәүче тарих фәннәре кандидаты Гөлсифа Бакиева да шушы авылдан булып чыкты. Аның "Сельская община тоболо-иртышских татар (XVIII—начало XX в.)"

дип аталган хезмәтендә *(Төмән-Мәскәү, 2003)* себер татарлары тормышы турында бай мәгълүмат бирелгән, шул исәптән, Түбән Әримҗан турында да. Әйтик, XVIII гасыр башында Түбән Әримҗанда утызлап ясак түләүче булса, гасыр ахырында да бу сан әлләни үзгәрми, халыкның табигый үсеше күренми, бу исә татарларның бер өлеше шул гасыр урталарында башка урынга күчерелгәнлеген күрсәтә.

XXI гасырга исә Түбән Әримҗан авылы менә шундый хәлдә килеп җитте, ул элеккеге кебек гыйлем үзәгенә әйләнеп китәрме, аңа милли йөзе кире кайтырмы, имам Хөсәен оныклары алып килгән ислам дине яңадан Түбән Әримҗанның иманына әйләнерме—монысы инде халыкның үзеннән дә тора. "Яңадан тәре үбеп ант итә күрмә, Әримҗан халкы, баш өстеңдә үткен кылыч торса да, бу хыянәткә барма, барма, барма!!! Нинди генә заманда яшәсәң дә, татар булып, мөселман булып кал, бу сиңа дин-милләт өчен шәһит киткән әби-бабаларыңның васыяте!" Җомга көн бу авылда укыган өйлә намазыннан соң мин әнә шундый теләкләр теләп, дога кылдым...

## Омск өлкәсендә дә татарлар яши...

Әйе, Омск өлкәсендә дә татарлар яши, һәм себер татарларының иң борынгылары шул якларда көн итә. Югыйсә себер татарлары дигәндә Төмән-Тубылны гына күздә тоталар, ә алар Омск, Томск, Новосибирск өлкәләренә таралып яши, хәтта Кемерово, Курган, Красноярск өлкәләрендә дә себер татарларын очратырга мөмкин бит! Менә мин дә хәзер Тубылны вакытлыча калдырып, себер татарларының иң борынгы, меңәр еллык авыллары урнашкан якларга—Омск өлкәсенә юл тотам. Мин эзләнүләр алып бара торган Габдрәшит Ибраһимов та шул яклардан бит, Омскидан 300 чакрым төньякка урнашкан Тара шәһәреннән, шул тирәдәге бер авыл мәдрәсәсендә белем алган. Бу юлы да максатым—Омск архивында эзләнүләр алып бару, Омск һәм Тара шәһәрендә милләттәшләр белән очрашу, татар авылларында булу. Поезд ак карга баткан кышкы урманнар буйлап кыйблага таба чаба, Ишим тирәләрендә инде карсыз далалар башлана...



*Тара шәһәренең иң карт татарлары Әсгат һәм Сафия Вәлиевләр.*

Омск өлкәсе табигатьнең бик чуар урынына урнашкан: көньягында—кыпчак-казакъ далалары, төньягында—тайга, карурман, ханты-мансы биләмәләре, көнчыгышта -Томск һәм Новосибирск өлкәләре, көнбатышта—Тубыл-Төмән җирләре. Төньяк-көнбатышта өлкәнең 25 процент җирләрен сазлыклар биләп торса, төньяк-көнчыгышта урманнар шаулый, ә көньякта исә—дала, дала, дала... Зур сулардан исә Иртыш, Тара, Ишим, Омь елгалары өлкәне кисеп үтә. Һәм шушы зур су буйларына таралып, кара урманнарга сыенып, сазлыкларга сырышып, татарлар яшәп ята. Омск өлкәсендә алар әлләни күп тә түгел кебек—50 мең чамасы, алар 66 татар авылында һәм өлкәнең барлык шәһәрләрендә дә яшиләр. Татарлар күбрәк төньякта—Усть-Ишим, Тевриз, Тара, Большеречинск районнарында яшиләр, алар Муромцево, Знаменск, Колосовка районнарында да шактый. Шунысын да әйтергә кирәк, бу төбәкләр—бик борынгы яклар, бирегә таш гасыр чорларыннан калган торак урыннары табылган, себер татарларының беренче дәүләтләре дә шушы якларда корылган һәм беренче башкалалары да хәзерге Усть-Ишим шәһәре тирәсендә булган, Кызыл-Тора дип аталган.

Минем Омск өлкәсенә беренче генә килүем түгел инде, шушы календарь ел эчендә өченче сәфәрем. Беренче тапкыр мин бирегә узган елның апрелендә, Габдрәшит Ибраһимовның 150 еллык юбилеен уздырырга дип килгән идем, Омск

һәм Тара шәһәрләрендә халык белән очрашулар үткәрдем. Икенче тапкыр исә Тевриз шәһәрендә өлкә Сабан туенда катнаштым, 580 еллык Яланкүл авылында Хәтер көнендә, тагы берничә татар авылында булдым. Бу юлы минә тагы архив һәм авылларга барырга ниятләп юлга чыктым, чөнки барган саен яңа нәрсәләр ачыла, яңа кешеләр белән танышасың, яңа планнар корып кайтасың.

Омск өлкәсендә бергә-бергә эшләрлек кешеләр дә күп—минә егерме елга якын милли хәрәкәтне җитәкләп баручы Хәким әфәнде Садыйков, аның абыйсы Хәлил әкә, ничә еллар буе бар татар дөньясына Омск-Томск яңалыкларын җиткереп баручы "Азатлык" радиосы журналистлары Сания ханым Мирхалиева һәм Рузалия ханым Сайганова, "Умырзая" татар-башкорт фольклор ансамбленең алыштыргысыз җитәкчесе Гафия ханым Алиева, әле күптән түгел генә милли хәрәкәт эшенә килеп кергән һәм аның алыштыргысыз ярдәмчесенә әйләнгән эшмәкәр Тамир әфәнде Алимбаев, 80 яшенә җитсә дә, көне-төне милләт турында мәкаләләр язган һәм актив иҗтимагый тормыш алып барган Сания апа Анненкова, Тара шәһәреннән "Нур" татар үзәге җитәкчесе Илдар әфәнде Маматов һәм башкалар, һәм башкалар... Мин аларны һәрвакыт сагынып киләм, аларның һәрвакыт ярдәм итәселәрен беләм, үзем дә кулымнан килгәнчә һәрберсенә ярдәм итәргә тырышам.



*Тарада Айтикиннар тарафыннан ачылган мәктәп. Тубыл тарихи-архитектур музей-тыюлыгы фондларында саклана торган репродукциянең фото күчермәсе.*

Омскида узган гасырның урталарына кадәр Мулланур Вахитов исемендәге татар мәктәбе эшли, "Азат Себер", "Кызыл Шәрык яшьләре", "Сталин юлы" дигән татарча газеталар нәшер ителә, әмма соңрак барысы да юкка чыга. Милли җанланыш 1989 елда, "Умырзая" татар-башкорт фольклор ансамбле төзелгәч кенә башлана, алар үз тирәләренә татар өчен эшләргә әзер кешеләрне туплыйлар. Бары тик татар милли хәрәкәте көче белән бирегә 1989 елдан татарча радиотапшырулар яңгырый башлый, хәзер ул айга бер тапкыр 15 минут эфирга чыга. Омскида башта "Ватан" татар иҗтимагый оешмасы (1992 ел), ә инде 1998 елда өлкә татарларының милли-мәдәни мохтәрияте эшли башлый. Омск шәһәренең 1нче педагогия көллиятендә татар бүлеге ачылуны да милли хәрәкәтнең җиңүе дип карарга кирәк. 2003 елда татар эшмәкәре Тамир Алимбаев "Татар дөньясы" дип аталган газета чыгара башлый.

Шулай ук Россиядә беренчеләрдән булып бирегә татар галимнәре барлана һәм аларның оешмалары төзелә. Омски өлкәсендә 130 татар галиме барлыгы билгеле була, шулар арасында җитмештән артыгы академик һәм фән докторлары, профессорлар, фән кандидатлары булуын әйтеп китәргә кирәк. Шулай ук Омск татарлары арасында берничә генерал, зур хуҗалык җитәкчеләре, депутатлар, танылган эшмәкәрләр дә бар. Әйтик, тарих фәннәре докторы Эрнст Хаҗиәхмәтов, авыл хуҗалыгы фәннәре докторы Камил Азиев, химия фәннәре докторы Рево Сәгыйдуллин, архитектура фәннәре докторы Альберт Кәримов, армия генералы, техник фәннәр докторы Илһам Галиев, Омск тимер юлы башлыгы, генерал-лейтенант, өлкә советы депутаты Равил Бикбавов, генерал-майор Риал Мусин, Омск нефть эшкәртү заводы генераль директоры, өлкә советы депутаты Илдус Сәрвәров, танылган спортчылар, дөнья чемпионнары, нәфис гимнастика остасы Галимә Шөгерова, көрәшче Тимерҗан Кәлимуллин һәм башкалар, һәм башкалар...

Әмма бүгенге көндә бирегә татар милли хәрәкәтенең төп эше "Умырзая" ансамбле һәм "Татар дөньясы" газетасы тирәсендә генә бара, калган оешмалар

кайсы ябылган, кайсы ябылырга тора. Һәр җирдәгечә, милли хәрәкәт үзе дә икегә бүленгән, электкеге бердәмлек һәм рух юк, ә хакимият исә моннан бик оста файдалана, милли-сәяси таләпләр куйган оешмаларны берәм-берәм яба бара. Омскида узган шундый судларның берсендә мин дә катнаштым һәм алга таба бу хакта язармын, иншаллаһ!

Бу юлы да эшемне Омск дәүләт архивыннан башладым. Аһ, сез ул урыс архивларының кырыслыгын, шыксызлыгын, салкынлыгын белсәгез икән! Монда сүз бина салкынлыгы турында гына түгел, ә һәр сорап килүчегә, бигрәк тә читтән килгән башка милләт вәкилләренә карата сакчыл салкынлык турында да бара. Читтән килгән чит милләт кешесе директорның үзенә кереп гариза язмыйча бер кәгазь кисәге дә күрә алмый, ә түрә күп вакыт: "Сезгә нәрсәгә кирәк ул?"—дип сорый.

Монда да шулайрак булды, Омск дәүләт архивы директоры марҗа түтәй Габдрәшит Ибраһимовның кем икәнлеген белми дә, белергә дә теләми иде, әлбәттә. Ул барлык сорауларга да "юк" дип кенә җавап бирергә ярата булып чыкты. Мин Габдрәшит Ибраһимов турында ялкынланып сөйләп биргәч, ул тыныч кына: "Сез бит инде болай да аның турында бөтенесен беләсез, сезгә нәрсәгә кирәк ул архив материаллары?"—дип сорап куйды. Алай да мин шактый авырлыклар белән, кайбер таныш-белешләкләрне дә эшкә җигеп, Тара шәһәре буенча XIX гасыр уртасы метрика белешмәләрен кулыма төшерә алдым. Әмма гарәп хәрефләре белән чуарлап язылган бу мәчет кәгазьләре 1860-70 елларныкы булып чыкты, ә миңа Габдрәшит Ибраһимов туган 1857 ел кирәк иде! Тагы директорга киттем, ә ул: "Бездә күп метрика кәгазьләре, белгечләр булмау сәбәпле, эшкәртелмәгән, укылмаган, системага салынмаган килеш",—дип җавап бирде. Ягъни гарәпчә кульязмалар укый белүче булмаганга, Россиянең күп кенә архивларында, музейларда, китапханәләрдә татар тарихына караган документлар, белешмәләр эшкәртелмичә, әйләнешкә керә алмыйча ята, һәм шулай мәңге ятарга да мөмкин, берәрсе чыгарып атканчы. Югыйсә бу эшне урындагы мәчет һәм мәдрәсә хезмәткәрләре, Казан-Уфадагы дин, фән белгечләре ярдәмендә дә башкарып чыгарга мөмкин булыр иде бит. Монда кем инициатива күрсәтергә тиеш икән—архивлармы, татар галимнәреме, дин белгечләреме, әллә шуларны берләштергән берәр комиссияме?

Архивта тагы берничә фонд белән кызыксындым, әмма үземә кирәкне таба алмадым. Моннан 150 ел элек Тарада яшәүче татарлар турында үзем белгәннән артыгын табып булмады. Алай да өметемне бөтенләй өзмичә, Омскидагы таныш-белешләремә архивта ниндирәк материаллар эзләргә кирәклеген әйтеп калдырып, башка эшләремне эшли тордым. Чөнки чит җиргә килгәч, санаулы көн тиз уза, аны гел архивларда гына утырып уздырсаң, милләт белән очраша алмыйсың, халык белән очрашып йөрсәң, фәнни эзләнүләрне ахыргача җиткереп булмый. Алай да мин татарлар белән очрашуны да кирәк санадым.

Беренче очрашуым Кызыл гвардиячеләр Мәдәният сараенда булды. Мин милләттәшләремә "Күчем хан" романының язылу тарихын сөйләдем, "Татар дөньясы" газетасына һәм аерым активистларга китабымны бүләк иттем. Шулай ук Габдрәшит Ибраһимовның "Дәүре галәм" китабы, авторның үзе турында да җыелган халыкка мәгълүмат бирдем. Әлбәттә, Күчем хан турында да, Габдрәшит Ибраһимов турында да сораулар күп булды, чөнки себер татарларының бу ике бөек шәхесе күпләрне кызыксындыра, алар турында татар телендә дөрес мәгълүмат әле чыга гына башлаган иде.

Әйткәнемчә, Омск шәһәрендә миңа тагы бер мөһим чарада—мәхкәмәдә катнашырга туры килде. Эш шунда, Омск өлкәсенең татар милли-мәдәни мохтариятен, уставына үзгәрешләр кертмәде, вакытында хисап тотмады дип, теркәүче оешма судка биргән һәм аның җитәкчесе Хәким Садыйков безне дә шул процесста катнашырга чакырды. Хөкүмәт шулай бит ул—татар оешмаларына үзе берни белән ярдәм итми, ә хисапны сорый! Берничә ел элек махсус яндырылып һәм су бастырып, бинасыз урамда калдырылган татар автономиясе ни турыда хисап бирсен аларга? "66 татар авылының өчтән берендә генә татар теле атнага бер сәгать укытыла, Омскида һәм Тарада бер татар мәктәбе юк, телевидениедән татарча тапшырулар юк, татар авылларына юл юк, газ юк, эш юк, дәүләт бу мәсьәләдә татарларга берниндн ярдәм күрсәтми",—дисенме? Әлбәттә, үзе дә профессиясе буенча адвокат-юрист булган Хәким әфәнде судта

бу турында сөйләмәде, әмма мин боларны судьяның исенә төшерергә мәҗбүр булдым, татар оешмаларына башта эшләү өчен шартлар тудырырга, аннан соң гына сорарга кирәклеген әйттем. Татар автономиясен яклап, галимнәр Линнур Шөгеров, Михаил Савиных, журналист Сания апа Анненкова да чыгыш ясадылар, нәтиҗәдә суд Омск өлкәсенең татар милли-мәдәни мохтариятен япмады, эшне кичектереп торды.

Омскида архивта һәм судларда эшемне бетергәннән соң, халык белән очрашып, китапларымны тапшырганнан соң, кышкы салкын иртәдә маршрут "Газел"енә утырып, 300 чакрым ераклыктагы Тара шәһәренә юл тоттым. Икенче шундый ук очрашуым "Нур" татар үзәгендә булды, шәһәргә татар язучылары бөтенләй килмәгәнгә, халык һәр сүземне йотып, сеңдереп утырды. Мин үзем дә Тара татарларын аеруча яратам, әллә Габдрәшит Ибраһимов монда туганга, бу шәһәр миңа аеруча якын, үзенә тартып тора. Тара хәрби кәлгәсе урыслар тарафыннан 1594 елда, Күчем хан идарәсен юк итү өчен төзелгән, дип язсалар да, бу урында татар каласы инде Күчем хан заманында ук була һәм ул "Ялым-Тора", дип атала. Иртыш буенда, карагай-эрбет урманнары уртасында утырган бу шәһәр өчен сугышлар озак бара, аны урыслар алгач та, татарлар дистә еллар буе Тараны тынычлыкта калдырмыйлар. Шуңа күрәме, иң көчле чукындырулар да, иң көчле мөселманнар да бу якларда була, ике дин, ике көч кара урманнар уртасында исән калу өчен соңгы көрәшкә керә...

Урыслар яулап алганнан соң да, Тара каласы барыбер өлешчә татарныкы да булып кала, чөнки монда урыс воеводаларына ияреп Тараны алырга килгән берничә йөз йомышлы Казан, Уфа, Касыйм татарлары да яши. Әмма башка татарларны кертергә куркалар, Күчем хан нәселе шәһәрне яңадан үз кулларына алыр дип шикләнәләр. Бу хакта танылган тарихчы Г. Миллер менә нәрсә яза: "...татар тутошных волостей побаивались и выполняли приказ: "в город не пущать, покамест город укрепится, чтобы им людей государственных не смечать". *(Миллер Г. Ф. История Сибири. Т. 1. М.-Л. ([937, с. 355.)* Әмма себер татарлары Тараны барыбер тынычлыкта калдырмыйлар, күп тапкырлар аңа һөҗүм итәләр. Күчем хан үзе дә Тара тирәсендә алган яраларыннан үлә, ул үлгәч тә аның уллары Тараны яңадан кире кайтару өчен көрәшәләр. Шундый каты сугышларның берсе 1626 елда була, ул чорда бөтен Бараба татарлары Россия подданствосыннан баш тарталар, урысларга каршы көрәш башлыйлар.

Тарихи белешмәләрдән күренгәнчә, Тара каласында 1622 елда килгән йомышлы татарлардан тыш, кәлгәдән тышта, тау асты бистәсендә җирле 21 бохарлы яшәгән. Ә бохарлылар—Күчем хан чакыруы буенча Себергә килгән иң укмышлы, иң булдыклы, иң тәкъва мөселманнар булганнар. Габдрәшит Ибраһимовның бабалары да 1572 елда Үргәнеч-Бохара якларыннан Себергә ислам дине таратырга килгән мөселманнар була, алар Тара тирәсендә дүрт авылда урнашып яши башлыйлар. Шуларның берсенә алга таба тукталырбыз, иншаллаһ! 1669 елның 8 сентябрендә Тарада моңа кадәр күрелмәгән көчле янгын була һәм шәһәрнең күп өлешен юк итә. Тарихи белешмәләрдән күренгәнчә, янгын вакытында хәрби кирмәндә—380, шәһәрнең тау асты бистәсендә 65 урыс өе, 163 татар йорты янып юкка чыга. XVII гасыр уртасында урыс шәһәре дип аталган Тарада шул хәтле күп татар өйләренең булуы милләтебезнең монда беркайчан да бетмәгәнлеген күрсәтә.

1704 елда Тарада мәдрәсә ачыла, мәдрәсә булгач, димәк, янында мәчете дә булган дигән сүз. 1763 елгы халык санын алу нәтиҗәләреннән күренгәнчә, шәһәрдә 105 бохарлы, 28 искедән калган татар яшәгәнлеге билгеле була. "1784 ел безнең Тара каласында Габдрәшит баба ахун буларак сайланган. 1790 елда Габдрәшит ахун Эрбет ярминкәсенә барып, Тара каласында мәсҗед бинасы өчен акча җыйган",—дип яза Габдрәшит Ибраһимов ул еллар хакында үзенең "Тәрҗемәи хәлем" дигән хезмәтендә. *(Габдрәшит Ибраһимов. Дәүре галәм. Тәрҗемәи хәлем.—Казан, 2001, 133 б.)* 1793 елда исә бохарлы бай Айтикиннар да ярдәме белән Тарада таш мәчет төзелә, аның түбәсе соңрак калайдан ябыла, бу шәһәрдә беренче таш бина була, анда Габдрәшит Ибраһимовның бабалары имамлык итә. Дөрес, урыс тарихчылары Тарада беренче таш бинаны урыс бае Нерпин 1796 елда салган дип язалар, әмма бу дөреслеккә туры килми. Төбәкне өйрәнүче Анатолий Юрьевның 2005 елны Омскида басылып чыккан "Тара. Годы. События. Люди" дип аталган китабының 30нчы битендә рәттән шундый

мәгълүмат бирелгән: "1793 год. В Таре построена мусульманская мечеть. Тарские бухарцы Айтыкины внесли значительную сумму на ее строительство", диелгән һәм: "1794-96 гг., В Таре возводится первое каменное здание крытый железом трехэтажный каменный дом купца И. Ф. Нерпина", дип язылган. Ә Габдрәшит Ибраһимов үзе бу хакта болай дип яза:

"1793 елда Аялыдан Сәид баба белән бохарилардан Габдрәшит ахун берлектә Тара каласында хәзерге вакытта булган таш мәсҗедне бина кылганнар. Габдрәшит ахун вафатыннан соң углы Ибраһим бай мәсҗедкә мөтәвәлли (мәчет, мәдрәсә эшләрен башкаручы кеше) булган, бу кеше безнең дәү әтиебез, хәзерге фамилиябез бу кешегә бирелгәндер." *(Күрсәтелгән хезмәт, 134 б.)* 1831 елда Тарада тагы бер мәчет төзелә, аның каршында 30 шәкертлек мәдрәсә-мәктәп ачыла, соңыннан Габдрәшит Ибраһимов шул мәчеттә 7 ел имам вазифасын үти һәм мәдрәсәдә мөгаллимлек итә. Күрәсез, Габдрәшит Ибраһимовның җиде буын бабалары да дин әһелләре, ахуннар, имам-мөдәррисләр, шәехләр һәм сәедләр булган. Әйткәнебезчә, башта алар Ахун фамилиясен йөрткәләр, аннан, буталмас өчен, Ибраһимов фамилиясенә күчәләр. Кыскасы, бөтен Тара шәһәре мөселманнары, тирә-яктагы татар авыллары халкы берничә гасыр буе шушы нәселдән белем ала, гыйлем туплый, Коръән өйрәнә, нәтиҗәдә, көчләп чукындыру заманында да иманда кала.

Габдрәшит Ибраһимовның нәселе Тара шәһәре татарлары тарихында якты эз калдыра, әмма бүгенге тормышта бу эзләрне табып булмый. Узган килешемдә үк инде Тараның бөтен архивларыннан, музей-китапханәләреннән ул эзләрне эзләдем, әмма тапмадым, әйтерсең лә бу затлы нәсел шәһәрдә яшәмәгән һәм милләткә хезмәт итмәгән! Аннан Таранын иң карт кешеләре янына киттем, әмма 90 яшьлек Әсгать абый Вәлиев тә, 92 яшьлек Сафия апа да ул заманнарны хәтерләмиләр иде инде. Габдрәшит Ибраһимов эшләгән мәчет сүтеп ташланган, ул яшәгән йорт юк ителгән, ата-аналары күмелгән зират көтүлек урынына әйләнгән иде... һәм беркем берни хәтерләми, белми...

Дөрес, моннан ун еллар элек Тара шәһәрендә яңа мәчет ачыла, "Нур" татар үзәге эшли башлый, ансамбльләр оештырыла, сабантуйлар уздырыла. Халыкта әкренләп милли үзаң уяна башлый. Очрашу вакытында күрдем—Тара шәһәрендә татар тарихы белән кызыксынучылар шактый иде, алар рәсми тарихта татарларга карата күп ялган барлыгын сизәләр, әмма дөреслекнең кайда икәнлеген белмиләр. Югыйсә, татар тарихының өстендә, түрендә утыралар бит алар, иң борынгы кешеләр яшәгән җирләрдә, бу якларда беренче булып ислам дине кергән урыннарда, Күчем ханның законлы биләмәләрендә яшиләр! Шуңа күрә, мин килгән саен аларга тарихны дөрес чагылдырган китаплар алып килергә тырышам, Омскида яшәүче милләттәшләребез дә онытмый, иң яхшы китаплардан өлеш чыгарып тора. Тарада яшәүче 2 мең милләттәшебез өчен бүгенгесе көндә "Нур" татар үзәге һәм мәчет төп аралашу урыны булып тора.

Ә инде Габдрәшит Ибраһимовның исемен яңадан туган якларына кайтару мәсьәләсенә килгәндә, монда беркемнән дә ярдәм көтеп тормыйча, үзебезгә хәрәкәтләнергә кирәк. Мин узган ел Омск өлкәсенә килеп киткәннән соң, Габдрәшит Ибраһимов турында Омск, Төмән, Казан матбугатында татар телендә берничә язмам басылып чыккан иде. һәм, ниһаять, шушыларга нигезләнеп, Габдрәшит Ибраһимов турында язмалар урыс телендә дә чыга башлады. Әйтик, Тара шәһәре газетасында "Нур" татар үзәге җитәкчесе Илдар Маматовның язмасы, "Труд" газетасының Омск кушымтасында Татьяна Бурундукованың "Японский тарчанин" мәкаләсе күренекле милләттәшебез Габдрәшит Ибраһимов турында башка халыкларга да бай мәгълүмат бирә. "Благодаря подвижничеству Ибрагимова, в 1939 году парламент Японии официально признал ислам—материалы о тюркских народах, мусульманской вере были включены в учебные программы, много японцев приняли ислам",—дип яза күп миллион тиражлы урыс газетасы. *("Труд", 2007, 13 июнь.)* Минем моңа сөенечем иксез-чиксез булды! Димәк, үзебез хәрәкәт итсәк, без теләсә нинди чолганыштан чыга алабыз икән, шул исәптән, мәгълүмати блокададан да! Тара татарлары хәзер Габдрәшит Ибраһимовның кемлеген белә, бирердә яшәүче рус интеллигенциясе дә инде бераз хәбәрдар, димәк, киләчәктә бу шәһәрдә аның музеен ачу да, берәр урамга Габдрәшит Ибраһимов исемен бирү дә инде җиңелрәк булачак, иншаллаһ!

Менә шулай урыслы-татарлы булып яшәп ята бүгенге Тара каласы. Татарлар

күбрәк шәһәрнең тау асты бистәсендә, үз өйләре белән яшиләр, каланың иске өлешендә дә ике катлы борынгы агач өйләр шактый, алар мең елда да череми торган карагайлардан салынган. Бу тирәләрдә нефть тапканнан соң, шәһәр бераз терпәкләнеп киткән, яхшы архив, китапханә, театр, Боз сарайлары салып куйганнар. Музейларда урыс тарихы кадерләп саклана, биредә сөргендә булган данлыклы шәхесләрне, Тараны өйрәнгән тарихчыларны исемләп беләләр. Ул елларда Тараның, гомумән, сөрген үзәгенә әйләнгәнлеген дә әйтеп үтәргә кирәк, бирегә патша режимына каршы булган декабристларны да, милли азчылык хокукларын даулаган еврей һәм полякларны да сөргәннәр. Әйтик, әле 1620 елда ук Мәскәү князе Афанасий Лобанов-Ростовский Тарага сөргенгә җибәрелә, 1730-31 елларда бирегә тагы 150 тоткынны китерәләр, 1791 елда—Александр Радищев, 1827 елда декабристлар Николай Басаргин, Фердинанд Вольф, Михаил Фонвизин, 1828 елдан 1845 елга кадәр декабрист, полковник Флегонт Башмаков, 1831дә Кавказның элеккеге вице-губернаторы Осип-Юльян Горский/ Граве/, 1841 елда декабрист, барон Владимир Штейнгель, 1846 да каторжник Руфим Пиотровский, 1850 елда язучылар Федор Достоевский һәм С. Дуров, 1877-1880 елларда сәяси тоткыннар Иван Баринов, Вера Любатович, Виктор Осташкин, Степан Зарубаев, Анна Комаровская, Никон Волянский, шул елларда ук революционер һәм тарихчы-галим С. П. Шевцов, йөзләгән баш күтәрүчеләр Тарада сөрген срогын үтәләр. Хәзер аларның исемнәрен Тараның урамнары йөртә, ә шушында туып-үскән, халыкка мәгърифәт нуры тараткан Габдрәшит Ибраһимовның үзенең дә, җиде буын ахун нәселе булган бабаларының да биредә исемнәре билгесез. Шулай ук Габдрәшит Ибраһимовның замандашы, шәһәргә зур ярдәмнәр күрсәткән, 1 гильдияле купец, сәүдә белән Кытай, һиндстаннарга хәтле барып җиткән Абдулла Айтикинның һәм аның нәселенең дә биредә эзе дә юк...

Тара үзенең данлыклы тоткыннары белән генә түгел, аны өйрәнгән танылган галим-тарихчылары белән дә билгеле. Әйтик, 1696-1701 елларда биредә танылган тарихчы, картограф Семен Ремезов Тара шәһәренең сызымнарын эшли, 1717 елда геодизистлар экспедициясеннән Иван Евреинов һәм Федор Лужин булалар, 1721дә Петр патша кушуы буенча Себерне өйрәнүче галим Данила Готлиб Мессершмидт Тарада булып китә, 1725 елда—данлыклы Витус Беринг һәм аның юлдашлары, 1733-34 еларда шул экспедиция әгъзалары Г. Миллер, И. Гмелин, Г. Стеллер, И. Фишер, С. Крашенников Тарада булалар, ә Герард Миллер исә архивта документларның копияләрен дә ала. Моннан тыш Тара шәһәрендә 1768 елда академик Фальк, 1771 дә күренекле галим Петр Паллас булалар, 1828 елда исә бөтен Себер, Котып, Камчатканы өйрәнүче сәяхәтче-галимнәр Гумбольд, Гельмерсон, Миддендорф, Эрман, Розе, Эренбург Тарада тукталалар. Кыскасы, урман-дала чикләрендә утырган урыс-татар Тарасы белән бик күпләр кызыксына, Себергә килүче тарихчы-галимнәр берсе дә Тарага кермичә калмый. Ә 1891 елда исә Тара халкы пристаньда булачак патшаны—Николай II не дә каршы ала, аның Иртыш буйлап пароходта сәяхәт иткән чагы була.

Соңгы чорда да Тара шәһәре илгә күп кенә фән эшлеклеләрен, мәдәният хезмәткәрләрен бирде, шулар арасында иң танылганнары—сәясәтче Сергей Бабурин һәм артист Михаил Ульяновтыр, мөгаен. Дөрес, Михаил Ульяновны инде башка урынга күчереп, юк ителгән татар авылы Бергамакныкы дип әйтәләр, әмма Тара халкы аны үз якташы дип исәпли. Танылган таралылар арасында безнең милләттәшләребез дә шактый, әйтик, фән кандидатлары Рәисә Кәримова, Әлфирә Кармышакова, Әнвәр Сайтбагин, Ракия Тимомеева, Роза Шахмарова, Линнур Шөгеров, рәссам Эдуард Муратов, шагыйрә-башкаручы Фәрзәнә Кулеева һәм башкаларны санарга була.

Мин бу юлы да Тарадан рухи яктан баеп, яңа танышлар табып, алга таба яңа планнар корып киттем. Яңа танышларым Рәүф һәм Йөзлебикә Иноятовлар, яшь галимә Роза Шахмарова, үзешчән тарихчы Равил әфәнде Беркутов, төбәкне өйрәнүче, берничә китап авторы, урыс кешесе Анатолий Ионович Юрьев, иске танышларым Илдар Маматов, Вагыйз әфәнде һәм Сания апа Садыйковлар, Али һәм Люция Колдашевлар һәм очрашуга килгән бик күп милләттәшләрем мине яңадан Тара шәһәренә чакырып калдылар. Алда мине Габдрәшит Ибраһимов мәдрәсәдә укыган Уыш авылы көтә иде...

*Ахыры киләсе санда*

*Роберт Миңнуллинга 60 яшь*

## УЛ ДА БИРӘҮ ГЕНӘ...

Гастрольләрдән йөреп кайтуга мине: "Уфада Роберт абыйның иҗат кичәсе булды. Шундый яхшы узды инде. Кызганыч, күрми калдың..."—дип каршылыйлар. Илешкә кайтсаң: "Роберт Миңнуллин бөтен татар-башкорт эстрада йолдызларын җыеп Сабантуй уздырды. Мондый нәрсәнең беркайчан да булганы юк иде әле!"—дип сокланалар. Авылга кайтсаң, әни-карчык сөйли: "Телевизордан Роберт абыеңны күрсәттеләр. Бер шигырен укыды. Вәт язып та караган, ичмасам!" Радионы ачсаң, тагын шул ук Роберт Миңнуллин.

Йә нәниләр аның шигырьләрен укый, йә аның сүзләренә язылган җыр янгырый. Китап кибетенә керсәң дә—Роберт Миңнуллин. Публицистик әсәрләре, шигырьләре, кечкенәләр өчен китаплары... Юньлерәк җырчының концертын карыйм әле дип, Салаватның видео-язмасын алып кайтсаң, аннан да Роберт Миңнуллин килеп чыга...

"Бу Робертка һаман җитми микәнни, ник барсына да катыша ул, ник әллә нәрсәләр оештыра, ник һаман нәрсәдер эшли?!."—дип көрсенүчеләр дә юк түгелдер. Аларны да аңлап була. Чөнки аларның күзенә соңгы нәтиҗәләр, уңышлар гына күренә, һәм ул уңышлар үзеннән-үзе килгәндер, язмышның бүләгедер кебек тоела. Кызыктыра, бераз көнләштерә дә. Ә шушы нәтиҗәләргә китергән йокысыз төннәр, ал-ялсыз көннәр, күңелнең өзелергә җитеп тартылган кыллары Иҗатчының үзеннән һәм якыннарыннан башка беркемгә дә күренми. Күренергә тиеш тә түгелдер.

Мин якташым, Сөндәшем, өлкән каләмдәшем Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллинның тынгысызлыгына, талантына сокланып яшим. Чөнки шагыйрь кеше өчен Казаннан килеп Башкортстанда иҗат кичәләре, концертлар, сабантуйлар оештыруның нәрсә икәнен мин яхшы беләм. Сүз сәясәт турында бармый. Сәнгатьнең үз кануннары. Гомумән, башка республикада иҗат кичәңне оештыру җиңел нәрсә түгел, ул шәхес буларак та, иҗатчы буларак та зурлыгыңны таләп итә. Һич югында, синең кем икәненне белергә тиешләр. Ә аны беләләр. Өстәвенә, яраталар да.

Язучы популяр булырга тиеш! Бу аның үзеннән дә бигрәк, иҗаты, укучылары өчен кирәк. Язучының популярлыгы ул әдәбиятның киңрәк танылуы, дигән сүз. Ә әдәбият—мәдәниятнең нигезе.

Татарда, әлбәттә, бер генә Роберт Миңнуллин бар. Әйе, ул бөтен җиргә дә өлгерергә тырыша. Әйе, аның вазифалары да күп. Әйе, ул соклангыч лирик та, ялкынлы публицист та, менә дигән юморист та, искиткеч балалар язучысы да...

Һәм ул бирәү генә...

***

Роберт Миңнуллинның балалар өчен язылган шигырьләре турында уйласам, бер күренеш күз алдына баса.

...Улымның бәләкәй чагы. Күпчелек шәһәр балалары шикелле үк, аның да татар язучыларына артык исе китми. Шулай да үз иткән бер китабы бар. Мәктәптән шигырь ятларга кушып кайтарсалар да, бәрәр бәйрәмдә чыгыш ясарга кирәк булганда да гел шуңа ябыша. Беркем берни кушмаган чакларда да шул китапны еш кулына ала. Әле дә шуны актарып утыра. Бу юлы Сабантуйга багышланган шигырь ятларга кушканнар. Ул бертын шулай тавыш-тынсыз утыра да сикереп торып баса:

—Уйнарга чыксам буламы инде?—Һәм әнисенең ни әйтергә чамалавын тоеп, өстәп куя.—Шигырь әзер ул. Сөйләп күрсәтимме?!

Әнисе "йә, сөйләп кара әле" дигәнне аңлатып, баш кага. Малай тамагын кырып ала да шигырь укырга тотына:

*—Колга тора мәйданда,*
*Биегрәк айдан да.*
*Әтәч колга башында,*
*Кызыктыра барсын да...*

Үз баланның булдыклылыгын күрү рәхәт, әлбәттә. Шигырьне малай ничава гына укый. Һәм мин әлеге әсәрнен үземнеке түгеллегенә аз гына "кытыкланып" та куям. Югыйсә мин дә шагыйрьләрнең иң начары түгел бит инде. Минекен укыса да булыр иде.

Нәрсәсе бар соң бу шигырьләрнең шул кадәр үзенә тартып торырлык?!.

...Минем инде мондый күренешкә беренче тапкыр гына гаҗәпләнүем түгел. Элегрәк, үзем язганны үз улым авызыннан ишетергә теләп, тапкырлау таблицасын да "шигырьләштереп" биргән идем. Малай күз генә йөгертеп чыкты да:

—Ярый, әти... Мин лутчы тапкырлау таблицасын гына ятлармын инде,—дип елмайды.

—Нәрсә, ошамадымы әллә?

—Кызык кына килеп чыккан...—Ул, мут күзләрен түбән кадап, бераз тынып торды.—Син тагын телевидение программасын да шигырьгә әйләндереп кара...

Нишлисең инде... Роберт Миннуллинның үз сүзләрен бераз үзгәртебрәк әйтсәк: "Баланы ахмакка санау—зур ахмаклык. Кайчан нәрсә укырга икәнен, кемне укырга икәнен үзе белә ул. Күңеле нәрсә тели—шуны укый. Аны җаны теләмәгән әсәрне укырга берничек тә мәҗбүр итә алмыйсың".

Ә малай укый. Шушы шагыйрьнең әсәрләрен яратып укуына инде күнегелә төшкән. Күңелне кытыклатып алган шайтан да шундук юкка чыга. Бер карасаң, әлләни шайтанлыгы да юк инде аның. Әлеге шигырьләрнең үзенә тартып торучы тылсымлы серен беләсе килү теләге генә ул. Һәм белә алмый интегү ачысы гына...

*Менә миңа да чират.*
*Менәм. Мин дә бит ир-ат!*

Кинәт әлеге сер пәрдәсенең бер як чите ачылып киткәндәй була. Бер мизгел эчендә генә. Мин үзем өчен нәрсәдер ачыклагандай булам. Тик аның нәрсә икәнен генә аңлап җитми калам... Һәм инде ничәнче кабат үземә бер үк сорауны бирәм:

—Нәрсәсе белән шул тиклем үзенә тарта соң бу шигырьләр?

Начар язганнарны укуы кыен, әмма язмаларына карата мөнәсәбәтеңне белдерү җиңел. Өч сүз дә җитә... Ә чын шагыйрьләрне ләззәтләнеп укыйсың, яратасың, ләкин ни өчен яратуыңны аңлата алмыйсың, кайчак үзең дә аңлап җиткермисең. Бары тик яратасың гына. Шуңа да алар иҗатын бәяләү бик җиңел нәрсә түгел...

Мондый сорау белән баш ватучылар бер мин генә түгел икән. Әзһәр Габиди әле 1978 елда ук болай дип язган: "Бу шигырьне укып чыккач, аның нәрсәседер борчыган да, уйландырган да, үз җылысы белән тартып торган да сыман булып китә. Башта шагыйрьне күзенә күренгән һәр күренештән шигырь ясарга тырышуда, ясалмалылыкта гаепләп куясың. Гаеплисең, ләкин моңа үзең ышанып бетмисең. Димәк, анда сине тартып торган нәрсәдер бар..."

Нәрсәдер бар...

Бу "нәрсәдер"не, бәлки, төгәл генә билгеләп тә булмыйдыр.

Шигырьләрне кабаттан барлап чыккач:"Аларда балачак бар!"—дип әйтәсе килә. Һәм бу дөрес тә. Һәр шигырьдә самимилек, сабыйларча шуклык, беркатлылык, тынгысызлык, бөтен нәрсә белән танышырга, һәр күренешкә үз бәяңне бирергә омтылу, шул рәвешле үзеңнең зур кеше икәнеңне расларга тырышу ярылып ята. Вакыты белән әлеге күренеш өлкәннәрне ирештерүгә кадәр барып җитә. "Безнең өйнең краны" шигыре менә ничегрәк яңгырый:

*Краннан су тамып тора,*
*Күп очракта агып тора.*

*Әнием и борган була,*
*И булыштырган була.*

Без бит балалар белән ниндидер төчерәк телдә сөйләшәбез:" Бәләкәчем минем, бәү-бәү итәсеңме? ...мәм-мәм ашыйсыңмы? ...печ итеп киләсенме?"—шул рәвешлерәк. Ә бу шигырьдә бала нәкъ менә шуның киресен эшли, үзенең зур икәнлеген исбатлау ниятеннәндер, өлкәннәр теле белән сөйли...

Һәм шушы җөмләдә аның өлкәннәргә булган яратуы да, аларның тормышыннан киная белән көлү дә, үзенә сабый итеп карауга канәгатьсезлек тә чагылып китә. Бу күренеш кайчак яшертен, ә кайчак ачыктан-ачык төсмерләнә:

*Зурлар безгә тапшыру да,*
*Кино да каратмыйлар.*
*—Ярамый да ярамый!—дип,*
*Көн саен кабатлыйлар.*
*—Кинолар кичен,—диләр,—*
*Өлкәннәр өчен!—диләр.*

Бала һәрчак бала булып кала. Ул ихлас. Үзен борчыган, сокландырган, игътибарын җәлеп иткән һәрбер нәрсә хакында уй-кичерешләрен җиткереп бара. Беркемнән дә, бернәрсәдән дә кыенсынмыйча. Ул хәтта көлкегә калудан да курыкмый. Чөнки үзен яратканнарын, гафу итәчәкләрен белә. Шигырьләр аша безгә мәхәббәтле гаиләдә үскән сөекле һәм сөйкемле бала карап тора сыман. Лирик геройның хөр күңеллелеге, шуклыгы, ә вакыты белән бераз иркәләнебрәк, очыныбрак китүе дә шуннандыр.

_"Шигырьләрдә балачак бар",—дию генә җитми. Бу шигырьләрдә БӘХЕТЛЕ БАЛАЧАК бар. Һәм балаларның аңа тартылуы бик тә табигый.

Югарыда китерелгән шигырь "Ә үзләре..." дип атала һәм болай тәмамлана:

*Әгәр дә карый башласаң,*
*Безгә бармак яныйлар...*
*Безгә дигән мультфильмны*
*Үзләре бик карыйлар!*

Бу шигырьдәге малай тагын шелтәләр инде, әмма Роберт Миннуллинның балалар өчен язылган шигырьләрен мин дә бик яратып укыйм. Кабат-кабат. Шигырьләр, әлбәттә, үзгәрми, әмма укыган саен әдәбият та, тормыш та яңа ягы белән ачылган кебек була. Бер караганда, мин ул әсәрләрдә үземнең малай чагымны күрәм. Балачакның самими шуклыкларын, ә кайвакыт миңа бик тәтеми узып киткән ямьле якларын сагынам. Ә күпчелектә, улларымның кечкенә вакытын күз алдыма китерәм. Шигырьләр нәкъ менә алар турында язылгандыр кебек тоела. Кайберләрендә аларның сүзләре турыдан-туры яңгырап киткәндәй була: "Энекәш кирәк миңа", "Юк инде", "Күчтек яңа фатирга", "Мин кунак яратам" һ.б... Шигырьләрне укыган саен балаларыңның күңелен ныграк аңлагандай буласың. Аларның бәләкәй чагын уйлап: "Ярый шулай эшләгәнмен әле!"—дип сөенәсең, яки узган хаталарыңны хәтерләп үкенәсең. Янә бер мисал:

*Белмиләр лә хәлләремне! -*
*Хәлләрем начар минем.*
*Пианино булсам, күптән*
*Бу өйдән качар идем.*
*Их, качсын иде,*
*Барыбер,*

*Уйный алмам мин аны...*
*Әни мине интектерә,*
*Ә мин... пианиноны.*

Менә мондый әсәрләр “балалар әдәбияты” дигән терминның шартлылыгын күрсәтә шикелле. Сабыйның психологиясен, кичерешләрен ачык күрсәткән халдә, бу әсәр, балалардан бигрәк, әти-әниләрне тәрбияли. Балаларны өлкәннәрнең хата карашыннан яклый ул. Шуна да балаларны да, өлкәннәрне дә үзенә тартып торадыр.

Роберт Миңнуллинның нәниләр өчен иҗат ителгән әсәрләре турында уйлаганда, үз балаларымның бәләкәй чагын искә алуым бер дә юктан гына түгелдер. Әдипнең балалар өчен язылган шигырьләре сабыйлар тормышын бөтен тулылыгында чагылдыра, аларның йөрәк тибешен тоярга мәҗбүр итә. Бу җәһәттән, алар һәрбер ата-анага бала күңелен аңлау өчен ачкыч, тәрбия әсбабы булырлык. Бәлки, аларны “балалар һәм ата-аналар әдәбияты” дип атау дөресрәктер дә әле.

* * *

Балалар өчен язылган шигырьләре өлкәннәргә кызык булган кебек үк, Роберт Миңнуллинның лирик, юмористик шигырьләре балаларга, үсмерләргә дә кызыклыдыр. Борынына ис кергән, күңелендә мәхәббәт бөреләнгән яшь-җилкенчәк турында әйтеп тә тормыйм инде.

*Синең серле карашыңнан*
*Бар уйларым тарала.*
*Әллә ниләр уйлап алам*
*Син караган арада,*

кебек юллар нинди генә яшь йөрәкне битараф калдырыр икән?!. Хәер, керсез-саф мәхәббәт турындагы шигырьләр бәләкәй чагында да укыла, аңлашыла алар. Һәр солдат кесәсендә генерал погоны яткан кебек, һәр бала күңелендә зур булып үсү хыялы һәм мәхәббәткә омтылыш яши.

*Күп тапкырлар тырышсаң,*
*Һәм тырышсаң тагы бер,*
*Теләгеңә беркөнне*
*Ирешәсең барыбер!*

Ә Роберт Миңнуллинның мәхәббәт шигырьләре—саф та, ягымлы да. Алар кайсы ягы беләндер назлы җилне хәтерләтә. Шигъри сөйләме җил кебек йөгерек—бер җирендә дә абынып-сөрлегеп тормассың. Укыганда да алар кемдер язган шигырь булып түгел, ә табигый рәвештә үзеңдә туып, үзеңдә яшәгән уйлар-кичерешләр агышы булып тоела. Табигый моң.

*Син минем җанымны*
*Газаптан арындыр!*
*Син минем беренче*
*Һәм соңгы ярымдыр.*

Ул моң ургылып та, ташып та түгел, ә сабыр гына саркылып чыга. Аны тыептуктатып та, ашыктырып та булмый. Кирәкми дә. Ул шул килеш тә дулкынландыра, ә үз янындагы әрнүләр белән кавышканда хәтта елата да ала. Елатса да, юатса да бу моң яраламый. Киресенчә, ягымлы бер дулкын булып җаныңны назлап уза, авыр тойгыларыңны оныттыра. Шул рәвешле сиздермичә генә, сине авыр уйлардан тартып алып, яктылыкка алып чыга.

*Кайтыйм гына, онытырсың*
*Күз яшьләреңнең барсын.*

*Моңсуланып озатсаң да*
*Елмаеп каршыларсың.*

Бу сыйфат мәхәббәт лирикасына гына түгел, аның бөтен иҗатына кагыладыр. Миңа калса, Роберт Миңнуллинның шигырьләрен кычкырып, яки трибунадан йодрык болгап укып булмый. Алар табигый үз тавышың белән укый торган шигырьләр. Сөйләшеп утыргандагы кебек. Алар шул килеш тә ерак ишетелә. Табип кулыдай сак, дипломат сүзедәй итагатьле:

*Язганнар язды бездә дә,*
*Менә дигән итеп,*
*Әйбәт заманнар килгәнне*
*Ятмадылар көтеп.*

Шул ук вакытта, табип кулыдай тәвәккәл, дипломат сүзедәй үтемле, кире каккысыз:

*"Шигырьләрең бармый",—диеп,*
*Хәзер беркем бормый.*
*Шәп шигырьләр язу җиңел -*
*Язып кына булмый.*

"Язганнар язды бездә дә" дип аталган бу шигырьне укыгач, елмаеп та куясың. Мондый әсәрләренең күплеген искә алсаң, авторны "кызык шагыйрьләр" рәтенә кертергә дә мөмкин кебек. Әмма шигырьдә сүз нәрсә хакында барганын уйласаң, бер дә елмаясы килми. Елмаерга җәелгән авызың шундук җыела, һәм шагыйрь күңелендәге әрнүләрне үз җаныңда кичерергә мәҗбүр буласың. Ә шушы шигырь тәэсирендә әдәбиятыбызның бүгенгесе, киләчәге хакында чиксез уйлануларга бирелергә дә, озаклап бәхәсләр корырга да мөмкин. Бу бүгенге шигъриятькә куелган диагноз шикелле яңгырый...

Монда шагыйрьнең тагын бер үзенчәлеге күренә—ул иң әрнүле проблемалар турында да якты каләм белән яза. Шигырь юлларында хәтта моңсу елмаюы да чагылып киткәндәй була. Бу җәһәттән, Роберт Миңнуллин шигърияте миңа кайсыдыр ягы белән Хәсән Туфан лирикасын хәтерләтә, аның дәвамы булып тоела. Шундый ук моңсу яктылык, шундый ук тыенкы әрнү... Юк, зарлану да, үрсәләнү дә түгел бу, ә күз яшьләре кебек үзлегеннән саркылып чыга торган бер моң:

*Була авыр халәтләрем,*
*Сәгатьләрем, көннәрем.*
*Андый көннәрдә дөньяның*
*Тиргим әллә кемнәрен.*

Җыр язучы композиторларның күбесенчә нәкъ менә Роберт Миңнуллин әсәрләренә мөрәҗәгать итүенең сере дә шул мондадыр. Көй язганчы ук җырлап тора торган шигырьләрне кемнең генә кулдан ычкындырасы килсен инде?!

Бүген, әлбәттә, көй чыгаручылар да, җырлаучылар да күп. Санап бетергесез. Җырлау рәвешләре дә, талантлары да, популярлыклары да төрле-төрле. Булсын, күпсенмик. Хәтердә калырдайлары халык күңелендә яшәр, калмастайлары онытылыр. Сүз башка нәрсә турында. Шушы ничәшәр йөз җырчының бүген яртысын себереп түксәң дә, татар эстрадасы берни сизмәячәк, бернинди югалту кичермәячәк. Әмма шушы җыр сәнгатеннән бер Роберт Миңнуллин иҗатын алып ташласаң... Күз алдына китерүе дә куркыныч... Бу инде иң танылган җырчыларыбыз иң яраткан җырларыннан колак кага, халкыбыз җырсыз кала дигән сүз.

*Сандугачлар китә инде,*
*Кала моңнары гына.—*
*Моңнарының күңелләрдә*
*Кала торганы гына.—*

ди ул үзенең бер шигырендә. Моны аз гына үзгәртеп, болай дияргә мөмкин: бүген халык күңелендә калырдай җырларның күбесе Роберт Миннуллин сүзләренә язылган.

Аның балалар өчен язылган әсәрләре дә, лирик шигырьләре дә ягымлы юмор белән үрелеп килә иде. Елмаю монда төп рольне уйнамыйдыр, ул өстәмә бизәк кеңәдер төсле иде. Әмма "Дусларым, дус-ишләрем..." җыентыгы шагыйрь иҗатындагы юморга аерым урын бирүне таләп итә сыман. Шигъри котлаулар, шаян тостлар, багышлаулар, иҗатташларына эпиграммалардан торган бу китапны укып чыккач, авторның башка әсәрләрендәге юмор да бүтән яссылыктарак күренә башлый. Роберт Миннуллин коеп куйган лирик кына түгел, менә дигән юморист та икән бит дип уйлыйсың.

Әдәбиятыбызда "юморист" ярлыгы тагылганнарның берсеннән дә ким түгел.

Әлбәттә, безнең әдәбият белеме котлаулар, тостлар кебек "вак-төяк" нәрсәне иҗатка санап вакланып тормый инде. Әмма соңгы елларда, бигрәк тә радио-телевидениедә котлау тапшырулары барлыкка килгәч, әдәбиятның бу юнәлеше бик тә актуальләшеп китте. Котлау шигырьләренә ихтыяҗ артты. Юньле шигырь таба алмаган дикторларга "әйбәт яза" дип даны чыккан шагыйрьләр ярдәмгә килсә, әдәбият өчен дә, халык өчен дә зыян булмас иде. Шагыйрь каләменнән чыккан—шагыйрьләрчә була инде ул. Монда инде әдәби зәвык турында бәхәскә урын калмас иде.

Аннан соң, бу юнәлештәге әсәрләрнең тагын бер әһәмиятле ягы бар. Шул ук шаян тостлар, эпиграммалар һ. б., бердән, шигъри сүзне халык арасында популярлаштырса, икенчедән, шул ук эпиграмма геройларына игътибарны арттыра. Тарихи романнар язучы М. Хәбибуллинга, Батуллага, Ф. Латыйфига багышланган эпиграмма менә нindирәк:

*Татарның прозаиклары*
*Сөембикәгә ташландылар,*
*Чишенеп ук ташладылар -*
*Яңа роман башладылар.*
*Сөембикәне моңа кадәр,*
*Әйтерсең лә, белмәгәннәр.*
*Әйтерсең лә, гомер буе*
*Бер хатын-кыз күрмәгәннәр.*

Кемузардан роман яза башлаган бу әдипләргә автор белән бергә мыек астыннан елмаеп карыйсың һәм, шул ук вакытта, әсәрләре белән танышу теләге дә уяна. Укыган кешегә кызык та, әдәбиятны пропагандалауның бер ысулы да мондый әсәрләр. Ә Роберт Миннуллин дәрәҗәсендәге талант иясе язса—бигрәк тә.

* * *

Бу язманың максаты Роберт Миннуллин иҗатына җентекле анализ ясау түгел. Кыска гына бер мәкаләдә андый олы эшне башкарып чыгып булмыйдыр да. Чөнки шагыйрь иҗаты зур, катлаулы. Тематика ягыннан да, әдәби алымнар куллану җәһәтеннән дә күптөрле, күпкырлы. Аның бер "балалар әдәбияты" дигән өлеше генә дә әллә ничә буын әдәбият белгечләрен "баетырлык". Бу өлкәдә шагыйрь мавыктыргыч һәм катлаулы БАЛАЛАР ДӨНЬЯСЫ тудыра алган. Ул дөньяның серләрен чишәргә дә, чишәргә әле...

Безгә, яшьрәкләргә исә, халык шагыйре Роберт Миннуллинга карап сокланырга гына кала. Һәм өйрәнергә.

**Марат КӘБИРОВ**

Марсель
Бакиров

# «ИДЕГӘЙ» ДАСТАНЫНА ЯҢА КАРАШ

Заманында Алтын Урда дәүләте (Җучи Олысы) составында булган халыклардан казакъларда, каракалпакларда, нугайларда, башкортларда, Кырым һәм Себер татарларында атаклы «Идегәй» дастанының төрле версияләре һәм вариантлары язылып алынган. Әлеге дастан беренче башлап Алтын Урданың Идегәй йогынтысында булган кыпчак телле олысларында җирле риваять-легендалар нигезендә туа башлаган дип исәпләнелә. Аның тәмам формалашып җитүе һәм, төрле якларга таралып, төрле версияләре тууы да, башлыча, шушы халыкларның бабалары биләмәләрендә соңрак барлыкка килгән Нугай Урдасы кысаларында була. Аерып әйтергә кирәк: Иртыш һәм Тубыл елгаларына кадәрге Себер җирләре дә ул чорда шул ук Урда биләмәләре булып исәпләнә.

«Идегәй» дастанының Себер татарлары арасында теркәлгән вариантлары дистәдән артып китә. Аларның тулы булмаган борынгырак ике редакциясе Кадыйр Галибәкнең «Җамигыт-тәварих» («Елъязмалар җыентыгы») әсәре аша килеп җиткән. Өченчесе XIX йөз ахырында В. В. Радлов тарафыннан язып алынган. Ә чагыштырмача тулырак варианты укытучы, журналист һәм галим Нигъмәт Хәким тарафыннан 1919 елда Ситдыйк Зәйнетдинов исемле чичән башкаруыннан теркәлеп алынган. 1940 елда исә, әлеге текстны да, шулай ук элекке һәм совет чорында язып алынган вариантларны да кертеп, әсәрнең күренекле язучы һәм галим Нәкый Исәнбәт эшләгән җыйнама-тәнкыйди версиясе дөнья күрде. Хәзерге вакытта «Идегәй» әсәре киң җәмәгатьчелеккә төрле басмаларда урын алган нәкъ шушы гомумиләштерелгән текст буенча билгеле. Шул ук вакытта Флора Әхмәтова төзегән җыентыкта *(Татар эпосы. Дастаннар.—К.: Раннур, 2004)* дастанның Ситдыйк бабайдан язып алынган варианты да басылып чыкты.

«Идегәй» эпос-дастанында XIV йөзнең ахыры—XV йөзнең башында Алтын Урда дәүләтенең таркалу чорына керүе һәм Урта Азиядә Аксак Тимер (Тимерләнк) дәүләтенең көчәеп китүе дәверендәге вакыйгалар тасвир ителә. Бу вакыйгаларның үзәгендә өч тарихи шәхес тора: Алтын Урда ханы Туктамыш, кыпчаклашкан мангыт кабиләсеннән чыккан Идегәй һәм Урта Азиядәге төрки дәүләт хөкемдары әмир Аксак Тимер. Билгеле, дастанда эпик образ рәвешендә тасвирланган геройлар белән аларның прототиплары, ягъни әлеге реаль шәхесләр арасында тигезлек билгесе куеп булмый. Алар әсәрдә жанр эстетикасына һәм халыкның яки чичән-җырауларның күзаллавына бәйле рәвештә теге яки бу дәрәҗәдә төрле үзгәрешләргә, трансформацияләнүгә дә дучар ителгәннәр.

Алтын Урданың кодрәтле ханы Туктамыш шөһрәтле Чыңгыз нәселеннән чыккан хөкемдар була. Хакимияткә ул Аксак Тимер ярдәмендә килә һәм, Урданың үзенә кадәрге ханы Тимер-Мәликне үтереп, тәхеткә утыра. Ә аңарчы Идегәйнең әтисе Балтычак (варианты—Котлыкыя) әлеге Тимер Мәликнең баш әмире, ә аның кызы—Идегәйнең апасы—әлеге хан хатыннарының берсе була. Үзенә хезмәт итүдән баш тартканы өчен, Туктамыш берьюлы Котлыкыяны да үтерә. Тимер-Мәликнең яшүсмер улы Тимер-Котлык исә, күпмедер вакыт сарайда торганнан соң, Идегәй

бәк ярдәмендә Аксак Тимер ягына кача.

Зур дәүләтнең хөкемдары булып алгач (1380 елда), Туктамыш мөстәкыйль сәясәт үткәрә башлый: эчке фетнә-чуалышларга чик куя, үзенә каршы торучы Мамай гаскәрен тар-мар итә һәм идарә итүенең баштагы җиде елы дәвамында Алтын Урданың бердәмлеген торгызуга ирешә. 1382 елда Мәскәүне яулап алып, руслардан ясак түләтә. Шул ук елда бәйсезлеккә омтылучы Идел буе Болгар дәүләтен, яу белән килеп, бастыра. Шуннан соң Туктамыш, дәүләтенең шактый көчәеп-үзәкләшеп китүеннән файдаланып, сугыш юлы белән Җүчи Олысының элекке хәрби данын һәм куәтен кайтаруга юнәлдерелгән, тормышка ашмаслык ниятен үтәргә алына. Тарихчылар аның үзенә тәхеткә менәргә ярдәм иткән Аксак Тимергә каршы башлап үзе һөҗүм итүен һәм җиңелгәннән соң да, кат-кат 200-әр мең кешелек гаскәр җыеп, аның белән канлы сугышлар алып баруын шуның белән аңлаталар да *(Д. М. Исхаков, И. Л. Измайлов. Этнополитическая история татар К.: 2007.—С.206-207; В. М. Жирмунский. Тюркский героический эпос.—Л.: 1974.—С.366-367).* Әмма үзенең янәшәсендә Алтын Урда дәүләтенең көчәюен теләмәгән баскак Аксак Тимер өчен бу бәрелешләр кулай булып чыга. 1389, 1391 һәм 1395 елларда ике арада булган иң зур сугышларның өчесендә дә Туктамыш җиңелә. Соңгы сугышның нәтиҗәләре аеруча фаҗигале була: Аксак Тимер гаскәрләре Туктамышны Иделгә кадәр эзәрлекләп киләләр һәм илнең башкаласы Сарайны яндыралар. Бу җиңелү тарихчылар тарафыннан Алтын Урда дәүләтенең куәте кимү һәм таркалуга йөз тотуының башы булып исәпләнә.

Шушы җиңелүдән соң Туктамыш Литва кнæзе Витовт ярдәмендә кабат тәхетен кире кайтарырга тырышып караса да, хәтта соңрак, Аксак Тимер алдында гафу үтенеп, аның куәтенә исәп тотса да, ниятенә ирешә алмый. 1406 елда ул Алтын Урда ханы Шадыбәк гаскәрләренең бер отряды тарафыннан Себердә, Төмән шәһәреннән ерак түгел урында үтерелә. Шунда сакланган бер курганны җирле халык хәзер дә Туктамыш кабере дип исәпли.

Алда Идегәй шәхесе турында өлешчә мәгълүмат бирелде, шул исәптән аның кыпчаклашкан мангыт нәселеннән чыкканлыгы әйтелде. Ул башта Нугай Олысы бәге була. Аннары, үзенең сәләте-таланты аркасында, Туктамыш хан сараенда карачы-бәк вазыйфасын башкаручы сул канат әмире дәрәҗәсенә күтәрелә. Элекке тарихи чыганакларга караганда, Идегәй үзенең әтисен үтергән усал холыклы Туктамыш алдында тыштан буйсыну һәм түбәнчелек күрсәтеп, әмма һәрчак сакланып, качарга әзер булып яши. Соңгы вакытта Туктамышның үзенә карата үзгәрүен сизенеп һәм исерек чагында авызыннан янау сүзләре ычкындыруын ишетеп, араны өзәргә була. Башкалар абайламаган арада чаптар аты янына чыга да Аксак Тимер янына качып китә.

Кайбер тарихчылар Идегәй әтисе өчен Туктамыштан үч алырга уңай вакыт җитүен генә көткән һәм Аксак Тимер янына да асылда шул планын әзерләү өчен киткән дип исәплиләр. Вакыйгаларның шуннан соңгы үсешеннән күренгәнчә, моның өчен Идегәй үзе кебек үк әтисе үтерелгән һәм үзеннән алда Аксак Тимер янына качкан Тимер-Котлыкны үз «уенына» тартырга тиеш була. Ягъни ул Чыңгыз нәселеннән чыккан әлеге хан улын, үз йогынтысына алып, киләчәктә аны Туктамышка каршы файдаланырга һәм аны Алтын Урда тәхетенә утыртырга ниятли. 1391 елда Туктамыш белән Аксак Тимер арасында булган сугышта әмир ягыннан Идегәй белән Тимер-Котлыкның да катнашуы менә шуның белән аңлатыла. Тарихи чыганакларда бу сугышны ачучы, башлап җибәрүче Туктамыш, шулай ук Аксак Тимер үзе булган диган карашлар да бар. Гарәп авторы Ибне-Гарәбшаһ исә Тимерләнкне Алтын Урдага яу белән барырга Идегәй котыртып күндергән дип язып калдырган. Алтын Урда ханы Туктамышның көчәергә, җирләрен орыш юлы белән киңәйтергә омтылуын исәпкә алганда, Сәмәрканд әмиренең исә үз иле белән янәшәдә сугышырга ашкынучы, кыдрач хан идарә итә торган куәтле дәүләт булуын теләмәвен күздә тотканда, сугышка ике якның да әзерләнгән булуы шиксез.

Идегәйнең күңелендә йөргән үтә кыю һәм хәтәр ният ике олуг хөкемдарның 1395 елгы өченче зур сугышыннан соң тормышка аша. Әлеге сугышта Туктамыш җиңелгәч һәм янган Сарайны ташлап качарга мәҗбүр булгач, Алтын Урда тәхетенә,

күпмедер ыгы-зыгылардан соң, Тимер-Котлык утыра. Чөнки, Чыңгыз нәселеннән чыкмаганлыктан, Идегәйнең ханлыкка хокукы булмый. Әмма ул хакимият башына үзе мендергән хан янында олуг карачы-бәк сыйфатында фактик идарәчегә әверелә һәм шактый еллар дәвамында аннан соң тәхеткә менгән Шадыбәк, Булат-Солтан, Тимербәк исемле урта кул ханнар янында да асылда тулы хокуклы житәкче булып кала. Чөнки олуг карачы-бәк Урданың идарә системасында урнашкан тәртип буенча әмирләр әмире, гаскәрләр башлыгы, суд һәм дипломатия эшчәнлеген үз кулында тотучы түрә булып исәпләнгән.

Туктамыш кебек үк, Идегәй дә Алтын Урданың бердәмлеген торгызуга һәм куәтен арттыруга алына һәм шушы юнәлештә житди эшләр башкара. Ачыклап әйткәндә, төрле реформалар үткәрә, шәһәрләрне төзекләндерә, сәүдәне киңәйтә, кол сатуны тыя. Шулай ук хәрби башлык, кыю полководец буларак та үзен таныта: башта тәхетен кире кайтару өчен көрәшүче Туктамышка ярдәм итәргә дип алынган Литва князе Витовтның әлеге хан гаскәре белән берләштерелгән явын тар-мар итә, аннары Хәрәзмне һәм Азовны яулап ала. Хәтта Мәскәүгә һөжүм итеп карый. Ахыр килеп, Идегәй Аксак Тимер белән мөнәсәбәтләрне жайга салу буенча да оста эш итә, илчеләр һәм бүләкләр жибәрү, әмирне олылавын белдерү исәбенә аның яу белән килүен булдырмый кала. Шул рәвешле ул дәүләтне кабат аякка бастыру, куәтен һәм абруен күтәрү буенча шактый гына эшчәнлек күрсәтә. Әмма, тарихчыларның бик хаклы раславынча, Алтын Урда дәүләте аңа кадәр үк инде акрынлап таркалу дәверенә кергән була. Аны Туктамыш та, Идегәй дә туктатып кала алмый. Чөнки ханлыкка дәгъва итүче Чыңгыз оныкларының үзара көрәшүләре-тарткалашулары һәм урыннарда сепаратизм, ягъни аерылып чыгарга омтылышның көчәюе моңа зур киртә булып тора. Чыңгыз нәселенә карамаса да, олуг әмир Идегәй дә шул фетнәлышларның корбаны була: аны Туктамышның улы Кадыйр-бирде явы белән ике арада булган сугыш вакытында үтерәләр.

***

Туктамыш белән Идегәйгә бәйләнешле реаль мәгълүматларга һәм вакыйгаларга болай киң тукталуыбызның сәбәбе, һичшиксез, «Идегәй» дастанының асыл мәгънәсен мөмкин кадәр объектив һәм дөрес итеп аңлау ихтыяжы белән бәйле. Чөнки фольклор һәм әдәбият белемендә әлеге әсәрне аңлау һәм аңлатуда бер-берсенә кискен каршы килә торган карашлар яшәп килә.

Алдан ук искәртик: тарихи «Идегәй» эпос-дастаны алда сүз барган факт һәм вакыйгаларның шактыен жанр таләбенә буйсындырып файдаланган һәм, безнеңчә, иң күзгә бәрелгәне—аларны чичән-жырауларның һәм—без монсын алда күрербез—социаль заказчыларның күзаллау призмасы аша да үткәргән. Шул ук вакытта әсәрдә эпос традициясеннән килә торган эпик уйланма һәм әкияти-мифологик элементлар да урын алган.

Дастан Туктамышның, атаклы лачынын бирүне сорап язган хаты өчен, Аксак Тимерне ямьсез итеп хурлавын бәян итүдән һәм, әлеге лачын балаларын шуңа сатуда гаепләп, үзенең бөркет караучысы Котлыкыяны һәм аның гаиләсен юк иттерүен тасвирлаудан башланып китә. Әмма булачак каһарман могжиза белән исән кала. Аны әтисенең дусты Жантимер бишектә чакта үз баласы белән алмаштырып һәм итек кунычына яшереп алып чыга, шуның өчен исемен дә Идегәй ("Итекәй" варианты да бар) дип куша. Әмма бала Жантимернең ишле гаиләсендә, елкы һәм куй көтеп, Кобогыл дигән икенче исемдә үсә. Батыр балачак һәм яшьтән үк акыл иясе булып үсү мотивларына бәйле рәвештә, ул елдан-ел могжизалы төстә сәләтен һәм искиткеч сыйфатларын арттыра бара һәм «уникегә житкәндә Алпамыштай ир" булып житешә, ә инде унбишенә житкәч, көрәшеп, жәйләүдәге балаларның барсын да берәм-берәм егып чыга да, аларның үзе тау итеп өйгән киемнәре өстенә утырып, «Туктамыш хан тәхетенә мин мендем» дип сөрән сала.

Менә шул рәвешле әсәрнең башлам өлешенә борынгы халыкара сюжет килеп керә: шул традицион эпик сюжеттагы кебек, дастанда да югары катламнан чыккан герой—көтүче, янә аның да ике исеме бар һәм ахырда ул да югары дәрәжәгә ирешә. Белүебезчә, бу сюжет Сөләйман пәйгамбәрнең прототибы булган яһүд патшасы

Соломон турындагы хикәяттән үк башлангыч ала.

Туктамыш хан белән очрашу вакытында үзенең ифрат акыллы җаваплары белән шаккаттырып һәм Дөрмән бинең баласына карата чыгарган хөкеменең дә хантөрә законы белән ярашуын исбатлап күрсәтеп, Кобогыл (Идегәй) үзенең гаҗәеп талантлы һәм сәләтле булуын таныта. Аны хан сараена хезмәткә алалар. Монда ул тиз арада сул канат әмире дәрәҗәсенә күтәрелә һәм, батырлык күрсәтеп, читтән кергән дошман яуларын кыйрата. Шулай ук ул өйләнеп тә җибәрә һәм Норадын (вариант - Морадым) исемле улы туа. Үзе кебек батыр булып үссен дип, аны үзе белән яуларга алып йөри. Гомумән, каһарман һәр җирдә үзен чын пәһлеваннарча тота. Хәтта хан булып хан, ул килеп кергәндә, үзе дә сизмәстән урыныннан торып баса торган була. Хатыны Йәнбикә искәрткәннән соң, итәген тәхет белән тоташтырып чәнечкән энә шартлап сынгач, Туктамыш бу хәлгә ышанырга мәҗбүр була. Шуннан соң болар, тәмам шүрләп, Кобогылны агуларга ният кылалар. Әмма ниятләре барып чыкмый—Идегәй исән кала. Шулай итеп, төрле отышлы мотивлар һәм эпик алымнар ярдәмендә Идегәй образы гаять дәрәҗәдә югары күтәрелеп, хәтта сарайның тәхет залында күренүе белән үк, хан гаиләсен өркетә торган алып ир итеп тасвирлана. Болар каршына: «Кобогыл исемле бу көтүче баласы кем икән?»—дигән борчулы сорау килеп баса.

Бу сорауга, билгеле, ханның үз янына чакырткан тугыз кешедән торган бер генә батыры һәм бер чичән-җыравы да, шулай ук иң якын вәзире булган Җанбай да җавап бирә алмыйлар. Шуннан соң вәзир һәм чичән Җанбай кинәше буенча Сарайга 195 яшь яшәгән легендар Субра-җырауны алып киләләр.

Төрле халыклар иҗатында чичән-җыраулар (хәтта шаманнар да!) гади җырчы гына түгел, ә төрле яшерен серләрне белүче һәм киләчәкне алдан күрүче күрәзәчеләр итеп тә тасвирланалар. Субра-җырау да шундый ук сәләткә ия чичән була. Ул бал эчеп алгач һәм каршында торган Кобогылны кат-кат хикмәтле сораулар биреп сынагач, ханга аның кем икәнен һәм киләчәктә нәрсә эшләячәген дөп-дөрес итеп әйтеп бирә:

*«Бар Урдаңны алыр ул,*
*Тәхетеңә бау салыр ул»,*

*«Котлыкыя бу улы*
*Идегәй ул—Кобогыл».*

Субра-җырау шулай ук форсаттан файдаланып тиз арада качып киткән Идегәйне куып тотарга һәм башын кисәргә куша. Күрәзәлек итеп, бу юлы аңа карата кискен гаепләү сүзләре дә әйтә:

*Исән-имин китсә ул,*
*Иделдән ары үтсә ул,*
*Шаһ Тимерне алып килеп,*
*Сарайны харап итәчәк.*

Идегәй, билгеле, мәкерле һәм хәйләкәр Җанбайның хан исеменнән зур бүләкләр вәгъдә итеп чакыруына алданмый, Җантимер малайларын ияртеп, туп-туры Аксак Тимер иленә юл тота. Юлда барганда ул әлеге солтанның Кара-Тиен (тегин?) Алып әсир итеп алган кызын коткара һәм, Аксак Тимер боларны «алтын-көмеш тәңкәләр чәчтереп», зур хөрмәт белән каршы алганнан соң, Ак Беләк исемле әлеге кызга өйләнә.

Алтын Урданың һәм Туктамышның киләчәк язмышы Субра-җырау әйткәнчә булып чыга: Сарайны яндыруда үзе катнашмаса да, Идегәй, чыннан да, Алтын Урда өстенә Аксак Тимер явын алып килә һәм алда әйтелгәнчә, бу хал 1391 елда була. Дастанда бу турыда болай диелә: «Сансыз чирү, кара яу—Идегәй аны апкилде». Үзенең туган иле Идел-йорт биләмәләренә килеп кергәч, аның күңеле тула, туган җир туфрагын үбеп, патриотик рухтагы сүзләрен тулгап әйтә. Әсәрнең бу гаҗәеп

тәэсирле һәм образлы урыны хаклы рәвештә туган жиргә багышланган мәдхия-ода булып исәпләнә.

Ләкин туган жирен өзелеп яратса да, әтисен үтергән һәм анын үзен дә үтермәкче булган Туктамыш ханга карата Идегәйнең үч алу, ачу-кӱралмаучылык тойгысы көчлерәк булып чыга. Моңа шулай ук, Урта гасыр тарихчылары язганча, анын үзен зурга санап яки үз көчен сизеп, хакимият башына менәргә омтылуы да, һичшиксез, килеп ялганган булырга тиеш. Аннары тагын бер сәбәп—кат-кат жиңелүенә карамастан, Туктамышның зур чыгымнар һәм күп корбаннар таләп иткән сугышлар алып баруы, әлбәттә, халык арасында да ризасызлык тудырган. Дастанда бу тарихи факт «халкы ханнан өркә инде, татарың белән нугаен ханга каршы купты инде» дигән сүзләр белән бирелә һәм Идегәйнең Туктамышка каршы яуда катнашуының янә бер сәбәбе итеп күрсәтелә. Димәк, үзенең шәхси дәгъваларын яки үз мәнфәгатьләрен тормышка ашыру өчен яуда катнашканда, булачак хөкемдар илдәге эчке ризасызлыктан да файдаланган булып чыга.

Дошман дәүләтнең гаскәрен Алтын Урдага китергәч, Идегәй баш күтәрүчеләрне «каршы барып алам» дип вакытлыча яудан аерылып китә. Аксак Тимер исә ганимәт (трофей) байлыгын тизрәк үз кулына төшермәкче булып, сугышка башта үз гаскәрен һәм үз батырларын гына кертә. Әмма дастанда Туктамышның Кыпчак исемле пәһлеваны боларның барсыннан да көчлерәк итеп сурәтләнә һәм болар хурлыклы жиңелү алдында калалар. Бу, әлбәттә, эпик уйланмага корылган, әмма, безнеңчә, баскак Аксак Тимергә каршы башта батырларча каршылык күрсәтелгәнлегенә ишарә итә торган бер дәлил. Менә шул киеренке чакта яуга үзенең якыннары белән Идегәй килеп кушыла. Дастан, Кыпчак бинең батырлыгын калку итеп сурәтләгән кебек, Идегәйнең каһарманлыгын да героик эпостан килүче алымнар ярдәмендә гаять көчле итеп тасвирлый. Берүзе мәйдан тотып, ул «аждаһадай сулаган булат кылычы» белән Туктамыш гаскәрләрен кыра. Соңрак аңа баһадир итеп сурәтләнгән Норадын да ярдәм итә. Кайбер хезмәтләрдә, Идегәйне акларга тырышып, әлеге сугышны Литва князе Витовт гаскәре белән Алтын Урда арасында 1399 елда булган сугышка кайтарып калдырырга тырышу бар. Белүебезчә, Бурсыклы елгасы буенда булган зур сугышта Витовтның Туктамыш гаскәре белән берләштерелгән явына каршы олуг карачы-бәк Идегәй житәкчелек иткән гаскәр көрәшә һәм, чыннан да, каршы якны жиңә. Әмма дастанда бу сугыш турында асылда бернинди дә сүз юк.

Чынында исә Алтын Урда жирендә булган 1391 елгы сугыш—әлбәттә инде, гомумиләштерү максатыннан чыгып—әсәрдә Аксак Тимернең 1395 елгы икенче жимергеч явы белән бергә кушып тасвирлана. Тарихи чыганаклардан мәгълүм булуынча, Идегәй үзе катнашкан беренче сугыштан соң, баскынчы Аксак Тимер белән арасын тәмам өзә, биш вакыт намазын укучы һәм гөнаһлары өчен куркучы диндар кеше буларак, әмирнең үз янына жибәргән илчесенә болай ди: «Үзегезнен хужагызга барыгыз да, кулын ялап, безнең аралашуыбызга инде чик куелуын, моннан ары минем аңа эшем-катнашлыгым юклыгын әйтегез, чөнки мин Аллаһтан куркам» *(В. К. Тизенгаузен. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды.—Спб., 1884.—Т.1.—С. 472).*

Туктамыш ханның, Сарай шәһәрен һәм тәхетен ташлап, яраннары һәм исән калган яугирләре белән качып китәргә мәжбүр булуы да Аксак Тимернең Идегәй бөтенләй катнашмаган икенче явы вакытына—1395 елга туры килә. Киткәндә ул, илен дошман кулына калдыруы өчен уфтанып һәм «ерактан сине күрә алмам, тиз генә әйләнеп кайта алмам инде» дип, туган йорт-жире һәм халкы белән саубуллаша. Шушы уңайдан Туктамышның Идел-йортка багышлап тулгап әйткән мәдхиясе шулай ук гаҗәеп образлы һәм лирик-эмоциональ булуы белән аерылып тора. Чөнки бердәмлеген һәм куәтен кайтару өчен үзе күп көч салган дәүләте аның өчен дә бик якын һәм кадерле була.

Идегәй исә, Сарайда Аксак Тимерне калдырып, улы Норадын һәм яугирләре белән бергә шунда ук Туктамыш эзеннән киткән итеп тасвирлана. Димәк, монда да сәнгати-эпик гомумиләштерү, уйланма һәм булган хәлләрне бергә үрү дәвам итә. Әсәрдә хан, төньяк тарафка юл тотканда, үз артыннан жимерек хәрабәләр калдырып барды, «әзгәри суккан Әтрәчне эргәсеннән куптарып, нократ (көмеш акча)

суккан Болгарны нөргәсеннән куптарып төнгә үтте Туктамыш» дип күрсәтелә. Һәм шушыннан алда гына Туктамышның әлеге текст белән аваздаш булган «айлык юлым алдан алырмын, Болгардаен калам бар, Болгар йортын алырмын» дигән сүзләре дә китерелә. Белгечләрнең раславынча, мондый урын дастанның башка вариантларында юк. Җыйнама версияне төзегән Нәкый Исәнбәт үзе әлеге урынны бер укытучы вариантыннан алдым дип күрсәткән. Ничек кенә булмасын, Туктамыш хан Болгар каласын җимерүче итеп күрсәтелгән сүзләрдә фактларны бутау, анахронизм ярылып ята. Чөнки Туктамыш гаскәрләренең баш бирергә теләмәгән Болгар җирен яу белән бастырып китүе 1382 елга туры килә. Ә инде Болгар каласы асылда, Туктамыш та, Идегәй дә дөнья куйганнан соң гына, ягъни 1431 елда Мәскәү кнәзе Василий Тёмныйның гаскәр башлыгы Фёдор Пёстрый тарафыннан җимерелә. Бу мәгълүмат исә дастанда «урысның бер гавере—авызы төкле княжы» изге шәһре Болгарны һәм башка калаларны «яндырып һәм көлгә-ташка болгап» китте рәвешендә бирелә.

Әмма Туктамышны эзәрлекләп барганда, Идегәй үз адресына карата да кискен шелтә-гаепләү сүзләре ишетә. Болгар хәрабәләре арасында утырган ил агасы Бодайби, аның йөзенә бәреп, мондый сүзләр әйтә:

*Бу җиһанның фетнәсе*
*Аксак Тимер дошманны*
*Сарайга алып китердең,*
*Йөз баһадир ирәннән*
*Йорт-җиреңне бастырдың.*

Күренүенчә, бу сүзләрдә туган йорт-җир белән чит илнең баскак ханы капма-каршы куела. Идегәйнең исә, халык әйтмешли, өрә белмәгән эт кебек үз оясына бүре китерүе, Аксак Тимер белән союзга кереп, аның явын үз иле өстенә алып килүе хөкем ителә. Әмма дастанда шул ук вакытта иленә яу килүгә Туктамыш үзе дә гаепле дигән фикер дә урыны-урыны белән чагылып китә. Мәсәлән, Аксак Тимернең яуга чыгар алдыннан «минем кулдан нан җыеп, такка (тәхеткә) менгәч мас булган (масайган) Туйгужа улы Туктамыш» дип әйткән сүзләре һәм аның үз иленә (Сәмәркандка) басып керүен гаепләп телгә алуы—менә бер мисал. Икенче бер урында исә Туктамыш «Идегәйнең башын алам дип үз башыма яу алдым» дип үз гаебен хәтта үзе дә таный.

Идегәй качып киткән ханны тота алмый. Шуннан соң ул әлеге эшне улы Нурадынга тапшырып, Сарайга әйләнеп кайта. Һәм монда, башкаланы Аксак Тимернең көлгә әйләндереп китүен күреп, өлешчә үзе дә сәбәпче булган баскынчылык сәясәтенең аянычлы бер нәтиҗәсенә тап була. Җитмәсә, Аксак Тимер элекке хан урынына Алтын Урдага «курчак хан» итеп Кыйгырчык исемле үз кешесен дә куеп киткән булып чыга. Үзен хан дип исәпләүче бу тәкәббер бәкне Идегәй шундук аягыннан тотып җиргә бәрә дә берочтан аның яранын, якыннарын да кырып сала. Ниһаять, вакытлыча булса да дошман як белән килешүгә, хыянәткә бару һәм күпме кан кою исәбенә әлеге үтә хәйләкәр, әмма һәрьяклап талант һәм акыл иясе булган каһарман Алтын Урда дәүләтенең идарә башына менеп утыруга ирешә.

Дастанның татар версиясендә Идегәй хан итеп куйган Тимер-Котлык образы бөтенләй тасвирланмый, ә аннан соң тәхеткә утырган һәм гаскәре Туктамышны эзәрлекләүдә катнашкан Шадыбәк (1400-08) исеме генә телгә алына. Аның каравы Идегәйнең әлеге ханнар заманында Алтын Урданың икътисади куәтен һәм сәяси абруен күтәрергә юнәлдерелгән эшчәнлеге бер-бер артлы тезеп күрсәтелә.

Тарихи чыганаклардан аермалы буларак, әсәрдә Туктамыш Идегәйнең улы Нурадын кулыннан үлгән итеп тасвирлана. Әтисеннән аерылып калгач, ул ханны куып тота һәм аларның икесе арасында эпос геройларына хас сүз бәйгесе булып ала. Туктамыш «мин Чыңгызмын, беләмсең, хан улымын, ханынмын» дип үзенең кем булуына басым ясый, «халыгыма, илемә өлге булган морзамын» ди, Нурадын исә аның үзен Сарайдан мәсхәрәләп куып җибәрүен исенә төшерә. Һәм иң ахырда, «казак булып җиреннән, куылып йөрсен иленнән» дигән каргышыннан соң, моның башын чабып өзә дә әтисенең каршына кайтарып сала.

Моннан арысы хан һәм Кара-Тиен Алып каргаганча булып чыга. Үзенә дип ниятләгән Туктамыш кызы Ханәкәнең, мәкерле Жанбай котыртуына бирелеп, эченә киез бәйләп каршылавын күргәч һәм моның өчен әтиең гаепле дигән сүзләрен ишеткәч, Норадын түзми, кулындагы думбрасын атып, Идегәйнең уң күзен чыгара. Шул рәвешле ул әтисен рәнҗетеп һәм күнеленә охшаган башка бер җиргә барып урнашырга өмет итеп, казак булып («каз» борынгы төрки телдә күчеп йөрү мәгънәсендә) ил гизәргә чыгып китә. Ләкин, төпләнеп калырга урын тапмыйча, бераздан кире әйләнеп кайта һәм атасының чакыруы буенча болар янә Сарайда очрашалар. Бу юлы Норадын үзе юк чакта тәхеткә әтисе ярдәмендә Шадыбәк утырганын белеп, эчендәгесен тышка чыгарып сала. «Йә син үзен хан булгыл, йә син мине хан кылгыл!» дип атасына хәл итмәслек сәяси дәгъва белдерә. Чыңгыз нәселеннән чыкмаганлыгын аңлап һәм «падишаһлык сөрә алмам—Алла үземә бирмәсә» дип аек акыл белән яшәгән Идегәй, әлбәттә моңа риза булмый. Нәтиҗәдә, ике арадагы конфликт тагын да кискенләшеп, ата кеше казак булып читкә (тарихи чыганакта Хәрәземгә) чыгып китәргә мәҗбүр була.

Соңрак чорга карый торган Кырымга бәйләнешле төрек чыганакларында Норадынның тәхеткә дәгъва белдерүе Шадыбәк үлгәч, ягъни Булат-Солтан хан булыр алдыннан булган хәл итеп күрсәтелә. Дастан ата белән ул арасындагы низагны үзенчә файдалана һәм, аларның иҗтимагый-сәяси карашларын ачу белән бергә, вакыйгаларның драматик киеренкелеген, тәэсирлелеген дә арттыруга ирешә. Ләкин, вакыйгалар үсеше күрсәткәнчә, Норадынның идарәче булырга омтылу теләге барып чыкмый. Икейөзле Җанбай корган хәйләле тозакка эләгеп, ул Туктамышның улы Кадыйрбирде кулына әсир төшә. Үтерелгән әтисе өчен үч алып, бу Норадынны ерткычларча җәзалый, һәм газаплауларны чын батырларча кичергән герой соңыннан үзенең атасы Идегәй алдында җан бирә. Үлгәндә ул бозылышканнары өчен әтисеннән, кулын үбеп, гафу үтенергә өлгерә. Норадынның үлеме дә драматик киеренкелекне көчәйтү максатына буйсындырылган. Чынында исә ул исән кала һәм әтисе һәлак булганнан соң Нугай урдасында хөкемдар була.

Ә хәзер моннан алда булган хәлләргә—Туктамыш ханның ничек үтерелгәнлегенә кабат әйләнеп кайтыйк. Әлеге хәлгә бәйле рәвештә әсәрдә гадәттән тыш күренеш тасвирлана: Норадын кылычы белән, Туктамыш ханның башын чабып өзгәч, аннан кан урынына сөт ага. Бу гаҗәп хәлнең мәгънәсе Идегәйнең үлеме белән чагыштыргач һәм ике үлемне боларның кылган эшләре белән тәңгәл куеп карагач кына ачыла.

Тарихтан билгеле булуынча, Туктамышның уллары, берәм-берәм сафтан чыга-чыга, Алтын Урда тәхетен үз кулларына төшерергә тырышып озак кына көрәш алып баралар. Шулардан бердәнбер диярлек исән калган Кадыйрбирде исемлесе, алда күрсәтелгәнчә Норадынны үтергәне, үзенең һөҗүмнәре белән Идегәйне кат-кат борчып тора. Әмма 1419 елда ике арада булган иң соңгы сугышта ул, ниһаять, Идегәй кулыннан һәлак була. 67 яшьлек каһарман моны «арыслан хәлдән тайса да, бер сарыклык көче бар» дип, «алты батман чукмар»ы белән сугып үтерә. Шул рәвешле Туктамыш нәселе тәмам киселә.

Ләкин бу канлы сугыш яраланып берүзе калган Идегәй өчен дә һәлакәт белән тәмамлана. Ахырда ул Кадыйрбирденең үзен чолгап алган «уникe түрә, алты би»ен кырып бетерсә дә, хәлсезләнеп калгач, Барын морза моның башын чабып өзә. Тәгәрәгәндә баш мондый сүзләр әйтә:

*Сөт урынына кан койдың,*
*Каныңны түгеп ни кылдың?*
*Казан, Кырым, Аҗдаркан,*
*Кунымны сорап купканда,*
*Ни булганын анда күрерсең.*

Менә монда инде без киселгән баштан кан агуы белән очрашабыз. Беренче очракта сөт ага, икенче очракта—кан, моның сере нәрсәдә соң? Дөрес җавапны табарга безгә «кунымны сорап купканда» дигән юл ярдәм итә. Борынгы төрки телдә «кын» җәза, үч дигән мәгънәне белдерә. Татар сүзлекләрендә «кун» (дастанның

Нигъмәт Хәким язып алган вариантында «кон») йолым, үч дигән төшенчәләргә туры килә дип күрсәтелә. Ә инде кыргыз телендә әлеге сүзнең мәгънәсе—«үтергән һәм гариплләгән өчен түләнә торган хак». Туктамышның Алтын Урда тәхетен яулаганда Идегәйнең этисе Котлыкыяны үтерүен, ягъни кан коюын исәпкә алганда, аннары Идегәй улы Норадынның, Туктамышны үтереп, кан үчен кайтаруын истә тотканда, элекке ырулар йола-гадәте буенча «үтерү хакы» түләнгән булып чыга. Сөт образы исә шушы бурыч яки йолымның кайтарылганын белдерә дә инде, һәм бу Норадынның корбанына «үз кылганың үзенә кайта» дип әйткән сүзләре белән дә раслана. Шул ук вакытта ак сөт символы—монысы инде аеруча мөһим—кан коеш тукталырга, иминлек белән алышынырга тиеш дигән мәгънәне дә аңлата. Әмма каршы як, кабат кан коеп, «кан канны тарта торган» юлга баса. Моннан тыш, әсәрнең берничә урынында «кызыл канлы кылычны ак сөт белән юу» мотивы яки шуның киресе кабатлана, шулай ук «саурык бия (кырыкмыш тай) сөтенең тыныч йортка кот» булуы турында әйтелә. Монда да сөтнең кан коешка чик куярга яки тынычлык-иминлек урнаштыруга чакыру мәгънәсендә килгәнлеген сиземләү кыен түгел.

Гомумән, «Идегәй» дастанының бөтен композициясе канга кан, явызлыкка явызлык, яхшылыкка яхшылык булып кайта дигән фәлсәфи принципка корылган. Идегәй авызыннан шушы принципны раслый торган сүзләр төрле вариантларда, шул исәптән контраст парлар рәвешендә дә әйттерелә:

*«Мин яхшыга яхшымын,*
*Мин яманга яманмын».*
*«Дустым утын сүндермәм,*
*Дошман утын яндырмам».*

Ошбу фәлсәфи канун күпчелек геройларның төрле вариантларда пар-пар итеп яки капма-каршы куеп сурәтләүләрендә дә, шулай ук аларның үзара мөнәсәбәтләрендә һәм кылган эшләрендә дә чагылыш таба. Әйтик, Котлыкыя Туктамышның атаклы ау бөркете балаларын Аксак Тимергә сата, бу хәл исә үзенең һәм гаиләсенең юк ителүенә китерә; әлеге гаилә Дөрмән би кулы белән һәлак ителә, әмма тиздән аның үз улына әҗәл килә. Идегәй туганнан туганы Кара Тиен Алыпның йөрәгенә ук белән ата, шуның каргышы төшеп, үз улы моны ахырда яртылаш сукыр итеп калдыра; Шаһ Тимер Алтын Урдага басып керә, җавабы—аның гаскәрен, эпик уйланмага корылган бәрелештә булса да, Туктамыш ханның пәһлеваны Кыпчак би кыйратып сала; әлеге баскак әмирне Идел-йорт өстенә алып килүче Идегәй була, нәтиҗәдә ул ил агасының (халыкның) бәддогасын ала һәм Сарайсыз, улсыз кала; Кадыйрбирде Норадынны җәзалап үтерә, әмма Идегәй соңыннан улын үтерүченең үзен һәлак итә һ.б. Кайбер антипод буыннарны башкачарак та төркемләргә мөмкин. Мәсәлән, Идегәйнең этисе Туктамыш тарафыннан үтерелә, тик ахырда үзе дә Идегәйнең улы кулыннан үтә. Кыскасы, башкаларга карата эшләнгән һәр ярамаган эш яки фаҗига тудыра торган гамәл дастанда шуңа ук бәрабәр җавапка дучар була, һәр начарлык тиешле җәзасын ала.

Әсәрнең «умыртка баганасын» яки үзенчәлекле эпик чылбыр тәшкил итүче мондый парлы контраст буыннарның бер өлеше, һичшиксез, героик эпос традицияләре яки каһарманлык мотивлары белән дә үрелеп килә. Мәсәлән, үзара сугыш һәм хәтта баш киселер алдыннан да ике якның бер-берсе белән батырларча сүз көрәштерүе, дошманың үткер тел белән өркетергә тырышуы, аерым каһарманнарның каршы як батырлары яки гаскәре белән орышканда әкияти пәһлеванга әверелүе, үлемсез батырның—Кара—Тиен Алыпның һөҗүмгә барешә торган култык астына ук белән атып һәлак ителүе. Каһарманлык мотивларының иң зур күпчелеге, әлбәттә, Идегәй һәм аның улы Норадын образлары белән бәйле. Туктамыш ягына килгәндә, мондый мотивлар теге яки бу дәрәҗәдә Кыпчак би һәм хан улы Кадыйрбирде өлешенә туры килә. Туктамыш хан үзе исә, ягъни дәһшәтле Аксак Тимергә каршы кат-кат яу белән барган кодрәт иясе, әсәргә бөтенләй ябышмый торган Болгарны җимерү эпизодын исәпкә алмаганда, шактый пассив, кыюсыз һәм хәтта куркаграк та итеп тасвирлана. Хәлбуки, бик еш «азамат ир», «олуг хан» дигән хөрмәтләү эпитетлары

белән аталса да һәм бабасы Чыңгызның абруена кат-кат таянылса да.

Моның, безнең уебызча, ике сәбәбе бар. Беренчедән, Туктамыш башта Алтын Урданың бердәмлеген торгызуга ирешсә дә, Җучи Олысының элгәреге куәтен кайтаруга алынуы акрынлап илнең зәгыйфьләнүенә, ә үзенең тәхеттән качып китүенә китерә. Икенчедән, үзен акламаган бу сәясәттән файдаланып һәм хәтта дошман як көченә таянып, хакимият башына сыгылмалырак һәм остарак сәясәт алып бара торган яңа идарәче килә. Бу хәл, үз чиратында, тарихи аңның һәм халык рухының үзгәрешенә китерә.

Табигый инде, Чыңгыз токымына караган олуг хан Туктамышны тәхеттән төшерүдә якыннан торып катнашкан һәм Алтын Урданың фактик идарәчесе булып киткән Идегәйгә, һичшиксез, өстен катламнар һәм халык алдында үзенең хөкемдар булырга хокукы барлыгын расларга кирәк булгандыр. Шулай ук Алтын Урданың бер өлешендә барлыкка килгән Нугай Урдасы башында, аннан соң да озак еллар буена утырган Нуретдин (Норадын) исемле улы һәм оныклары да моңа мохтаҗ булгандыр. Дастанның «Җамигыт-тәварих» исемле Кадыйр Галибәк җыентыгындагы бер вариантында бирелгән «Идегәй»нең «изге нәсел» шәҗәрәсен тарихчы Миркасыйм Госманов нәкъ шушыңа бәйләп аңлата да *(М.А.Усманов. Татарские исторические источники XVII-XVIII вв.—К., 1972.—С. 82-83)*. Әлеге шәҗәрә буенча, Идегәйнең нәсел башы, имеш, Мөхәммәд пәйгамбәрнең хәлифәсе-көрәштәше һәм каенатасы булган Әбүбәкердән башлангыч ала, ә кайсыдыр буында мөселман изгесе һәм кыпчакларның героик эпос геройларын яклаучы легендар Баба Төкләскә (Төкле Бабага) барып тоташа. Реалистик төсмер бирелеп, әлеге шәхес XII йөздә яшәгән атаклы суфый шагыйре Әхмәт Ясәви белән дә тинләштерелә һәм әсәрдә Идегәйнең бабасы Баба Төкләс Хуҗа Әхмәт булган дип күрсәтелә дә.

Дастан герое Кара-Тиен Алып сүзләре буенча, без Идегәйнең әнисе, имеш, пәри (resp. аккош) булган дигән әкияти-мифик мәгълүмат белән дә очрашабыз. Янәсе, Баба Төкләс үзенең аккош «тире-киемен» салып күлдә су коенган чибәр кызга өйләнгән һәм, Котлыкыя исемле балалары тугач, әлеге кыз-аккош боларны ташлап киткән. Котлыкыя исә, үсеп җиткәч, гүзәл пәри кыз белән кавышкан һәм шул никахтан Идегәй туган, имеш.

Югарыда китерелгән шәҗәрәләрнең икенчесе, тотемистик катламнан арындырылып һәм ислам дөньясының «алтын баганалары» белән бәйләп мөселманлаштырылганы, соңрак барлыкка килгән дип исәпләнә. В. Жирмунский фикеренчә, бу изгеләштерелгән «фәнни» шәҗәрә Идегәйнең Алтын Урда башында утырырга хакы барлыгын раслау максатында ул үзе исән вакытта ук туа башлаган булырга тиеш. Һәм ул төрле каналлар аша, шул исәптән «социаль заказ» буенча аерым чичән-җыраулар ярдәмендә дә, Алтын Урданың ислам дине тоткан халкы арасына максатчан рәвештә таратылгандыр да. Идегәйдән соң Нугай Урдасы башында калган нәселе-варислары да, әлбәттә, бу эштән читтә калмагандыр.

Дөрес, шәхси дәгъвасын гамәлгә ашырганда, Идегәй үзе илдә хан булып Чыңгыз нәселеннән чыккан бәк яки әмир генә утырырга тиеш дигән канунга да ярашырга мәҗбүр булган. Әмма шул ук вакытта ул «изге нәсел» шәҗәрәсен дә бик оста эшкә җиккән булуга охшый. Дастанда турыдан-туры аның үз авызыннан әйтелгән сүзләр нәкъ шуны раслап тора да:

*«Туксан башлы Урдага*
*Тунамый ия булмасам»,*
*«Әйткәнемне кылмасам,*
*Мин үчемне алмасам,*
*Баба Төкләс бабам биргән*
*Идегәй атым корысын!»*

Бу гына да түгел, каһарман гаять эреләнеп һәм масаеп, хәтта «борындагы Чыңгызның үзе белән тиндермен» дип тә әйтеп сала. Шушы ук фикерне «Чыңгызның кайсы улыннан кимдермен?» рәвешендә Идегәйнең улы Норадын да әйтә.

Иң мөһиме, «Идегәй» дастанында ил-дәүләт тотучы хөкемдарның дәрәҗәсе

Чыңгыз нәселеннән чыгу-чыкмавына карап кына түгел, ә аның идарә итү осталыгы, ягъни күрсәткән эш-гамәлләре белән билгеләнергә тиеш дигән гадел фикер үткәрелә. Менә шуна күрә дә Чыңгыз токымына бәйле «законлы хан Туктамыш» (гәрчә баштагы чорда зур уңышларга ирешкән булса да!) ясаган җитди хаталары өчен әсәрдә урынлы тәнкыйть ителә. Җөмләдән, үлемгә хөкем ителгән Котлыкыя авызыннан: «Били белсәң, ханиям, икселмәс (кимемәс, какшамас) дәүләт иде бу» ,—дип, хан адресына илне зәгыйфьләндергәне өчен кискен гаепләү сүзләре әйттерелә. Шулай ук заманында бай төбәктә яшәгән җирле халыкның каласы юкка чыгу һәм үзенең «кола чүлгә» күченергә мәҗбүр ителүе өчен дә гаеп ташлана. Соңгы очракта сүз Аксак Тимер белән алып барылган мәгънәсез сугышларның аянычлы нәтиҗәсе хакында бара. Бу турыда галим Марсель Әхмәтҗанов, 1395 елгы сугышны да кертеп, болай яза: «Алтын Урда халкы арасында монарчы күрелмәгән күченү-буталу хәрәкәте башлана. Әлеге дә баягы 1391, 1395 еллардагы мәхшәрдән соң икътисад, һөнәрчелек, мәдәният үзәге булган шәһәрләр һәм утрак тормыш хөкем сөргән төбәкләр бушап кала, дөресрәге, хәрабәләр өеменә әйләнә» *(Марсель Әхмәтҗанов. Нугай Урдасы.—К., 2002.—Б.178)*. Нәкъ шушы фаҗигале хәлләр Котлыкыяда гына түгел, ә халыкның төрле катламнарында ризасызлык тудырган да инде. Ә соңгы сугыш аеруча зур корбаннарга, җитди югалтуларга китергән һәм хакимият алмашыну белән тәмамланган. Калганы инде безгә билгеле.

Димәк, алда сөйләнгәннәрдән күренүенчә, Алтын Урда тормышына һәм Туктамыш белән Идегәй шәхесләренә бәйләнешле вакыйгалар гаять катлаулы, киеренке һәм кискен булган икән. «Идегәй» дастаны әлеге вакыйгаларны төрле үзгәртүләргә һәм сәнгати-эстетик эшкәртүгә дучар итсә дә, аларның реаль юнәлешен һәм рухын сакларга тырыша. Шул ук вакытта, бигрәк тә Идегәй образының шактый ык идеаллаштырып, калку итеп тасвирлануында, билгеле бер дәрәҗәдә социаль заказга нигезләнгән субъектив-тенденциоз бәяләмә дә катнаша. Һәм басым ясап әйтергә кирәк: әлеге бәяләмә, һичшиксез, халыкның гадел хөкемдар образында үзе күрергә теләгән гаделлек, туган җирне ярату, коллыкта яшәүчеләрне азат итү, төрә-кануннарны саклау, бала җанлык кебек сыйфатлар белән дә үрелеп килә. Өстәвенә, дастанда каһарманны гадел халыкка һәрчак ярдәм итүче чын кеше итеп сурәтли һәм данлый торган берничә вариантлы рефрен да бар. Ошбу рефренда саналган кешелек сыйфатлары Идегәйдә көтү көтеп үскән вакытында ук инде тернәкләнгән һәм акрынлап аны гади халык арасында танылткан итеп тасвирлана. Менә ул рефренның Колчура тарафыннан әйтелгән варианты:

*Ятимнәргә—яр булган,*  
*Колчурага—дус булган,*  
*Аты юкка—ат булган,*  
*Чүлләгәнгә—су булган,*  
*Адашканга—юл булган,*  
*Ялгызга ясак булган,*  
*Җәяүгә—таяк булган,*  
*Карны ачканга тамак булган*  
*Идегәй ир бар икән.*

Ләкин искә төшерик: халык үзе идеаллаштырган Идегәйне, иле өстенә дошман гаскәрен алып килгәне һәм Сарайны җимерттергәне өчен, үзе үк ачыктан-ачык гаепли, кискен рәвештә хөкем дә итә. Монда инде дастан авторлары—чичән-җырауларның, үзләре тудырган һәм социаль заказ йогынтысын да чагылдырган идеал, романтик, ягъни героик-эпик образ кысалары белән генә чикләнмичә, тарихи-реаль Идегәйнең халык күңелендә тирән эз калдырган хыянәткә бару фактын да кертеп җибәрүе, димәк, объектив дөреслеккә баруы күренеп тора. Нәкъ менә җимерек Сарай символы аша һәм Идегәйнең хәтта үз гаиләсендә шау-шу чыгуын тасвирлау ярдәмендә халык Аксак Тимер явының илгә иксез-чиксез бала-казалар китергәнлегенә дә ишарә итә.

Югарыда сөйләнгәннәрдән үзеннән-үзе соралып торган бер нәтиҗә шул: эпик

Идегәй, берьяктан, идеаль-героик итеп сурәтләнгән образ булса, икенче яктан, ул драматик-трагик каһарман да икән. Һәм бу, һичшиксез, аның тормышта да героик табигатьле, әмма каршылыклы трагик шәхес булганлыгы белән бәйле икән. Әмма Идегәйнең үз иленә мөнәсәбәтле ялгыш һәм мәкерле адымын аклап булмаса да, шуннан чыгып аны, узган чорның олы галиме Ризаэтдин Фәхретдинов кебек, «Тимерләнне бу мәмләкәткә алып килеп, Дәште Кыпчак дәүләтен харап иттерде... Бу көндә ошбу җир мөселманнарының түбән вә хур булып калуларының сәбәпчесе Тимерләң вә аның да мондый һәлакәтне җиренә житкерүгә сәбәпче Идегәй мирза булды» *(Ризаэтдин Фәхретдин. Идегәй мирза // «Шура» журналы, 1908, №8.— Б.231)* дип, гаепләү һәм бу ике шәхесне үзара тәңгәл кую белән килешеп булмый торгандыр. Шулай ук, бүгенге кайбер галимнәр кебек үк, Идегәй образына яки шәхесенә Алтын Урданың таркала һәм җимерелә башлавына нигез салучы дип мөһер сугу да акланмыйдыр. Чөнки мондый үтә берьяклы карашлар Алтын Урда тарихын монографик планда өйрәнгән мәшһүр галимнәрнен—Б. Д. Греков белән А. Ю. Якубовскийның объектив һәм гадел нәтиҗәсе белән бөтенләй ярашмый. Менә ул нәтиҗә: «Идегәй иң соңгы Алтын Урда хөкемдарларының берсе иде. Ул Көнчыгыш Европада татар хакимиятенең элекке бөек державачылыгын булдырырга омтылып кына калмады, ә билгеле бер вакытта аны гамәлдә дә тормышка ашырды» *(Б.Д.Греков, А. Ю. Якубовский. Золотая Орда и его падение.—М., 1975.—С. 104).* Аерым галимнәр Идегәйнең күпкырлы эшчәнлегенә бүгенге фән биеклегеннән торып та шундый ук бәя бирәләр: «Бурсыклы буендагы бөек җиңүеннән соң Идегәй, бөтен властьны үз кулына туплап һәм үзенә ошамаган ханнарны алмаштыра-алмаштыра, титаник тырышлык салу исәбенә Алтын Урданың таркалуын янә ун ел буена диярлек тоткарлап-туктатып килә, ирешелгән бердәмлекне саклый» *(Искандер Измайлов. Звездный час Идегея // Идель. —1991.—№8-9.—С. 70).* Белүебезчә, бүгенге фольклор һәм әдәбият белемендә янә Туктамышның уңай якларына һәм казанышларына күз йомып, яисә әлеге ике шәхесне капма-каршы куеп, Идегәйне генә күккә чөеп мактаган өченче төрле карашлар да бар.

Без үзебез, объектив анализыбыздан күренгәнчә, әлеге берьяклы карашлар белән килешмибез һәм, тарихи фактларга нигезләнеп, алар белән ярашмый торган «алтын урталык» ягында торабыз. Гаепләү юлыннан китсәң, һәр ике тарихи шәхеснең дә гаепләрен табарга мөмкин. Асылда Туктамыш та, хөкемдар булу һәм әтисе өчен үч алу өчен, туган иле Алтын Урда җиренә кат-кат Аксак Тимер гаскәрләре белән керә һәм дәүләт башына да, нәкъ Идегәй кебек үк, Аксак Тимернең хәрби көченә-ярдәменә таянып, хәтта Урданың законлы ханы Тимер Мәликне үтереп менә. Монда да, димәк, шәхси дәгъва катнашканлыгы шиксез.

Әмма, бу шәхесләр Алтын Урданың бердәмлеген һәм куәтен торгызуга һәм үстерүгә икесе дә күп көч салалар һәм, ниһаять, аларның үлемнәре дә әсәрдә генә түгел, тормышта да якынча бер үк төрле. Орыш-сугышларда Аксак Тимердән җиңелүе һәм социаль заказ катнашуы аркасында Туктамыш дастанда түбәнсетелебрәк тасвирланса да, асылда ул да, Идегәй кебек үк, героик-трагик шәхес. Ике хөкемдарның тормыш юлы һәм үлеме шактый охшаш булуга һич тә гаҗәпләнергә кирәкми. Урта гасырларда, бигрәк тә тынгысыз һәм гаугалы чорларда, властька дәгъва итүче төрле нәсел яки кланнар арасында гына түгел, ә бер үк ата балаларының яки кан-кардәшләрнең дә бер-берсен үтерә-үтерә хакимият башына үрмәләве, яисә шул ук юл белән көрәш мәйданыннан китүе киң таралган гадәти күренеш булган. Бу исә, үз чиратында, күп кан коелуга һәм зур корбаннарга китергән, ил һәм халык өстенә иксез-чиксез кайгы-хәсрәт һәм бәла-каза булып төшкән.

«Идегәй» эпос-дастанында да без нәкъ шул хәлне күрәбез. Әсәрнең композицион төзелеше нигезендә ятучы, алда сүз барган күпчелек парлы яки капма-каршы буыннарның үтереш-кан коешка корылуы һәм үзенчәлекле канлы чылбыр тәшкил итүе—моның кире каккысыз дәлиле. Алтын Урданың таркалуына да асылда (әлбәттә, илдә башланган икътисадый һәм демографик кризисны да кертеп) морза-бәкләрнең нәкъ менә дәүләт тәхетенә утыру яки, киресенчә, аерылып-бүленеп чыгу өчен бертуктаусыз тарткалашуы һәм, күп меңнәрчә халыкны үлем-сугыш ялanына кертеп, үзара кырышу-кан коешуга мәҗбүр итүе сәбәп булган да инде. Чөнки бу дәүләтне

тотып торучы бердәмлекнең һәм ил куәтенең юкка чыгуына китергән. Дастанның мәрсия-сыктау характерындагы соңгы юллары нәкъ шуны раслап тора һәм киләчәк буыннарга гыйбрәтле кисәтү булып яңгырый:

*Идел-йортны дау алды,*
*Яу өстенә яу килде,*
*Идегәй әйткән көн килде.*
*Чыңгызның куйган хан тагы*
*Кан тагы булып әверелде;*
*Хан сарае камалды.*
*Кырым, Казан, Аҗдаркан*
*Башлы-башлы ил булды,*
*Алтын Урда таралды.*

Әгәр ике бәланең зуррагын атап күрсәтик дисәк, бу мәшһүр дәүләтнең таркалуына, Туктамыш һәм Идегәй кебек илне берләштерергә һәм үзәкләштерергә омтылучы олуг шәхесләрдән бигрәк, мөстәкыйльлеккә һәм аерылып чыгарга омтылучы «ыбыр-чыбырның», ягъни ваграк көчләрнең акрынлап өстенлек алуы иң зур сәбәп булган дигән нәтиҗәгә дә килергә буладыр. Туктамыш белән Идегәй көчле шәхесләр булуларын үзләре дә аңлаганнар. Беренчесенең киселгән башы сөңге очында өскә күтәрелгәннән соң да, һаваланып, Норадынга «баш әле дә синнән югары» дип әйткән булса, Идегәйнең соңгы сүзләре төбендә «киләчәк артка чигенмәсә дә, минем хөрмәт белән телгә алыначак исемем алдагы көннәргә барачак» дигән мәгънә ята. Түбәндәге хикмәтле сүзләрне башкачарак та, әмма, һичшиксез, батырларча һәлак булган Идегәйнең үзен читтә калдырмыйча аңлау вариантлары да юк түгел, әлбәттә:

*Алдагы көн агырга (кадер-хөрмәткә)*
*Без барабыз, ул килмәс.*

Үз халкы белән киләчәккә барачагына һәм тарихта калачагына каһарманның менә шулай өмет баглавы, әлбәттә, бик урынлы һәм табигый. Чөнки ул үләр алдыннан үзенең эшчәнлеге һәм көрәше иленә, туган җиренә һәм халкына багышлаганлыгы турында искәртә. Һәм шушыны халкым аңласын, белсен иде дигән теләк һәм ышаныч белдерә.

*Илем өчен илсенеп,*
*Җирем өчен җирсенеп,*
*Халыгым өчен яхшы уем –*
*Күкрәк тулып, җилсенеп,*
*Көрәшкәнне халыгым*
*Аңладымы—белалмам,*
*Аңламаса халыгым,*
*Аңлатмастан үлалмам!*

Дастанның җыйнама версиясендә дә, шулай ук Ситдыйк чичән-җырау вариантында да чагылыш тапкан бу сүзләрдә Идегәйнең төп яшәү мәгънәсе ачыла һәм ана карата халыкның чын, гадел бәяләмәсе дә нәкъ шуннан чыгып бирелергә тиеш дигән инсани фикер ярылып ята.

Җыеп әйткәндә, дастанда, олуг Кыпчак дәүләтенең юкка чыгуына зур аяныч һәм әрнү белдерелү белән бергә, фаҗигале нәтиҗәгә китергән канлы сугышларга карата ризасызлык идеясе дә үткәрелә. Тынычлык һәм иминлекне белдерүче сөт символының, алда әйтелгәнчә, әсәрдә кат-кат калкып чыгуы һәм канлы кылычны сөт белән юарга чакыру менә шуны раслап тора. Бу очракта әлеге образлы гыйбарәнең гаҗәеп көчле һәм матур яңгырашлы булуына аеруча игътибар итәргә кирәк. Татар халкы тудырган бу кинаяле образ Библиядәге «перекуем мечи на орала»

(«кылычларны эретеп сабан ясыйк») дигән саллы гыйбарә белән аваздаш.

Дастанның поэтикасы, ягъни төзелеше һәм сәнгатьчә эшләнеше турында алда өлешчә сүз булды инде. Шуларга өстәп, янә түбәндәгеләрне әйтергә мөмкин. Әсәрнең теле гаять халыкчан һәм борынгы төрки-кыпчак диалектларыннан килүче сүзләргә дә шактый бай. Шуның өстенә, поэтик сөйләм гаҗәп дәрәҗәдә образлы да. Шигъри текст урыны-урыны белән бер-бер артлы тезелеп киткән афоризмнардан, мәкаль кебек хикмәтле һәм фәлсәфи итеп әйтелгән җор гыйбарәләрдән тора. Бер мисал:

*Кол сагышын би белмәс,*
*Би сагышын хан белмәс;*
*Ярлы көнен бай белмәс,*
*Яуның серен яу белмәс;*
*Ач кадерен тук белмәс,*
*Сырхау кадерен сау белмәс;*
*Ым белмәгән тел белмәс,*
*Тел белмәгән ил белмәс;*
*Зир(алтын) кадерен зирәкләр белер,*
*Ир кадерен ирәннәр белер;*
*Күп яшәгән ни белер,*
*Күп кыдырган(йөргән) ул белер!*

Дастанда символларның роле аеруча зур. Җөмләдән, Идел-йорт—Алтын Урда яки Кыпчак дәүләтен, канлы тәхет-власть өчен барган фетнә-сугышларны, бай тирәк егылу—ханның тәхеттән төшүен, ил агасы Бодайби—гомумиләштерелгән халык образын, 17 саны борынгы төркиләрнең мифологик ышануларыннан ук килүче иң кулай берләшмәне яки магик бербөтенне белдерә. Әсәр текстының шигырь төзелеше нигезендә күбесенчә 7-7, 8-7, 8-8 иҗекләр арасында тирбәлүче традицион такмаза-дастан үлчәме ята. Поэтик тезмәләр яки юллар язма шигырьдәге кебек икешәр-икешәр яки дүртәр-дүртәр юллык строфаларга бүленми, чөнки алар, чичән-җырауның бер тын белән ярым көйләп, ярым такмаклап уку алымына буйсынып, төрле зурлыктагы строфаларга берләшәләр. Туктаусыз үзгәреп торучы һәм егермешәр-егерме бишәр юлга җитүче мондый эпик строфа төре әдәбият белемендә тирада (французчадан, «сузу» мәгънәсендә) яки, татарчалатып, сарын дип йөртелә. Урыны-урыны белән байтак янәшә юллар, бер үк төрле сузык яки тартык авазларга башланып, ягъни үзенчәлекле юл башы «рифмалары»на корылып, аллитерацион шигырь төре тәшкил итәләр. Кыскасы, поэтикасы, шигъри- сәнгати эшләнеше ягыннан да «Идегәй» әсәре—татар фольклорындагы эпос-дастан жанрының иң гүзәл һәм классик үрнәге.

# Е

**ЕРШОВ** Пётр Павлович (22.2.1815, Тобол губ. Ишим өязе Безруково а.— 18.8.1869, Тобол ш.), шагыйрь. Петерб. ун-тын тәмамлый (1834). 1836 елдан Тобол шәһәрендә яши. Гимназиядә укытучы, инспектор, директор булып эшли. Язучы буларак Е.ны аның «Конёк-горбунок» (1984) исемле әкияте танытты. Е. Себер халыклары, шул исәптән себер татарлары фольклорын өйрәнә; фольклор әсәрләренә нигезләнеп әдәби әсәрләр яза. С.-Петербургта «Современник» ж-лында 1838 дә басылган «Сузге» поэмасы нигезендә Урта Иртеш татарларынын себер ханы Күчүмнең икенче хатыны турындагы легендасы ята. В.Г.Белинский поэма хакында уңай бәя бирә. 1896 да Тобол композиторы И.Е.Корнилов поэма сюжетына «Сүзге» операсын яза. 1920 дә шул ук сюжетка Е.Г.Маляревский драма яза һәм ул һәвәскәр һәм профессиональ сәхнәләрдә куела. 1940 та поэма татар теленә тәрҗемә ителә. Е. себер татарлары риваятьләренә нигезләнеп, фольклор стилен һәм телен уңышлы файдаланып, хикәяләр яза. «Тимерче Бәзим, яхуд Зирәкле ярлы» («Кузнец Базим, или Прозорливость бедняка») пьесасы үзәгендә—прототибы жирле татар тимерчесе булган, булдыклы кеше образы.

Әсәр.: Сочинения. Омск, 1950; Сузге. Иркутск, 1984.

*А.С.Иванов.*

**ЕФРЕМОВ** Сергей Иванович (2.2.1917, хәзерге Воронеж өлкәсе Воронцовка а.—30.4.1965, Алабуга ш.), язучы. Бөек Ватан сугышы башланганчы Ленинград, Обухово шәһәрләрендә эшли. 1949 елдан Алабугада яши, Тукыма фабрикасында эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1941 нең көзендә әсирлеккә эләгә, 1943 тән яшерен оешма эшчәнлегенә тартыла. 1944 тә Дахау концлагерена күчерелә. Анда күргәннәрен «Бухенвальд кыңгыравы» («Колокол Бухенвальда», 1965) повестенда тасвирлый. Сугыш турындагы истәлекләре новеллалардан төзелгән «Севастополь дәфтәре» («Севастопольская тетрадь», 1967) җыентыгына кергән. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Гиниятуллина А. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. справ. К., 1970; Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

# Ж, Җ

**ЖУРАВЛЁВ** Тихон Кононович (13.8.1913, хәзерге Воронеж өлкәсенең Лискин р-ны Залужное а. — 24.1.1985, Казан), язучы. 1937-46 елларда Мәскәү хәрби округы «Красный воин» («Кызыл сугышчы») г-тасында, «На разгром врага» («Дошманны тар-мар итәргә»), «Суворовец» («Суворовчы»), «На страже Родины» («Ватан сагында») фронт г-таларында эшли. 1949 дан Казанда яши. Сугыш, патриотизм язучының гомере буена төп темалары булды: «Рядовой Антипов» (1950) повесте, «Сугыш турында хикәяләр» («Рассказы о войне», 1958), «Плацдарм» (1960), «Солдат турында сүз» («Слово о солдате», 1962), «Батырлык» («Подвиг», 1963), «Хәрби повестьлар» («Военные повести», 1972) хикәя һәм повестьләр җыентыклары, «Сугыш булды» («Была война», 1961) новеллалар җыентыгы. «Комбайнёрлар» («Комбайнёры», 1954) повесте, «Курган» (1955), романы, «Авыл өстендә йолдызлар» («Звёзды над селом», 1966), «Авыл повестьлары» («Сельские повести», 1980) повесть җыентыкларына кергән әсәрләр авыл тормышыннан алып язылган. Ике Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

Әд.: Шкерин М. Военные повести Тихона Журавлёва // Красная звезда. 1958. 15 июля; Гиниятуллина А. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. справ. К., 1970; Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**ҖАМАНАКЛЫ** (псевд. чын исемфамилиясе Рәшидов Кәрим Рәшид улы) (21.1.1905, Таврия губ. Кизләү өязе Жаманак а. — 1.8.1965, Алабуга ш.), шагыйрь, фольклорчы, әдәбият галиме. Кырымтатар һәм рус телләрендә язды. 1934 елда Симферополь пед. ин-тын тәмамлый. 1941 гә кадәр Бакчасарай шәһәрендә яши. Бөек Ватан сугышында катнаша. Мәҗбүри рәвештә туган ягыннан сөрелүгә дучар була. 1944 тә Сәмәрканд ун-тында укыта, 1945 тән Алабуга пед. ин-тында. Беренче

*Дәвамы. Журналыбызның 2005 ел, 4 санынннан басылып килә.*

шигырьләре 1924 тә «Яна дөнья», «Яшь куәт» г-таларында, «Элгәре» ж-лында дөнья күрә. Бакчасарайда басылып чыккан «Азадлыкъ йырлары» (1927), «Балаларга Ленин акъкында» (1939), «Ананынъ йыры» (1940), «Бахытлы халкънынъ йырлары» (1940) һәм «Достларга» (Ташкент, 1978) шигъри җыентыклар авторы. Кырым-татар фольклорын өйрәнү һәм бастырып чыгару б-н шөгыльләнә. Кырым-татар шагыйрьләре Х.Туктаргази, У.Инчи иҗатларын өйрәнә. Аерым хезмәтләре Г.Тукай, Г.Ибраһимов, М.Җәлил иҗатларына багышланган.

Әд.: Крымскотатарская энциклопедия. Симферополь, 1993; Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблогр. белешмә. К., 1986.

*В.Х.Ганиев.*

**ҖӘЛАЛ** (Җәләлев) Вакыйф (1886-1922, Ташкент), шагыйрь. Дистәгә якын шигъри җыентыклар ш. и. «Сәда-и мәдәният» (1908), «Күз нурларым» (1913), «Яна Гөлстан» (1917), «Вакыйф Җәлал шигырьләре» (1918), «Кара тормыш» (1913) исемле хикәя авторы. Әсәрләрендә заманының социаль каршылыкларын чагылдыра, татар халкын гыйлемгә өнди. Тулаем алганда, иҗатында күнел төшенкелеге хөкем сөрә. 1920 еллар башында Урта Азиягә китә, фаҗигале рәвештә һәлак була.

Әд.: Гыйлаҗиева Р. Ялкынлы моң // Казан утлары. 1992. № 5; Әхмәтҗанов М. Шагыйрь Вакыйф Җәлал эзләреннән // Мирас. 1994. №9.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ҖӘЛАЛ** Садри (псевд., чын исем-фамилиясе Вәлидов Садрислам Хәйретдин улы) (1891, Тәтеш өязе Апас а.—29.7.1943, Казан), язучы. Ж.Вәлидинең энесе. «Буби» мәдрәсәсендә (1906-10), Казан татар укытучылар мәктәбендә (1911-15) белем ала. 1918 елдан Арча кантонында укытучылар хәзерләү курсларында укыта, 1919-26 да «Кызыл Армия», «Эш», «Татарстан» г-таларында, «Безнең юл», «Чаян» ж-лларында эшли, 1927-32 дә Татар рабфагында, Казан театр-сәнгать техникумында татар теле һәм әдәбияты укыта. Ж.нең беренче хикәяләре «Ак юл», «Ан» ж-лларында 1913-14 тә басылып чыга. Аны киң катлау укучыга 19 йөз морзалар тормышыннан алып язылган «Дим буенда» (1914) исемле мәхәббәт турындагы романтик повесть таныта. «Кадерле кунаклар», «Иртә белән», «Кызыл солдатның хатирә дәфтәреннән» (1919да басыла) исемле әкият һәм нәсерләрендә Гражданнар сугышы вакыйгалары, Октябрь рев-циясеннән соң яна тормышка аяк баскан гади кешеләр образлары чагылыш таба. Ж. «Чаян» ж-лында юмористик хикәяләр һәм фельетоннар б-н катнаша. Ул публицистик мәкаләләр һәм рецензияләр яза, татар теленә Ф.Шиллерның «Вильгельм Телль» («Вилһелм Телл», 1920) драмасын, П.К.Безсальконың «Катастрофа» («Һәлакәт», 1922) повестен, М.Горькийның «Макар Чудра» (1927), «Мальва» (1928) хикәяләрен, Д.А.Фурмановның «Красный десант» («Кызыл десант», 1930) повестен, Д.Н.Мамин-Сибиряк, Дж.Лондон хикәяләрен һ.б. тәрҗемә итә. 1931 елда ул М.Х.Солтангалиев эше б-н кулга алына һәм биш елга хөкем ителә. 1935 тә аны азат итәләр. 1937 дә кабат кулга алалар, үләр алдыннан гына азат ителә. Үлгәннән соң реабилитацияләнә.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр. К., 1964.

Әд.: Агишев Я. Садри Җәлал // Җәлал С. Сайланма әсәрләр. К., 1964; Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары. Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

*З.З.Рәмиев.*

**ҖӘЛӘЛИЕВА** Мәдинә Шәйхи кызы (29.9.1925, Арча р-ны Югары Шашы а.—5.5.2005, Казан, Әтнә р-ны Олы Әтнә а.нда җирләнә) әдәбият галиме, филол. фән. канд. (1966). Казан. пед. ин-тын тәмамлый (1947). 1950 елга кадәр Бөре укытучылар ин-тында, 1953—86 да Казан пед. ин-тында укыта. Хезмәтләре урта гасырлар татар әдәбияты тарихына (кеше концепциясе), жанрлар эволюциясенә, әдәбият теориясенә (татар прозасындагы вакыт һәм пространство образы дөнья әдәбияты б-н бәйләнештә), татар фольклоры поэтикасына, аерым язучылар иҗатына (Ә.Баян, Г.Бәширов, А.Гыйләҗәв, Ә.Еники, Г.Ибраһимов, Һ.Такташ, К.Тинчурин, Г.Тукай) карый. Югары уку йортлары өчен укыту программалары, урта мәктәп өчен әдәбият дәреслекләре авторы.

Хезм.: Гумер Баширов. К., 1959; Борынгы татар әдәбиятында кеше образы. К., 1968; Әдәбиятыбызның җырлы чишмәләре. К., 2001.

**ҖӘЛИЛ** (Җәлилов) Муса Мостафа улы (2.2.1906, Оренбург губ. Мостафа а.—25.8.1944), шагыйрь, Советлар Союзы Герое (1956, үлеменнән соң). 1914-19 елларда Оренбург шәһәрендә «Хөсәения» мәдрәсәсендә, 1919-24 тә Татар халык мәгарифе ин-тында укый. 1925-27 дә Оренбург, Орск шәһәрләрендә ВЛКСМның өяз комитетларында инструктор булып эшли. 1927-38 дә Мәскәүдә яши. 1928 дән «Кечкенә иптәшләр», 1929 дан «Октябрь баласы» ж-лларында мөхәррир булып эшли, бер үк вакытта Мәскәү ун-тында укый (1927-31). 1933 тән «Коммунист» г-тасында әдәбият һәм сәнгать бүлеген, 1935 тән Мәскәүдәге Татар опера студиясенең әдәбият бүлеген житәкли. 1939-41 дә ТАССР Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы сәркатибе булып тора.

1919 да «Кызыл йолдыз» хәрби г-тасында беренче шигырьләрен бастыра. Беренче «Барабыз» исемле шигъри җыентыгы 1925 тә Казанда дөнья күрә. 1920 еллар иҗатында рев-ция һәм Гражданнар сугышы героикасына дан җырлый («Үткән юллар» поэмасы, 1924-29), социализм төзүче гади кешеләрнең романтик образларын («Орденлы миллионнар», 1934; «Хат ташучы», 1938, җыентыклары басыла 1940) тудыра. 1930 елларда романтик шартлылыктан һәм шәрекъ метафораларыннан ваз кичеп, яңа реалистик төсмерләр таба; иҗатында психологизм һәм хиссилек арта. Г.Тукайга ияреп язудан һәм аруз ритмикасын файдаланудан башлап, Җ. әкренләп, Һ.Такташ шигъриятенә һәм халык силлабик шигыренә хас булган, тоник үлчәмгә күчә. Ул популяр җырлар, романслар һәм либреттолар авторы (шул исәптән «Алтынчәч» операсы, СССР Дәүләт бүләге, 1948).

Үз иҗатында Җ. ачык, лозунгка корылган, публицистик поэзиядән («Бәхет», «Ил халкына») башлап, тасвирлы, хисчән поэтик сөйләм («Чишмә», «Сагыну») юнәлешендә үсә. Аның әсәрләре арасында балалар өчен язылган гади шигырьләр дә, көн кадагына куелган поэтик репортажлар да, шигъри фельетоннар да бар. Г.Кутуй, К.Нәҗми, Һ.Такташ, Х.Туфан һ.б. яшь шагыйрьләр б-н бергә Җ. 1920-30 елларда новаторлык эзләнүләрендә катнаша. Бөек Ватан сугышы елларында 2 нче удар армиянең «Отвага» г-тасы хәбәрчесе була. 1942 елның июлендә авыр яраланып әсирлеккә эләгә, Польша, Балтыйк буе, Германиядәге фашист лагерьлары аша үтә. Пленда вакытта Г.Кормаш төзегән татар хәрби әсирләреннән торган яшерен төркем эшчәнлегендә катнаша, аның идея рухландыручысы була. Бу төркем йөкләмәсе б-н Җ. немецлар тарафыннан татар хәрби әсирләрен «Идел-татар легион»ына тарту максатыннан пропаганда эшен алып бару өчен төзелгән «Tatarische Mittelstelle» («Татар арадашлыгы», Берлин) оешмасында эшли; анда ул легионга көчләп куып кертелгән хәрби әсирләр арасында мәдәни-агарту, гитлерчыларга каршы җимерү эшен алып бара. Яшерен оешмада катнашкан ун иптәше б-н бергә фашистларның Плецензее төрмәсендә җәзалап үтерелә.

Җ.нең сугыш еллары иҗаты сугышчан-патриотик лириканың үрнәге булып тора («Окоптан хатлар», 1944). Ул әсирләр лагеренда да, үлемгә хөкем ителгәннән соң елдан артык утырган Моабит төрмәсендә дә язудан туктамый. Аның шигырьләре антифашистик листовкалар б-н бергә яшерен оешма әгъзалары арасында кулдан-кулга күчеп йөри. 1942-44 тә әсирлектә язылган 93 шигырьдән торган ике дәфтәр, Франция, Бельгия илләре аша катлаулы юллар үтеп, 1946-47 елларда илгә кайталар. «Моабит дәфтәре» (1953) циклында аның сугышка кадәрге лирикасының героика һәм романтик мотивлары аеруча ачык чагылыш таба. Бу дәфтәрләр-совет халкының чыдамлыгы һәм батырлыгы, бөек Җиңүнең нинди хисапка ирешелүе хакында сөйләүче, җанны тетрәндергеч документ булып торалар. Бер үк вакытта төрле жанрда һәм стильдә язылган ул шигырьләрне югары поэзия дип тә атап була. Аларда эчке культура, шигъри каләмнең ныклыгы, тирән милли нигез бар. «Моабит дәфтәре»ндә тиздән киләчәк үлемне күтәп яшәгәндә кеше гомеренең кыйммәтен аңлау таң калдыра. Циклның асылы—яхшылык б-н явызлык, гомер б-н үлем арасындагы мәңгелек каршылык. «Серле йомгак», «Вәхшәт», «Алман илендә» исемле шигырьләрендә шагыйрь фашизмның бөтен тереклек дөньясына дошман булуын күрсәтә; аның өчен фашизм һәм үлем синоним булып тора. Аның соңгы шигырьләре—Ватан сакчыларына гимн.

Муса Җәлилнең шигъри мирасы күпмилләтле совет әдәбиятының аерылгысыз бер өлешен тәшкил итте. Татар поэзиясенең гражданлык яңгырашын ул героика мотивы б-н яңартты һәм баетты. Җәлил совет чоры татар поэзиясенә лирик шагыйрь буларак та, җыр текстларын язучы буларак та, зур лироэпик поэмалар авторы буларак та үзеннән зур өлеш кертте. «Моабит дәфтәре» циклы дистәләрчә мәртәбә рус, татар телләрендә басылып чыга, бүтән телләргә тәрҗемә ителә, 1957 елда Ленин бүләгенә лаек була. 1968 дә М.Җәлил исем. Татарстан комсомолы премиясе булдырылды (1997 дән М.Җәлил исемендәге Респ-ка премиясе), 1966 да Җ.гә һәйкәл куелды (сынчы В.Е.Цигаль, арх. Л.Г.Голубовский), 1970 тә Минзәләдә шагыйрьнең музее, ә 1983 елда Казанда аның музей-фатиры ачылды.

*Әсәр.:* Әсәрләр: 5 томда. К., 2006; Избранные произведения. Л., 1979.

*Әд.:* Мустафин Р. По следам обор-ванной песни. М., 1974; шул ук. Муса Джалиль. Жизнь и творчество. Довоенный период. К., 1986; Юзиев Н. Муса Җәлил поэмалары. К., 1960; Кашшаф Г. Муса Җәлил. К., 1961; Муса турында истәлекләр. К., 1964.

*Р.Ә.Мостафин*

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# ЗАМАНА МӘГЪРИФӘТЧЕСЕ ИДЕ

## КҮРЕНЕКЛЕ ГАЛИМ, ШӘРКЫЯТЬ ҺӘМ ИСЛАМИЯТ БЕЛГЕЧЕ РАВИЛ ҮТӘБАЙ-КӘРИМИНЕҢ ТУУЫНА 75 ЕЛ



Милләтебезнең асыл һәм гыйлемле улларының берсе—күренекле галим, энциклопедик хәтергә ия шәркыять һәм исламият белгече, ялкынлы публицист Равил Кәриминең арабыздан китүенә дә өч елдан арткан. Татарстанның Теләче районы Казаклар авылында туган Равил ага. Гомеренең соңгы 45 еллабын Уфада яшәде, укытты. Тарих, тел, әдәбият институтында эшләде.

Башкортстан татарлары арасында үзен дәрманлы җәмәгатьче итеп тә танытты Равил ага. Уфаның зур Мәдәният сарайлары залларында аның ялкынлы чыгышларын беренче тапкыр сиксәненче еллар азагында тынлап рәхәтлек кичерә башлады милләттәшләребез. Башкортстан Татар иҗтимагый үзәгенең һәм башка татар мәдәни оешмаларының җыелышларында катнашып, милләт язмышына кагылышлы төпле фикерләрен янгырата иде Равил ага. Менә шунда аның ни дәрәҗәдә бай эрудицияле, киң карашлы шәхес икәнлеген анларга мөмкин иде! Оратор иде ул. Бернинди кәгазьгә карамыйча, сәгатьләр буе теләсә нинди темага мөнбәрләрдән чыгыш ясый ала торган зыялы һәм дәрманлы шәхес булды Равил Үтәбай-Кәрими.

Галимне Башкортстанда да, Татарстанда да яхшы беләләр иде. Аны Казанда да, Уфада да «аяклы энциклопедия» дип йөрттеләр. Белмәгәне юк иде шул. Уфада профессор, академик дәрәҗәләрен йөрткән галимнәр дә аңа теге яки бу мәгълүматны алырга, киңәш сорарга килә торган булды. Динебез ислам һәм шәрык дөньясы турында тирән белемгә ия иде Равил ага. Гарәп, төрек һәм алман телләрендә иркен сөйләште ул. Шулай ук төрки телләрнең һәммәсен су урынына эчте.

Равил Үтәбай-Кәрими үзенең татар һәм башкорт мәдәниятен, театр сәнгате тарихын яхшы белүе белән дә сокландырды. Күренекле шәхесләребез турында сөйли башласа, әллә нинди вакыйгаларны искә төшереп, бай мәгълүмат бирә иде ул. Аксакал галимебез язган фәнни хезмәтләрнең исәбе-хисабы юк. Аларны туплап нәшер итсәң, берничә китап булачак. Равил ага гомере буена Татарстан һәм Башкортстан вакытлы матбугат басмалары белән тыгыз хезмәттәшлек итте. Аның газета-журналларда төрле темаларга дөнья күргән мәкаләләре генә дә меңләгән.

Татар һәм башкорт дөньясында бүгенге көндә Равил ага кебек чын галимнәр, халык академиклары бик аз дип уйлыйм. Дөрес, галим буларак зур дәрәҗәләр алмады. Чөнки терсәкләрен тырпайтып, дан-дәрәҗә артыннан кумады да. Күбрәк белем туплау өчен, фән дөньясына чумды. Рәсми танылу урынына, киресенчә, еш кына эзәрлекләделәр дә әле аны. Чөнки дин турында сөйләргә ярамаган елларда ук исламны, шәрык дөньясын ныклап өйрәнүе, гыйльми хезмәтләр язуы күпләргә ошамый иде. Хәтта Казаннан татар матбугатын алдыруы өчен генә дә күпләр аңа дошман итеп карый иде. Бар иде шундый еллар. Иминлек оешмаларының даими күзәтүе астында яшәргә туры килде аңа. Ләкин бернигә дә карамый, үз эшендә булды, үз кыйбласын ныклы тотты чын галим. Ә соңыннан барыбер гаделлек җинде, динебез ирек алды.

Башкортстанда һәм Татарстанда Ризаэддин Фәхреддин хакында тәүге мәгълүматларны халыкка һәм матбугатка житкерә башлаучыларның да берсе Равил Үтәбай-Кәрими булды.

1984 елның гыйнварында Башкортстан Фәннәр академиясендә чыгыш ясап, Равил ага Ризаэддин Фәхреддиннең исемен киң жәмәгатьчелек хозурына чыгарды, барлык төрки халыклар галимнәренә мөрәжәгать итеп, Р. Фәхреддиннең гыйльми хезмәтләрен бөртекләп өйрәнергә чакырды. Равил ага үзе дә шул юнәлештә биниһая зур эшләр башкарды. Әле исеме телгә алынырга рөхсәт ителмәгән елларда ук Ризаэддин Фәхреддиннең рухи мирасын жентекләп өйрәнгән Равил агабыз аның дөньякүләм дәрәжәдәге зур галим булуын киң жәмәгатьчелеккә күрсәтә һәм исбат итә алды. Р. Фәхреддиннең архивын айлар, еллар буе берәмтекләп өйрәнеп, аның байтак хезмәтләрен татар, башкорт, рус телләренә тәржемә итеп матбугатка тәкъдим итте. Оренбургта гомер иткән танылган милләттәшебез, халык галимәсе Мәдинә Рәхимкулова белән берлектә "Жәвәмигул кәлим шәрхе"н тәржемә кылып нәшер итү дә шул тырышлыкның бер татлы жимеше булды. Казанда шушы китапны бастырып чыгару бәхетенә ирешкән Равил ага соңрак аны башкортчага да тәржемә иттереп, "Агыйдел" журналында да ташка бастырды. Гомумән алганда, Равил Үтәбай-Кәриминең бай рухи мирасы арасында Ризаэддин Фәхреддингә багышланганнары гына да кырыктан артык.

Уфада Ризаэддин Фәхреддин исемендәге мәдрәсәдә мөдәррис һәм мөгаллим булып эшләгән елларында Равил ага бу олуг затның каберен эзләп табып, аны һәрдаим тәрбияләп торды, анда үзенең шәкертләрен дә гел йөртә, аларга мәшһүр мәгърифәтчебезнең, галимебезнең тормышы һәм хезмәтләре хакында бай мәгълүмат бирә торган иде.

Равил ага үз фикерен кычкырып әйтергә курыкмаган батыр йөрәкле шәхес иде. Менә шул туры сүзлелеген, акны—ак дип, караны кара дип әйтә алу сәләтен соңгы көннәренә кадәр саклый алды олуг галим. Үз-үзенә хыянәт итмичә, милләтебезгә тугры калып, бакыйлыкка саф күңеле белән күчте Равил ага. Үзенең васыятендә әйткәнчә, күренекле галим туган ягына -Татарстанның Теләче районы Казаклар авылына алып кайтып җирләнде. Аның рухына баш ию өчен Уфадан да, Казаннан да киләләр бирегә.

Равил Үтәбай-Кәриминең шәкертләре, фикердәшләре булган затлар арасында Башкортстан мөселманнары диния нәзарәте рәисе, мөфти Нурмөхәмәт хәзрәт Нигъмәтуллин, "Ихлас" мәчете имам-хатибы Мөхәммәт хәзрәт Галләм, Башкортстан дәүләт университетының татар теле бүлеге профессоры Алмаз Шәйхулов, танылган журналист һәм язучы Фәрит Фәтхуллин һәм башка зыялылар бар. Нурмөхәмәт Нигъмәтуллин фикеренчә, Равил Үтәбай-Кәрими замана мәгърифәтчесе иде. "Ул үзе генә бал кортыдай гыйлем туплап калмады, ә шул гыйлемнәрне башкаларга да юмарт өләште",—ди мөфти хәзрәт. Мөхәммәт Галләм әйтүенчә, Равил ага ана соңгы егерме елга якын чор дәвамында рухи остаз һәм тәжрибәле мөгаллим булып торган. «Мин динебез исламны өйрәнә башлаган көннән алып, Равил агабыз шушы өлкәдәге белемемне үстерүгә биниһая зур өлеш кертте,—ди Мөхәммәт хәзрәт.—Аның алтынга бәрабәр һәр сүзен йотып бара идем. Инде үзем дә динебез исламда шактый ан-зиһен туплауга карамастан, һәрдаим мәшһүр галимебезнең рухи таянычын һәм бәяләп бетергесез ярдәмен тоеп яшәдем мин. Һәм шулай ук күп имамнарга, шәкертләргә, динне өйрәнүче галимнәргә дә уртак остаз булды Равил ага".

Әйе, мөрәжәгать иткән һәркемгә риясыз ярдәм итәргә атлыгып торды атаклы галимебез. Хәзер инде безгә аның бай рухи мирасын жентекле өйрәнергә, гыйльми хезмәтләрен туплап, аларны киләчәк буыннарга да тапшыру хәстәрлеген күрергә кирәк.

**Фәнис ФӘТХИ**
Уфа

# КҮҢЕЛЕНӘ САНДУГАЧ ОЯЛАГАН...

Балачакта аны таң калдырганы ишек алдында, бакчада эшләп йөргәндә әтисенең әллә нинди көйләр чыгарып сызгырып йөрүе була. Тын да алмый шул көйләрне тыңлый ул. Үзе дә сызгырырга азаплана, әмма... Әнисенең дә сизелер-сизелмәс кенә моңланып алганын күргәне-ишеткәне бар. Бервакыт әнисенә кушылып җырлап та җибәрә әле ул. Менә монысы барып чыга... Һәм кечкенә Мирсәет, авыл янәшәсендәге болынлыкка чыгып, япа-ялгыз җырлап йөрергә күнегә башлый. Табигать ана үзе дә булышадыр кебек. Җырлый да җырлый Мирсәет!..



Әмма, җырчылыктан бигрәк, төзүче булу теләге көчле була анарда. Казанга да шул теләк белән аяк баса егет. Башкала исә аның күңеленә бүтәнчәрәк фикер сала. Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, Рәшит Ваһапов, Җәвәһирә Сәләхова җырларын көн саен радиодан ишетеп тору да үзенекен итә: күңелендә оялаган былбыл көннәрдән бер көнне үз канатына утыртып Казан дәүләт консерваториясенә алып килә. "Тәфтиләү", "Әллүки"ләр аңа югары уку йортының ишекләрен ача. Инде килеп, "Эскадрон", "Олы юлның тузаны", "Су буйлап" кебек җырларны үз төсмерләрен, үз мелизмнарын, үз аһәңнәрен кушып башкаруы бик тә өметле җырчы үсеп килүен раслый. Аны шундук күреп алалар, зур концертларга чакыра башлыйлар. Дөрес, иҗатының беренче елларында анда Илһам Шакиров чалымнары сизелә, һәр җырчының үзенә генә хас башкару алымнары булырга тиешлеген баштарак дусларча искәртүләр дә булмый түгел.

Шулай да әлеге уңайдан Татарстанның халык шагыйре Фәнис Яруллин язганча: "Ике чишмә янәшә акканда вакыт-вакыт аларның чылтыраулары да бер-берсенә охшый икән—бу табигый хәл. Димәк, Илһам Шакировның дәвамчысы бар. Тормышта да нәкъ менә шушылай килеп чыга да. Халык җырларын башкару һәркемнең дә көченнән килә торган гамәл түгел. Мирсәет Сөнгатуллин булдыра аны. Ул утыз елдан артык инде шушы изге сәфәрдә. Тарихыбыз, сагышыбыз, моңыбыз, киләчәккә өмет-хыялларыбыз салынган җырларны шул көенчә тыңлаучыга җиткерә ала. Милләттәшләребез яши торган һәр төбәктә ул—зарыгып, көтеп алынган җырчы. Һәм Татарстанның халык артисты Мирсәет Сөнгатуллин, халкыбыз җырларының һич искерми торган хәзинә икәнлеген аңлап, тамашачы алдына чыга. Аның репертуарында гына да 300 гә якын халык җыры исәпләнә. Йөзләгән

халык жырын үз эченә алган кассета да нәшер итте инде ул. Хәзер тагын 100 халык жырын кассеталар сыйфатында халыкка җиткерү өчен әзерләнә. Аны тыңлаганда уйланасың, моңланасың, илһамланасың. Җырчының көче менә шунда да инде. Мирсәет—бөтен барлыгы белән моңга уралган җырчы. Халкыбызны моң яшәткән кебек, аны да моң яшәтә һәм ул шул моңны түкми-чәчми халыкның үзенә өләшә, җыр хәзинәсе итеп кайтара.

Мин аңа тормыш хәлләренә бәйле сораулар белән дә мөрәҗәгать иттем.

—Мирсәет, улың Алмазның җырчы булуын телисеңме?

—Ничек кенә әле! Алмаз, шөкер, иҗатын халык җырлары белән башлады. Сәхнәдән иң беренче башкарган җыры "Уракчы кыз" булды. Алмаз белем алуын дәвам итә. Күп нәрсә аның үзенә бәйле. Иншалла, ул халык җырларыннан аерылмас. Хатыным Кадрия дә Алмазның җырчы булуын тели, һәртөрле киңәшләрен биреп тора.

—Кадрия үзе җырлыймы соң?

—Җырлый шул. Һәр җырчы, һәр җыр турында аның үз фикере бар. Минем белән дә, Алмаз белән дә бәхәсләшеп тә ала.

—Кайвакыт көйләрне үзең дә язганлыгыңны беләбез...

—Андый хәлләр дә була. Үземнең туган төбәгемә багышланган шигырьләргә көйне үзем яздым, үзем башкарам да. Туган ягыма багышланган җырларны миннән дә остарак кем башкарсын инде?!

Бу очракта туган төбәк дигәнне Татарстан, милләттәшләребез тупланып яши торган төбәкләр дип тә аңларга кирәктер. Ул үзен халыкка хезмәт итүгә багышлаган, халкыбыз үз асылына кайтсын, рухи байлыгын югалтмасын өчен җырларыбызны саф, самими килеш яшенә дә, өлкәненә дә җиткереп торучы. Ул елата да, юата да.

**Габделбәр РИЗВАНОВ**

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире иияләренә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**

## Шәүкәт Биктимеров



Татар сәхнәсенең күренекле артисты Шәүкәт Хәсән улы 1928 елның 28 октябрендә Казанда туа. Әти-әнисе Саба авылларында (Мингәр) мөгаллим буларак укытып йөргәнлектән, балачагының байтак өлеше шул якларда уза.

Ул 1945 елда Казан театр училищесына укырга керә. Аны тәмамлаганнан соң, Г. Камал исемендәге татар дәүләт драма театрында эшләп китә. Аңа 1950 еллар башында совет армиясе сафларында хезмәт итәргә дә туры килә.

Шәүкәт Биктимеров сәхнәгә килеп чыктымы, тамашачыны ул беренче минутларда ук үзенең ир-егетләрчә мәһабәт гәүдәсе һәм ипле-үзенчәлекле бәрхет тавышы белән әсир итә. Актерлык сәнгатенең психологик мәктәбе тарафдары. Татар театрының реалистик традицияләрен дәвам иттерүче иң күренекле вәкилләреннән. Сәхнәдә иҗат иткән дистәләрчә үзенчәлекле образлар белән таныла.

Актер башкарган төп рольләрдән кайберләре: Хәмит ("Беренче чәчәкләр" К. Тинчурин), Галин ("Габбас Галин" Г. Гыйззәт), Сәетгәрәй ("Гөлҗамал" Н. Исәнбәт), Байтимер ("Гүзәлем "Әсәл" Ч. Айтматов), Фаюнин ("Ябырылу" Л. Леонов), Әлмәндәр ("Әлдермештән Әлмәндәр" Т. Миннуллин) Ленин ("Мылтыклы кеше" Н. Погодин) һ. б.

РСФСРның К. Станиславский (1979), ТАССРның Г. Тукай исемендәге (1967) Дәүләт премияләре лауреаты. СССРның халык артисты.

## Туфан Миңнуллин



Драматург һәм прозаик Туфан Габдулла улы 1935 елның 25 августында Татарстанның Кама Тамагы районы Олы Мәрәтхуҗа авылында туган. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, районның төрле оешмаларында хисапчы, сонрак комсомол путевкасы белән чирәм җирләргә китеп, Кустанай өлкәсендә дә хисапчы бухгалтер булып эшли. 1956-61 елларда Т. Миннуллин Мәскәүдә Щепкин исемендәге Театр училищесында укый. Аннары Минзәлә, бераздан Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында актер булып эшли. Казан телестудиясе, " Чаян" журналы редакциясе...

Ләкин ул татар әдәбияты тарихында язучы һәм җәмәгать эшлеклесе буларак ныграк танылды. Драматургия жанрында күп кенә данлы әсәрләрен иҗат итә. Аларны шушы кыска гына сүздә санап чыгу мөмкин түгелдер. Ләкин иң мөһимнәрдән берничәсен санап китик: "Миләүшәнең туган көне", "Канкай улы Бәхтияр", "Әлдермештән Әлмәндәр", "Моңлы бер жыр", "Дуслар жыелган жирдә", "Үзебез сайлаган язмыш", "Әниләр һәм бәбиләр".

Драматург тормыш материалын, үзен борчыган иҗтимагый һәм әхлак проблемаларын сәнгатьчә хәл итү, заман кешесенең рухы дөньясын тамашачыга үтемлерәк житкерү өчен төрле жанр һәм алымнарга еш мөрәҗәгать итә.

Татарстан комсомолының М. Жәлил исемендәге (1974), ТАССРның Г. Тукай исемендәге, РСФСРның К. Станиславский исемендәге (1979) Дәүләт премияләре лауреаты. Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе. Татарстан әдипләренең X съездында (май, 1984) Союз идарәсенең рәисе итеп сайланды. Бүгенге көндә—Татарстанның халык депутаты.

**Альфред АБДРӘШИТОВ**

# ХАТЛАРДА ДА БЕЗНЕҢ ЯЗМЫШ

**Соңгы айларда әкренләп кенә дистә еллар буе өемдә җыелган өем-өем, папка-папка кәгазьләрне барлап утырам. Алар—шигырьләр, мәкаләләр, чыгышлар, беркетмәләр, рәсми документлар, тәрҗемәләр, чакыру кәгазьләре, телеграммалар... Күрәсең, аларны беркадәр тәртипләргә миңа да Вакыт җиткән. Архивым, әгәр аны архив дип әйтергә ярасa, шактый бай (өлкән яшьтәге кешенең берәр төрле байлыгы булырга тиештер инде!). Саргайганрак кәгазьләрне актарганда, "эт картайса, койрыгын сөйрәр, кеше картайса, үткәнен сөйләр" дигән шактый усал әйтем дә искә төшеп ала. "Үткән белән яшәгәннең киләчәге шикле" дигәне дә хәтергә килә. Хаклык юк түгел бу әйтемнәрдә. Әмма тагын бер олы хакыйкать бар: Хәтерсез халык—бетүгә хөкем ителгән халык. Тикмәгәмени: баскынчылар яуланган халыкның, җелеген суырган шикелле, иң әүвәл Хәтерен бетерергә тырышалар. Хәтер ул—Тарих. Ә тарихсыз—шәхес тә, халык та, милләт тә була алмый.**

**Язмышка рәхмәт: гомерем буе күңел тарткан, яраткан эшем белән шөгыльләнергә мөмкинлегем булды. Бу яктан мин бәхетле кеше. Исән-сау, сәламәт килеш инде ярты гасыр чамасы Әдәбиятта хезмәт итәм. Язу эшенә яшьли кереп, язучылар, гомумән, әдәбият-сәнгать дөньясының үзәгендә кайнарга насыйп булды. Моны раслау өчен, күп дәлилләр китермичә, шуны әйтү генә дә җитә кебек: инде кырык елдан артык, бер өзлексез Татарстан Язучылар берлегенең Идарә әгъзасы булып торам икән. Үзе бер гомер! Әдәби даирәдә кемнәр генә күрелмәгән дә, нинди генә хәлләр кичерелмәгән! Узган гасырның соңгы дистә елларында, СССР һәм РСФСР Язучылар союзларының идарә составында булып, күп милләтле совет әдәбиятының байтак күренекле вәкилләре белән даими аралашып яшәргә туры килде. Съездлар, халыкара симпозиум-конференцияләр, әдәбият көннәре, пленумнар, юбилей тантаналары... Очрашулар, аралашулар күп булды. Идеология бер яклы булса да, әдәбиятка ышану көчле иде, кешеләр арасында ихлас мөнәсәбәт тә зур иде. Очрашуларга сыймаган хис-тойгылар бер-беребезгә хатлар аша җиткерелде. Заманында күп хатлашканбыз икән! Килгән хатларның якынча да исәбен әйтә алмыйм әлегә. Әйтик, рәссам Әхсән Фәтхетдиновның миңа юллаган хатларын җыйнап бастырсаң да, үзләре берничә калын китап булыр иде!**

**Хөрмәтле укучыларыбызга, шул елларның хатирәсе буларак, архивымда сакланган хатларның бер бәләкәй өлешен тәкъдим итәм. Хатларның адресаты мин булсам да, аларның байтагы, шәхси мәнфәгатьләргә караганда, күбрәк әдәби хәрәкәткә, иҗтимагый хәлләргә бәйләнешле. Аларны укып шул чор (60-80 еллар) атмосферасын, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтен, әдәбиятка, рухи дөньяга карашларын беркадәр күз алдына китереп була шикелле. Әгәр хатларның башында "хөрмәтле Р., кадерле, уважаемый, дорогой" кебек сүзләр бар икән, зирәк укучыларыбыз аларны эпистоляр жанрның стиль үзенчәлеге итеп кабул итәр дип уйлыйм. Тукайлар заманында да хат башлары, гадәттә, "хөрмәтле вә гыйззәтлебез" дип башланган бит. Бигайбә!**

Равил ФӘЙЗУЛЛИН<br>13 июль 2008

* * *

Равил иптәш Фәйзуллин!

Миңа кыска язуыгыз һәм фикер әйтергә омтылуыгыз ошады. (Сүз «Чаян» журналына җибәргән шигырьләр турында бара.—**ред.**) Әйбәт сыйфат. Инде теләгәненне төгәл итеп әйтеп бирүгә ирешергә кирәк.

Беренчесендә, мәсәлән, "рецензияләр яза башлады" дию генә йомшак. Ачыграк итеп—башкаларны шигырь язарга өйрәтә башлады дигәндә отышлырак булыр. Кабат эшләп карагыз әле.

Икенчесенен дә фикере әйбәт. Дөрес тотып алынган бу. Ләкин "шул вузга", "колхозга" дип рифмалаштыру унышлы түгел. Мондый кечкенә әйберләр бигрәк күренә бит ул.

Яна әйберләрегезне җибәрә торыгыз.

*Укуыгызда уныш теләп,*
*"Чаян" хезмәткәре:* ***Шәүкәт Галиев.***
*Казан, 29 апрель 1959 ел.*

---

Шәүкәт Галиев (Идиятуллин) Гали улы (1928)—Татарстанның халык шагыйре (1995).

* * *

Равил!

1

*Кем күккә таш орды?—*
*чәлпәрәмә килгән ич күк, чәлпәрәмә.*
*Текәлеп тәрәзәгә,*
*түшәгемнән сикереп тордым:*
*кем күккә таш орды?*

*Ныклап баксам,*
*Күк йөзендә бары*
*шәрә калган алмагачның*
*чәчрәп киткән ботаклары...*

Бу минем бүгенге иртәдән алган тәэсирем. Тагын да ныклабрак уйлагач, менә мондыйрак фикергә килдем: вакытның һәр секунды безнең аң аша үткәндә акыл күзәнәкләренә үзенең я шатлыгы, я кайгысын, я шомын, я ... башка нәрсәләрен салып калдыра һәм иҗади аң өчен шул җитә кала—китә я шатлыклы, я кайгылы, я шомлы шигырь. Хат башындагы әйбер безнең мондагы кәефне бераз гына чагылдыра. Анлыйсындыр инде—бәйрәм... шатлык һәм анын антилары... Минем үземнен бу мәсьәләдә кәефләр нормальный. Партиягә кердем.

2

Әй, малай! Теге чактагыча, урам уртасына басып сез катык эчкәндәгечә, синең белән бер сыра дингезенә чумып, сырадагы күбекләрне шартлатып-шартлатып... Җөмләне ахырына хәтле житкереп тормыйм—болай да аңлашыладыр. Давай, кайт тизрәк! Билгеле, бәйрәмнәр үткәч, алайса—

*Кем безнең төннәрне тыныч,*
*Таңны шатлыклы итәр?..*

Шагыйрьнең кулында (автомат?), (пистолет?) Да, малай!

Ә бер карасаң, шагыйрьнең кулында җирнең барлык иң чиста, иң әшәке, иң көчле, иң дәрмансыз, иң саф, иң коскыныч... әйберләре дә бер генә мәртәбә булса да булырга тиеш.

Кайвакытта мин болай уйлыйм: шагыйрь нәфрәтнең, мәхәббәтнең, дуслыкның, дошманлыкның һәм башка бик күп абстракт төшенчәләрнең төрле төсмерләрен үз йөрәге белән татып карый. Ләкин бөек төшенчәләр рәтендә х ы я н ә т дигән төшенчә дә бар. Ул аны да татый—... менә шуңа күп шагыйрьләр сөекләренә хыянәт итәләрдер дә. Илгә хыянәт итмәс өчен... Минем үземә калса—аң пакьлеге тән пакьлеге аша гына. Икесе бергә—җан пакьлеге, намус. (Әлегә).

## 3

Яңалыклар. Кординаль үзгәрешнең булганы юк. Шушы арада ике кызыклы җыелыш булды. Берсе: “Яшь һәм башлап язучыларга ярдәм” дигән мәсьәлә каралды. Икенчесе—“Казан утлары”ның 7-8-9 саннары турында фикер алышу.

Беренчесе буенча. Яшьләр шактый гына резкий, кырыс чыгышлар ясадылар: Р. Мингалимов, Ә. Синегулов, Т. Миңнуллин һ. б. Гомумән алганда, сүзләренең төбе—яшьләр журналы кирәк. Син 9нчы сандагы Н. Фәттах мәкаләсен укыгансыңдыр инде. Рөстәм шул мәкаләгә дә бераз тукталды. Иң кырыс чыгыш Миркасыйм Гәскәревнеке булды. Аның бер фикере: “Н. Фәттахны мин ихтирам итә идем. Бу мәкаләсен укыгач, аның әдәбият теориясендә профан икәнлеген аңладым”. Каты бит, ә? Г. Ахун, М. Әмир, Л. Ихсановалар, И. Юзеевләр: “Ярдәм итәбез бит, китапларын чыгаралар ич!” Ш. Рәкыйпов: “Егетләр—“Беренче карлыгачлар”! Бу үзе генә дә нинди ярдәм!!!”

Икенчесе хакында: Күзәтүче (оппонент) А. Гыйләҗев иде. Бәширне тетте. Г. Минскийны тетте. Гришаның, аның шигырьләренең гомумән ошаганын әйтте. Шәүкәт абыйның шигырьләрен, Х. Камал поэмасын мактады. Н. Фәттахка: “Нигә син яшьләргә кусәк күтәрәсең? Тоның начар синең...” диде.

Бу җыелышта мин дә чыгыш ясадым. Тезислар: 1. Н. Юзиев, Г. Халит мәкаләләре ише мәкаләләр белән яшьләргә ярдәм итеп була. (Яшьләр әдәбият теориясен шактый яхшы беләләр, чөнки югары белемлеләр)... 2. Р. Фәхретдинов һәм Ф. Вәлиев мәкаләләре ишеләр икеләтә яхшылар, чөнки алар сәнгатьче белән халык арасындагы аралыкта үткәргеч ролен үтиләр. Ягъни шагыйрьне масса өчен аңлаешлы итүдә булышалар. Бу кирәк, чөнки шагыйрь масса дәрәҗәсенә төшсә—ленинча булмый. 3. Н. Фәттах күрсәткән услуга—медвежья услуга, чөнки ул теоретик яктан гаҗәеп сай (беренче абзацка гына игътибар ит әле, аңларсың: бу дөньяда “балалар әдәбияты” дигән жанр бар икән... (!)), икенчедән, аклыгы аксиома булган нәрсәләрне кара дип исбатларга тырыша (ритмика, созвучие мәсьәләләре), өченчедән, нәрсә сөйләргә кирәген белми сөйли (“Беренче китап һәм балалар әдәбияты” дигән баш астында нинди проблема күтәрергә тиеш иде ул? Ә?)... Әгәр тәнкыйть шундый булса, һәм ул журнал битләрендә шул рәвештә күренсә, яшьләр өчен дә, журнал өчен дә файдасыз.

“Книга времени” дигән бер китап чыкты. Редакторы Н. Беляев. Синең “Непростой гимн”ың бар. Минем өч шигырь кергән, өчесе дә Н. Беляев тәрҗемәсендә.

“Зимная орбита”ны (татар шагыйрьләренең рус телендә чыккан китабы.—**ред.**) син беләсең инде.

Декабрь аенда Язучылар Союзы яшь авторлар конференциясен үткәрергә җыенып йөри. Сөйләүләре буенча масштаблы булырга тиеш. Гриша да, мин дә катнашабыз. Бәлки, син дә кайтып өлгерерсең әле. Тыңлап утырырга.

Күптән түгел Мәскәүдән А. А. Штейнберг дигән бер тәрҗемәче килде. “Дружба народов”тан. Әлеге дә баягы без өчәү берничә подстрочник биреп җибәрдек. Синең кайбер әйберләреңне (китаптан) бирмәкче идек тә, мина Союздан бирәләр аны, мәшәкатьләнмәгез, диде. Кирәк дип саныйсың икән—миңа җибәр, мин подстрочниклар ясап Мәскәүгә олактырырмын.

Тагын бер яңалык. Мин һәм син (син—так себе гына) “Чаян”га эләктек. А. Яхин “Болай тезсән” дигән фельетон язып чыкты. Минем уйлавымча—“Болай тезсән—йөз дустың арта”... дигән юллар аңа бик охшаганнар, аңа рух һәм идея биргәннәр. Шул идея синең белән мине дә “Чаян”га сөйрәп кергән. Ул фельетонда мин әйтмәгән фикерне миннән әйттергәннәр. “Аҗаган” (Р. Ф. ның икенче китабы.—**ред.**) өчен мине каккалыйлар. Шәп, между прочим.

## 4

Гриша, Рөстәм, Марс искечә генә яшәп яталар. Гриша хатынын, әнисен һәм баласын Казанга күчерде. Рөстәм Радиф фатирында ята. Марс сәяхәтнамә яза. Ив. Данилов “Салдымышкин” көенә җырлап, “хатын аеру” дигән операда прима рольдә. Н. Беляев һаман эшкә урнаша алмый аптырап йөри. Р. Кутуй турында бер сүз дә әйтә алмыйм—хәбәрдар түгелмен. Борис Хәлимов хәзер Айдар Халим. Ул өйләнде—баллы-майлы-җайлы-айлы көннәр кичерә. Ш. Маннапов турында ни әйтергә дә белмим. Яши!

Ш. Мәхмудов сирәк кенә хат язгалый. Ул бик нык эшли. Кызыклы һәм тирән шигырьләре күп.

5

Наилә, Лилия сиңа бик күп сәлам әйтәләр.

6

Давай, кайт! Кабан өстеннән бу күтәрелә.

Ялгыштым ла—Кабан өстеннән синең сагышың күтәрелеп, болытка әйләнде инде. Казан өстендә көн-төн яңгыр, тамчылары Миля (Бикә Рәхимова.—**ред.**) керфегендә. Давай, кайт! Каешың белән билең бу да, кайт! Башыңны салларга салып!

*__Ренат__ бу.*

*Казан, 28 октярь, 1967 .*

Ренат Харис (Харисов) Мәгъсүм улы (1941)—Татарстанның халык шагыйре (2004). Р. Харис ул елларда "Яшь ленинчы" газетасының җаваплы сәркәтибе булып эшләде. (Хат Р. Фәйзуллинның солдат хезмәтендә булган чакта язылган.—**ред.**)

* * *

Равил, исәнмесез!

8 нче сандагы ("Казан утлары", 1968.—**ред.**) шигырьләрегезне укыдым. Бүтән берәүнекенә дә охшамаган бик үзенчәлекле шигырьләр. Тормыштагы тышкы күренеш, тышкы буяулар белән мавыкмыйча, "күңел диалектикасы"н анализлау—әдип һәм шагыйрь өчен бик күркәм сыйфат. Шигырьләрегезнең бу ягын хуплыйм, икенче бер ягын тәнкыйтьләргә исәп.

Кайберләре бик абстракт, заман рухы сизелми, сүз кайвакыт хакында—аңлашылмый, теләсәң ничеккә юра... Мәсәлән, беренче шигырь. /"Балачактан туры..." дип башлана/ "Кире беткән чирү китмәк булды таптап"—бу нинди чирү, кай заман, сүз ни турында—аңлап булмый. "Ашканда, чапканда хөрлеккә йөз төбәп..."—күктә асылынып тора торган абстракт хөрлек. "Тамак-өс кенә—безнең җанга, дидек,—булыр кечкенә!" Бусы инде ниндидер претензияме? Кемгә карый бу претензия? "Нәни йөрәк" белән кемгә каршы көрәштек?

"Элегияләр"дә күңел төшенкелеге бик зур урын ала. "Кара шәмнәр" кабызырлык нинди сүнгән еллар икән ул? "Күзләрдә яшьләр, яшьләр..." "Күңелдә сагыш, сагыш..." "Эчләрдә ялкын, ялкын"—дөнья куярга вакыт җиткән карт шагыйрьгә, янәсе, шулай сагышлы, күзләрендә яшьләр, эчләрендә ялкын... Мин, мәсәлән, үз замандашларымны яхшы беләм, без—китәсе буын, яшь буынга—сезгә андый ышанычсызлык белән һич карамыйбыз, без беләбез—яшьләр кыланачак, кыланачак та табигый юлга төшәчәк, безнең кебек үк /бездән әйбәтрәк!/ эшләп барачак, ә безнең күзләрдә яшьләрнең булганы юк, күңелебез дә сагышлы түгел. Шушындый рухтагы шигырьне күбрәк укысаң инде, бәлки... күңел төшүе ихтимал /анда да безнеке түгел, тәҗрибәсез яшьләр күңеле/.

"Сөю көчле иманнан..." Әйе, мәхәббәт бик көчле... Монда сүз, һәрхәлдә, мөселман иманы хакында бармый, гражданский иман хакында бара... Гражданский иман бик зур нәрсә ул—дөньяви сыйнфый фәлсәфәң була инде ул гражданский иман... Тарас Бульба үзенең улы Андрейны, иманын мәхәббәткә алыштырган өчен, үз кулы белән атып үтерә...

Әлбәттә, Сезнең шигырьне укуга берәр тиле гашыйк мәхәббәт өчен илен сатар дигән сүз түгел, әмма яшьләр күңеленә нинди фикер салабыз?

"Теләге бәхеттә иде"—әйтергә теләгән фикерен шагыйрь монда бик оста әйткән. Тик фикере нинди? Соң дәрәҗәдәге өметсезлек!

Кайбер шигырьләр бөтенләй аңлашылмый. Табышмак, шифровка! Мәсәлән, "Күпсенмә, күк!"

Күңелгә уй төшә: каян килгән Сезгә, яшь кешегә, мондый абстрактлык? Мондый замансызлык? Сәбәбе ни моның? Тормышны белмәү дип булмый, Сез инде азмы-күпме

дөнья күргән, армиядә булган, ә төшенкелек каян килгән? Моны шигъри алымнарга гына кайтарып калдырып булмый, бу—дөньяга караш, фәлсәфә.... Нәрсә белән аңлатабыз моны? Яшь шагыйрьнең авызыннан дөньяның гүзәллеге, көрәшнең матурлыгы хакында ишетү табигыйрәк булыр иде.

*Сәлам белән,* ***Ибраһим Газый.***
*Казан, 12/IX-68.*
*P.S. Тәнкыйтем өчен үпкәләмәссез дип уйлыйм.*
*И.Г.*

Гази (Мингазиев) Ибраһим Зариф улы (1907-71)—язучы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. 1968-71 елларда Татарстан Язучылар союзының рәисе булып эшләде.

* * *

Равил дус!

Сиңа Малеевка урманнарыннан кайнар сәламнәр юллыйм.

Килеп урнаштым, ял итү әлегә бик эләкми, коточкыч арылган икән, аллә ниткән төшләр керә, көндез язу белән уза. Шулай да нервылар тынычлана кебек.

Үзең Зур Союзда эшли башлагансыңдыр инде. Анда безнең Лениногорск егете Альберт Хәсәновның союзга керер өчен делолары калган иде, Хөршидә апа сиңа бирдеме аны? Шул делоларны Прием комиссиясенә тапшырырга кирәк бит инде. Тагын бер йомыш: күрәсең, бу юлы Ренат Харисовны да карарлар комиссиядә, Ренатка әйтә күр, үзе иң яраткан бер 10 шигырен (сиңа да ошаганнарын) подстрочник ясап куйсын.

Мәскәүдә быел без җибәргән кандидатураларны Союзга кабул иткән чакта Гәрәй Рәхимгә бераз ыңгыраштылар, имеш, китабы бик юка, диделәр. Андый чакта подстрочник булса әйбәт була, диде Ладонщиков. Монысы Ренатны яратканнан—алдан әйтеп куюым. Өченче йомыш—Татиздатта эшләүче Рәйсә Каюмовага Әнәс Камал исталегең тәрҗемә итәргә биргән идек (подстрочник). Әгәр эшләгән булса, Союзга тапшырса, шуны "Лит. Россия"гә җибәрегез. Илгиз Кәримов исеменә (М. Кәрим малае). 6 январьда Г. Камалга 90 яшь тула бит. Ф. Кәрим хакында З. Мәҗитов "Лит. Россия"гә язса шәп булыр иде. Юбилей комиссияләре төзедегезме?

Тагын. Кемнәр кайда, кайчан чыгыш ясый—язып, теркәп бар, яме. (Союз буенча). Пропаганда бүлегенекен Мөнип үзе бирә.

Соңгысы. Мин кайтканчы үзеннең җыентыгыңны әзерләп бетер. Бергәләп Мәскәүгә җибәрербез.

Барлык изгелекне телим.

Ибраһим абыйга күп сәлам.

***Гариф Ахунов.***
*Мәскәү, 2/XII-68*

P. S. Союздагы апаларга сәлам әйтерсең. Эшләр турында кыска гына бер хат язсаң— иллә дә шәп булыр иде.

Гариф (Гарифҗан) Ахунов Ахунҗан улы (1925-2000)—Татарстанның халык язучысы (1993). 1968-71 елларда Татарстан язучылар союзының җаваплы секретаре. Г. Ахунов Мәскәүгә кыска сроклы курсларга укырга киткәч, вакытлыча ул вазифаны миңа башкарырга туры килде. Хат шул вакытта язылган (Р. Ф.).

* * *

Исәнмесез, кадерле шагыйрем Равил!

Казанны сагынганда, әлбәттә, Сезне сагынмый мөмкин түгел. Чөнки иң соңгы иҗат җимеше бергә үстерелде ич! Ерак-ерак Андижан шәһәреннән, әллә ничә мең чакырым җирдән кайнар сәлам!

Равил! Үзегезгә мәгълүм, мин опера-балет театры артистлары белән концерт гастроленә киттем ич. Менә шул концертларда Сезнең исем һәр көн, һәр кич кабатлана. Концертны алып баручыбыз, сүз остасы Әзәл Яһудин сезнең "Улымның бар дүрт сүзе" һәм "Алладың,

хыял" шигырьләрен укый һәм алар зур уңыш белән бара (зур мәвәффәкыять белән баралар). Яһудин аларын бик кызык-мавыктыргыч итеп оста башкара.

Мин концертның иң башында (мине Яһудин халыкка матур итеп сөйләп, концертның беренче бүлеге минем иҗатыма багышланганны һәм музыка өлкәсендә шактый зур өлеш керткән, халыкның ихтирамын казанган, дип, мине тәкъдим итә). Чыгыш ясап, Татарстан кырларыннан, киң Идел ярларыннан, Татарстанның эш сөюче хезмәтчел халкыннан сәламләп, аз гына үземнең ничек артистка һәм композитор булып киткәнемне әйтеп, саулык-уңыш-тыныч тормышлар теләп кереп китәм. Халык бик алкышлап каршы ала. Мин, әлбәттә, чит илләр, чит тормышлар, төрле-төрле халык күреп, тагы да киң карашлар, киң уйлар, зур хисләр җыеп кайту ягыннан үкенмим. Ләкин миңа бу коллектив белән чыгарга кирәк булмаганын да аңладым. Кайткач, уйларым белән бүлешермен әле. Үзегездә ни хәлләр бар?

Казанны сагыну, Казанның һәр ташын сагыну зур инде. Андижанның урамнарында йөргәндә каядыр әтәч кычкырды да, шунда туган яклар искә төшеп, мин болай дидем:

*Йөргән чакта Андижанның урамында*
*Ишеттем мин әтәч тавышын.*
*Чолгап алды мине шул чагында*
*туган илләремнең сагышы.*
*Күргән кебек булдым, болыннарны,*
*Челтерәп аккан чишмә тавышын,*
*тезелеп киткән якты, матур өйләр*
*туган шәһәремнең һәр ташын...*

Читтә йөреп, үз иленне сагынгач, шагыйрь дә булып була икән!..

Равил туган! Без хәзер Андижанда концертларны бетереп, 8нче майда Фирганәгә күчеп, бер атна шунда эшләп, 15ендә Казанга кайтачакбыз. Һәр көн саен Хәсән Туфанның "Казан кичләре" яңгырый. Сәлам әйтегез үзенә. Һәр көн Нәби Дәүлинен "Иң якын дус—беренче дус"ы яңгырый. Сәлам әйтегез аңа.

Хатымны бетереп, сезгә кабат сәлам һәм иҗади бәхетләр теләп:

**Сара апаң Садыйкова.**
*Андижан. 4 май, 1973 ел.*

---

Садыйкова Сара Гариф кызы (1906–86)—композитор, актриса, җырчы. Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1990).

* * *

Исәнме Равил!

Хатыңны алдым, рәхмәт. Үзем дә һаман хат язмадым, теге фотоларны эшләп булмасмы, дип. Очрашу, Амет-хан Солтан һәйкәленә чәчәкләр салу турында Симферополь радиосыннан һәм "Советский Крым" газетасында информацияләр булды, ләкин газетаны эләктерә алмый калдым, 1 генә данә бар, кайткач күрсәтермен. Фотоларны берничә мәртәбә эшләтеп карасам да, начар чыктылар. Рәис (Рәис Даутов.—**ред.**) сиңа бирәм дип алып киткән иде, алгансыңдыр.

Бик шәп итеп яздым. Яңа повесть язам, кулдан 180 бит яздым (машинкада 130 битләр булыр), ләкин әле бетмәде, тагын 60-100 битләр булыр. Үземә ошый, кешеләр нишләр? Баштанаяк мәхәббәт, сөю-сөешү, зина кылу турында.

Равил, хәзер бит мин Алуштадан Ялтага килдем. Дом творчестводан тауга табан 300-400 метр күтәрелсәң, безнең санаторий була. Чехов исемендә, чөнки аны революциягә кадәр Антошка ачкан. Монда килүнең сәбәбе дә бик үк күңелле түгел. Бу хирургия санаториясе. Аңлашыла ки, миңа операция тәкъдим итәләр. Аптырадым инде, бармак бите кадәр генә урында чир бетеп бетми. Врачлар кисәргә, бары тик кисәргә генә тәкъдим итәләр. Чөнки инде иң дефицит, иң көчле дарулар да эчелеп бетте. Йөрдем-йөрдем дә, риза булдым. Озакламый кисәрләр. Ләкин операциянең кайчан буласын хатынга

әйтәсем килми, борчылмасын, болай да ел азагы нәшриятта эш бик күп. Бераз терелгәч, операция булды дип әйтермен.

Менә шундый хәлләр әле миндә. Ләкин бик борын төшермим, бик оптимистик рәвештә барам. Тик операциягә кадәр повестьны гына төгәлләп булмады, хет черновой вариантны бетерергә кирәк иде.

Рөстәм белән Рәдифтән хат алдым, Ренат та язгалап тора.

Ярый хәзергә. Минем адрес: Крым, г. Ялта, сан. им. Чехова, кор. 3 пал. 21.

***Гәрәй.***

*3.12.72.*

---

Гәрәй Рәхим (Родионов Григорий Васильевич. (1941)—шагыйрь, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1984).

* * *

Равил!

Әлмәтнең Радищев урамы, 20 нче йорт, 17 нче фатирдан (бу йортта 1960-70 нче елларда Гариф Ахунов һәм Равил Фәйзуллиннар гаиләләре белән яшәде.—**ред.**) сәлам сиңа!

Син хәзер секретарь булып эшлисеңдер, яна пост белән котлыйбыз!

Синең "Наз" исемле китабың чыккан, шул китабың белән котлыйм! Ул китап әле китап кибетенә тиз кайтмас, укый торырга, бәлки, берне җибәрә алырсын, ә?

Шуннан сиңа—рәсми кешегә рәсми йомыш бар иде. Син баш бухгалтер янына мөбарәк тәпиләрең белән үзең менеп әйт әле, ул безгә акча җибәрсен, күп җибәрсен, ул секретарь кешенең сүзен тынлар, бәлки. Анда минем күпме акча калган икән, шул сумманы бер кәгазьгә язып җибәр әле, семья бюджитен (сметасын) төзегәндә аякны күпме сузарга мөмкин икәнен белү фарыздыр.

***Гамил Афзал.***

*11 декабрь, 73 ел. Әлмәт.*

---

Афзал (Афзалов) Гамил Гыймазетдин улы (1921-2003)—Татарстанның халык шагыйре (1991).

* * *

Күп сәламнәр сиңа, Равил абый!

Җибәргән китабыңны алдым, бик зур рәхмәт. "Наз" Ерак Көнчыгышка килгәч мин укыган беренче татар китабы булды. Аннан алданрак Хабаровскидан Сибгат Хәким шигырьләрен табып алган идем, Мәскәүдә чыккан соңгы китабын. Ә шулай да "Наз"ның тәэсире көчлерәк булгандыр, ахры. Ни өчен дисәң, үземнең күңелдә дә шул рухтагырак юллар туа башлады. Менә берсе:

Казарма тулы жегетләр йоклый.

Ә каядыр кызлар тулай тораклары да бар бит...

Бу үземчә шаяру булды инде. Теге: "тик торганда үлеп китте Владимир Ильич", дигәндәй.

Тормышка килгәндә—артык авыр түгел. Вакыт калган саен укырга һәм шуларны переваривать итәргә тырышам. Пока бераз вакыт бар, алда тагын ничек булыр. Кайчагында бу ике елның булуы әйбәт тә түгел микән әле дип уйлап куям. Ә дөресен бер Алла белә инде.

Ярар, Равил абый, вакыт ягы сездерә башлады. Сиңа иң шәп теләкләр белән: Мансур.

Ә "Наз" турында дөресен генә әйткәндә, ул мин көткәннән күпкә әйбәтрәк булып чыккан. Һәм тагын да эчтәгерәген әйткәндә, синең иҗат минем өчен байрак булуын дәвам итә.

P.S. Ноябрьда без үзебезнең хезмәт итү урынына—Спаск-Дальний шәһәренә кайтабыз.

Приморский край, Спаск-Дальний-13

Краснознаменная 11, кв. 43.

*Мансур Вәлиев. 19.10.73*

---

Вәлиев Мансур Хажи улы (1948)—язучы, әдәбият тәнкыйтьчесе. Озак еллар "Казан утлары" журналында бүлек мөхәррире булып эшли.

* * *

Mon cher, my dear, дорогой Равиль, кадерлебез!

Сәлам сиңа вә сөекле гаиләңә—дингез ярларыннан, Кырымнан! Вә күп догалар Сиңа!

Күптәннән җыенсам да, тиз үк яза алмадым. Әүвәл, шактый вакыт, суык тидереп йөреп, кәефсез идем. "Бүрегә бәхетне тешләрен сындырып бирә" дигәндәй, гомергә бер эләккән дингездә дә тиз генә коена алмадым. Хәзер менә коенам, кызынам, "ялкаулык итәм"—шулардан җаныма "саулык кѳтәм".

Мин күзаллаганча ук булмады бу җирләр. Пожалуй, степной Крым булгангадыр. Дингез дә суыграк монда, табигать тә ярлырак. Иске Кырым, Бакчасарайларга барып кайттым—анда исә матуррак, җанлырак табигать икән. Бигрәк тә Бакчасарай тирәсе кызык. Дингездә катерда да йөреп карадым—Карадаг тавын дингездән карау кызык икән.

Иҗат йорты шартлары әйбәт. Ашау-эчү дә... Публика—күбрәк мәскәүлеләр, берничә срокка калып, көч җыялар. Шактый сноб халык, тәкәббер. Юан, ямьсез хатыннары, чыр-чу килгән балалары белән яр буен тутырып яталар.

Сиңа ошамас иде, пожалуй, бу җирләр. Синең натурага ят бу ял шартлары, минемчә. Иптәшләр белән бергә-бергә булганда инде, бергәләп сәяхәтләр, прогулкалар, тауга менү, сөйләшүләр, бәхәсләр—менә бусы шәп булыр иде. Монда мин Габдулла Шәрәфи гаиләсе белән аралашам. Уфадан—кайчандыр бергә укыган башкорт, тәнкыйтьче, галим, Роберт Баимов монда.

Евтушенко, гадәттәгечә, эре-эре адымнар белән йөреп ята.

Чиләбедән—русча язучы татар, прозаик Рөстәм Вәлиев бар. Безнең язучылар белән таныш, күбесен белә икән. Татарча бик яхшы белә, культура-сәнгатьтән хәбәрдар, гомумән, яхшы егеткә охшый.

...Бүген Феодосия шәһәренә барып кайттым. А. Грин музеена кердем. Дингездә коенып алдым. Феодосия—әлләни матур түгел. Әмма мондагы шәһәрләрдә обеспечение яхшы: халык рәхәт яшәргә күнеккән. Без галахларга бу нәрсә авыр тәэсир итә. Тукайча:

Я ходай, без нигә болай соң, без дә хакның бәндәсе...—дип куясың. Әлех...

"Казан утлары"ның 6нчы санын җибәрделәр. Мансур Вәлиевның мәкаләсе (сүз тәнкыйтьченең Р. Фәйзуллин иҗатына багышланган "Безгә ак болыт булырга язмаган шул..." дигән хезмәте турында.—**ред.**)—тәбрик аңа!—бик әйбәт, аңлап, бик җитди һәм әдәбиятчы теле, стиле белән язылган. Миңа бик ошады. Үзеңә ничек?!

Сезнең анда бик мәшакатьле, авыр хезмәттәр инде. Эшләрең күптер.

Мөхәммәт Мәһдиев "бәлки, 1нче июльдән килермен" дип торган иде—килсә шәп булыр иде. Мин үзем 6 нчы июльдә юлга чыгам. Бик аз гына булган кебекмен, әле тәменә керә дә алмадым.

Һава әйбәт миңа. Үпкәләр җиңел сулый, рәхәт. Әмма, әллә нинди ялгызлык хисе кичерәм. Монсу.

Ярар. Күрешергә язсын.

*Сезгә бәхет теләп, **Рәдиф.***

*Ялта, 27 июнь 74.*

---

Рәдиф Гаташ (Гатауллин) Кәшфулла улы (1941)—шагыйрь, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (2008). Озак еллар "Казан утлары" журналында поэзия бүлеге мөхәррире булып эшли.

* * *

Дорогой Равил!

Письмо с выпиской получил. Большое тебе спасибо. Рахмат. Тут у нас, как и у вас, есть всякие люди, поэтому выписка мне очень даже пригодилась. А причину ты знаешь—сказал тебе по телефону.

Как жизнь? Какие планы? Всем нам некогда, но друг друга все же не следует забывать. Я тут от всей души стараюсь пропагандировать своих татарских друзей, в дальнейшем можно будет стараться еще больше. Но возникает иногда некоторое "но", вкладываться сомнение: думаю, а достаточно ли старания только одной стороны. Нам бы было интересно, если бы сотрудничали обе стороны, чтобы и мы, молодые чувашские поэты, время от времени появлялись в татарской печати. Это было бы выгодно нам всем.

Извини, Равиль, за назойливость, но ведь, к сожалению, ни Гарай, ни Рустем мне не отвечают, при встречах мы все хорошие ребята, а на расстоянии все забываем. Мы ведь как бы один народ: булгары и сувары и это все мы хорошо знаем, вся разница в том, что нас русские окрестили при помощи огня и меча, обмана. Жду ваших писем, Равиль, однокашник мой. Еще раз рахмат. Салам всем, всем. Жду!

**Савея** *(любя вас всех)* **Михаил Сениэль.**

*29/X-1974. Чебаксары.*

---

Егоров (Сениэль) Михаил Павлович (1942)—чуаш шагыйре. Үткән гасырның 70нче елларда Чуашстан китап нәшриятында өлкән мөхәррир булып эшләде.

* * *

Равил!

Гөнаһлымын, гафу үтенәм, нинди җәзага да ризамын.

Китапчыкларны (извини за выражения) Казаннан кайту белән салырга тиеш идем. Башта "Тимер фил"не таба алмадым. Аннан соң мин югында җыелып барган редакция эше суырып алды да харап итте.

Синең оперативность, энергия, билгеле, минем таркаулыкка бәрелеп хурлангандыр инде. Синең шикелле КПДны 1гә якынлаштырып эшләп алу югалып килә миндә, нишлисең бит.

Үземнең җинаятемнән арыну өчен синең өчен теләсәң суга, теләсәң утка, хәтта тәмугъка керергә риза. Чын күңелдән әйтәм, сиңа шул ук мерка белән яхшылык эшләргә тиешмен. Син мине бурычлы иттең.

Ярый, бу мәсьәлә ачыкланды шикелле. Сиңа үз хәлем турында сөйләп, эчемне бушатасым килә. Мин дә нәкъ синең шикелле әдәбият сәясәте өчен үземне корбан итәргә тиешмен. Белмим, кирәктерме икән? Әлеге эшем әйбәт: көйләнгән, материал яктан яхшы, солидность (выход теге Зур Йортка), Союзда берданбер должность һ. б., һ. б. Миңа теге син килеп йөри торган йортта (РСФСР Язучылар Союзы күздә тотыла.—**ред.**) мальчик на побегушках булып эшләргә тәкъдим итәләр. "Идите вы..." дип әйтә алмыйм, чөнки башка, безнең әдәбиятка төкерү нияте белән утырган кеше бу урында мин ихтирамлый торган кешеләргә начарлык эшләү мөмкинлеге бар. Шул очракта ул кешеләр—"син үз шкураңны әдәбият интересыннан югарырак куйдың", диючеләре бар. Бик катлаулы проблема алдында мин, син аңлыйсың мондый хәлне. Сине кодалаганда мин кодалаучылар ниятен хуплый идем, хәзер үзем шул халгә төшкәч, сине аңлау дәрәҗәсенә җиттем. Син корбан булып караган кеше—минем зарны аңлый торгансыңдыр? Бу турыда бер-ике сүз язып җибәрсәң, бик әйбәт булыр иде. Нишләргә инде?

Китапчыкларны соңга калып җибәрүем өчен гафу үтенәм, чын ихтирам белән,

***Миргазиян Юныс.***

*Мәскәү, 6/II-74 ел.*

---

Юныс (Юнысов) Миргазиян Закир улы (1927)—язучы, диңгезче, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (2004).

* * *

Дорогой Равиль!

Заки Нури собирается в своем журнале опубликовать цикл моих стихов на татарском. Часть стихов любезно согласился перевести он сам. Я бы просил Вас также принять участия в переводе моих стихов. Если они покажутся Вам приемлимыми. З. Нури обратится к Вам по этому поводу.

*Ваш,* ***Олег Шестинский.***
*Москва, 16/I-76 г.*

---

Шестинский Олег Николаевич (1929)—рус шагыйре. 80нче елларда Ленинград Язучылар оешмасы җитәкчесе, СССР Язучылар союзы секретаре.

* * *

Равил туган!

*Мәхәббәт сүзсез була, ди,*
*ярату күзсез була.*
*... Безнең мең күзле булды,*
*гайбәтле, сүзле булды!*

Китабыгызны кулга алу белән, ни хикмәттер, шул бит ачылды, шул сүзләргә иң әүвәл күз төште. Юкка түгел икән—бастым да каттым, күзгалмый шул шигырьне укып чыктым. Бу—поэзия! Аннары китапны (сүз шагыйрьнең 1976 елда Татарстан китап нәшриятында чыккан "Шигырьләр һәм поэмалар" дигән сайланма томлыгы турында бара.—**ред.**) әйләндерә-әйләндерә карадым—нинди гаҗәеп тышлык: күн дисән, күн түгел, шуңа охшаттым, ләкин никтер ул каен тузы белән тышланган кебек тоелды миңа. Тышы ук җанлы—коеп куелган кыса түгел. Теләсәләр, бездә дә китапны шулай чыгара алалар икән!

Эчтәлеге... Анысы турында мин әйтеп тормыйм—бары шул: бу чын поэзия, мин әле ана кат-кат әйләнеп кайтачакмын.

Рәхмәт Сезгә бу Олы бүләк өчен.

*Сәлам белән—**Хәлиф Курбатов.***
*Казан, 23. XII. 76.*

---

Курбатов Хәлиф Рәхим улы (1927-2005)—тел галиме, филология фәннәре докторы. Озак еллар ТР Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләде.

* * *

Равил салям!

Спасибо, я получил договор из "Советского писателя". Там пошло около ста строк, я очень рад, с первого раза это немало.

Как понравились мои переводы Джалиля?

Огромная просьба у меня: я говорил с Ильгизом Каримовым о переводах Тукая к юбилею, но у меня нет оригиналов переведенных стихотворений. Говорят, они есть у Сибгат-абы Хакима, но я почти незнаком с ним, и прямо написать ему не решаюсь. Если можно, если не очень трудно, пожалуйста, пришли мне несколько таких стихов—апрель близко и нужно уже работать. Может быть, я сам через пару недель буду в Казани—тогда просто зайду. Но если успеешь—мой адрес: Москва, 117234, Лен. горы, МГУ, Б-1114.

Равиль Бухараев.

P.S.: Извини, пожалуйста, что затрудняю тебя, у меня сейчас просто нет другой возможности. Я знаю твою занятость, извини.

Но сделать это я давно хочу и нужно по-новому перевести Тукая. Тем более, что это нужно срочно.

*Еще раз спасибо, до свидания,* ***Равиль.***
*Москва, 26 февраль, 1976.*

---

Бохараев Равил Рәис улы (1951)—рус теледә иҗат итүче татар әдибе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. 1991 елдан бирле Лондонда яши.

* * *

Уважаемый Равиль Абдрахманович!

На основании предварительной договоренности с Вами посылаю один экземпляр своей рукописи под названием "Эзләнүләр". Надеюсь, что после ознакомления с ней напишите мне свое мнение и заключение о возможности опубликовании ее в журнале "Казан утлары" в 1977 году в мартовские дни, посвященные памяти Галимджана Ибрагимова.

На другой день после разговора с Вами я встретилась с т. Хасановым Мансуром Хасановичем, который еще раз подтвердил устно, что мнение его об этой работе вполне положительное и обещался дать свое письменное заключение о ней не раньше чем в начале июня месяца, после того как пройдут тукаевские дни и еще какой-то симпозиум, предстоящих в конце мая.

*С приветом*
***Гульсум Мухамедова.***
*Казан, 14/Х-76 г.*

---

Мөхәммәдова Гөлсем (Өммегөлсем) Давыд кызы (1903-88)—язучы, тәрҗемәче. Галимҗан Ибраһимовның хатыны. Озак еллар Сәмәркандта гомер кичерде, гомеренең соңгы елларында Казанда яшәде.

* * *

Мөхтәрәм Равил туган!

Сибгат белән[1] өемә килмәвең сәбәпле бирәлмәгән истәлекне (китаплар.—**ред.**) почта аша җибәрергә мәҗбүр булдым.

Иркен шартларда сөйләшеп һәм танышып та булмады. Шул да бер үкенеч булып калды.

*Самими сәлам белән:*
***Сәйфи Кудаш.***
*15. Х. 1976 ел. Уфа.*

---

Сәйфи Кудаш (Кудашев) Фәттах улы (1894-1993)—Башкортстанның халык язучысы.

* * *

Хөрмәтле Равил!

Чыда: бу юлы мин сине мактарга булдым!

"Яшь ленинчы"ның 25нче январьда басылган кыска шигырьләреңне бик кызыксынып һәм кайта-кайта укып чыктым. Молодец, дингезчеләр әйткәндәй: "Так держать!" Беләсең, фикер никадәр кыска, образлы һәм матур язылса, шулкадәр үк ул көчле дә була. Син менә маһир кешесең, адым саен үсә баруың да дусларыңны сокландыра. Бу кыска һәм көчле җөмләләреңнән минем үземә: "Аучы истәлеге", "Янгыр", "Кышын", "Батырлыгын...", "Үрмә гөл", "Хурлык", "Янару", "Йолдызлар", "Күрче, кояш...", "Хак"... бик ошадылар.

---

[1] Сибгат ага Хәким белән 1976 елны Уфада Габдулла Тукайның 90 еллыгы тантаналарында катнашкан идек (Р. Ф.).

Әлбәттә, башкалары да әйбәтләр. Мин менә "Бер карт сүзе"нә ияреп: "Тән белән күңел сафлыклары—сафлыклар сафлыклары",—дип бер җөмлә дә яздым. Сиңа ияреп язарга тырышулары—безнең кебек "яшь прозаикларга" да күңелледән күңелле эш ич ул!..

"Кыска шигырьләр"ең дөньяга чыгу белән миңа да бер данәсен җибәрсәнче! Ярыймы, кадерлем?!.

Искәрмә: Рус телендә Вл. Воронцовның һәркем өчен кирәкле ике китабы басылып чыкты: "Служение музам" һәм "Симфония разума" (шагыйрь-әдипләрнең берсеннән-берсе гайрәтле вә гыйбрәтле афоризмнары). Бу китаплар китаплары синең үзеңдә булмаган хәлдә мин аларны сиңа укып-карап чыгу өчен 1 айга гына җибәрә алам... әгәр дә ул китапларны бирәрсе чәлдермәсә!..

*Сине сагынып: **И. Туктар.***
*Зеленодольск. 13. II. 78.*

---

Туктаров (Туктар) Идрис Ильяс улы (1896–82)—язучы.

* * *

Равил!

Ялта татарларыннан күп сәлам сиңа.

Менә ялыбызның бер атнасы узып та китте инде. Иялəшеп тә беттек кебек. Тәмам ялкауландык—ашыйбыз-эчәбез (әмма аракы түгел, пепси кола, кымыз, сыра, шифалы су кебекләрне генә), туйганчы йоклыйбыз, су коенабыз (диңгездә), йөзәбез (бассейнда), урамнар әйләнәбез. Эшләгән эш юк дияргә мөмкин, бераз китаплар гына укыштыргалыйбыз. Хәер, бу соңгылары Диләрә белән миңа гына кагыла торганнары. Мондагы татарларның күбесе шактый тырышып эшли шикелле. Һәрхәлдә, Рәдиф, Зәки Нури көннең күпмедер өлешен бүлмәләрендә уздыралар, эшләп утырабыз, диләр. Ә менә Роман Солнцев чыннан да нык эшли бугай—аны завтрак, обед, ужин вакытларында гына күреп була. Ул монда әнисе белән килгән, бик мөлаем апа; үзе дә әйбәт кеше күренә; безгә өч китабын бүләк итте, ара-тирә сөйләшкәләп утырабыз.

Көннәр әйбәт тора, суның җылылыгы—17-18° тирәсе. 6 октябрьда Бакчасарайга экскурсиягә барып кайттык, 8 ендә Севастопольгә юл тотарга җыенабыз. Әгәр Коктебельгә туры юл булса, анда барып килергә дә ният юк түгел иде түгелен, әмма бер көнебез әрәм китәр дип куркабыз. Инде, һичьюгы, кайтышлый үзең кереп чыгарсың дигән өмет бар. Китапларны, шәт, алгансыңдыр. Монда калган нөсхәсе кулдан-кулга йөреп искерә башлады шикелле инде. Һәммәсе мактыйлар үзеңне (син мактауны яратасын бит—шуңа әйтүем). Әгәр монда керә калсаң, вакытыңны чамалап, куныл китәрлек итеп кил. Синең өчен урыны да, башкасы да һәрвакыт табылыр, чын менә. Сүз сөрешеннән аңлашылганча, Роман Солнцевның да сине бик күрәсе килә булса кирәк. Кыскасы, истә тот, без сине көтәбез.

*Тагын бер кат сәлам белән—**Рәис абзаң.***
*7/X-76. Ялта.*

---

Рәис Даутов Нәүширван улы (1928-2007)—текстолог галим, тәрҗемәче (Равил Фәйзуллинның берничә китабының мөхәррире булган әдип), Татарстанның фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт премиясе лауреаты (2005).

* * *

Кадерле Равил туганкай!

Саратов юлларындагы эчкерсез ярдәмнәрегез өчен мин Сезгә рәхмәтләремне һичкайчан әйтеп бетерә алмам, ахрысы! Шундый да кайнар хисле, олы акыллы, шундый да фидакарь ярдәмчел юлдашларны очрату бик сирәк буладыр ул. Ул Саратов сәяхәте көннәр узган саен олы тәэсирле, кадерле бер истәлек була бара, ә Сезгә минем рәхмәтем артканнан-арта бара.

Кызганычка каршы, Авдеев (А. П. Авдеев—"Сов. Татария" газетасының әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире.—**ред.**) минем язып җибәргән язманы кичектерә биреп чыгармый калдырды. Бәлки, үзем дә соңлабрак биргәнмендер. Сезнең хатны алгач ук язып җибәргән

идем жибәрүен. Бер шалтыраткан идем, сонлады түгелме сон, диде. Юк, мин әйтәм, бу бит литературное событие, басарга кирәк! Ә материал чыкмый калды. Минем мыштырлык инде! Ни телефон юк, ни автобусларга утыра алмыйм, ни йөртер кешем юк. Мина да аны иртәрәк уйларга кирәк булган, синен хатың килеп җиткәнче үк!

Ә менә синен радиодан ясаган чыгышын да, газетага биргән интервью да бик әйбәт чыкты, кин карашлы, олы акыл белән эшләнгән чыгышлар. Чын күнелдән рәхмәт сина!

Кызык булды әле бу хат. "Сез дип башладым, "син"гә килеп җиттем. Үзем дә сизми калганмын. Сөйләшә торгач, үзен дә сизми "син"гә күчеп китү, күрәсен, сине чын күнелдән якын күрүемнең табигый бер хәледер.

Янәдән бер үзенә рәхмәтләремне яудырып, тазалык-саулыклар, янадан-яна ижат казанышлары, олы бәхет-шатлыклар теләп, кайнар сәламнәр белән

*Мәҗит абыең Рафиков.*

*Казан, 29-VII-78.*

---

Рафиков Мәҗит Мәгъсүм улы (1925-86)—язучы, тәрҗемәче.

* * *

Уважаемый Равиль Абдрахманович!

Обращаюсь к Вам с большой просьбой.

Вероятно, Вы наслышаны об уникальной библиотеке книг с автографами, которую мы создаём на строительстве подшефной Нурекской ГЭС? О ней много пишут и говорят. Сейчас она насчитывает уже более 8 тысяч томов. К слову, на днях свои книги нурекчанам подарил Л. И. Брежнев.

Очень бы мне хотелось видеть в этой библиотеке и Ваши книги—на татарском или русском.

Подошлите мне, пожалуйста, в редакцию одну-две книги своих с добрыми пожеланиями нашим подшефным ("В интернациональную баруздинскую библиотеку "Дружбы народов" в героическом Нуреке от..." и т.д.).

Хорошо?

Буду ждать!

Заранее благодарен Вам!

Большой Вам привет от Розы Михайловны!

*Искренне Ваш—**Сергей Баруздин.***

*Москва, 6 июля 1978 г.*

---

Баруздин Сергей Алексеевич (1926-91)—рус язучысы, СССР язучылар союзы секретаре. Үткән гасырның 60-70 нче елларында "Дружба народов" журналының баш мөхәррире булып эшләде.

* * *

Дорогой Равиль!

Спасибо тебе за хорошую книгу. В этом году мне повезло—в Пицунде познокомился с тобой! У грузин есть хорошая поговорка что ли: ибяти бунебит—поэт от природы. Судя по твоей книге, ты из этого разряда поэтов. Мне было приятно и то обстоятельство, что в чем-то твоя поэтическая индивидуальность очень близка мне как по содержанию эмоций и размышлений, так и укрощению или усвоению опыта современной поэзии в широком смысле слова. Это мне тем отрадней сознавать, что ты поэт другого поколения, идущего вслед за нами.

Мне нравится, что ты прибегаешь к верлибру не от неумения владеть строгой дисциплиной классического рифмованного стиха, а по богатству возможностей. Когда-то (в 50-ые годы) я начинал пробовать опыт стих на осетинской почве и просыпались упреки... Но я продолжал писать и обычным стихом, при этом усложнял его формальные возможности. Я хотел доказать, что верлибром имеет право пользоваться только тот, кто отлично владеет всеми возможностями традиционного стиха, умеет их разнообразить, что-то к ним добавить... и прибегает к свободному стиху для обогащения возможностей

национального стиха, а не от того, что и многие иноязычные поэты это делают.

С тех пор своб. стих утвердился у нас и ныне и в голову никому не приходит оспаривать его право на существование. Сам я ныне прибегаю к нему редко (нахожу, что возможности классического стиха далеко еще не только не исчерпаны, но и не освоены), но молодые поэты (твои ровесники) пишут им и довольно успешно.

И еще—в твоей лирике я уловил тенденцию с годами стремиться к простоте поэтического высказывания. Это мне также дорого самому и отрадно видеть у другого поэта. "Впасть в простоту, как в ересь"—хорошо сказано об этом Пастернаком. Выше мудрой простоты видимо нет ничего в поэзии. Все проходит—и буйство глаз, и бросание образов пригоршнями, и эмоциональное неистовство, а это остается. В сентябре С. Наровчатов в рецензии на ныне премированную книгу сделал комплимент Вознесенскому—"князь метафор". Мне он кажется сомнительным. Сказать поэту, что он князь метафор, сравнений, эпитетов или рифм, аллитераций и т. д., по-моему значит обидеть его. Так не скажешь о Пушкине или Лермонтове. Видимо надо быть князем поэзии,, а не метафор, между тем Вознесенский—поэт отличный и похвалы заслужил, но не такой обнобокой, он вовсе не занят сочинением метафор, этим успешно может заниматься любой рифмоплет с развитой фантазией.

У тебя есть эта тенденция—искать высшую поэтичность в простоте и она говорит о большом запасе прочности у твоего таланта. Ты сделал очень много, но я убежден—твой звездный час еще впереди. Какой-то внутренний голос говорит мне, что ты до старости лет не расстанешся с поэзией и будешь из года в год писать лучше и по-новому—проще и плотнее, внутренне благороднее и изящнее по фактуре.

Мне очень жаль, что я не знаю языка оригинала. Я почти как самому себе верю Мустаю (Мустай Карим.—**ред.**), но хотелось бы самому пощупать пульс стиха, почувствовать интонацию, но...

Спасибо тебе, Равиль, за прекрасный подарок!

От души желаю тебе и здоровья, и душевной отрады, и новых мыслей и образов. Да не покинет тебя вдохновение во все дни твоей жизни и в горе, и в радости.

Пусть исполнятся все твои поэтические и человеческие замыслы!

Искренно протягиваю тебе братскую руку на трудную дружбу.

***Нэфи Джусойты.** 16. XI-78 г. Цхинвали.*

---

Джусойты Нафи Григорьевич (1924- )—осетин язучысы һәм әдәбият галиме.

* * *

Хәерле көн, Равил!

Сезнең белән концерт залларында яки опера спектакльләрендә очрашсак та сөйләшә алмый калам. Музыка белән кызыксынуыгыз, премьераларда булуыгыз мине куандыра. Дөресен әйтергә кирәк, әдипләребез музыка кичәләрендә сирәк күренәләр.

Сез бервакыт миңа җырчы Фатыйма Гомәрева турында язарга теләвегез турында әйткән идегез. Бик мактаулы эш. Фатыйма апага 79 яшь тулды. Анын турында язарга бик вакыт. Әгәр чыннан да ул теләктән күнелегез кайтмаган булса, хәерле сәгатьтә керешегез инде ул эшкә. Миннән бирәр мәгълүмат кирәк булса—мин Сезгә белгәнемне сөйләргә әзермен. Фатыйма апа Тукай, Кариев белән күп тапкырлар очрашкан кеше.

Фатыйма апаның телефоны: 2-75-62. Адресы: Комлева, д. 19а, кв. 34.

*Сезгә сәламәтлек һәм иҗади уңышлар теләп: **Зәйнәп.***
*Казан, 24/III-79.*

---

Хәйруллина Зәйнәп Шәйхулла кызы (1916)—музыка белгече.

* * *

Сәлам, Равил абый!

Хат алу белән үк, мин бүлек мөдире белән сөйләштем. Нәтиҗә шул: драматург

Ш. Хөсәенов турында язу буенча Р. Фәйзуллинга заказ бирелгән дип уйларга кирәк. Мәкалә бик сонармаса яхшы булыр иде.

"Балалар матбугаты һәм без" икенче якшәмбедә үк басылып чыкты. Кайбер кыскартулар булды, әмма аларнын сәбәпләре бар. Беренчедән, өч баганалык кына урын бар иде. Икенчедән, подпискага кагылышлы урыннар, ЦК күрсәтмәсенә туры килмәгәнлектән, төшеп калды. Чөнки хәзер подписка мәсьәләсен пропагандаларга (тем более безнең газетта) ярамый.

Шуңа карамастан, летучкада материалга бик шәп бәя бирделәр. Редактор үзе "Мәкалә мина бик ошады. Балалар матбугаты турында безнең бөтенләй язганыбыз юк..." диде.

Ниһаять, "Лит. Россия"дә минем исем дә күренде. Дөрес, шигырьләр дә, кереш сүз дә кыскартылган. Шуңа карамастан, фамилияләрне меңләгән кәгазьгә басып, бөтен Рәсәйгә тарату—минем өчен жиңү. Котлаучылар күп булды. Кереш сүз язып, шигырьләрне чыгаруда ярдәм иткән өчен зур рәхмәт.

Башка яңалыклар юк шикелле.

*Кырымдагы көннәрнең бәрәкәтле үтүен теләп: **Зиннур.***

*Казан, 1 октябрь, 79.*

---

Мансуров Зиннур Мөжип улы (1949)—шагыйрь, публицист, җәмәгать эшлеклесе. "Мәдәни җомга" атналык газетасының баш мөхәррире. Узган гасырның 70нче елларында ул "Социалистик Татарстан" (хәзерге "Ватаным Татарстан") газетасында эшләде.

* * *

Здравствуй, дорогой Равиль!

Приехал? Привыкаешь к неяркой осени?..

У меня пока штиль. Стихов не пишу. Горы подстрочников нет.

Вчера была в Москве. Изъяла у рецензента—алкоголика рукопись и отнесла в издательство. Там так расстрогались меня подвигом, что предложили мне самой выбрать рецензента из их списка, но я там никого не знала, а Эдика Балашова—не рискнула. Так что "Современник" выходит мне боком. У этого Кудимова еще гора рукописей.

Вот так!... Зашла еще наверх, туда, где твоя книга коротких стихов. Князева, оказалось, ушла на повышение. Рукопись у нового редактора—Иванова Геннадия Викторовича. Говорят, человек солидный. Его я не видела—его послали учиться на какие то политические курсы. Но в понедельник должен быть т. е. 22-го звонить по телефону Князевой, лучше с утра, с 9-ти. Если письмо успеет, позвони. Но навряд ли он успел прочитать рукопись,—так они говорят.

Заправляет поэзией народов СССР Бояринов Владимир Георгиевич.

Была в "Дружбе народов" познакомилась с Серебяковым. Показался симпатичным человеком. Он хотел бы, чтобы ты заехал (если будешь в Москве)—подумать над шапкой подборки, которая точно будет. Думал в №1—80 г. Но там "неожиданно свалились марийцы (или мордовцы) с юбилеем". Сказал, что в первых номерах будущего года. В подборке переводы Рустема и мои. Замечания скорректировали там же, сразу. Словом, остается только ждать журнала.

Баруздин—элегантнейший редактор, и они там, кажется, все в него влюблены. Я так—с первого взгляда. Ну что еще написать!.. Я думаю, что с "Д. Н."—порядок. А с "Современником"—почти порядок. Уж если Князева—сама!—заинтересовалась в свое время рукописью и взяла ее себе! Но ты их все же поторопи.

Письмо сейчас же брошу в ящик.

Надеюсь, что ты получил предъидущее письмо с копиями рекомендаций.

Желаю всем здоровья, благ!

У Р. Бухараева в 1 кв 1980 г. в "Современнике" выходит книга—это я подглядела в их планах.

Самое удивительное, Равиль, что в чистоплюйской литературе и кристальной поэзии ни шагу нельзя ступить без знакомства. И сколько, вероятно, истинных талантов погибло, расшибив лоб об эту стену.

Вот как...

До свидания!

И еще: Равиль, я не отказала в просьбе Мансуру (Зиннур Мансуров.—**ред.**) о переводе его стихов. Посмотрю на досуге. Парень этот серьезный и хороший по-моему.

*М. А.*

*Тверь, 18. 10. 79 г.*

Аввакумова Мария Николаевна (1943)—рус шагыйре. 70-80 елларда байтак татар шагыйрьләренең (шул исәптән Р. Фәйзуллинның) шигырьләрен рус теленә тәрҗемә итте.

* * *

Дорогой Равиль!

Обнимаю и приветствую тебя, мой прекрасный товарищ и поэт! Сижу на твоих рукописях и думаю, что Равиль злится, а как вернуть? Почтой? Вышлю, как только напишешь. Мне они очень пригодились, но вот, прочитав их, я понял, что написано тобой 13 и более книг, а соразмерность критического слова равна 2-3 книгам. То есть много тобой сделано, да мало об этом всерьез сказано. Видно, сейчас у тебя такой период (ты—умная голова, сам чувствуешь), что нужно сказать о тебе побольше, пошире. Не говорю, что есть корысть, а здесь просто необходимость, интерес. Чего тебе говорить комплименты!..

Равиль! Кое-что мне еще пока неясно, но, работая над статьей, я с тобой спишусь—ты уж мне ответь. Сейчас же всего два вопроса, которые мне нужно знать.

Первое: Твое отношение к восточной поэзии, классической. Второе: что тебя больше привлекает в русской поэзии (и современной)?

Не трудно—черкни.

Когда будешь в Москве? Я бы выехал в Казань, но жена, брат, скоро рожает (середина декабря), не могу. Привет тебе, Равиль!

*Твой—*

***Вадим Дементьев.***

*21 ноября 79. Москва.*

Дементьев Вадим Валерьевич (1950)—әдәбият тәнкыйтьчесе, галим. Россия һәм элеккеге СССР халыклары әдәбияты, бигрәк тә поэзия турында күп хезмәтләр авторы.

* * *

Добрый день, дорогой Равиль!

Большое спасибо за книги. Часть стихов прочитал. Но, как сказал Мустай (Мустай Карим.—**ред.**), нельзя их читать бегло. Прочитал вступительные слова В. Туркина.

“Короткие стихи” напомнили японские танки. Мне нравится. В свое время я тоже написал довольно большое количество двухстиший. А двенадцатистрочные “полусонеты”—я так условно назвал, неполные сонеты, продолжаю писать и сегодня. Так что ваши поиски близки. Более того, неделю тому назад я выслал в Татарское издательство рукопись “Избранного”. Включил в него довольно большое количество 12 строчных стихов из цикла “Жизнь и размышления”. Я написал директору, что эти стихи по строю близки Вашим стихам и вы, наверное, если бы пожелали, сумели перевести их хорошо. Книга должна выйти скоро.

Еще раз большое спасибо за отличные книги. У меня скоро должны выйти книги в Москве—за мной долг.

*С приветом*

***Давид Кугультинов.***

*22. III. 1981, г. Элиста.*

Көгелтинов Давид Никитич (1922-2006)—Калмыкстанның халык шагыйре. Совет әдәбияты классикларының берсе.

* * *

Равил!

Сина күнелле яллар теләм калам. Просьба:

1. Мина килгән хатларны алып кайт, үзеңдә сакларсың.

2. Анда бер магазин бар—Карадагка таба главный урамнан барганда ("Коктебель" дигән универмагка барганда) юл өстендә сул якта "Юность" булса кирәк—спорттовары.

Шунда, пожа-ста, кереп чык, кара төстә күн тышлы обложкалар бар. 20 тиенлек (башка төрлесе кирәкми). Шуны 10 шт ал, пож-ста. Искәндәр өчен кирәк иде, сабый балалар өчен йомыш тыңламый калмассың дип ышанам. Кайткач Гомәр абыеңа тапшырсаң (мин Мәскәүдә булам), бер кайткач 2 тәңкә акча бирәсе дигән сылтау белән күрешербез.

*Сәлам белән Мөхәммәт абыең.*

P. S.: Ахметьянов Ким сине көтеп калды анда, син килмәдең. Мин 19ы иртүк киттем. Ахметьянов ящигын да кара инде, булса ала кайт, ул бик борчылды.

*12 сентябрь 1985. Кырым. Күктүбә.*

---

Мәһдиев Мөхәммәт Сөнгат улы (1930-1995)—Татарстанның халык язучысы (1993).

* * *

Дорогой Равиль!

Спасибо за добрую телеграмму. Я была очень ей рада. Конечно, твое светлое и человеческое творчество достойно самых высоких слов. Можно было бы написать и больше и лучше, но мои поездки помешали этому.

Все, что я высказала в статье, прошло через мое сердце, к твоим стихам—ведь в них я нахожу строки, помогающие мне в жизни.

Мудрость и простота, ...... и справедливость так естественно переплелись в твоей Поэзии.

Я тебе уже писала, что послала в "Лит. Россию", хотя и читала раннее опубликованную рецензию "Единство мысли". Мне подумалось, что эта статья (рецензия) получилась немного односторонне, хотя и очень грамотная. Но, видимо, они дважды не печатают об одной и той же книге. Они мне об этом написали. Не будем на них обижаться, они одинаково относятся к нам хорошо.

Равиль, отправил ли ты эту статью в "Советскую Россию"? Если да, это прекрасно. Я бы сделала сама, но у меня, к сожалению, не осталось ни одного экземпляра. Главный редактор Ненашев Михаил Федорович ко мне относится хорошо. Газета обязательно напечатает. Постарайся отправить. Или—что ты мне посоветуешь? Если тебе неудобно, вышли мне копию статьи и я срочно сделаю.

Как живешь, творишь, Равиль? Что у тебя нового? Я была в Дагестане, приглашал Расул Гамзатов. Отказываться было неудобно. Он очень обидчив.

В этом году я подготовила две рукописи. Сдала их. Я, кажется, тебе об этом писала.

Равиль, напиши мне свое мнение по поводу статьи в "Советскую Россию".

Будь счастлив и здоров. Кланяюсь семье.

*Всегда с уважением* ***Раиса Ахматова.***

*11. X. 85. Грозный.*

---

Ахматова Раиса Солтанморат кызы (1928) Чечен Республикасының халык шагыйре, дәүләт эшлеклесе. 1963-85 елларда Чечено-Ингуш АССР Югары Советы Рәисе булып торды.

* * *

Хөрмәтле Равил кусты!

Сибгат агайны җирләп кайтуның икенче көнендә үк больницага салдылар—кардиология үзәгендә ятам. Шушы больницаның китапханәсеннән (анда әзрәк татар, башкорт китаплары бар) синең өр-яңа көе торган "Җырларда ил гаме" дигән китабың күзгә чагылды да, укырга яздырып алдым, чөнки ул китабыңны магазиннарда очратмаган идем.

Кызганычка каршы, китапка тупланган мәкаләләреңнең берсен дә вакытында укымаганмын, ә И. Нуруллин белән әңгәмәгә күз салып чыккан идем, аңа да җентеклерәк карамаганмын, игътибар итмәгәнмен булса кирәк.

Менә хәзер койкада яткан килеш җыентыгыңны укып чыктым һәм үзем өчен синең яңа бер сыйфатыңны ачтым. Поэзия хакында, аерым-аерым шагыйрьләрнең иҗатлары (китаплары) хакында тирән һәм югары кимәлдә фикер йөртүләрең сокландырды, Нуруллин белән сиңа кушылып, өчәүләп бәхәсләшәсе дә килеп китте.

Бөтенесенә караганда Х. Туфан һәм С. Хәким хакындагы мәкаләләрең күңелгә якын тоелды, чөнки, алар хакында, бигрәк тә С. Хәким хакында минем дә өч мәкаләм бар, аларның соңгысы ике томлык сайланмасына баш сүз булып китте. Дөресрәге, баш сүз итеп яздым. Мин аны шул мәкаләдә үк (1984 ел) "чын мәгънәсендәге халык шагыйре" дигәнмен, әмма бу хатымның сиңа язылу сәбәбе шул: соңгы мәкаләдәге минем бер әйтемем белән синең бер әйтемеңә туры килә—ул да булса "Тукайчы" дию. Мин аны шулай дип 1984 елда атасам, үзем өчен бер "ачыш" дип күрсәм, син аны—"Тукайчы" дип 1979 елда ук атагансың икән. Шуңа шатландым да, көенеп тә куйдым. Минем мәкаләне укырга туры килсә, зинһар, миннән чәлдергән дип уйлама, әйтәм бит мәкаләләреңне укымаганмын.

Бер карасаң, без бик читләшеп беттек, бигрәк тә хәзер—Ык буена кара һәм акка буялган чик баганасы гына утыртасы калды. Аралашмыйбыз, күпләребезне күрешеп белмибез, ә күрешү бик мөһим бит! Тукай көннәрендә синең игътибарга лаек булган Әхмәт Рәшитов белән таныштым, синдә искә алынмаган Кави (Кави Латыйп.—**ред.**) белән бергә утырырга туры килде, ә яшь шагыйрьләр күпме?!

Язасы сүзләрем шулар иде.

*Сәлам белән* ***Нажар Нәҗми.***

*Уфа, 29. VII. 86.*

P. S. Равил кустым! Адресны дөрес язмаганмын да хат кире кайтты. Кичә радио аша Куйбышевта булганыңны тыңладым. Мин һаман больницада әле.

*Н. Н.*

*28. VII. 86.*

---

Нажар Нәҗми (Нәҗметдинов) Нәҗметдин улы (1918-1999)—Башкортстанның халык шагыйре.

---

## Авторларыбыз игътибарына

Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кульязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.

Хатлар исә, җиңел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.

Әхмәт Рәшит



# ҺӘРКЕМНЕҢ... ҮЗ СУКМАГЫ

ХАТИРӘЛӘР

*Мин яшәдем—сукранмадым,*
*Язмышым болай ярый—*
*Шатлыкның да, кайгының да*
*Йөрәккә сыйды бары.*

## Кереш сүз

**Олыгая барган саен үткән гомернең гыйбрәтле һәм кызыклы вакыйгалары, күңелдә эз калдырган шәхесләре һаман ешрак искә төшә икән... Искә төшә генә түгел, алар озак-озакка уйга да талдыра, хатирәләр диңгезенә ерак сәяхәткә дә алып китә.**

**Көннәрдән бер көнне мин әнә шул күңел "сәяхәтем"не кәгазьгә төшерергә карар кылдым һәм яза башладым. Әмма хис-кичерешләргә бирелеп кайсыбер урыннарда артык киңәеп киткәнмен ахрысы, язып бетергәч карасам—300 биттән артык сырлап ташлаганмын...**

**Биредә исә мин укучыларга үз хатирәләремнең нигездә вакыйгалы өлешләрен генә тәкъдим итәм. Ә тулы килеш алар бәлки киләчәктә китап булып дөнья күрер.**

## Мин дөньяга килгәнче...

...Миңа 9-10 яшьләр чагында бабайның энесе Хөсәен абзый исән иде әле. Озак тормый, тиф белән авырып, үлеп китте. Миңа ул 16 бабамны өйрәткән иде. Малай чак бит—шәҗәрә кайгысымы?! Онытканмын. Үсә төшкәч, бераз акыл кергәч кенә, уйлана башладым. Нәселләрендә дин әһелләре булган кешеләрдән сораша торгач, уникесен ачыкладым шикелле. Никадәр дөрестер?! Картлар һәммәсе дә бер үк исемнәрне атадылар югыйсә. Шуңа күрә ышанмыйча да булмый. Әле тагын шунысы: безнең авыл халкы хәзерге Кайбыч район үзәге тирәсеннән—Иске Чәчкап авылыннан—күчеп килгән. Бүре, Кылый һәм Мыек нәселләре. Әлеге авылга мәчет ачылу тантанасына баргач, аш мәҗлесендә катнашкан бабайлардан сорашкан идем—шәҗәрәнең башында шул ук таныш исемнәрне атадылар. Аларның кайсысыдыр көчләп чукындырудан качкан булса кирәк... ә бәлки лашманчылык кебек коточкыч авыр хезмәттән котылырга теләгәннәрдер. Ул чакта бит Петр патша кораблар төзү өчен нәкъ менә Кайбыч ягының нык имәннәрен дә кистергән. Бер үк вакытта мөселманнарны православие диненә көчләп күчерү дә дәвам иткән—"новокрещенные" дигән билгеләмә шул чорларда килеп чыккандыр инде... Югыйсә бу якларда дини җәберләү Иван Грозный заманнарында ук башланган. Тарихтан билгеле булганча, Казанның үзен яулаудан алда бу мәрхәмәтсез патша Тау ягын кулга төшергән. Аннан соң да мондый тәре походлары гел-гел кабатланып торган. Лука Канашевич атлы кара йөрәкнең милләтебезгә нинди әшәкелекләр кылганын

Әхмәт РӘШИТ (1936)—*шагыйрь, публицист; "Йөрәк кыңгыраулары", "Иман яңартканда", "Таң илчесе", "Фидаиләр" һ.б. китаплар авторы. Гаяз Исхакый исемендәге премия лауреаты. Казанда яши.*

хәреф таныган һәр татар кешесе белә. Әле ул гынамы—ул каһәрле заманнар турында риваятьләр буыннан-буынга күчә-күчә хәтта бүгенге көннәргә кадәр килеп житкән. Хәтерлим әле, безнең өйгә авыл хатыннары жыелып, оекбаш яки бияләй бәйли-бәйли, дөнья хәлләре турында сөйләшеп утыралар иде. Инде сиксән чиген узып киткән бер әби (исемен хәтерләмим инде) сүзен "Безнең бабай үз бабасыннан ишеткәннәрне сөйли иде..." дип башлый да Яңа Чәчкап авылында татарларны ничек чукындыру тарихын сөйли иде. Мин, мич башында жылынырга дип яткан малай, юрган читеннән колагымны гына чыгарып, карчыкларның шул әңгәмәсен тыңлыйм. "Садырби абзыйларны беләсез, аның бабасы малай гына булган әле ул чакны. Авылга патшаның кулына мылтыклар тоткан әтрәте белән бергә муеннарына ат башы хәтле тәреләр таккан бер көтү поплар (тәүбә, тәүбә, әстәгъфирулла!) килгән икән. Халыкны, язгы карлы-бозлы суга куып кертkәннәр дә, "менә бу тәрене үпсәгез, исән каласыз..." дип ыржаешып көлеп торалар икән. Үләсе килмәгәннәр, нишләсеннәр, ярга чыгып, муеннарына тәре асалар да, бер чәшкә аракы эчеп, диннән ваз кичәләр. Садырби абзыйның бабасы чыгасы итмәгән, язгы ташу белән агып киткән шунда. Соныннан мәетен дә тапмаганнар. Әле мин бала чакта да Кукаудан поплар килеп өй борынча тикшереп йөриләр иде. Иконнары бармы, янәсе. Ләкин безнең авыл чын-чынлап барыбер урыс диненә күчмәгән. Ревизия килгәндә, йорт почмагына иконнарны куеп торалар да, аннан алар киткәч, үзебезчә, Мөхәммәт галәйһиссәлам кушканчы тора башлыйлар иде".

Сабый күнеле үтә тәэсирләнүчән бит ул. Әлеге әби сөйләгәннәрне мин үз күзләрем белән күргәндәй булам. Миңа куркыныч булып китә. Әйтерсең лә, ат башы зурлыгындагы тәре таккан поплар мине дә шул бозлы суга ташламакчы булалар. Мин, авыр уйлар өермәсенә эләгеп, озак кына ята торгач, ниһаять, арып-талып йокыга талам. Төшемдә дә әллә ниләр күреп, саташып бетәм. Әнә, зур корсаклы, куркыныч тәре таккан поп, мине әни кочагыннан тартып ала да, ашкынып аккан язгы суга ыргыта. Мин чәбәләнәм, тартышам, елыйм, мәрхәмәт сорыйм. Ләкин мине кызганучы юк. Бары тешләрен ыржайтып бөтенесе көләләр генә. Мин, шыбыр тиргә батып, кычкырып уянам. Минем тавышка уянган әни, яныма килеп, башымнан сыйпый, юрганымны рәтләп куя. Озак кына янымда басып тора. Аннан, аяк очларына гына басып, онытылып йоклап яткан сеңелем янына, ятагына юнәлә.

Мин кечкенә чагында авыл хатыннары үзара талашканда, бер-берсенә "керәшен токымы", "тәре баганасы" дип кычкыруларына гажәпләнә идем. Олыгайгач кына авылның балаларга таныш булмаган кайбер серләренә төшендем. Чыннан да, кемнәрдер егерменче гасыр башына кадәр Алексей Семенов, Никита Борисов, Яков Никитин, Петр Васильев, Роман Дмитриев, Матрена Максимова, Дмитрий Андреев, Александра Герасимова, Мария Иванова, Михаил Семенов һәм башка исем-фамилияләрдә йөргәннәр икән. 1892 елда Яна Чәчкап авылы кешеләре 117 керәшен исеменнән үзләренең чынлыкта мөселман динен тотулары, идарәче даирәләрнең, хөкүмәт законына таянып, мәчеттә гыйбадәт кылырга рөхсәт итмәүләре, балаларының мәдрәсәгә йөрүдән мәхрүм ителеп надан калулары турында кабат-кабат Петербургка—Россиянең эчке эшләр министрлыгына мөрәжәгать итәләр. Республика архив фондында шушы эш буенча 21205/616 санлы эш тупланмасы саклана. Авылдагы хәлләрнең ничек икәнен белү өчен шул документларның берсен китерү дә житә. Ул Тәтеш өязе исправнигына бирелгән рапорт:

"Во исполнение Предписания от 21 марта сего года (сүз 1897 ел турында бара.—Ә.Р.) за № 777, представляя при сем прошение доверенных от крестьян деревни Новых Чечкаб Чирки-Кильдуразовской волости крестьян этой же деревни Ахметсафы Иблеева, Зиганши Ильясова, доверенность данную им на подачу означенного прошения с имянным списком доверителей и список крещенных татар этой деревни с обозначением в нем семейного положения и отметками местного священника о лицах бывше крещенными по православию, имею честь донести Губернскому Правлению, что по произведенному расследованию по обстоятельствам, изложенных в прошении, оказалось следующее: в Тетюшском уезде, во многих волостях, населенных татарами, жители некоторых деревень были обращены в христианство, с требованиями своими обращались к приходским священникам, в дома свои принимали св. иконы, венчались в церкви, детей своих крестили по православию, не переставая однако вместе с тем исполнять в тайне и обряды магометанской веры, и эти так называемые "крещенные татары", хотя

и именовались русскими, но сохранили и свои магометанские имена, наречия и одежду, а с 1866 года все явно отпали от православия в магометанство, в дома свои стали принимать мулл, детей пускать в медресе для обучения татарской грамоте и обрядам магометанской веры.

В 1865 году доверенными крестьян разных деревень Тетюшского уезда, в том числе и доверенных от крещенных татар деревни Н.Чечкаб, крестьянам дер. Каменного Брода Аитом Салимов были поданы на Высочайшее Имя четыре Прошения о дозволении крещенным татарам обратиться из православия в магометанство. Прошения эти до доведения их до Высочайшего усмотрения были оставлены без последствий, о чем на них и были сделаны надписи Г. Министром Внутренних Дел. Распоряжение это было объявлены крещенным татарам лично Казанским Вице-Губернатором Г. Розовым, но они единогласно заявили, что в православии оставаться не желают. Вследствие чего было возбуждено дело сначала против поверенных на Высочайшее Имя прошение, а затем и против прочих лиц, участвовавших в даче своего согласия на подачу тех прошений. Вслед за тем—частью по донесениям местного духовенства, а частью по распоряжению ближайших чинов полиции, стали привлекаться к ответственности крещенные татары за отпадение от православия, причем о каждом таком случае уклонения возбуждалось отдельное следствие. Таким образом в Казанском Окружном Суде возникло 35 отдельных производств по рассмотрению которых 28 марта 1879 года, Казанский Окружной Суд признал дела эти подлежащими рассмотрению Судебной палаты. По делу этому, рассмотренному 15 мая 1879 года в распорядительном заседании Судебной палаты состоялось постановление о прекращении производства этого обвинения суду, так как отступление от христианской веры православного исповедания в веру не христианскую, подвергаются только увещеванию и вразумлению посредством духовного начальства. В настоящее время в архивных делах как Полицейского управления, так и бывшего Земского Суда никакой переписки отпавших от православия в магометанство крещенных татар Новых Чечкаб нет.

Все означенные крещенные татары к магометанским приходам до прежде сего не принадлежали и не принадлежат, к принятию христианства просителей и их родителей никто не притеснял и от православных приходов никто не отчислял. У всех просителей никаких треб, ни православный священник, ни магометанский мулла не совершают, а таковые исполняются между собой грамотными татарами без записей в метрические книги".

Әллә, бу киребеткән татарларны барыбер күндереп булмас, дип, әллә Россия императоры Николай Икенченең 1906 елгы манифестын үтәү йөзеннән, ниһаять, авылга поплар килеп йөрүе тәмам тукталган. Шулай да мөселманнар белән керәшеннәр арасында ул чакларда никахлашу дигән нәрсә барыбер булмаган әле. Аралар акрын-акрын, керәшеннәр, тәмам мөселманлыкка күчеп, башкалар кебек көн итә башлагач кына жылынган. Хәзер инде ул чорларны хәтерләүчеләр дә юк. Авыл, бөтен үткәннәрне онытып, инде туганлашып беткән. Шул каһәрле чорларның бер сагышлы ядкаре булып "Бабайлар зираты" дигән урын гына калган. Анда хәзер кеше күммәсәләр дә, барыбер караулы, тирә-ягы тотылган. Каберләр өстендә үскән агачлар гына, шул хәтәр заманнарны искә төшергәндәй, үзара тын гына нәрсәдер сөйләшәләрдер сыман.

Минем бабайлар әлеге чукындыру афәтеннән ничек котылып кала алганнардыр—билгесез. Әмма бу нәселдән укымышлы муллалар да чыккан. Берсе хәтта, кыр эшләре тәмамланып бераз иркен сулыш алырга жай тугач, ерактагы далаларга барып, казакъ һәм кыргыз балаларына дин сабагы да биреп йөргән. Шәжәрәнең мин белгән өлешендә, иң түрендә—Мыек нәселе вәкиле Йөркәй бабай. Минем үтенеч буенча авыл картлары төзеп биргән схемада ул гарәп хәрефләре белән "Жүркә" дип язылганга ошый. Сөйләштә "ж"еләштерү галәмәте генәдер бәлки. Аның улы Чуртый һәм оныгы Чурай да кайбер сораулар тудыра. Борынгы Иске Чәчкап авылы көчләп чукындыруга бездән шактый алда—ике йөз елдан элегрәк дучар ителгән бит—шуның бер чагылышы түгел микән?.. Хәер, ул чорларда моңа охшаш исемнәр кулланышта әле йөргән бугай. Академик Гомәр Саттаровның "Татар исемнәре сүзлеге"ндә бу исемнәрнең төрдәшләре байтак китерелә. Минем шәжәрәдәге Чурайдан соң гына чын-чынлап мөселман исемнәре тезелеп китә: Бикмәт—Ишмәт—Бикмөхәммәт—Ишмөхәммәт—Вәлиша—Бәхтияр—Батырша—Гаделша—Габдерәшит...

*Бу җирләргә башлап аяк баскан*
*Бабайларны барлыйм кай ара—*
*Шәҗәрәләр серен чишә-чишә*
*Әллә нинди уйлар яңара.*

*Заманалар белән бәхәсләшеп,*
*Иманнарын саклап күңелдә,*
*Язмышларның яңа сәхифәсен*
*Сырлап язган алар бирәдә.*

Аерылып башка чыккан Бүре, Кылый, Мыек нәселләре иң беренче туган нигезләре белән багланышларны бервакытта да өзмәгәннәр, күрәсең. Иске Чәчкапта мәчет ачылу уңаеннан җыелган аш мәҗлесендә картлар миңа: "Фәлән абзый исәнме әле?", "Фәлән апа синең әти-әниеңне белергә тиеш" кебек сораулар да яудырганнар иде. Мөгаен, элемтәләр әле без яшәгән заманда да нык булган, ә татарлар мөселманнарга һәм керәшеннәргә бүленгән катлаулы чорларда, яңа урынга тупләнгән кияү буласы егетләр кәләш эзләп, еш кына Иске Чәчкап тарафына да чыгып киткән. Шушы авылда туып-үскән һәвәскәр тарихчы Кадыйр Галимов, Казан, Ульяновски, Мәскәү архивларында казына торгач, мин белгән бабайларның элгәрләре дә элекке иске нигездә яшәгәннәр, дигән фикергә килгән иде. Бирегә беренче күчеп килүчеләрдән соң әлләни күп буын алмашынмаганын искә алсак, минем туган авылыма, егерменче гасыр башынача дип санасак, 240-250 еллар элек кенә нигез салынган булып чыга. Ә яңа дәвер, үзем шаһит булган дәвер, миңа азмы-күпме таныш инде...

Тарих упкыннарында никадәр сер бар? Ничекләр генә фараз кылсаң да, ахыргача очына чыга торган түгел. Мин үземне дә иң соңгы дөрес сүзне әйткәнмендер дип санамыйм. Авылым Яңа Чәчкап атамасын да галимнәрнең төрлесе төрлечә аңлата: кемдер Чәчкә атлы би (бәк) белән бәйли, икенчеләр исә анда Болгар хатын-кызларының бизәнү әйбере—чәч кабы ясалган остаханә булган дип бара. Кызыксынуым ничек кенә көчле булса да, аларга хөкем чыгару минем эш түгел.

*Бу тарихлар күптән үткән—*
*Анда түгел бәхәсем...*
*Чәчкап исемен Чәчкап алган*
*Һәм иманын саклап калган,*

*Татар угылы татар туган—*
*Шәҗәрәгә дәвам булган..*
*Шунысы алтын бәясе..*

## Өзелгән чылбыр

Бабаларымны саный торгач, иң соңыннан Габдерәшит дигән исемне атаган идем!.. Габдерәшитнең "Габде" дигән өлеше хәзер тәмам онытылган инде. Хәзер без аның оныклары "Рәшитов" булып кына йөрибез. Мин дөньяга килгәндә, ул булмаган инде. Хәтта әтием Габделәхәт тә (аның да исемен яңа заманда Әхәт дип кыскартканнар), бабай гаип булган елларда ун-унбер яшьләрдә генә әле. Бу—егерме беренче, тарихларда, Мәҗит Гафури һәм Галимҗан Ибраһимов кебек атаклы язучыларыбыз әсәрләрендә каһәрләнгән ачлык еллары. Безнең авылда алар тасвирлаган кеше ашау галәмәтләре булмаган булуын. Әмма ачлык үзенең кара эшен барыбер эшләгән—буыннар чылбыры өзелгән. Бабайның энесе Хөсәен абый сөйли торган иде. Алар, нәрсәгәдер өмет итеп, ул чактагы Петроградка юл тотканнар. Ә анда... тоттырдылар, ди капчыгын, шул ук хәл... Хөсәен абый, тормышын рәтләү түгел, хәтта бердәнбер абыйсын—минем Рәшит бабайны да—шул ачлык-ялангачлык дөньясында югалтып, көч-хәл белән туган якларга кайтып егылган. Таза, көчле, буе ике метр тирәсе кеше иде. Барыбер үлгәнче тернәкләнә алмады.

Шул каһәр суккан елда бабай белән әби ике малайны үзара бүлешкән булганнар: бабай әтине, ә Хәдичә әби—аның абыйсы Габделкаюм абзыйны ач үлемнән коткарып калырга дип килешкәннәр. Хәдичә әбине аз гына хәтерлим әле мин. Ул күрше—Кужак дип йөртелгән көмешчеләр авылыннан. Таяныр туганнары аз-маз ярдәм иткәләгәнме, чаялыгы, авылдагы хатыннарның берсенә дә баш бирмәс булуы, чәчрәп торуы булышканмы, ничектер ул очын-очка ялгый алган. Әти исә, әбидән ярдәм тамгаласа да, капчык асып тирә-юньдәге хәллерәк авылларга теләнергә чыгып киткән. Гади теләнче генә булмаган ул үзе—тамагын җыр җырлап, такмак чыгарып туйдырган. Аңа бу сәләт бабайдан күчкәндер, күрәсең—Каюм абый аның кызыклы-кызыклы әкиятләр сөйләвен әледән-әле искә ала, "әти сөйли торган иде" дип бик күп мәртәбәләр әйткәли иде. Юктан гына булмагандыр. Һәрхәлдә әтинең чордашлары ул чыгарган бәетләрне һәм такмакларны миңа күп тапкырлар кабатлап искә төшерәләр иде. Ничәмә-ничә еллар шуларны хәтердә тотарга кирәк бит!

Тормышлар бераз рәтләнгәч, ул укыйсы иткән. Уку дигәч тә, ул вакытта авылда шул башлангыч мәктәп кенә инде. ТБУМ дип мәзәкләргә кергәне юк әле ул чагында.

Әти тырышып укыган, күрәсең—аны иң беренчеләр рәтендә жиде яшүсмер арасында пионерга да кабул иткәннәр. Ачлык-ялангачлык, авыл халкының тенкәсенә тиеп беткән авыр хезмәт аркасында буйга да әлләни үсә алмаган. Югыйсә минем бабайлар болай элек-электән эре сөякле, мәһабәт гәүдәле булганнар. Минем үз малайларым да шул бабаларына тартканнар, күрәсең—икесе дә озын буйлылар. Мин генә, кәтәнә булмасам да, буем белән бик мактана алмыйм. Шул авыр заманнар хикмәтедер инде.

Әтинең такмак чыгарга һәвәслеге турында әйтим әле.

Мин малай чагында авылдашлар сөйли торганнар иде. Кайберләре турында әти колхозның стена газетасында усал-усал эпиграммалар да язып чыгарган. Кайберләрен авыл агайлары көлешә-көлешә мина да аңлаткаладылар.

—Ну ачуым килгән иде инде ул вакытта атаңа,—дип өстәп тә куялар иде. Минем архивымда аның белән якыннан аралашып яшәгән Имам абыйның хатирәләре саклана. "Әхмәт, жибәргән хатыгыз мине бик еракка, моннан ярты гасыр элек үткән үсмер чагыма алып китте,—дип яза ул.—Менә әтиегез Әхәт абый да, ике кулы чалбар кесәсендә килеш һәрвакыттагыча ачык йөз белән елмаеп, күз алдыма килеп басты. Дөрес, Әхәт абый белән безнең яшь аралары зур. Шулай да бер-беребезгә мөнәсәбәтебез якын иде.

Минемчә, моның сәбәбе—без икебез дә әдәбиятны бик ярата идек. Ул мина күп вакытта үзе укыган "Совет әдәбияты"н (хәзерге "Казан утлары".—Ә.Р.) бирә иде. Икенчедән, Әхәт абый авылның культура-агарту эше буенча иң актив оештыручысы дисәк тә ялгыш булмас. Чөнки аның катнашыннан башка бер генә спектакль дә узмады. Ул, спектакльләрне әзерләгәндә, мине суфлер итеп ала иде: "Хажи әфәнде өйләнә", "Банкрот", "Галиябану"ны куйган чаклар нык хәтердә калган. Әхәт абый бик мәзәкчән кеше иде. Бервакыт ул мина: "Син, егет, беләсеңме, Такташның "Мокамай"ын өйрән, сәхнәгә чыгып сөйләрсең,—диде. Мин бик тырышып өйрәнеп килдем. Мин, күрәсең, бик кычкырып сөйләргә тотынганмындыр. Ул: "Тукта, ул кадәр кычкырма. Такташ абыең ишетсә, колагыңны борыр",—диде. Ул үзе шигырьләрне бик яхшы укый иде. "Менә болай укырга кирәк",—дип яңадан өйрәнеп килергә кушты.

Сез, аның шигырьләрен искә төшерә алмассызмы, дип сорагансыз. Хәтердә калганы шул. Бервакыт тракторчылар Изах, Риза, Жәләл кызу эш вакытында тракторларын кырда калдырып өйгә чәй эчәргә кайтканнар. Әхәт абый аларны:

| | |
|---|---|
| *Тракторны ватканнар,* | *Авызыбыз кипте, диеп,* |
| *Кырын китеп ятканнар,* | *Чәй эчәргә кайтканнар,—* |

дип стенгәзиттә язып чыгарды. Әхәт абыйның:

| | |
|---|---|
| *Арып кайткан Сәкинә,* | *Майсәрвәрне үлгән, диләр,* |
| *Сузылып яткан сәкегә,* | *Әле дә булса селкенә,—* |

дип язганы да хәтердә сакланган. Тагын бер вакыйга истә калган. Бер чакны колхоз идарәсендә Гафият абый, Жамалетдин абый, тагын кемнәрдер атлар үрчетү турында сүз көрәштерәләр. Әхәт абый тыңлап тора да:

| | |
|---|---|
| *Тукта әле, Гафият,* | *Сорап карыйк—бу турыда* |
| *Сөйләп торма әкият,* | *Нәрсә әйтер Гатият,—* |

дип көлдерә.

Әхәт абый бик күңелле кеше иде. Минем аның бервакытта да кеше белән ачуланышканын күргәнем булмады".

Мин дә шулайрак уйлаган идем. Буа район газетасы "Яңа юл"ның төпләмәсен, чыга башлаган вакытыннан алып карап, актарып утырдым. Нишләптер, шигырь затыннан бернәрсә дә күренмәде. Әти имзасы белән чыккан ике мәкалә генә очраттым. Үзебезнең "Үзәк" колхозындагы хәлләр турында тәнкыйть. Аннан... аның үзе турында... "Критика и самокритика" дигән нәрсәләрнең чәчәк аткан чагы бит. Ләкин, көл дә, ела да, дигәндәй, авторларның псевдонимнарына игътибар ит әле син—нинди "Очлы күз", "Күреп торучы", "Сак колак", "Күрүче"... тагын әллә нинди аноним авторлар. Әнә, нинди "Белүче" дигән берәү "Активлар кирегә тарталар" дигән мәкаләсендә авыл советы хисапчысы Рәшитовның 50 килограмм ит налогы урынына әле 19 кг гына тапшыруы турында чаң кага. Икенче берәү агитатор Ә.Рәшитовның сайлау алды компаниясендә сүлпән катнашуын тәнкыйть итә...

Әйе, нишлисең бит, үзең яшәгән заманнан өстен булу мөмкин түгел. Еллары да нинди бит аның. Социализм төзи торган чор. Кешеләрнең алдагы көнгә өмет һәм

ышаныч белән караган, ил башлыкларын яхшы патша итеп кенә түгел, Алла итеп санаган чаклар. Гомер-гомергә шулай бит инде ул—адәм баласын өмет яшәтә.

Әти дә, алма пеш, авызыма төш, дип күккә карап ятмаган. Өйләнер вакыты житкәч, Донбасс шахталарына барып, бераз акча эшләп кайткан. Безнең татарның шулай бит инде—үз көнен үзе күрергә тырыша. Аннан, авылга кире әйләнеп кайткан да, гаилә кору хәстәренә керешкән. Нишләптер, күзе үзебезнең авыл кызларына төшмичә, кәләшне күршедәге Норлаттан эзлисе иткән. Бәлки ул мина әни буласы кешене әле малай чагында, теге авылдан-авылга йөреп, жырлап, биеп, такмак чыгарып йөргән чакларда ук күзләп куйган булгандыр. Ә бәлки... Ни әйтсән дә, Норлат—мәдәниерәк, затлырак, алдынгырак авыл. Безнең Яңа Чәчкап исә, ни әйтсәң дә, карангырак, мәдрәсәсе дә кадими, кешеләре дә, Тукайча итеп әйтсәк, “искеләр”, дигәндер. Хәер, кем бизмәнгә салып караган инде ул кадәресен. Әнинен жан дусты—сердәше Гөлсем апа сөйли торган иде: “Атаң ике көннән берендә килеп йөрде безнең авылга, әниенне тәки үзенә каратты. Анын ул теле белән, патша кызын ярәшсә, хәтта патша да биш куллап риза булыр иде... Чибәр иде шул әниен... йөргән егете булмыймы соң шундый кызларның. Ә атаңның шайтан төкергән теле тәки анын башын әйләндерде. Ходай шулай язгандыр инде”.

Шулай итеп әни Яңа Чәчкапка килен булып төшкән. Житеш гаиләдә туып үскән, үз кадерен үзе белгән әнигә ниндидер шахталарда зимагур булып йөргән әти белән салам түбәле балчык өйдә яшәп китүләре жинелдән булмагандыр. Кайнанасы Хәдичә әби дә ут кебек чәчрәп торган, бер сүзгә уны белән жавап кайтаручы, авыл хатыннарының атаманы саналган кеше бит әле! Әнинең атасы Хисаметдин бабай, колхозлашу чорында ике аты, өч сыеры тартып алынса да, аягында нык торган, бер-бер нәрсә килеп чыкса, таянырдай Сиражетдин, Минһажетдин, Низаметдин кебек әзмәвердәй өч энесе булган, абруйлы кеше бит әле ул чакларда. Сөйләшүләренә караганда, шул дүрт егет бөтен Норлат авылын үз кулында тоткан—аларның кайсын да булса рәнжетергә беркем кыймаган.

Әнинең туган жире булгангамы, әллә вакыт-вакыт күнелем яраларын оныттырырдай бер тылсымлы урын тоелганмы, мин Норлат авылын гомер буе якын иттем. Анда бабамның һәм әбиемнең күнелемне юатырдай кардәшләремнең эзләре сакланадыр шикелле. Бала чагымда ук жай чыккан саен барасы гына килеп тора иде. Инде олыгайгач та эзне суытканым юк. Нәрсәдер гел шунда тарта, бер өзлексез чакырып-ымсындырып тора. Югыйсә андагы туганнар—нәсел агачының ерак, әллә ничәнче буын ботаклары. Ә бер кайтуымда гажәеп ачыш ясадым. Әти белән әнинең кавышуына шаһит... әйтсәң кеше ышанмас... авыл башында үскән гап-гади... карт өянке белән кабат очраштым. Исән икән бит әле ул. Колач житмәстәй юан шул жан иясен... (әйе, әйе, жан иясе дип атыйм мин аны—биологлар битәрләмәсеннәр!) кабат күргәч, күнелем әллә нишләде. Күпме гомерләр башка дөньяларга күчкән, күпме хатирәләр—яктылары да, сагышлылары да онытылган, ә ул... исән. Ә ул яз саен яфрак яра... Һаман да хатирәләрне яңарта.

Хәтта аңа багышлап шигырь язганымны да хәтерлим әле. Әллә нишләдем мин ул вакытта. Елак малайныкы кебек күзләргә яшьләр тулган иде. Ә мин ак кәгазь битенә сырладым да сырладым.

*Исәнме, йөзьяшәр өянке, исәнме,*
*Жилләр соң рәнжетеп, йә назлап исәме?!*
*Ә минем йөрәккә кирт булып уелган*
*Боегып яшәгән ул еллар исәбе.*

*Син минем әнинең яшьлеген күргәнсең,*
*Син аны әтигә кияүгә биргәнсең;*
*Бердәнбер шаһит син ул туйга Норлатта—*
*Сөйлисең шул хакта елап та, жырлап та.*

*Әти дә, әни дә күптәннән юк инде—*
*Тәннәре күптәннән туфракка төренде;*
*Күптәннән гөл үсте каберләр өстендә,*
*Хәсрәтле ул еллар башлардан кичте дә.*

*Еш килә идем мин син үскән бу жиргә—*
*Күнелләр тулганда еладык гел бергә.*
*Иң ачы күз яшем шушында төшкәндер—*
*Тамырлар буенча кәүсәңә күчкәндер.*

*Елама, өянке, ул еллар ерakta—*
*Яралар төзәлми... төзәлмәс елап та...*
*Нык булыйк, нык торыйк—башкача ярамый,*
*Үскәнбез бит әле, жилләргә карамый.*

*Исән бул, йөзьяшәр өянке, исән бул—*
*Тимәсен, кисәм, дип, кәүсәңә усал кул.*
*Синнән гел таңнарда яфраклар жырында*
*Сөйләнсен бәхетле язмышлар турында.*

## Варис

Кайчан тәпи йөреп киткәнемне дә, ничек бытылдый башлаганымны да белмим. Әнә кайбер җан ияләре, дөньяга килүгә үз күннәрен үзләре күрә башлыйлар. Кеше кавеме генә гомеренең күпме өлешен мәми сорап, тәти таләп итеп үткәрә. Кайберләренең ул чоры озаккарак та сузыла. Нәрсә хәтерлим мин ул заманнардан?! Әлбәттә, җитди сәбәбе булмаса да, гел-гел елаганымны... Өлкәннәрнең сөйләвенә караганда, бик тә елак булганмын мин. Авыл хатыннарының: "Әниең, бу баланың бирәр җире авыртса микән әллә, елавыннан бер дә туктатып булмый, дип гел-гел зарлана иде",—дип күп тапкырлар сөйләгәннәре бар. Тенкәсенә тигәнмендер инде. Хәер, минем кечкенә малай да унике-унөч яшьләренә кадәр елак булды. Әнисенә, аптырагач: "Кайгырма, Лев Толстой да елак булган" дип шаярта идем. Хәзер менә уйланам-уйланам да, үземчә нәтиҗә ясап куям: бүкән кебек тавышсыз-тынсыз бер утырган җирдә сәгатьләр буе кымшанмыйча утырган сабыйлар, үсеп җиткәч тә, Ходай биргәнгә шөкер итеп яшиләр, "ник алай, ник болай түгел?", дигән "ахмак" сораулар бирмиләр, эш үгезе кебек, ни кушсалар, карышмый-нитми шуны эшлиләр. Әлбәттә, алар арасыннан да зур дәрәҗәләргә ирешкән кешеләр чыга. Чыкмый дип әйтмим... чыга. Ләкин... Юк, үземнең елаклыгымны аклар өчен әйтмим. Әмма мина үз дигәнемне шулай әйтергә кирәк булган. Нәрсәнедер ватарга, җимерергә кирәк булган, ни өчендер, "ләчә белән чүни" ягъни сабый теленнән хәзергегә күчерсәк, "келәшчә белән чүкеч" кирәк булган. Әти белән әнинең минем кирелекләремә риза булып торулары кирәк булган. Бәлки бу минем үтә иркә булуымнан килгәндер—кем белә бит. Ләкин әти белән әни, нишләптер мина яраргa, мине юатырга тырышканнар. Бигрәк тә әти мөкиббән булган инде минем туууыма. Үзе ятим калып, кимсенеп, кагылып-сугылып үскәнгәме, ниһаять, минем дә дөньяда үз варисым бар, дигән сөенечле уйданмы, ул бернәрсәне дә кызганмаган: бир дисәм биргән, ал дисәм алган. Хәтта исем кушкан чакта да үз исеменә охшаганын сайлаган: Әхәт угылы Әхмәт булсын, дигән. Ә әни мәрхүмә, гөнаһсына кереп әйтмим, бераз кырысрак иде шикелле. Хәлбуки төсем-битем белән мин ана ошаганмын. Халык әйтмешли, суйган да каплаган.

Миннән соң туган сеңелләрем исә—Раушания дә, Фәүзия дә әти ягына тарткан иделәр. Раушанияне бераз гына хәтерлим әле мин—ул өч яше тулар-тулмас чәчәк авыруыннан дөнья куйды. Чаялыгы, уйнаганда гел малайлар арасында буталганы өчен, әни үзен: "Ирдәүкәләнеп үсмә" дип орыша да иде. Фәүзия исә әти кебек үк "ике түбәле"—баш очында да, маңгай турысында да чәчләре бөтеркәләнеп тора иде.

Әти, балаларын тигез күрсә, тигез яратса да, аның мина мөнәсәбәте ничектер үзгә булгандыр, күрәсең. Бәлки мина гына шулай тоелгандыр. Ата кешегә ир бала, ни әйтсәң дә, якынрак була бит.

Ул тыныш, тынгысыз, тиктормас кеше иде. Шактый хәлле гаиләдә туып үскән әнине, җылы оясыннан аерып, салам түбәле тар, бәләкәй, балчык ызбага алып кайтуына эченнән хурлана да торган булгандыр. Утыз тугызынчы елда, тормышларны бераз рәтләп булмасмы, дип, туган-үскән җирдән аерылып, Пермь өлкәсенең Барда районындагы "яна җирләр"гә күчеп китәсе иткән. Ничектер мием күзәнәкләренә сеңеп калган шул Карман дигән авылның кай якларда булганын озак еллар буе белми дә яшәдем. Олылардан сорашыр идем—кыюлык җитми. Хәер, күбесенең андый атаманы ишеткәне дә булмагандыр. Әллә Башкортстанның Янавыл төбәгендәге Карман, әллә хәзерге Зәй районындагысы... Азмыни дөнья картасында шундый исем йөрткән авыллар. Тәпчепә торгач, тәки ачыкладым мин аны: балачагыма шаһит ул авыл фольклорчы галим Рәшит Ягъфәров туып үскән якларда булып чыкты. Әле ул гынамы?! Анда безнең шәҗәрәнең бер бик якын ботагын тәшкил итүче ерак туганнарым да яши икән әле. Барда каласының татар гимназиясендә әдәби очрашулар оештырырга килгән язучылар һәм шагыйрьләр каршында җирле һәвәскәрләр дә чыгыш ясаган иде. Аларга пианинода бик матур итеп уйнаган Гүзәл исемле чибәр ханым аз да түгел, күп тә түгел, минем дүртенче буын сеңелем булып чыкты. Ул мине аннан соң өендә дә кунак итте, башка туганнар белән дә таныштырды. Ат кешнәшеп, кеше сөйләшеп таныша, дип тикмәгә генә әйтмиләр шул. Шулай итеп бер өзелгән җеп янадан ялганды.

Кеше дигән җан иясендә ниндидер аңлаешсыз, интуитив җирсү, нәрсәгәдер тартылу хисе була, диләр. Башка юлдашларым (без шагыйрә Резеда Валиева, драматург Радиф Сагъди, балалар язучысы Ләбиб Лерон, бу якларда яшәүче һәвәскәр композитор Сәубән Чуганев һәм фольклорчы галим Рәшит Ягъфәров), белмим, ничектер, әмма

мин Барда якларына ниндидер бер ашкыну белән килдем. Ерак калган балачагым белән очрашасым килгән иде. Әтием бу якларда урман кисү, сал агызу кебек эшләрдә эшләгән. Ул чорлар хәтердән өзек-өзек кинокадрлар шикелле генә уза. Менә мин үзебез фатир кергән бер бабайның мич башында аның мылтыгы белән уйнап утырам (нишләптер бу авылның һәр өендә мылтык тоталар иде). Малай-шалай өчен аннан да кызык әйбер бармыни?! Менә көтүченең быргы кычкыртканы ишетелә—сыерлар, сарыклар, кәҗәләр шул тавышка үзләре үк билгеле бер җиргә туплана башлыйлар. Менә мин, әтигә ияреп, болынга барам—печән чабучылар артыннан кып-кызыл тасма сузыла, җир җиләгенең исәбе-хисабы юк. Һәм менә... хәтердә сакланган иң куркыныч вакыйга. Без сеңелем Раушания белән (минем тиктормаслык аркасында инде!) авыл өстенә авып торган урман эченә, куе чытырманлыкларга кереп китәбез һәм... адашабыз. Миңа ул вакытта дүрт, сеңелемә өч яшьләр булгандыр. Табигый, куркышып, елашып беткәнбез—котылудан тәмам өмет өзгәнбез.

Безнең бәхеткә, әти шул урманга юкә каезларга кергән булган. Елаган тавышыбызны ишетеп, безне эзләп тапкан. Югыйсә шул карурманда харап буласыбыз икән! Бу хәлләрне мәрхүмә әни соңыннан бик күп мәртәбәләр гел-гел тетрәнеп сөйли иде. Ул вакытта бик үк тыныч һәм ышанычлы булмаган, төрле яклардан җыелган төрле халык—сезонлы эшчеләр белән мыжлап торган ул Яңа Җир дигән урыннан туган-үскән якларга—Буа районының Яңа Чәчкап авылына—кире кайтырга да әтине әни күндергән. Безнең урманда адашуыбыз аның өчен бик зур борчу булган. Әти, шактый "баеп" авылга кайтуга, шыңгырдап торган нарат бүрәнәләрдән хәтта авылның хәллерәк кешеләре дә көнләшерлек итеп, зур йорт салдырган.

Барда ягына бергә барган юлдашларыма әнә шул хәлләр турында да сөйли-сөйли йөрдем. Әлбәттә, буяулар бераз куертылган да булгандыр. Шулай да сөйләгәннәрем шагыйранә, чын, балачак хыяллары белән генә өртелгән иде.

*Истә икән әле, истә икән*
*Карман авылының зәңгәр таңы;*
*Каршы ала мине шаулый-шаулый*
*Балачакның сихри карурманы.*
*Ул чордан соң күпме сулар аккан,*
*Ничә давыл кичкән безнең баштан;*
*Татлы хыяллары балачакның*
*Тик барыбер инде чынга ашкан.*

*Бик күрәсем килгән иде аны,*
*Яшь сарыла шуңа күзләремә;*
*Урамнарын буйлыйм, баса-баса*
*Балачакның кайнар эзләренә...*
*Сагындыра Карман, сагындыра—*
*Ул гомерләр калган үткән чорда;*
*Мин адашкан идем урманында—*
*Һәм бүген дә әзер адашырга...*

Ни өчендер минем күңелне гомер буе шундый әкияти урыннар—куе карурманнар, шашып-шашып шаулаган диңгезләр, биек-биек таулар әсир итә. Безнең авыл исә "Кыр ягы" дип санала. Дөрес, кайчандыр, әле бабайлар бу якка күчеп килеп, Яңа Чәчкап авылына нигез салганчы башкачарак булган дип сөйлиләр. Пермь якларындагы кебек карурманнар шаулап тормаса да, авылдашлар йорт салырга, каралты-кура корырга кирәккәндә, әллә кайларга барып, кемнәргәдер гозерләп йөрмәгәннәр—төзелеш кирәк-ярагын тирә-юньнән генә тапканнар. Кызганыч, ул урманнарның, таллыкларның, алардагы күлләрнең инде атамалары гына сакланган. "Имән чирәме", "Куш куак", "Баллы куак", "Тәүгелде чирәме" кебек җирләр генә узган дәверләрне искә төшереп тора бугай. Хәер, алай дисәң, табигатьнең үзенең дә, мөгаен, хәтере бардыр. Мин туып үскән нигездән ерак түгел генә, җир күпмедер инеп, туфрак сазлыкка әйләнеп, җикән камышлар үсә башлаган. Ул урында кайчандыр күл булган имеш дип тә сөйлиләр.

"Кыр ягы" дип хурласалар да, якын ул миңа, бик якын. Беренче илһамымны шунда тапканмын бит әле. Ул, бәхет эзләргә дип читкә киткән әтине дә үзенә чакырып кайтарган.

Пермь якларыннан кайткач, әти Яңа Чәчкаптан җиде чакрым арырак урнашкан Тутай авылына барып, "Байкал" колхозы хисапчысы булып эшли башлады. Ул елларда укый-яза белгән, бигрәк тә исәп-хисап эшенә һәвәс кешеләр бармак белән генә санарлык бит—аны биш куллап кабул иткәннәр.

Әти ат җигеп атнага бер тапкыр авылга кайтып килә, еш кына мине дә үзе белән "кунакка" алып китә иде. Моның мин сабый аңламастай үзенә күрә бер сере дә булган икән. Хәер, анысы турында бераз соңрак...

*Дәвамы киләсе саннарда*



***—Татар рухын, милләтебез бердәмлеген кайгыртучы матбага буларак ачылган "Шәһри Казан" соңгы елларда чын мәгънәсендә халык газетасына әверелде. Алга таба мәсләгегез нидән гыйбарәт?***

**«Шәһри Казан" газетасының баш мөхәррире Мансур МОРТАЗИН:**

—"Шәһри Казан" газетасының беренче саны дөнья күргәндә мин әле 24 яшьлек өйләнмәгән егет идем. Бүген инде "Шәһри Казан"га да 18, мина да бер айдан 42 яшь тула. Газетаның егет чагы, ә мин исә ир уртасы, ике бала атасы. Әгәр мине "Шәһри Казан"га иртәрәк мөхәррир итеп билгеләп куйган булсалар, монда эшли алыр идемме икән? Кырыкны узгач, шактый дөнья күргәч, лаеш шулпасы эчкәч, тормыш тәҗрибәсе туплап кына "чын безнеңчә, милли матур" газетага килүем эшне башлаганда үземә бик зур таяныч булды. Юкса, без өйләнгәч төн кыскара дигәндәй, мин баш мөхәррир булып эшли башлауның беренче көннәреннән үк массакүләм мәгълүмат чараларын акционерлаштыру, ягъни үз көннәрен үзләре күрү юлына этәрә башладылар. Җитмәсә әле газетаның болай да үз хәле хәл иде. Хәзер инде авырлыкларның күбесе артта калды. Шөкер, 18 яшьлек "Шәһри Казан"ның бүген инде үз йөзе, үз укучысы бар. Әбунәчеләребезнең саны да акрынлап кына булса да арта бара. Авторларыбыз саны да ишәя. Татарстан Журналистлар берлеге һәм "Татмедиа" АҖ үткәргән массакүләм мәгълүмат чаралары конкурсында быел "Шәһри Казан" газетасы "Иң яхшы шәһәр газетасы" исеменә һәм "Бәллүр каләм"гә ия булды.

90нчы елларда шагыйрь Равил Фәйзуллин тәкъдим иткән исем белән дөнья күрүче "Шәһри Казан" газетасы нәшер ителә башлавының беренче көннәреннән үк милли мәсьәләләр турында тәфсилләп яза башлады. Моңа гаҗәпләнергә дә кирәкми, чөнки газетабыз мөстәкыйльлек дип җан атып йөргән 1990 нчы елда, ягъни Татарстанның суверенитеты турындагы декларация кабул итәргә 13 көн генә калгач, үзенең тәүге санын чыгарды. Без бүген дә халкыбызның үткәненә, бүгенгесенә, киләчәгенә кагылышлы язмаларга урынны түрдән бирәбез. Милләтебез, телебез сакланмаса—"Шәһри Казан"ның да киләчәге юк.

"Шәһри Казан" газетасының республикабызның барлык шәһәр һәм авылларында әбунәчеләре булса да, без беренче чиратта Казан газетасы саналабыз. Шуңа да аның битләрендә меңьеллык башкалабыздагы хәл итәсе мәсьәләләргә зур урын бирелә. Казандагы яңалыклар мәркәзебездән читтә яшәүче укучыларыбызны әле күбрәк тә кызыксындыра. Төбәкләрдә укучыларыбызның күбрәк булуы шул хакта сөйли. Әмма Казаныбызда яшәүче ярты миллионнан артык милләттәшебезне дә татар матбугатына тартасы иде бит. Без хәзер шушы олуг максатны тормышка ашыру өстендә эшлибез. Әмма шәһәр татарыннан татар ясау кебек гаять катлаулы бурычны без бергәләшеп эшләсәк кенә гамәлгә ашыра алачакбыз. Димәк, Казан шәһәрен татар иленең башкаласына әйләндерергә теләгән һәр кеше дә "Шәһри Казан"ны укырга тиеш. "Шәһри Казан"да бергә кайныйк" дигән безнең шигарьгә сез дә кушылсагыз иде.



*Дуслар (сулдан уңга): Хәмит Әбүбәкеров (музыкант), Ренат Гыйбадуллин (рәссам), Заһит Хәбибуллин (композитор), Марат Рахманколов (рәссам). 1934 ел. Мәскәү.*



*Андре Тиммерманс (1917-67)—Бельгия гражданы. Муса Җәлилнең "Моабит дәфтәре"н, төрмә-зинданнарда саклап калып, Илгә кайтарткан шәхес.*



„АНГЪ"

کتبخانه‌مز

کوچرلدی:

*"Казан утлары" журналының башлангычларыннан берсе саналган "Аң" журналының (1912-1918) тышлыгы. Нашире һәм мөхәррире—Әхмәтгәрәй Хәсәни.*



*Күренекле язучы Ләбибә Ихсанова I нче татар гимназиясендә очрашу вакытында. 1998 ел.*



*Күренекле әдәби тәнкыйтьчеләр. Сулдан уңга: Рафаэль Мостафин (Казан), Роберт Бикмөхәммәтов (Мәскәү). 17 май, 1989 ел. Татарстан Язучылар берлегенең чираттагы (XI) съезды көне.*



*"Дружба народов" журналының баш мөхәррире Александр Эбаноидзе (уртада утырган) "Казан утлары" редакциясендә кунакта. 2005 ел.*

## Мирфатих Зәкиевкә 80 яшь



Күренекле галим Мирфатих Зәки улы Зәкиев төрки халыкларның этник тарихын өйрәнү өлкәсендә үз мәктәбен булдырган галим. 1928 елның 14 августында Татарстанның Ютазы районы Зәйле авылында туган егет урта мәктәпне тәмамлаганнан соң Казан университетының татар филологиясе бүлегенә укырга керә, аны бик яхшы билгеләренә генә тәмамлап аспирантурага кабул ителә. Сабый чагыннан тырыш, эш сөючәнлек сыйфатына тугры калып ул биредә дә сынатмый, кандидатлык диссертациясен тиешле вакытыннан алдарак яклап, өлкән укытучы итеп билгеләнә. 1960 елда исә яңа гына оешкан татар тел белеме кафедрасы җитәкчесе итеп куела, 1963 елда докторлык диссертациясен яклый.

Галимнең төп гыйльми эшчәнлеге—татар теле грамматикасы, татар теле һәм халкы тарихы, тел сәясәте мәсьәләләре. Ул татар теле буенча мәктәп һәм югары уку йортлары өчен дәреслекләр һәм уку әсбаплары авторы. “Төрки-татар энтогенезы” (Казан-Мәскәү “Фикер”, “Инсан” 1998), “Татар синтаксизы” (Югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан. Мәгариф. 2005), “Проблема языка и происхождения Волжских татар.” (Казань. татар. книж. издат. 1986.), “Происхождение тюрков и татар.” (Москва. Инсан 2003.), “Тюрко-татарское письмо: История—состояние и перспективы.” (Москва. 2005.)

М. З. Зәкиев КДПИ институты ректоры (1967-1986) булып эшләгән елларында гыйльми-педогогик кадрлар әзерләү буенча да, институтның дәрәҗәсен күтәрүдә үзеннән зур өлеш кертә, күп көч куя.

1986 елдан 2000 гә кадәр М.З. Зәкиев Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры итеп билгеләнә. Институтта мөстәкыйль эшләүче этнография, кулъязмалар һәм текстларны өйрәнү, лексикология һәм лексикография, татар энциклопедиясе, экономика бүлекләре оеша.

Фәнни һәм оештыру эшләре белән берлектә М.З. Зәкиев актив җәмәгать эшләре дә алып бара. Ун ел буе Татарстан АССР Югары Советы Рәисе булып тора. Шулай ук Татарстан Югары Советының телләр турындагы закон проектын әзерләү комиссиясе рәисе, иҗтимагый һәм гуманитар Фәннәр буенча республика советы рәисе була. Озак еллар филология фәннәре буенча Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы гыйльми комиссиясен, татар теле буенча Татарстан Мәгариф министрлыгы комиссиясен җитәкли. Галимне төрле телләр арасындагы, милләтара һәм телара багланышлар, икетеллелек һәм күптеллелек кебек мөһим мәсьәләләр дә кызыксындыра, һәм бу өлкәдә дә аның фәнни хезмәтләре бар.

Башкарган хезмәтләре һәм фәнни эшчәнлеге өчен М.З. Зәкиев Хезмәт Кызыл Байрагы һәм Халыклар Дуслыгы орденнары белән бүләкләнә.

Филология фәннәре докторы, профессор Татарстан Фәннәр академиясе хакыйки әгъзасы, гуманитар фәннәр бүлеге сәркәтип-академигы, Татарстан һәм Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе ТР Дәүләт премиясе лауреаты М.З. Зәкиевне олуг юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз, сәламәтлек телибез.

### КАЗАН КРЕМЛЕ—ҖИҢҮЧЕ!

Казан Кремленен Кол Шәриф мәчетен һәм Благовещение соборын үз эченә алган архитектура комплексы "Россиянең жиде могжизасы" Бөтенроссия конкурсында җиңү яулады.

2007 елның көзендә башланып, 7 июльдә тәгалләнгән тавыш бирүнең соңгы нәтиҗәләрен "Всемирный следопыт" журналы хәбәр итте.

Журнал барлык татарстанлыларны Казан Кремленен Благовещение соборын һәм Кол Шәриф мәчетен үз эченә алган архитектура комплексының тавыш бирүдә зур аерма белән беренче урынны алуы унаеннан тәбрик итте. Безнең архитектура комплексы 46483 тавыш җыйган. 17183 тавыш җыйган Псков-Печерский монастыре—икенче, Санкт-Петербургтагы Сарай мәйданы һәм Кышкы сарай (17106 тавыш) өченче урынны яулаган. "Кижи" музей-тыюлыгы (Карелия) дүртенче урынны алган, аның өчен 13723 кеше тавыш биргән. Тубыл Кремле (13236)—бишенче, Выборг замогы (13102)—алтынчы, Түбән Новгород Кремле һәм София соборы (12944) җиденче урынга лаек булган.

### АЛТЫН КАЛӘМ ТУТЫКМАС!

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин парламентта балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр матбугатының "Алтын каләм—Золотое перо-2008" республика фестивалендә җиңүчеләр белән очрашты. Дәүләт Советының матбугат үзәге хәбәр иткәнчә, быел фестиваль Гаилә елына, шулай ук Казанда 2013 елда Универсиада үткәрүгә багышланган иде. Фестиваль 3 этапта узып, аның сайлап алу турлары 30 шәһәр һәм районны колачлады. Төрле номинацияләрдә "иң яхшылар" дип табылган журналист хезмәтләрен тәкъдим итүчеләр (йөзләп яшь журналист) фестивальнең йомгаклау өлешендә катнашты. Ул июньдә "Борис Полевой" теплоходында Казан-Тольятти-Самара-Казан маршруты буйлап узды.

Өч көнлек сәфәр вакытында яшьләр газеталар чыгарды, видеосюжетлар әзерләде, һөнәри осталыкка багышланган дискуссияләрдә катнашты. Жюри Балык Бистәсе районыннан Ләйсән Фәтхетдинова, Яшел Үзәннән Ксения Витовскаяны фестивальнен Гран-приенә лаек дип тапты. Аларга Казан дәүләт университетының журналистика һәм социология факультетына ташламалы шартларда укырга керү хокукы бирелде. Фестиваль ТР Журналистлар берлеге һәм Казан дәүләт университетының журналистика һәм социология факультеты ярдәмендә Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы тарафыннан оештырылды.

### КИЛЕШҮГӘ КУЛ КУЕЛДЫ

Премьер-министр урынбасары—ТР мәдәният министры Зилә Вәлиева белән Россия Федерациясенең Тышкы эшләр министрлыгы каршындагы Россиянең халыкара фәнни һәм мәдәни хезмәттәшлек үзәге җитәкчесе Элеонора Митрофанова Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм «Росзарубежцентр» арасында хезмәттәшлек турындагы килешүне имзаладылар. Ул оешмаларның үзара хезмәттәшлегенең күпьяклы аспектларын көйләргә тиеш булачак.

### ТЕЛЛӘР БАГЛАНЫШЫ

Казанда глобальләшү шартларында туган тел һәм мәдәниятләрне саклау проблемаларына багышланган «Идел буе халыклары телләре бәйләнешләре» дигән җиденче Халыкара симпозиум булып узды. Аны ТР Министрлар Кабинеты, Казан дәүләт университетының татар филологиясе һәм тарихы факультеты оештырды. Җыенда Татарстан, Финляндия, Төркия, Германия, Казахстан, Мордовия, Чувашия, Мари Эл Республикалары галимнәре катнашты.

Симпозиумда татар милләтенең яңарышы һәм үсеше мәсьәләләре, заманча мари һәм мордва телләре лексикасы үсеше, фин-угорлар һәм ислам, Казахстан Республикасы дәүләт идарәсе системасында казах телен куллану мәсьәләләре, татар язуының латинга күчүнең, лингвистик нигезләренә кагылышлы һ. б. мәсьәләләр күтәрелде.

### ТАРИХИ-МӘДӘНИ КҮПЕРЛӘР

Моннан 30 ел элек гамәлгә куелган Халыкара музейлар көне дөньяның 150 илендә билгеләп үтелә. ТР Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева, музей хезмәткәрләрен һөнәри бәйрәмнәре белән котлап, башкала музейла-

рының һәм авыл жирендәге кечкенә генә экспозицияләрнең жәмгыятькә йогынты ясау дәрәжәсе төрле булса да, һәммәсенең дә әһәмияте гаять зур икәнен билгеләп үтте. Музейларның, идея, мәдәни, мемориаль үзәк булараk роле елдан-ел үсә бара, аларның милли казанышларыбызны саклауга, яшь буында Ватаныбыз тарихына ихтирам тәрбияләүгә кертkән өлеше отыры арта. Республикабыз музейлары—төрле халык мәдәниятләрен баету, алар арасында үзара аңлашу һәм хезмәттәшлек урнаштыруда да алыштыргысыз ярдәмче. Болгар шәһәрлеге һәм Алабуганың "Ак тирмә"се, "Свияжский благовест" һәм Шишкин сәнгать симпозиумы, "Казан Кремле" музей-тыюлыгы, Милли музей һәм ТР Сынлы сәнгать музее республикада гына түгел, бөтен Россиядә данлыклы.

Бәйрәм уңаеннан Зилә Вәлиева музей хезмәткәрләренә һөнәрмәндлек, фидакарьлекләре өчен ихлас рәхмәтен житкерде һәм аларга ижат энергиясе, гаиләгә иминлеге, нык сәламәтлек теләде.

### БОЛГАРИЯ ҺӘМ БОЛГАР

Агымдагы елның июль ахыры—август башында "Города-побратимы" фильмының икенче өлешен төшерү башланачак. Әлеге документаль фильмның беренче өлеше Болгариянең Шумен, Мадар һәм Плиск шәһәрләрендә төшерелгән. Икенче өлешен төшерү исә Казан, Болгар, Биләр шәһәрләрендә үтәчәк. Проектны әзерләүчеләр фикеренчә, әлеге фильм Казан белән Болгарның визит карточкасына әверелергә, шулай ук Казан белән Шумен шәһәрләренең якын мөнәсәбәтләрен чагылдырырга тиеш. Документаль тасманы ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туристлык министрлыгы, Казан шәһәре башкарма комитетының тышкы элемтәләр һәм туристлык комитеты ярдәмендә режиссер Людмила Усова житәкчелегендәге ижат төркеме әзерли.

### АКЧА ЖИТСӘ—ЭШ БАРАЧАК

Татарстан Ижтимагый палатасының мәдәният буенча комиссиясе түгәрәк өстәл утырышы үткәрде. Анда «ТР кинематографиясен үстерү концепциясе» проекты, кино сәнгате буенча кадрлар әзерләү һәм туплау мәсьәләләре хакында фикер алышынды. «Татаркино» директоры Владимир Батраков, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты проректоры Павел Терехов, драматург һәм киносценаристлар Мансур Гыйләжев, Айсылу Хафизова, кинорежиссер Салават Юзиев кебек кино сәнгатенә мөнәсәбәте булган ижат әһелләре катнашты.

«Татарстан кинематографиясен үстерү концепциясе» хәзерге вакыттан башлап 2010 һәм алга таба 2015 елларга кадәрге вакытны колачлый. Документ тиздән ТР Министрлар Кабинеты каравына тапшырылачак.

Утырышта катнашучылар, концепциянең теоретик нигезе уңай шәрехләнгән, ләкин аның материаль базасын хәл итәсе бар, дип билгеләде. В. Батраков сүзләренчә, әгәр Татарстанда кино сәнгатен үстерү өчен елына 90 млн. сум чамасы акча табылса, үзебезнең кино төшерү павильоныбыз булса, 2 уен нәфис фильмы, бер аннимацион фильм, кыска метражлы берничә фильм төшереп, кино сәнгатенең үсешенә ирешү бик мөмкин. Ә хәзергә әле Татарстан бюджетыннан кино сәнгатенә елына нибары 9 млн. сум акча бүлеп бирелә.

### ГАРИФ АХУНОВ УРАМЫ

Башкаланың «Кояшлы шәһәр» микрорайонында Татарстанның халык язучысы, ТР Фәннәр академиясенең шәрәфле академигы, Габдулла Тукай һәм Гаяз Исхакый исемендәге премияләр лауреаты, күренекле жәмәгать эшлеклесе Гариф Ахунов исемендәге урам ачылды. Әлеге урамга татар классигының исеме 2007 елның сентябрь аенда ук ТР Министрлар Кабинеты һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты карары белән бирелгән иде. Торак комплексындагы бу урамны Гариф Ахунов исеме белән атау инициативасын Татарстан Язучылар берлеге һәм язучының гаиләсе белдергән.

Әдип исемендәге урамны ачуда ТР Премьер-министр урынбасары—Мәдәният министры З. Вәлиева, Татарстанның Язучылар берлеге рәисе И. Ибраһимов һәм башка рәсми кешеләр катнашты. Тантанага язучының «Хәзинә» романы буенча төшерелгән шул исемдәге нәфис фильмда төп рольләрнең берсен уйнаган РФ халык артисты Александр Филиппенко да килгән иде.

Киләчәктә «Кояшлы шәһәр» микрорайонында, Гариф Ахунов урамыннан тыш, танылган татар архитекторы Мидхәт Булатов һәм танылган рәссам Бакый Урманче исемендәге урамнар да булачак дип көтелә.

### ЯДЬ ИТҮ

2 июньдә мәшһүр татар композиторы, СССРның халык артисты Нәжип Жиһановны искә алу чарасы узды. Туганнары, дуслары, укучылары, хезмәттәшләре, Татарстан Композиторлар берлеге һәм дәүләт хакимияте вәкилләре Арча зиратына барып, Нәжип Жиһановның каберенә чәчәкләр салды.

Республиканың музыка мәдәниятен үстерүдә Н. Жиһановның өлеше ифрат зур. Аның ижатына милли һәм интернациональ берлек, татар, рус, бөтендөнья музыка сәнгатенең иң яхшы традицияләре белән

бәйләнгән үзенчәлекле стиль хас.

### ШАГЫЙРЬНЕ ИСКӘ АЛУ

Арча районының Утар Аты урта мәктәбендә фронтовик шагыйрь Әхмәт Исхакны (1905—1991) искә алу кичәсе үткәрелде. Очрашуга Казаннан аның тормыш иптәше Гөлсем ханым Исхакова, язучы Рашат Низами һәм Ш. Камал исемендәге музейның өлкән фәнни хезмәткәре Равилә Мөбәрәкшина килгәннәр иде.

Алар Ә. Исхакның үз заманы өчен зур шагыйрь, оста тәржемәче булуын (Нәваиның "Фәрхад һәм Ширин", Пушкинның "Руслан һәм Людмила", Лермонтовның "Демон" һәм башка классик шагыйрьләрне тәржемә иткән), озак еллар "Чаян" журналын житәкләве турында сөйләделәр.

13 майда шагыйрьне искә алу кичәсе Ш. Камал исемендәге музейда да үткәрелде.

### КАЛӘМДӘШЛӘРЕБЕЗ БӘЙРӘМЕ

Чиләбедә Мифтахетдин Акмулла исемендәге татар-башкорт әдәби берләшмәсенең 45 еллыгын зурлап үткәрделәр. Бәйрәмгә килүчеләр башта татар, башкорт әдәбиятлары секцияләре эшендә, татар-башкорт китапханәсендә үткәрелгән бәйрәмдә катнаштылар. Кичен Прокофьев исемендәге Концерт залында зур тантана булды. Бу чараларның һәркайсында әлеге берләшмәнең бу төбәктә яшәүче татар, башкорт халкының милли үзаңын үстерүдә, туган телне, әдәбиятны, мәдәниятне саклап калуда, өлкәдә яшәп иҗат итүче каләм әһелләренең иҗатын үстерүдә зур роль уйнавын билгеләп үттеләр. Шушы берләшмәдә әдәби чыныгу алган, монда үткәрелгән чараларның үзәгендә кайнаган Газиз Кашапов, Ирек Сабиров, Салисә Гәрәева, Камил Мостафин, Басыйр Рафиков, Энҗе Гыйрфанова, Булат Батталов һ. б. каләм ияләренең исемнәре татар әдәбиятын сөючеләргә күптән таныш.

Бәйрәмдә каләмдәшләребезне Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев тәбрикләде. Ул шулай ук Татарстан Мәдәният министрлыгы, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты, Журналистлар берлеге котлауларын да ирештерде. Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбле солисты, Татарстанның атказанган артисты Рамил Миннегалиев үзенең җырларын бүләк итте.

Бәйрәм чараларында Татарстан Республикасының Екатеринбургтагы даими вәкиле Равил Бикбов катнашты һәм чыгыш ясады.

### ГАРӘП КАЛЛИГРАФИЯСЕ БӘЙГЕСЕ

Татарстан мөфтие Госман хәзрәт Исхакый агымдагы елның октябрендә гарәп каллиграфиясе бәйгесен уздыру турындагы нигезләмәне раслады. Ул кин җәмәгатьчелек һәм хакыйкый мөселманнарның игътибарын җәлеп итү, гарәп язуы һәм аның мөмкинлекләрен мөселман мәдәнияте казанышларын пропагандалау максатыннан оештырыла. Конкурс профессиональ рәссамнар, бизәүчеләр, дизайнерлар, гарәп теле һәм каллиграфиясе мөгаллимнәре, гарәп каллиграфиясе белән кызыксынучылар һәм балалар арасында үткәрелә. Конкурс кысаларында каллиграфия күргәзмәсе дә оештырылачак.

### КҮРГӘЗМӘ КӨЗЕН УЗАР

Эрмитаж һәм Луврның «Лувр-Эрмитаж-Казань-Исламика» берләшкән уникаль күргәзмәсе агымдагы елның 19 ноябрендә ачылачак. Ул Казан Кремлендә урнашкан «Эрмитаж-Казан» күргәзмә үзәгендә узачак. Шулай ук Татарстан музейларының Санкт-Петербургның зур музейлары, аерым алганда Дәүләт рус һем Россия этнография музейлары белән берлектә күргәзмәләр оештыруы турында да килешенгән. Күргәзмәдә мөселман сәнгатенең Кытайдан Испаниягә кадәр булган үзенчәлекләрен күрергә мөмкин.

### АРТИСТЛАР САБАН ТУЕ

Инде икенче ел рәттән Саба районының Лесхоз бистәсендә театраль Сабантуй уздырыла. Әлеге бәйрәмнең үзенчәлеге шунда: анда республиканың бик күп сәнгать әһелләре катнаша. Быел исә Сабантуйда Россиянең Кече театры, Башкортстан һәм Чуашстан артистлары да кунак булды. Театраль бәйрәм җирле халык тормышына да үзгәрешләр керткән икән. Сабалылар, танылган артистларга кызыгып, бер ел эчендә 115 спектакль куйган. Быелгы бәйрәм исә "Әкият" театры артисты Юрий Чуктиев өчен аеруча истәлекле. Сабантуйда баш батыр калган артистка Премьер-министр Рөстәм Миннеханов исеменнән Fiat автомобиле бүләк иттеләр.

### КИТАП—САБАНТУЙ БҮЛӘГЕ

Сабантуй унаеннан «Татнефть» ААЖ Бүләк итү көннәре үткәрде. «Рухият» хәйрия фонды чыгарган меңнәрчә китаплар милли-мәдәни автономияләргә бүләк ителде.

Компания көньяк-көнчыгыш нефть төбәге районнарын да игътибардан читтә калдырмады. «Татнефть» «Таткнига» ААЖнән 519 мең сумлык 13 мең данә китап сатып алып район һәм шәһәр китапханәләренә бүләк итте.

### ЧЫН МӨСЛИМӘ

Татарстан хатын-кызларының "Мөс-

лимә" ижтимагый оешмасы Мәдәният министрлыгы белән бергәләп эшләячәк. Бу хакта министр Зилә Вәлиева белән оешма җитәкчесе Әлмира Әдиятуллина очрашып сөйләште. Очрашу барышында Зилә Вәлиева "Мөслимә" газетасы редакторы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Әлмира ханымны 70 яшьлеге белән дә котлады.

8 июль көнне "Казан" милли мәдәният үзәгендә танылган журналистның юбилей кичәсе узды.

### МУЛЬТФИЛЬМ ДИН ӨЙРӘТӘ

Балаларга ислам дине нигезләрен өйрәтә торган "Кечкенә Камил" дип аталган мультфильм татар теленә тәрҗемә ителгән. Төркиядә төшерелгән әлеге анимацион фильмны татар теленә тәрҗемә итү, татар менталитетына яраклаштыру, милли музыка кую эшен "Призма" мәдәни-агарту фонды башкарып чыккан. Мультфильм 3 сериядән тора. Аның гомуми озынлыгы—54 минут. Төп геройлар—Камил исемле малай һәм аның бабасы. Мультфильмда ислам нигезләре, диннең роле, әдәп-әхлак турында сөйләнелә.

### МӨСЕЛМАННАР ӨЧЕН КУНАКХАНӘ

Киләчәктә Казанда мөселманнар өчен кунакханә төзеләчәк. Әлеге проектны Татарстан Мөселманнар диния нәзарәте Ислам үсеш банкы белән берлектә башкарып чыгарга ниятли.

Татарстан урамындагы кайчандыр мөселман җәмгыяте урнашкан иске бина урынындагы кунакханә Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры каршында төзеләчәк. Биш катлы корылма бар унайлыклар да тудырылган 26 бүлмәне, 250 кешелек ресторанны үз эченә алачак. Хезмәт күрсәтү шәригать кануннары буенча башкарылачак.

Төзелеш таләп иткән алты миллион евро акчаны Ислам үсеш банкы бүлеп бирәчәк.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасы хакына нәтиҗәле хезмәте һәм республиканың массакүләм коммуникация чараларын үстерүгә зур өлеш керткәне өчен ТР «Татмедиа» массакүләм коммуникация агентлыгы дәүләт учреждениесе генераль директоры **Марат Яшәр улы Моратов** «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде.

### ПРЕЗИДЕНТНЫҢ РӘХМӘТ ХАТЫ

Күпьеллык нәтиҗәле әдәби эшчәнлеге, Татарстан Республикасында мәдәниятне һәм сәнгатьне үстерүгә зур өлеш кертүе өчен язучы **Вәлиев Диас Назих улы** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Казанда—Республика көне

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Марат Кәбиров**.

# Яңа китаплар




**Сөләйман** (Сөләйманов Җәүдәт Шәүкәт улы). Нәфес. Шигырьләр. Казан: "Мәгариф" нәшр., 2007.—95 б. Тиражы—1000 данә.

Җәүдәт Сөләйманов киң җәмәгатьчелеккә иң әүвәл галим һәм "Сәләт" яшьләр хәрәкәте җитәкчесе буларак билгеле. Әмма техник фәннәр докторы, академик Җ. Сөләймановның тагын бер җитди шөгыле бар: ул шигырьләр яза, китаплар чыгара. "Нәфес"—шагыйрь Сөләйманның инде сигезенче китабы. Исеменнән үк күренгәнчә, автор, нигездә, яшәү мәгънәсе турында фәлсәфи шигырьләр яза. Китап башында эпиграф итеп китерелгән сүзләр дә шуңа ишарәле—"Үлемгә ике сәбәп бар: беренчесе—җан йортының яраксыз хәлгә килүе, икенчесе—нәфес бетү".


Китапка кереш сүзне Нияз Акмал (инде мәрхүм) язган, шигырьләргә ятышлы рәсемнәрне Рәйсә Сафиуллина ясаган.




**Асия Юнысова.** Алмагач песие: Балалар өчен шигырьләр. Казан: "Мәгариф" нәшр., 2007.—71 б. Тиражы—2000 данә.

Танылган журналист һәм шагыйрә Асия Юнысованың бу китабын сайланма җыентык дип тә әйтеп була; чөнки аңа элегрәк төрле елларда чыккан китапларның ("Үскән кыз", "Кышны яратам", "Җәйне сагынам") сөземтәсе кергән. Җыентыкта шулай ук авторның "Ташбаш хикәяте" дип исемләнгән яңа әкият-поэмасы да урын алган. Шагыйрә, нигездә, нәниләр өчен иҗат итә. 2004 елны А. Юнысованың бер китабы ("Кышны яратам") республика күләмендә иң укыла торган басмаларның берсе дип табылып, диплом белән дә бүләкләнгән иде.

Китапның мөхәррире—Л. Гыйззәтуллина, рәссамы—Р. Хәбибуллин.



Марат Кәбиров

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)